# казан утлары

9
СЕНТЯБРЬ-1970

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
КЫРЫК ТУГЫЗЫНЧЫ ЕЛ ЧЫГА

**9**

СЕНТЯБРЬ
1970

## БУ САНДА:

### РОМАН, ПОВЕСТЬ, ХИКӘЯ, ШИГЫРЬЛӘР

**Р. ТӨХФӘТУЛЛИН.** Җиләкле аланнар. Истәлек-хикәяләр . . . 3
**Н. АРСЛАНОВ.** Казагыстан — туган ягым. Шигырьләр . . . 33
**Н. ФӘТТАХ.** Әтил суы ака торур. Тарихи роман. 40
**Ш. МӘХМҮДОВ.** Дөнья шул ук... Мәңгелек сәфәр. Кояшка. Чирек гасыр... Төнге уникс. Бик күп нәрсәләр бар... Диңгез буенда уйланулар. Эз. Стәрле юлы. Шигырьләр . . . 103
**К. МОСТАФИН.** Батырны бит белә әллә кемнәр... Тиен. Июнь төннәрендә яшен яшьни. Кое. Шигырьләр . . . 108
**З. НАСЫЙБУЛЛИН.** Исем турында баллада. Канәгать. Урал. Этюд. Шигырьләр . . . 111
**Т. ФӘТТАХ.** Сөләйманның беренче җыры. Нигә орттым... Китәм. Зәңгәр күзләр. Шигырьләр . 113
**И. АБДУЛЛИН.** Арыш сохарие. Юлларыңа чыгам ел саен. Аппендицит. Якасыннан алып булмый... Хикәяләр . . . 115

### ДУСЛАР ҖЫРЫ

**Э. ГЮНТЕР.** Бары бер сүз. Шигырь . . . 122

### ЗАМАНДАШЛАРЫБЫЗ

**С. РАФИКОВ.** Таш билге. Очерк . . . 124

### ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**Ш. ГАЛИЕВ.** Гражданин нәни буламы, яки 437 сорауга җавап турында . . . 136

### ИСТӘЛЕКЛӘР, ЯЗМАЛАР

**Х. МАННАН.** Ул минем остазым иде . . . 144

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

КИТАП КҮЗӘТҮ

Г. БИЛАЛОВ. Ленин нурлары яктылыгында . . . 147
Р. ЛОТФУЛЛИН. Гел кояшка карап. . . . . . 151
Ф. ЯРУЛЛИН. Үткен каләм. . . . . . . . . 154

ТӨРЛЕСЕННӘН

Г. САТТАРОВ. Татарстан районнары һәм район үзәкләренең исемнәре. . . . . . . . . . . 156

БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ

Р. ТИМЕРШИН. Беренче кар. Тере алма. Флюгер. Сикәлтә. Белеп торам. Үкенеч. Кызыгалардыр әле. Көз. Шигырьләр. . . . . . . . . . . 170

УКУЧЫЛАР СҮЗЕ

Х. АЛМАЕВА. Тәрҗемәләр әйбәтрәк булсын. . . 174
һ. АФЗАЛОВА. «Урамнар артында яшел болын». 174

ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ

Т. МИННУЛЛИН. Гомердә булмаганны... Комедия . 175

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары. . . . . . . 185

Редакциягә килгән кульязмалар кире кайтарылмый

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52, бүлекләр — 2-39-52.

Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

Баш редактор: Зәки Нури.
Редколлегия: Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова, Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рәфикъ Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.

Производствога бирелде 19/VI-1970 ел. Басарга кул куелды 11/VIII-1970 ел. ПФ 05202, Кәгазь форматы 70×108[1]/16. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 83546 экз, Заказ С-366. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19, 1970 ел.

Рафаил Төхфәтуллин

# ҖИЛӘКЛЕ АЛАННАР

ИСТӘЛЕК-ХИКӘЯЛӘР



Болай ук булыр дип уйламаган идем... Әлбәттә, бик сагынып килдем мин ул аланны. Җиләкле икәнен дә белә идем ул төшләрнең. Аланнан аланга чыга торган салкынча-тын урман сукмаклары да күз алдыма килде.

Һәм менә... Мин тирәк төбендәге кызыл җиләккә үрелдем. Тәмленең тәмлесе хуш ис борыныма бәркелә. Каен җиләге исе! Бала чагыбыз исе, үсмер чаклар исе ич бу! Туган җир исе!

Күңелне истәлекләр өермәсе биләп ала. Тәгәлләнгән вакыйгалар хатирәсе түгел әле бу — әнә шул җиләкләр, чикләвекләр, балтырганнар, таныш йөзләр, ягымлы елмаюлар, моңлы аһәңнәр хатирәсе генә хәзергә. Ләкин һәммәсе күңелнең әллә кайчаннан йокымсыраган әллә кайсы кылларын тибрәтә. Татлы итеп тә, авырттырып та тибрәтә...

Аланнар, җиләкле аланнар! Нинди садә, нинди бай, никадәр газиз һәм моңлы сез!

Чү! Чыннан да музыка яңгырый түгелме? Алан үзенең иске дустын шулай җырлап каршылыймы әллә?

Кинәт... Литавралар чыңы, барабан гөрелтесе.

Ах, бу — каядыр магнитофонмы, транзистормы уйнаталар икән ич. Яшьләр урманга ялга килгән, ахры.

Ул арада берьюлы берничә мотоцикл тырылдавы аланны яңгырата.

Елга ягыннан, колак тондыргыч пытырдап, моторлы көймә үткәне ишетелә.

Без бала чакта мондый авазлар яңгыратмый иде аланны. Юк иде андый авазлар...

Әлеге транзистор музыкадан туктап, инде сөйләүгә күчте. Җил уңаена аермачык ишетелә: соңгы хәбәрләр тапшыралар. Аланда дөнья хәлләре яңгырый. Бик тынгысыз һәм шактый шөбһәле дә хәбәрләр.

Бай һәм садә, газиз һәм моңлы гына түгел, бик тынгысыз да икән сез хәзер, җиләкле аланнар!..

Юк, болай ук булыр дип уйламаган идем. Бары тик көрешеп кайтырга дип кенә килгән идем мин сезгә, бала чагым аланнары!

Баксаң, никадәр истәлек-хикәяләр дә алып кайтам мин сездән, җиләкле аланнар! Тынгысыз аланнар...

## БЕРЕНЧЕ АЛАН

# Чормадагы китаплар һәм... Ул бабай нигә җылый?

Яңа квартирыбыз миңа бик ошады.

Аннан элек тә ничәмә тапкыр квартирдан квартирга күчкән идек инде без. Әмма алары авыл эчендә генә иде һәм берсеннән икенчесе әллә ни аерылмый иде. Аерма тик шунда гына була иде: бер абзый безгә квартир итеп галанка мичле ак өен бирсә, икенчесе бик зур ипи мичле кара өенә кертә. Шарт-искәртүләр исә шул ук: безгә, бала-чагага, артык шаулап уйнамаска, каралты-кура түбәсенә, печәнлеккә үрмәләмәскә (егылсак, бәласеннән башаяк — бер; тавыклар, күкәй салганда, бала-чага чыр-чуын яратмый — ике), аннары абзар артындагы шалкан, суган түтәлләре дә ни... тапталмасын.

Бу юлы исә авылдан ук күчеп киттек. Әтине Кышкар авылында яңа ачылган мәктәпкә укытучы итеп билгеләделәр.

Яңа мәктәп Кышкарның мәшһүр таш мәчетенә урнашкан иде. Безгә квартир итеп шуннан ерак түгел мәзин йортын бирделәр.

Мәзин үзе дә, абыстай да инде күптән гүр ияләре, бала-чагаларын да язмыш кайсын кая таратып бетергән. Шушы зуп-зур өйгә, тез тиңентен алма үләне үскән шушы ишек алдына, печәнлекләре-түбәләре белән бар каралты-курага, өй түрендәге корган алмагачлы, эт миләше куаклары баскан шушы серле бакчага без тулысынча үзебез хуҗа булып кереп утырдык.

...Өй мине, иң беренче, үзенең төс-буяулары белән таң калдырды. Юк, кеше кулы белән буялган өй түгел иде ул, аны табигать шулай бизәкләгән иде. Түбәсе ямь-яшел, куе көрән һәм кызгылт-соры мүк белән капланган иде, кояш карамаган чакта ниргә бүрәнәләре дә шундый ук төсләрдәге йомшак бәрхет белән тышлангандай иде. Тәрәзә пыялаларында исә нинди генә төсләр юк! Сезнең сабын суыннан куык өреп уйнаганыгыз бардыр инде. Ике бармак озынлыгында салам кисеп аласың да, шуның бер башын чачакландырып, сабын суына манасың һәм саламның икенче очыннан сак кына өрәсең. Салам эченнән йодрык кадәр, кайвакыт аннан да зуррак куык килеп чыга. Алсу, кызгылт, яшел, шәмәхә, зәңгәрсу төсләр шундый да иркә-нечкә бизәкләр булып чагыла бу куыкта. Безнең тәрәзә пыялалары да әнә шул сабын куыгындагы төсләргә кергән иде.

Аннары, ишекләр бик күп иде бу өйдә. Тышкы якка да өч тарафка өч ишек чыга, өйалды да әллә ничәгә бүленеп, һәрберсендә ишек. Дөрес, ул ишекләрнең күбесенә аркылы такта кадакланган иде. Ләкин әнә шулай такта кадакланып, керергә ярамавы белән, эчендә нининдидер серле нәрсәләр булуы ихтималы белән безнең күңелләрне биләп алды инде бу ишекләр.

Һәм без, әти-әни өйдә юк чакта, бу ишекләрне берәм-берәм ачып керә башладык. (Без дим, ягъни Чарльз энем белән мин. Ә Роза апа,

эти-әни югында өйгә тулы хуҗа булып калучы олы кыз, безнең бу «ярамаган эшкә» катнашмый, ишек ачылып беткәч кенә, безне тиргитирги, бүлмә эчен актарышырга кирә иде.)

Әй,ниләр генә юк иде бу бүлмәләрдә! Менә хәзер уйлап карыйм да, безнең билетсыз гына кергән беренче музеебыз булган икән бу бүлмәләр. Музей дигәч, андагы бик мул тузан һәм пәрәвез белән капланган тимер-томыр, күн-каеш, чүлмәк-чынаяк ватык-сыныкларын хәзер инде күңелдән бераз тәртипкә дә салып карыйм.

Менә бер башына чыра кыстырыр өчен җәпле тимерә булган көйгән таяк. Калайдан ясалган май тәлинкәләре. Эреле-ваклы шәмдәлләр. Менә асылмалы, утыртмалы калай, пыяла лампалар... Өйне яктырту тарихы бу.

Менә тимер чукмарлар, кистәннәр. Озын гына чылбырга асылганы да бар чукмарның, тешле-тешлесе дә, йодрык зурлыгы да, безнең баш кадәресе дә. Шунда ук төрле-төрле, күгәргән мылтык көпшәләре... Монысы ау-сунарга йөрү тарихы.

Менә муртайган күн-каеш кисәкләрендә эреле-ваклы таңкалар, шөлдерләр, чуклар, кыңгыраулар... Болары бабаларыбызның ат-аргамакны ничек бизәп җигү осталыгы үрнәкләре.

Тагын чәчәкле-гөлле, укалы-путаллы чынаяк, савыт-саба китекләре дә бик күп иде анда. Болары инде безнең күзне яндырудан бигрәк, апама безне тиргәргә кирәклеген онытырырга ярдәм итте шикелле...

...Ниһаять, соңгы ишекне дә ачып кердек. Бу ишек иң караңгы бер почмакта булганлыктан, анда таба атлауга идәннәр аеруча шөбһәле, аеруча усалланып шыгырдый башлаганлыктан, шулай иң соңга калды да бугай. Ләкин әлеге кистәннәр, чукмарлар белән коралланып алгач, без бу ишекне дә батырларча җиңдек.

Ишекне ачып җибәрүгә, безнең алда бусагадан ук башланган текә баскыч пәйда булды. Өстә, колакларны тондырып, чәүкәләр чыяклый башлады. Борынга ачы тузан бөркелде. Төчкерә-төчкерә, бер-беребезне алгарак этә-этә, кыйшык-мыйшык басмалар буйлап өскә үрмәли башладык.

Чорма тишегеннән башыбызны тыгуга, без чәүкәләр өермәсе эчендә калдык. Әйе, чын мәгънәсендә өермә иде бу. Канатлары канатка тиеп, бихисап чәүкәләр очына, бурандай йон-каурый бөтерелә, тынны кысардай тузан күтәрелгән иде.

Менә бераздан бу өермә тынды. Әле генә бөтен чорманы тутырып очынган миллион чәүкәнең берсе дә калмады. Безнең башларга, иңбашларына аксыл-кук йомшак йоннар кунды.

Иң беренче, чорманың урта бер җирендә чүмәләдәй өелгән калын-калын китапларга күзебез төште. Әтинең китапларындагы рәсемнәрне без инде күптән карап бетергәнлектән, өстәвенә, мин инде хәреф тә таный башлаганлыктан, билгеле, тизрәк шунда ыргылдык.

Ләкин бу китаплар безне шатландырмады. Беренчедән, никадәр генә актарынсак та, кайбер бит башларындагы бизәкләрне искә алмаганда, бер генә дә рәсемле китап таба алмадык. Икенчедән, мин таный торган яңалиф хәрефләре белән түгел, ә искечә — гарәп хәрефләре белән язылган иде бу китаплар. Ә искечә икән, димәк, дин китаплары, буржуй китаплары. Тузан эчендә тик аунап ята бирегез шунда... Хаҗәтегез бер тиен.

Бу уңышсызлыгыбызны бик тиз оныттырырдай кызыгы да бик тиз табылды. Кәрниз уентыгында, купкан-сынган һәр такта ышыгында чәүкә оялары бик күп иде монда. Буш оялар гына түгел. Һәр ояда диярлек зур сары авызлы, күгелҗем сары тәнле икешәр-өчәр бала ята. Без ояга үрелүгә, алар авызларын зур итеп ачалар, кара сәйләндәй күзләре

усал ялтырый, тәннәрендә сирәк чәчтәй йоннар тырпая иде. Кара инде, моңарчы әле без бер кош оясы күрер өчен дә тез-терсәкләрне сыдыра-сыдыра биек тупыл башларына менеп йөрсәк, биредә кыйшык баскычтан күтәрелүгә — чәүкәләр шәһәрчеге. Юк, шәһәрчек кенә дә түгел, чәүкәләрнең башкаласы ук булмагае әле бу!

Шушы көннән башлап, чорма безнең даими горурлыгыбызга, мактанычыбызга әверелде. Малайларның иң дус күргәннәрен генә чәүкәләр башкаласына алып менәбез, ә аеруча җан дусларга бирәр чәүкә баласы да бүләк итә идек.

Әлеге китаплар да бик ярап куйды. Калын иде, шома иде ул китапларның битләре — без алардан очырткыч ясый башладык. Көткәнгә караганда да шәбрәк очырткыч чыкты алардан. Ничәмә көннәр буе авыл өстендә без җибәргән очырткычтан да биегрәге булмады. Шулай авыл өстендәге биеклекне үз кулыбызда тотуның ләззәтен җитәрлек татыгач — чаманы да белергә кирәк бит — малайларга да берәм-берәм бу шома-калын китап битләрен бик юмарт бүләк итә башладык.

Бик күңелле иде болар — авыл өстендәге зәңгәр биеклеккә хуҗа булу да, малайларга шома кәгазьләр өләшү дә. Ләкин... соңрак үкенергә дә туры килде.

Безнең каршыда гына тагын бер гаҗәп өй бар иде. Бик зур өй бу, ике катлы, хәтта өч катлы дияргә була — түбәсендә бик матур челтәр тәрәзәле кечкенә генә тагын бер өй, ягъни чарлагы да бар иде.

Өйнең аскы кат тәрәзәләренә бик ныгытып такталар кадакланган, ишекләрендә ат башы кадәр йозаклар — колхозның склад-амбарлары иде бу бүлмәләрдә.

Икенче катта авыл Советы, колхоз идарәсе, китапханә. Болардан кала тагын буп-буш бүлмәләр дә бар — аларда стена буйларына чүгәләп утырып, абзыйлар тәмәке көйрәтәләр иде.

Бик ярата идек без бу өйгә кереп йөрергә.

Бусагадан атлауга, өске катка менә торган бормалы баскыч култыксасының шарлы-сырлы араталарына күз төшә. (Их, Түбән очның Җылы ипи Җаббар кебек, шуның бер шарын сындырып алсаң икән.)

Аннары, бу өйнең тәрәзәләреннән карау бик кызык. Тәрәзәләрнең аскы өлгеләре гади пыяладан түгел, ә кызыл, зәңгәр, сары, яшел төсләрдәге пыялалардан иде. Юк, безнең мәзин өендәге кебек, табигать үзе бизәгән пыяла гына түгел инде болар, матурлык өчен шулай махсус куелган пыялалар иде. Бер өлгедән карыйсың, сиңа бөтен дөнья алсу булып күренә, икенчесеннән карасаң, дөнья серле зәңгәрлеккә чума, өченчесе сиңа алтынсу-сары дөнья ача.

Дөньяны шулай матур-матур төсләргә манчып карап туйгач, тәмәке көйрәтүче абзыйлар янына керәбез. Абзыйларның сөйләшүләрен тыңлавы да кызык, аннары, түрдәге мичтән һич күзне алып булмый. Бик матур мич ул. Ялтырап торган шакмак-шакмак чынаяк белән тышланган, һәр шакмакка аллы-гөлле бизәкләр төшерелгән. Һәр шакмак өчен шулкадәр күп төрле бизәкләрне ничек табып-уйлап бетергәннәрдер!

Абзыйлар янында чуала торгач, берәрсенә ияреп, авыл Советы бүлмәсенә дә кереп китәбез. Монда инде безнең игътибарны иң нык җәлеп иткәне — авыл Советы председателе Фазыл абый һәм ул утырган урындык.

Менә, ичмасам, утыра Фазыл абый урындыкның кәттәсендә! Ул урындыкның аркасы утыручының башыннан да биегрәк, ян-ягында таянычлары да бар. Урындыкның ул биек аркасына сырлап-уеп матур-матур чәчәкләр, бизәкләр ясалган. Ул таянгычлары, аяклары да бормалы, сырмалы, бизәкле.

Фазыл абый әнә шул гаҗәеп урындыгына утырып ала да, олы гәүдәсен таянгычның әле берсенә, әле икенчесенә сала төшеп, ара-тирә Чапаевныкына охшаган сары мыегын сыпыргалап куеп, кешеләр белән сөйләшә. Кайберләрен нәрсәгәдер үгетли, кайберәүләрне орышып та ала. Орышу дигәне бик кыска аның. Тәрәзә пыялаларын зыңлатырдай гайрәтле-калын тавыш белән шундый да усал итеп бер кычкырып җибәрдеме, бүлмәдә шунда ук сискәнүле тынлык урнаша, теге абзый да председатель әйткәнгә шунда ук күнә иде шикелле.

Гомумән, авылда Фазыл абыйдан бар кеше дә бераз шүрли иде бугай. Аның ул гайрәтле калын тавышы да шом салгандыр инде, аннары кушаматы да бик хәтәр иде аның — Бүре Фазыл. Әмма болардан да дәһшәтлерәк тагы бер сәбәп бар иде әле. Авылда бөтен кеше белә — Фазыл абыйның наганы бар һәм ул аны гел кесәсендә генә йөртә икән. Бу наганны Фазыл абыйга гражданнар сугышында акларга каршы бик батыр сугышканы өчен Азин батыр үзе бүләк итеп биргән һәм ул бүләккә берәүнең дә кагылырга хакы юк икән.

Бередә көн саен диярлек безнең калкынып торуыбызның да төп сәбәбе әнә шунда иде инде. Бер заман, ачуы бик кабарып, Фазыл абый наганын да чыгармасмы дип көтәбез. Аннары кәефе килеп, акларга каршы ничек-ничек сугышып йөргәннәрен дә сөйләмәс микән дип өмет итәбез.

Ләкин без Фазыл абыйның ул дәһшәтле наганын кесәсеннән чыгарганын бер тапкыр да күрә алмадык. Исәлекләргә бирелергә дә вакыты юк иде аның. Гел кемнәр беләндер сөйләшә, кемнәрнедер үгетли, кемнәрнедер орыша Фазыл абый. Янсә кесәсеннән түгәрәк печать чыгарып, аңа бик озаклап өрә-өрә дә кәгазьләргә шалт-шолт печать суга. Ул арада бик ашыгып каядыр чыгып та китә.

...Авылда Фазыл абыйдан иң нык шүрләгән кеше, ихтимал, Кәрим бабай иде бугай. Ап-ак сакаллы, җәен-кышын башына кырпулы бүрек, аягына чуар киез итек киеп йөрүче бу бабай шушы ук йортның бакчасындагы кечкенә генә өйдә яши иде. Өйдә аның дөм-сукыр карчыгы да бар, диләр. Әмма ул әбинең ишек алдына чыкканын безнең бер вакытта да күргәнебез булмады. Кәрим бабай исә, киресенчә, кечкенә өенә бары тик йокларга гына керә иде бугай. Кәкре башлы юан гына таягына таянып ала да, чуар киез итек кигән аякларын җирдән сөйрисөйри генә атлап, гел бакчада, ишек алдында йөри яки рәшәткә буендагы эскәмиядә күзләрен аска текәгән килеш тик утыра. Үткән-сүткән кешеләр аңа сәлам биреп узалар, ә Кәрим бабай аларга күтәрелеп тә карамыйча, авыз эченнән нәрсәдер мыгырданып кала иде.

Ә менә ишек алдында Фазыл абый күренсә, Кәрим бабай тәмам үзгәрә. Шунда ук урыныннан сикереп тора, бөтен йөзен җыерчыклар белән тутырып елмая һәм бөтенләй көр тавыш белән ерактан ук дәшә:

— Исәнме-саумы, Фазыл энем! Имин-лек-тынычлыкмы? — ди.

Әмма Фазыл абый бабайны бөтенләй дә күрмичә үтә дә китә иде.

Хәтеремдә, Кышкарга безнең яңа гына күчеп килгән көннәрдә,— шушы өй тирәсендә уйнап йөри идек,— ул бабай безне үзе янына чакырып алды.

— Собханалла! Кем балалары әле сез?.. Ә-ә-ә, мөгаллим малайлары. Собханалла, собханалла... Исемнәрегез ничек инде сезнең?

Безнең исемнәргә аның тиз генә теле күнми торды. Без бик тырышып аңа исемнәребезне өйрәтеп бетергәч, тирән генә көрсенеп куйды.

— И дөнья!.. Исемнәр үк хәзер...— Тагын нидер мыгырданды, аңысын ишетеп булмады.

Шуннан соң, очраган саен безне туктата торган булды бабай. Туктата да, күз кырые җыерчыкларына хәйләкәр генә очкыннар яшереп, сорый:

— Кайсыгыз Рапаел, кайсыгыз Чарлис әле сезнең? Ә-ә, шулай бит әле... Собханалла-машалла.

Аннары бик җитдиләнеп, озак кына кесәләрен актара башлый, аннан ап-ак кәгазьгә төрелгән икәр кисәге яки берәр конфет килеп чыга.

— Мәгез әле. Акыллы балалар күренәсез, тәүфыйклы булып үсегез. И дөнья...

Күпмедер вакытлар үткәч, олылар сөйләшүеннән без бик сәер һәм бераз куркынычрак та бер нәрсә белеп алдык. Бу бабай элекке заманда бик бай сәүдәгәр булган, бу матур чарлаклы, борма баскычлы, төсле-төсле тәрәзәле бик зур йорт бөтенләе белән — бизәкле мичләре, хәтта әлеге гаҗәеп урындыгы-ние белән аның бер үзенеке булган, хәзер яшәп яткан өйләре исә ул вакытта үзләренең мунчалары гына булган икән. Фазыл абый ул вакытта — ышануы да кыен — бабайның хезмәтчесе булган. Тагын да сәеррәге шул әле: моннан берничә ел элек кулакларны сөргән вакытта, Фазыл абый Кәрим бабайны бик карт инде ул дип, карчыгы да сукыр дип, яклап алып калган.

Шушы хакыйкатьне белеп алгач, без дә бабайның үз янына чакыруларын ишетми башладык. Каршы очраса да, бу тере буржуйны бөтенләй күрмичә, Фазыл абый кебек башны бик горур, югары тотып кына үтеп китә идек.

Эчкә шик тә төште. Ул буржуй мыштым гына гел йөрена дә йөренә, ниндидер явыз ниятләр корып йөрми микән?

Һәм без, мәрхүм мәзиннең әлеге күгәргән кистәннәре белән коралланып алып, үзенә сиздерми генә, бабайны күзәткәләп йөри торган булдык.

Кистәннәрне эшкә кушарлык шикле-хәтәр эш фаш итә алмадык алуын, әмма бабайның бер сәер гадәтен сизеп алдык. Агачлар арасына гына яшеренеп, озак-озак таш мәчет манарасына карап тора иде бабай, үзе иреннәрен генә кыймылдатып ниләрдер пышылдый иде.

Җылы ипи Җаббар, үзенең атаклы шарын да алып, безнең очка төшкән иде ул көнне. Авылда ул шарга сукмаган бер генә малайның да кәшәкәсе калмаганлыктан, хәзер инде аның кайдан чәлдерелгәнлеген танырлык та түгел, шунлыктан без, һич шикләнмичә, авыл Советы тәрәзәсе турында ук шар сугыш уенын башлап җибәрдек.

Уен кызып кына барганда, капка төбенә бер җигүле ат килеп туктады. Башын аска гына игән җирән туры ат, тимер ходлы арба, арба башында, дилбегә тотып, киндер алъяпкычлы абзый утыра — болары әнә шул яшел чирәм кебек үк бик гадәти иде. Әмма арбада бик ыспай кара эшләпә кигән, ап-ак күлмәгенең якасын кара пиджагы өстенә кайтарып салган тагын бер абый утыра — монысы инде бик үк гадәти түгел, мондый ыспай эшләпәне, мондый ап-ак яканы безнең әле монарчы авылда гына түгел, районнан килгән кешеләрдә дә күргәнебез юк иде.

Һәм без, эшләпәле абый арбадан төшеп, шулай ук бик гадәти булмаган бик зур, бик калын сары портфелен күтәреп чарлаклы өйгә таба юнәлүгә, тизрәк аның артыннан ияրдек.

Ишек төбендә Фазыл абыйның ачулы карашы безне тукталып калырга мәҗбүр итсә дә, кызыксынуыбызны, әлбәттә, аз гына булса да баса алмады. Барыбер олылар кергән-чыккан арада без дә берәм-берәм бүлмәгә үтеп кердек.

Бик хәтеремдә, Фазыл абый районнан булсын, бүтән берәр җирдән булсын — кем генә килсә дә, алай каушап калучылардан түгел, йөзендәге шул ук җитди тынычлык белән әлеге гаҗәеп урындыгында гел шулай какшамас-нык утыруын белә иде. Ә бу юлы... Ыспай эшләпәле бу абый каршында... Нәрсә булган Фазыл абыйга?

Ул, аякларын аера төшеп, идән уртасында басып тора, чыраенда, бөтен кыяфәтендә... Була бит шундый малайлар: ачуы чыкса, шунда ук әтәчләнеп сугышырга тора, әмма шул ук вакытта нәрсәдәндер шүрли дә үзе... Әнә шундыйрак кыяфәттә иде Фазыл абый.

— Син нәрсә, иптәш...— ди ул, зур учына икенче кул аркасы белән шалт итеп сугып куя.— Без монда капитализмның барлык калдыкларына каршы, значит и дин сөременә каршы, революцион көрәш алып барабыз, ә син... Иске китапларга акча түләргә дә әзер. Нәрсә бу? Безнең эшкә аяк чалумы?

— Анлагыз әле шуны, председатель иптәш,— ди эшләпәле абый, аның тавышы бик аптыраулы, хәтта ялварулы яңгырый.— Барлык иске китаплар да дини китаплар гына түгел бит. Алар арасында милли культурабызның җәүһәрләре дә бар.

— Һе, җәүһәрләр! Кайда-кайда, безнең авылда андый җәүһәрләрне таба алмассыз. Безнең авылда иң дини, значит и иң кадим, мәдрәсә булган. Иң контр мулла, значит и дәмелля дип йөрткән мулла, безнең авылда булган. Ә син... җәүһәрләр, имеш!..

— Шулай да...

— Юк инде. Без барлык иске китапларны да, дингә каршы, значит и капитализмга каршы, важный чара буларак, җыеп яндырдык.

— Яндырдыгыз?!

— Яндырдык. Өй борынча җыеп алдык та яндырдык. Значит и капитализм калдыклары белән без алай чикаться итеп маташмыйбыз. Так што, иптәш... Зрә килгәнсез безнең авылга мондый эш белән.

Һәм ул нык-нык басып, үзенең матур урындыгына килеп утырды.

Эшләпәле абый папирос алып кабызды. Соңгы папиросы иде бугай, кабын йомарлап, күзләре белән аны ташларга урын эзләде, бүлмәдә чүп савыты-мазар тапмагач, йомарланган капны кесәсенә кире тыгып куйды. Папиросын икенче бер суыруга, буыла-буыла йөткерә башлады.

— Яндыр... Кхм-кхм... Яндырдыгыз... алайса?

Фазыл абый дәшмәде. Бик җитди кыяфәттә, өстәлдәге кәгазьләрне актара иде.

Эшләпәле абый йөткереп бетергәч, бүлмәдә тып-тын булып калды. Менә шушы тынлыктан файдаланып, мин тел очыма бая ук килгән сүзләрне әйтеп салдым.

— Фазыл абый! Бездә бар андый китаплар. Иске китаплар... Чорма тулы.

Фазыл абыйның усал күзләре башымнан аягыма кадәр капшап алды.

— Кем малае әле син?

— Газиз малае ич.

— Кайсы Газиз?

— Укытучы.

— Ә-ә-ә... Әтиең китапларымыни?

— Ю... ук!.. Без килгәндә үк бар иде. Чорма тулы...

Шунда Фазыл абый эшләпәле кешегә таба борылды да, мине бик гаҗәпкә калдырып, кинәт бик якты елмайды.

— Дөрескә чыкмагае малайның сүзе. Гомәр мәзин өендә булуы ихтимал андый китапларның. Бәхеткә каршы, ул иске өй хәтердән дә чыккан безнең. Бик ихтимал...

...Һәм менә эшләпәле абый безнең чормада, китаплар чүмәләсе янында басып тора. Матур эшләпәсе кырыеннан пәрәвезләр асылынган, ап-ак якасына күксел чәүкә йоннары кунган. Кулында аның бая ап-ак яулык иде, хәзер инде ул яулыгы соры төскә керде — абый өемнән бер китап ала да яулыгы белән тузанын сыпыра, тиз-тиз актарып карый, аны сак кына читкә алып куя, тагын икенче китапка үрелә... Ул арада кесәсеннән әлеге буш папирос кабын чыгара, кире тыга.

Шул йомарланган буш папирос кабын ничәнчемедер тапкыр кесәсеннән чыгарып карагач, абый мине күреп алды.

— Энем, сезнең монда кибет еракмы?

— Ерак түгел, абый. Монда гына.

— Алайса, син миңа папирос алып кайтып бирче. «Звезда» дигәне булса, шәп булыр иде,— дип, миңа кәгазь акча сузды.

Мин, әлбәттә, очтым гына. Үзем эчемнән кабатлыйм: «Звезда», «Звезда»...

Булды, нәкъ «Звезда» дигәне булды.

Эшләпәле абый пачканы алып, шунда ук берне кабызып җибәрде, ләкин учым тулы сдача акчаларын алмады.

— Сезнең кибеттә конфет бармы? — диде ул папиросын суыра-суыра, кулындагы китабын актара-актара.

— Бар да... Аңа карточка кирәк шул.

— Ә карточкасыз гына алып була торган берәр тәмле әйбер бармы?

— Патока дигән бар. Төсе нәкъ бал кебек үзенең, ә тәме... бер дә бал кебек түгел.

— Алайса, нәрсә аласың соң инде бу акчаңа?

— Һи... Минем акча түгел бит ул, абый, мә.

— Минеке кәгазь акча иде, ә бу бакыр-көмешләр синеке инде хәзер.

— Бик күп бит бу, абый.

— Күп булса, синең дус малайларың да күптер әле. Барыгыз, бергәләп уйлашыгыз нәрсә алырга икәнен.

Шулай итеп, бер уч акчага ия булдым мин ул көнне. Әлбәттә, ул акчага нәрсәләр алырга дип киңәш бирүчесе дә, тизрәк тотып бетерергә ярдәм итүчесе дә табылды аның. Ләкин нәрсәләр алдык икән без ул акчага? Тәгаене һич истә калмаган. Шул гына хәтердә: кесәмә тыгылсам, кулымны кармак тырный, кепкамны кисәм, башыма кармак кадала... бик күп көннәргә кадәр шулай җәфа чигәргә туры килде. Хәер, монысы — әнә шулай кадаганга-тырнаганга күрә генә истә калган, ә ул көнне... Канатлы идем, юмарт идем, көләч идем мин ул көнне. Бик ерактан нindидер олы эш белән килгән сәер абыйга минем ярдәмем тиде, Фазыл абый да миңа якты итеп бер елмайды,— әнә шулар канатландырды мине ул көнне, шулар күңелемне куаныч белән тутырды. Ләкин...

...Җәйге озын көнне ахыргача озатып бетереп, кичке салкында чебиле аяклар шактый сизелерлек әрни башлагач кына, өйгә кайтып кердем. Ишекне ачуга, кыздырган май исе борынны кытыклап алды. Әни ниндидер тәмле әйбер пешереп йөри, ә түр якта әти белән әлеге абый, сөйләшә-сөйләшә, чәй эчеп утыралар иде.

— Мәзинен мәзин, ә менә, сөйләүләренә караганда, бик йөрәкле кеше булган ул карт,— ди әти.— Бик оста сунарчы булган диләр аны. Теге, куян-төлке куучы гына түгел, бүре ауларга бик азарт булган. Аннары, ике мәртәбә хаҗга барып кайткан. Берсендә — дәмелля акчасына, икенчесендә — Кәрим бай акчасына барып, тегеләрне һаҗи иткән.

— Так, так, так... Алайса, аңлашыла.

— Нәрсә?

— Китапханәсендә аның гарәп китаплары да күп кенә. Шуннан кайткан китаплар инде, алайса.

— Шулайдыр. Картлар ул турыда да сөйлиләр. Бик галим иде, белмәгәне юк иде диләр.

— Да-а... Тик менә шунысы кызганыч. Бик тә кыйммәтле китаплар бар, ләкин күп кенә битләре юк. Ертылган, таралган...

Башыма, әйтерсең, күсәк белән китереп суктылар. Без бит, без гаепле ул битләрнең юклыгына... Очырткыч ясадык, малайларга өләштек...
Салынды, сынды минем көнлезге канатларым.
Төне буе эреле-ваклы бихисап күп үрмәкүчләр белән сугышып-саташып чыктым.

Иртәгесен, көтү чыккап вакытлар иде бугай, быдыр-быдыр сөйләшкән тавышка уянып киттем. Почмак якта кем белән сөйләшә ул әни?
— Син, Бәһар сеңелем, боларны мин китергәнне ул кешегә әйтә күрмә тагын,— ди ирләр тавышы.
— Нигә? Рәхмәт кенә әйтер ул үзенә.
— Аллам сакласын!.. Теге вакытта ник камсамуллардан яшереп калдырдың дип бәйләнә башласалар... Юк, юк, бәласеннән башаяк, зинһар, әйтә күрмә! Аллам сакласын!..
— Соң... Кем китерде дип сорар бит ул.
— Без болай итик, Бәһар сеңелем... Боларны чормага менгезеп ташлыйк та, шуннан теге үзе эзләп табар. Инде бер дә күзенә чалынмый икән, таптым диган булып, үзең алып төшеп бирерсең...
Шыпырт кына торып, бүлмә тактасы ярыгыннан карамыйча түзә алмадым. Керүче — Кәрим бабай икән. Калтыраган куллары белән урындыктагы төенчекне чишеп маташа. Шакмаклы ашъяулыкны ачып җибәрсә, аннан... калын-калын китаплар килеп чыкты.
— Менә, Бәһар сеңел, үзе уянганчы тизрәк алып менеп куй. Мин чыгыйм әле, кеше-кара күрсә, әллә ни уйлар. И заманалар...
Һәм безнең шыгырдык ишекне аз гына да шыгырдатмыйча ачып, чыгып та китә.
Мин башта ни уйларга белмичә аптырап калдым. Аннары, үзем дә сизмәстән, елмаеп җибәрдем.
Әгәр Кәрим бабай китергән ул китаплар без ерткан китаплар булса?! Бик тә шәп була бит әле бу!..

ИКЕНЧЕ АЛАН

## Актырнак ничек Караборынга әверелде

Кап-кара тәпиләренең тырнаклары һәм тырнак төбе йоннары чыннан да ап-ак иде аның. Гәүдәсе дә кара, ә койрык очы белән башымуены тагын ак. Хәер, башы бөтенләй үк ак түгел, колак яфракларына һәм очлы танавына тагын тәңкә-тәңкә кара чәчрәп киткән.
Төп бер генә хуҗасы юк иде ул Актырнакның. Ул безнең, Югары оч малайларының, барыбызныкы да иде. Шулай да... Бүген нигәдер Жылы ипи Җаббарны аеруча үз итә ул. Сикерә-сикерә гел аның битен ялый, ул ыргыткан таякны уктай атылып алып килеп бирә... Иртәгесен чыксаң, Актырнагыбыз Җәүдәтнеке булган. Безгә, шул исәптән Җаббарга да: «Нихәл, малай!» дигәндәй койрыгын болгый-болгый шул бер караш ташлый да авызы колакларына җиткән Җәүдәт янында бөтерелепме-бөтерелә.
«Этнең хуҗасы — кем ашатса шул», дип тә әйтә алмыйсың аңа. Кесәләребез аңа дигән сыйдан беребезнеке дә буш булмый. Әмма Актырнагыбыз бүген кемнедер дус күреп өлгергән икән, аны инде иң тәмле сөяк-калҗа белән дә үзенә карата алмыйсың.
Синс кайчан дус итәсен ничектер үзе белә иде ул.
Мине дә шулай бик белеп дус итте Актырнак. Нәкъ шул көннәрне

анын исеме дә минем өчен Актырнак түгел, Караборын булып әверелде...

Актырнак... Караборын. Ничек кенә сөйләп бирергә соң моны?.. Тукта, укучым бит әле күршеләребез Касыйм абзый белән дә, Гөлсем апа белән дә таныш түгелләр. Сүзне алардан башларга кирәк булгандыр миңа.

Гел кәрәсе килеп кенә тора иде ул өйгә. Һәрвакыт жылы, һәрвакыт якты була иде аларның өе. Бу жылылык, бу яктылык, барыннан да бигрәк, Гөлсем апаның көләч йөзеннән, Касыйм абзыйның түгәрәк чал сакалыннан бөркелә иде бугай.

— И, минем дәү улларым кергән икән,— ди Гөлсем апа, бөтен түгәрәк йөзе, колак очларындагы зур гына алкалары, зәңгәр чемчекле ап-ак яулыгы-ние белән яктырып елмая.

— Бусагага тоз сибәсе калган икән дип кайгырып тора идем әле. Ансыз да керә белгәч, бик әйбәт инде ул,— ди Касыйм абзый. Ул бервакытта да елмаймый-көлми, йөзе хәтта бераз ачулырак та, шунлыктан аның шаяртамы, әллә чынлап сөйлиме икәнен тиз генә белә дә алмыйсың.

Иртә яздан кара көзгә кадәр гел шау чәчәктә утыра, яшел суганнан алып, редискасы, кыяры, помидоры авылда иң алдан өлгерә торган бакчалары бар иде аларның. Безне, кергән саен, әнә шул бакча сыйлары каршылый. Кыяр кетердәтә-кетердәтә, Гөлсем апаның күңелле гөрелдәвен тыңлый-тыңлый, түр стенадагы рәсемгә карап торулары инде дә рәхәт. Ә ул рәсемгә карамыйча мөмкин түгел. Башына йолдызлы шлем кигән, гимнастерка якаларында әллә ничә кечкенә өчпочмагы булган бу кызыл командир — боларның уллары Исмәгыйл абый. Бик ерактa, ил чигендә үк сакта тора ул. Газеталарда бик еш нәкъ менә Исмәгыйл абый кебекләр турында язалар булыр, жырларда да алар турында жырлыйлардыр. Ничек карамыйсың ул рәсемгә!

Ләкин никадәр жылы-якты, ничаклы юмарт-сыйлы булмасын, күршегә ешрак керер өчен сәбәбе дә кирәк бит. Безнең иң ышанычлы йомышыбыз — Касыйм абзыйдан чәчләребезне алдыру.

— Һмм... Пәкене кайрап өлгермәдем бит әле, каһәр,— ди Касыйм абзый бер керүдә безнең чәч әле шытып кына чыккан башларыбыздан сыйпый-сыйпый. Икенче бер керүдә пәкене бик кайрамакчы да... Әллә песи ашаган инде, кайракны һич таба алмый.

Ниһаять, мин муенга агып төшкән салкын күбектән куырыла-куырыла, артсыз урындыкта утырам. «Песи ашый башлап ташлаган» кайрак пәкене бик үк үткерләп бетерә алмаган, ахры, һәр учма чәч белән тешләрне кысып, күзләрне чытырдатып йомып кына саубуллашырга туры килә.

— Анасы, бу балалар безне тәмам баетып бетерәләр бит,— ди Касыйм абзый, минем уттай кызган башны шытырдата-шытырдата.— Алар үстереп биргән чәч белән безнең инде теге капчык шыплап тула, шуны тиреләче Һадига тапшырсак, акчасына нәрсәләр генә алып бетерербез икән?

— Ыланнарга әҗерен ничек түләп бетерербез диген син, атасы,— ди Гөлсем апа, почмак як ишегеннән аның түгәрәк алкалы түгәрәк йөзе балкып күренеп китә.

Ә дымлы керфек араларыннан менә-менә яшь сытылып чыкмакчы... Ләкин яшь сыгарга һич ярамый, стенадан, әнә, сиңа кызыл командир карап тора, өстәвенә, почмак якта нәрсәдер бик тәмле чыжлый...

...Аларның әлеге гел чәчәкле, гел жимешле бакчалары артыннан ук кечкенә инеш ага. Инешнең теге ягында колхоз яшелчә бакчасы башланып китә. Анысына да Касыйм абзый хуҗа. Яшь балалы апалардан, карчык-корылардан торган бригадасы белән Касыйм абзый колхоз бакчасында да кыяр-помидорны тирә-юньдә иң алдан өлгертә.

Әйтергә кирәк, Касыйм абзый бакчаның иң усал, бик нык куллы хуҗасы. Һәркемгә, шул исәптән колхоз җитәкчеләренә булсын, район кешеләренә булсын, кыярны үз кулы белән генә өзеп бирә ул, әгәр дә кыяр әле яшь икән, уңыш җыяр вакыт җитмәгән икән, никадәр генә авыз суыңны йотма, анысы да эләкми. Аннары тагын менә нәрсә...

Соңрак, башка авылга күчеп килгәч, мин яна дусларымның кыяр, кишер түтәлләренә керергә бик яратуларын күреп, чын гаҗәпкә калган идем. Кышкар малайларында исә андый гадәт юк иде. Моның сәбәбе булган икән.

Бервакыт, яшелчәләргә кичен су сипкән чак иде. Инеш буе чиләклэйкәләр чынлавы, әби-апаларның гөрләшеп сөйләшүләре, каргалар карылдашуыннан күнелле генә яңгырап тора. Бакчаның теге башына су озын улаклар буйлап килә, улакка суны инештән зур чыгыр чыгарып тора иде. Бүген шул чыгырның кай җиредер ватылган да, Касыйм абзый шуны төзәтеп маташа иде. Мин Касыйм абзый кулындагы балтаның шундый да җитез йөрүенә, юан-юан казыкларны бер чабуда кырт өзеп чыгаруына сокланып карап торам.

Шунда Касыйм абзый кинәт башын күтәрде дә, инеш буеның бар күнелле гөрелтесен басып, бик ямьсез итеп, куркыныч итеп кычкырып җибәрде:

— Ах, мур кыргыры!.. Кадалып киткере... Ух!..

Күтәрелеп карасам, арырак, койрыгын селти-селти, кәбестәләр белән сыйланып йөрүче ала кәҗәне күреп алдым.

Ул арада Касыйм абзый бик яман сүгенә-сүгенә шул якка йөгерде. Бераз баруга, кулындагы балтасын бар көченә ыргытып җибәрде... Белмим, бик төз куллы булды микән ул, әллә туры гына килдеме... балта кәҗәнең арт санына барып тиде. Бичара мәхлук, иләмсез акырып, җиргә ауды, сырты турындагы ак кәбестәләр шунда ук кып-кызыл төскә керде.

Әби-апалар чыр-чу килә-килә йөгерешә башладылар.

— Һай, харап итте кәҗәне!..

— Тизрәк ирләрдән берәрсен чакырырга кирәк.

— Һай, Майҗиан кәҗәсе бугай... Нишләр!

Ни арададыр халык җыелып өлгерде, ирләр дә күренде. Кайсылары кәҗәне тизрәк чалып калу хәстәренә керештеләр. Әмма иң күп кеше Касыйм абзый янында, барысы да аны юаталар, аны тынычландыралар иде — «малкайны харап иткәнсең» дип, ник кенә берсеннән бер авыз сүз чыксын!

Соңыннан Маһиҗиһан апаны ничек ризалатканнардыр, ул кадәресен белмим, ләкин бу турыда сүз чыкса, олылар әйтә иде:

— Касыйм бакчасы белән шаярырга ярамый ул.

— Бер кабынып китсә... Туган атасын да җәлләмәс.

— Эшенә дә бөтен җанын бирер, ну инде эшенә тисәң, синең җанынны суырырга да күп сорамас.

Сөйләп тә алалар... Герман җирендә әсирлектән бик яман бакча җене кагылып кайта Касыйм абзыйга. Лапас артларындагы әрем баскан җирне ни арада шау чәчәкле, мул җимешле бакчага әвереләрә. Авылда яшелчә үстерү, җиләк-җимеш бакчалары бөтенләй булмый әле ул вакытта. Шунлыктан, малай-шалайдан булсын, егет-җиләнчектән булсын, Касыйм абзый бакчасына күз яндыручылар да табыла. Менә шунда инде күрсәтә ул тегеләргә... җимешнең иң татлысын. Ау мылтыгына ядрә урынына тоз тутырып тегеләрнең арт якларына атулар, сыек тал чыбыгы белән, кычыткан көлтәсе белән...

Бу — элегрәк шулай булган. Хәзер инде, әйтәм ич, кеше бакчасына күз ату гадәте юк ул Кышкарда.

Моңысы шулай. Аның каравы... Авылда берәрсе авырып китсә, Касыйм абзыйларга йөгерә. Кышын-язын яңа агачтан өзеп кенә алган

кебек кып-кызыл алмасы да табыла аларда, тозлаган кыяр, кәбестә ишеләрне әйтеп тә торасы юк. Туй үткәрәсеме, егетләрен армиягә озатасымы бар икән, ул өй Касыйм абзый бакчасында үскән шундый да матур чәчәкләр белән тула. Язларын Касыйм абзый яшелчә орлыкларын, үсентеләрне кешеләрне үгетли-үгетли үзе өләшеп йөри. Ләкин кешеләр ул орлыкларны лапас артындагы түтәлгә төртеп куялар да тәрбияләп үстерү ягына әллә ни мәшәкатьләнмиләр. Ник дигәндә, никадәр генә тырышма, барыбер Касыйм абзыйдан да шәбрәк үстереп булмаячак, аннары, колхоз бакчасында Касыйм абзый бригадасы үстергән кыяры, помидоры, кишере, кәбестәсе хезмәт көненә болай да бик мул бүленә.

Ай, ул яшелчә бүлгән көннәр! Без бала-чагага ин-иң күңелле бәйрәм була торган иде ул.

Менә инеш буенда тау-тау кыяр өемнәре. Шунда ук агач таганга асылган зур үлчәү. Үлчәү янында зәңгәр халатын киеп алган Касыйм абзый.

Түтәл араларындагы бөтен сукмаклар да кешеләр белән тулы. Монарчы әле бу сихри бакчага керү бик санаулы кешеләргә генә рөхсәт ителгәнлектән, алар башларын селки-селки Касыйм абзый бригадасы үстергән хәзинәне карап йөриләр.

Бала-чага исә әлеге кыяр өемнәре тирәсендә. Их, исләре генә дә ни тора бу тауларның! Әллә нинди салкынча-рәхәт ис ул — кыяр исе. Бөтен тәннәрне җиңеләйтеп җибәрә торган ис.

Ә Касыйм абзыйны, Касыйм абзыйны гына күрсәгез икән бу көнне! Ул бүген дөньяда иң ягымлы, иң юмарт, иң көләч кеше. Көләч дигәннән, күзе, иреннәре һаман да кырыс-җитди аның, әмма чал сакал-мыегы елмая моның. Әллә ничек, әнә шулай түгәрәк сакал-мыегы белән генә елмая белә иде ул карт.

Әнә ул, туктаусыз сөйләнә-сөйләнә, кешеләргә кыяр үлчи.

— Кыяр түгел, оҗмах җимеше бу, беләсегез килсә. Тәннән чирсырхауларны куа, йөрәкләрне яшәртә бу. Ходайның һәр бирмеш көнендә, бисмилланы әйтеп, шулай берәр кыярын, помидорын ашап торсаң... Мин сина әйтим, йөз елдан да артык яшәрсең.

Ул арада әле үз өлешләрен алырга өлгермәгән бала-чагага берәр кыяр төртә.

— Мәгез, тишек борыннар, кетердәтә торыгыз.

Көндезен бакчада күбесенчә картлар, бала-чага гына була. Кичкә таба егетләр, кызлар да инеш буена төшә. Җыр, гармонь яңгырый башлый. Касыйм абзый инде күптән кайтып киткән, үлчәү янында бер кәрзин тулы кыяр гына калган. Телисең икән,— рәхим ит — Касыйм абзый юри калдырган бу кәрзинне яшьләргә.

...Менә шушы кешене Фазыл абыйның нигәдер яратмавын, бервакыт аны каты гына итеп тиргәвен дә күргәч, миңа бик тә күңелсез булган иде.

Мин инде икенче класс малае, өйдәге эти рөхсәт иткән барлык китаплар да укылып беткәч, хәзер каршыдагы китапханә бусагасын таптый башлаган идем. Ләкин китапханәче Сәкинә апаның, белмим, бүтән эшләре дә бик күп булды микән, ул ишекнең ачык чагын очрату шактый кыен була иде.

Бервакыт, әнә шул ишекне сагалаштыргалап, әлеге абзыйлар тәмәке көйрәтә торган бүлмәдә утыра идем. Тышта бик ачы җилле буран уйнап торганлыктан, бирдә кеше аеруча күп, тәмәке төтене аша аргы почмакны да күреп булмый иде.

Бүлмәгә Фазыл абый да килеп керде. Кемнәндер тәмәке төреп кабызды да Касыйм абзый каршына килеп басты.

— Ләчтит сатабызмы? — диде ул, коры гына.

— Алучы булганда, сатарга иренмибез,— диде Касыйм абзый, кая-дыр читкә караган килеш.

— Ие, анысына иренмисез! Ә мена укырга йөрергә дигәндә... Юк! Сон инде шунда курска йөреп укырга өйрәнеп чыксагыз, монда ләчтит сатып утырганчы, өегездә бирәр китап укып ятыр идегез, понимаешь. Миегез тулы томаналыктан, значит и җыен капитализм калдыкларыннан, тизрәк арыныр идегез.

Аңа каршы дәшүче булмады.

— Бу ниткән консерватизм бездә, понимаешь! Колхозыбыз «Авангард» дип атала, значит и иң алдан баручы дигән сүз. Анысы дөрес, хуҗалык эшләре буенча алай бигүк артта да сөйрәлмибез. Ә мена аң-белем тарату, наданлыкны бетерү буенча... арттан санаганда районда икенче урында барабыз, понимаешь. Әйтәсең дә юк, авангард!

Абзыйлар, тамак кыргалый-кыргалый, тын гына утыра бирделәр.

— Ә син, Касыйм абзый, аң-белем эшенә явный аяк чалу юлына баскансың. Үзең дә йөрмисең курска, понимаешь, Гөлсем апаны да йөртмисең.

— Мин карчыкны тотмыйм, йөрсен. Әмма ләкин миңа кирәкми ул яңалиф.

— Ничек инде ул, кирәкми? Ни дигән сүз бу тагын?

— Шулай... Җаным тартмый.

Фазыл абзый, болай да гайрәтле-калын тавышын күтәргәннән-күтәрә барып, Касыйм абзыйны «капитализм калдыгы» дип бик каты орыша башлады.

Касыйм абзый һаман да читкә караган килеш хәрәкәтсез утыра, үзен орышканны бөтенләй дә ишетми кебек иде. Аннары ул тирән генә сулап куйды.

— Белмисең син, Фазыл... Аңламыйсың,— диде.

— Как-так? Нәрсәне аңламыйм?

Касыйм абзый урыныннан торды. Күзләре усал ялтырап китте.

— Ничәмә еллар сугышында, аннары пленда йөреп, болай да гарык мин ул немецлардан. Гарык! Инде килеп, хәрефләрен дә күрәсем килми. Булдыра алмыйм, юк!.. Мена, минем кебек, ул юнкер-мункерларның камчысын алып кара әле!.. Аннары аңлар иден.

Фазыл абыйның тәмәке тоткан кулы авызына сузылганда ярты юлда тукталып калды.

— Нигә немец хәрефе булсын ул яңалиф? Яналиф ул... Яңалиф, ул — яңалиф,— диде инде бөтенләй йомшак тавыш белән.

— Барыбер җаным тартмый... Ә малайга хатны үзебезчә, искечә язам.

— Сөйләш сезнен белән...— диде председатель һәм кинәт борылды да ишекне бик каты ябып чыгып китте.

Бер көнне, әлеге шул чәч алдыру сылтавы белән аларга кергәч, Касыйм абзый гадәтенчә «пакене кайрамаган-фәлән» дип маташмады, караваттагы мендәрләр өеменә кырын яткан килеш: «Кәефем юк әле бүген, улым», дип кенә куйды. Гөлсем апаның да түгәрәк алкалы түгәрәк йөзе алай балкымый, «Әниен ниһли?» дип, «Әтиен өйдәме?» дип сораштырып алды да почмак якка кереп китте.

Мин инде чыгып китәргә дип борылган идем, Касыйм абзый туктатты.

— Син, улым, укый беләсең бугай хәзер?

— Белә-эм... Әллә кайчаннан инде.

— Болай, китаптан гына укыйсынмы, әллә кулдан язганны да булдырасыңмы?

— Булдыра-ам.

Гөлсем апа да, бөтенләй үзенчә балкып, бу якка чыкты.

— И-и, кара инде, искә дә килми тора икән ич. Укып бирсәңче, улым, Исмәгыйл абыеңның хатын.

Нәрсәләр язылды икән ул хатта? Исемдә юк: хатны укып бетерүгә, Касыйм абзый дуылдап тагын караватына барып ятты.

— Вәйт, шайтан малай, ә! Монысына кадәр немец хәрефенә күчте хәзер. Бер дә бүтән түгел, Фазыл эше бу. Шул котыртып язган малайга. Шул бүре тыкшына бөтен эшкә. Язам, бүген үк язып салам. Маташмасын анда... Әтисе укырлык итеп язсын хатларын. Вәйт, шайтан малай, ә?..

Язгандырмы ул, юктырмы бу турыда, ләкин Исмәгыйл абый хатлары моннан соң да яңалифчә килде. Хат укырга дип, бу өйгә керергә яңа сәбәп табылуга мин бик шат идем, әлбәттә... Шул ук вакытта, бик кыен да иде миңа. Хат укыган саен Касыйм абзый улын да, Фазыл абыйны да бик каты тирги башлый, ә минем һич кенә дә тиргәтәсем килми иде аларны, кызыл командирны да, председательне дә.

Ничәнчедер хатны укып биргәч, мин Гөлсем апага күптәннән уйлап йөргән ниятемне әйтеп салдым:

— Әйдәме, Гөлсем апа, укырга өйрәтәм сине. Бернәрсәсе дә юк аның... укырга өйрәнүнең.

Ә Касыйм абзыйга мондый ният белдерергә шүрләдем. «Җаным тартмый» дип, бигрәк инде ачынып әйтте бит теге көнне.

Гөлсем апаның түгәрәк йөзе алсуланып китте.

— И-и, улым, булмас ла ул миннән. Искечәсен дә көчкә генә ермачлаганны... Матур итеп әйтүеңә рәхмәт.

— Була, Гөлсем апа. Бернәрсәсе юк. Менә күрерсең...

— Юкка гына баш катырып утыру булыр ла ул. Вакыт уздырып кына...

— Гөлсем апа дим...

Шунда мәсьәлә һич көтелмәгәнчә хәл ителде.

— Син моны үз теләгең белән әйтәсеңме, улым, әллә берәрсе куштымы? — диде Касыйм абзый, минем башымнан сыйпап.

— Берәү дә кушмады. Үзем.

— Сәкинә апаң әйтте мәллә?

— Ю-ук.

— Мәктәптә куштылармыни?

— Юк инде.

— Әллә ниме... Фазыл кушмагандыр бит?

— Ю-ук!.. Минем белән сөйләшкәне дә юк аның, Фазыл абыйның. Әллә кайчаннан бирле.

— Алайса син, анасы, каршы килмә малайның изге ниятенә,— диде Касыйм абзый.— Берәү дә тумыштан грамотный булып дөньяга килми. Тырышсаң, ник булмасын!

— Һай, фәрештәләрнең амин дигән чакларына гына туры килсәче канә,— диде Гөлсем апа.— Тегендә, мәптеккә йөрсәм, кеше арасында көлкегә калмагаем дип бик курка идем аны. Улым үзебезнеке әле, көлмәс, шәт, рәхмәт яугыры.

Көнүен дә көнде Гөлсем апа укырга өйрәнергә, Касыйм абзый да бик хуплап тора бу эшне, ләкин... Ай-яй, кыен икән ул укытучы булуы!

Кичә генә өйрәндек ләбаса бу «Т» белән «F» хәрефләрен, инде аларны бутамый да башлаган иде. Бүген тагын «Т» ны «F» дип, «F» ны «Т» дип утыра... Элек өйрәнгән хәрефләрне дә кушып, at дип, fәп дип укып та утырды кичә, бүген инде онытып та өлгергән.

Язарга өйрәтүләре исә... Жылыйсылар килә кайчак. Һич тынламый карандаш Гөлсем апаның бармакларын. Дәфтәр юлларын бар дип тә белми, бер хәрефе ат башы кадәр чыкса, икенчесе кырмыска тикле генә. Хәрефләре хәреф төсләме соң тагы... Тараканны карага манып кәгазьгә жибәргәннәр диярсең.

Ә Касыйм абзый, әллә чыннан, әллә юрамалый гына инде, карчыгын мактарга тотына.

— Карале син бу кортканы, тәки булдыра бит. Тырыш, карчык, тырыш. Әйтәм ич, тумыштан грамотный булып дөньяга килми адәм баласы. Тырышлык белән алдыра. Булдырасың бит әнәтерә.

Еш кына миннән сорашып та ала Касыйм абзый:

— Менә монысы нинди хәреф әле, улым? Ә-ә, безнеңчә «ләм» була инде, алайса. Монысы нинди хәреф? Безнеңчә, «жим» икән. Ә монысы? Монысы?.. Я, ярар, өйрәнегез үзегез генә. Комачау итмим.

Һәм авыз эченнән нидер пышылдап, идән буйлап йөренә башлый. Тагын безнең янга килеп туктый.

— Болай булгач, Исмәгыйльдән хат килсә, шартлатып үзең генә укып бирәсең инде, ә, карчык? Шәп була бит бу.

Гөлсем апа тыелып кына көрсенеп куя.

— Хаты килсәйде әле... Әллә, атасы, үпкәләттек инде без ул баланы...

— Кирегә сукалап утырмачы! — ди Касыйм абзый бик ачулы.— Вакыты юктыр. Службада ни генә булмый. Маневры, заданиесе... Арка кашырга да вакыт булмый кайчак.

Ул дуылдап караватка барып ята.

— Үпкәләгән генә булса, анысы... Вакыт тауны да тигезли,— дип, бераздан үз алдына гына сөйләнгәндәй әйтеп куя.

— Нигә алай дисең, атасы?

— Жә, жә! Ал кулыңа хәрендәшеңне. Өйрән!

Менә айдан артык инде, Исмәгыйль абыйдан хат килми иде.

Язга таба мина «дәрес бирү» шактый жиңеләйде.

— Һай, улым, китабың тулы бала да чана, ана да бала... Берәр кызыграк жире юкмы соң монының? — диде Гөлсем апа бер кичне.

— Бар, Гөлсем апа, бар. Хәзер табам.

Мин әлифбаның арырак битен ачып, укып күрсәттем:

Гәрәй, Вәли һәм Гали
Кызу шуып барганда,
Бер-бер артлы тәгәри.

— И улым, монысы да инде... бала-чага сабагы. Без картлар да укый торганы юк микән дигән идем мин.

— Ник булмасын. Иртәгә үк апкилäм, Гөлсем апа.

Иртәгесен аларга кергәндә, минем кулда Һ. Такташның «Кара борынның дусты» дигән китабы да бар иде. Китапханәгә яңа кайткан. Менә, ичмасам, китап! Гөлсем апага да ошамый калмас бу.

Һәм дөрестән дә... Иң кызык жиргә генә житкәч, мин үзебезнең укытучыга охшатып:

— Ә калганын иртәгә укып бетерербез,— дигән идем, Гөлсем апа да, Касыйм абзый да:

— Тагын бераз укы инде, улым.

— Әле алай соң түгел, бәлки, ахырына да житәрбез,— диештеләр.

Укып бетергәч, картлар беразга тын гына утырдылар.

— Бичара... Ниләр генә кичми ятимнәр башыннан,— диде Гөлсем апа.

— Булды инде андый хәлләр ул елларда. Яңадан күрсәтмәсен генә,— диде Касыйм абзый.

Мин бүгенге дәресемнән бик канәгать булып, китәргә җыендым.

— Карале, улым, ул китабыңны калдырып тор син,— диде Касыйм абзый.— Без мәптәккә йөргәндә, хәлфә болай итә иде. Китаптан берәр бит сабак биреп җибәрә иде дә иртәгесен шуны тыңлатып карый иде. Син дә шулайрак итсәң нишләр? Апаңа шушы китаптан сабак биреп калдырсаң, дим.

— Нигә... Әнә беренче биттән укый башла алайса, Гөлсем апа.

— И улым, булдырып булмастыр ла.

— Алайса, без болай итик. Син шушы биттән «S» хәрефләрен, аннары «С» хәрефләрен, аннары «Q» хәрефләрен табып куй.

— Күрсәтеп бирсәң... Тырышып карармын, улым.

Бик тә шәп ысул булып чыкты бу. Гөлсем апаның да ялгышмыйча таный торган хәрефләре арткannan-арта бара, минем дә эшләр көйләнде. Иң элек, Гөлсем апа «Караборынның дусты»ннан мин кичә әйтеп калдырган хәрефләрне таба, аннары мин аңа яңа биттән яңа хәрефләр табарга «өйгә эш» бирәм, аннары кычкырып китап укыйм, аннары бик тәмләп чәй эчәбез... Аннары, Гөлсем апа шыпырт кына кисәмә салган алманы бөтенләй дә сизмәгәнгә салышып, горур гына исәнләшеп чыгып китәм.

— Тик менә... Түр стенадагы рәсемгә генә күтәрелеп карап булмый. Һаман да хат юк Исмәгыйл абыйдан.

Без инде бик күп китаплар укып чыктык. Тышлыкларындагы рәсемнәре, калынлык-юкалыклары белән әле дә күз алдымда ул китаплар. Менә М. Әмирнең «Калку кырга кар ява» дигән китабы. Тышында малайлар кар тәгәрәтә. М. Галинең «Ул үсте» китабының тышында нигәдер бер рәсем дә юк. Г. Разинның «Соңгы сугышу» китабының да тышында рәсеме юк, аның каравы эчендә рәсемнәр бар. Мондый юкарак китаплар бер кичкә генә җитә иде, соңга таба калынрак китапларга күчтек. Л. Сәйфуллинаның «Закон бозучылар», А. Гайдарның «РВС» китаплары, Г. Толымбайның «Түбән елгада»сы... Мондыйларын өч-дүрт кич буе укыйбыз.

Укыр китаплар шулай гел алмашына торды, ә «Караборынның дусты» һаман да төп дәреслек булып калды.— Гөлсем апага «өйгә эш»не һаман да шул китаптан бирәм.

Барлык хәрефләрне дә диярлек таный инде хәзер Гөлсем апа, тик менә шуларны бергә кушып укуы гына бик авыр бара. Бармагын китап битенә төрткән килеш, авыз эченнән пышылдый-пышылдый бер сүзне оештырып укыганчы әллә ни гомер вакыт уза. Аннары, язарга өйрәтүләр...

— И улым, бүген язып тормыйк ла инде. Кулларым да бик арды... Китап кына укыйк. Бигрәк кызык төшендә калган идек тәнәген,— ди Гөлсем апа бу турыда сүз ачуга.

Мин дә моңа бик тиз күнәм.

Юкса... Карандаш һаман да Гөлсем апаның бармакларын тынларга теләми, ә түр стенадагы рәсемнән Исмәгыйл абый моны күреп тора да, миңа да, әнисенә дә ачуланадыр кебек... Әнә шуңа, ачуланганга күрә, язмый микән әллә ул хатларын?

Ә китап укыганда болар барысы да онытылып тора.

Касыйм абзыйның күңеле дөрес сизенгән икән.

Шатлыгы да, гаҗәбе дә, бераз хәсрәте дә берьюлы килде ул көнне.

...Җәйгә чыгуга, минем Гөлсем апага дәрес бирү, китап укулар тукталаыбрак калды. Касыйм абзый да, Гөлсем апа да бакчадан караңгы төшкәч кенә кайталар, миңа да уен бик сагындырган, күзләр бәйләнеп, кичке салкыннан аркалар чымырдый башламыйча торып, өйгә керер утырасы килми.

Анын каравы, мина, остаз кешегә, инеш буендагы бакчага полный юл ачык хәзер. Беренче өлгергән редискалардан беренче авыз итүче дә, ихтимал, мин булдым бугай.

Ул көнне дә әнә шул берәр кызыл редискага өмет итебрәк төшкән идем бакчага. Әле яшелчәләргә су сибәргә керешмәгәннәр, бакчада Касыйм абзый белән Гөлсем апа үзләре генә түтәлләрдә чокчынып йөриләр иде.

Шунда әллә кайдан, җир астыннан гына калыккандай, хат ташучы кыз килеп чыкты.

— Гөлсем апа, исәнмесез! Хат китердем сезгә.

Гөлсем апа да анын килүен күрмәгән иде бугай, тәмам каушап калды.

— Исмәгыйл улымнан... Әнә, өчпочмаклы печате дә бар... Атасы, җәтрәк, хат бар!.. Һай, балакаем...

Үзе хатны әле бер кулына, әле икенче кулына ала, буш кулы белән яулык астыннан чыккан чәчләрен рәтли, битләрен сыпыра, күлмәк изүләрен тарткалый иде.

Касыйм абзый, җилтерәп килеп җитә-җитешкә, анын кулыннан хатны тартып алды.

— Әйе, анын кулы,— диде конверт тышына текәлеп.

— Кая, атасы, бир балага. Җәтрәк укысын.

Ләкин Касыйм абзый минем сузылган кулымны акрын гына кире этәрде.

— Юк инде, анасы. Үзем укыйм! — диде.

Мин ирексездән елмаеп куйдым. Укырсын менә, тагын яналифчә язгандыр әле Исмәгыйл абый.

Касыйм абзый озаклап конвертны ачты, хат тоткан кулын алга ук сузып, башын арткарак ташлап, тагын шактый вакыт кәгазь битенә карап торды.

Шул арада мин үрелеп кенә хатка күз төшереп алдым. Әйе, яналифчә язган Исмәгыйл абый. Минем авыз тагын ерылды. Ерылды да ничек җыелганын сизми дә калды... Касыйм абзый иҗекли-иҗекли укып та китте.

Гөлсем апа алъяпкыч итәге белән күзләрен сөрткәли башлады.

Нәрсә, чыннан да укыймы ул, әллә шаярта гынамы Касыйм абзый?

Мин, Касыйм абзыйның алга сузылган куллары арасыннан башымны тыгып, үрелә-үрелә тагын хатка күз салдым. Юк икән ич, шаяртмый икән бит, чыннан да яналифчә укый белә Касыйм абзый, укый белә! Дөп-дөрес итеп укый.

Ә хатта нәрсәләр язылганны мин үзем тагын бер кат кычкырып укып чыккач кына төшенеп җиттем. Әйе, сугышчан задание үтәгән Исмәгыйл абый. Чик буенда кораллы бәрелешләр булган. Шунда ул яраланган. Хәзер госпитальдә ята икән. «Хәлем бик әйбәт, бу хат сезнен тарафларга барып җиткәндә, мин инде яңадан сафка баскан булырмын», диган.

— Һай, кул-аяклары сау микән балакаемнын. Интеккәндер инде бичара...— дип, Гөлсем апа гел күзләрен сөртә, ә Касыйм абзыйның тавышы шактый ачулы иде.

— Син, анасы, кирегә сукалап маташма. Раз яңадан сафка басам дигән икән, раз служ6ага голен икән, бөтен җире сау-сәламәт, малай тап-таза дигән сүз. Шуны бел син!..

...Ничек барып кергәнмендер дә, ничек кыюлыгым җиткәндер, бераздан сон мин авыл Советы бүлмәсендә, Фазыл абый каршында басып тора идем.

— Син, малай, борчак кына сиптермисендер бит? Дөресме инде бу? Чыннан да укый беләме? — ди Фазыл абый күзләремә туп-туры карап.

— Дөрес инде!.. Әйтәм ич, үзем дә шаклар каттым. Син, Фазыл абый, моннан соң ачуланмыйсыңмы инде аңа? Касыйм абзыйга дим.

— Ачулар бетә инде, болай булса. Ә Гөлсем апаңны укырга өйрәтергә кем, әллә әтиең әйттеме?

— Юк ла... Үзем.

— Ә Касыйм абзаңның укырга өйрәнгәнен сизми дә калдың, ә? Вәйт хитрый карт!

Һәм ул шаркылдап көлеп җибәрде.

Бүлмәдә Сәкинә апа да бар, почмактагы өстәлдә беләк буе хәрефләр белән ниндидер лозунг язып утыра иде.

— Касыйм абзыйдан булыр аннан. Үлсә үләр, үз дигәнен итәр,— дип, ул да сүзгә кушылды.

Фазыл абый, идән буйлап йөренгән җиреннән туктап, җилкәмә авыр кулын салды да мине дер селкетеп куйды.

— Молодец, энем! Чын пионер икәнсең син, болай булгач. Сәкинә, бүген үк барып тикшер дә икесен дә неграмотныйлар исемлегеннән сыз. Районга да хәбәр итәргә кирәк. Беләсеңме, бездәге грамотность проценты күпмегә үсеп китәчәк. Молодец, энем!

Урынына барып утырды, тәмәке кабызып җибәрде.

— Исмәгыйл абыең ниләр язган соң хатында? Күптәннән хаты килгәне дә юк иде бугай?

Мин сөйләп бирдем. Фазыл абый тагын урыныннан сикереп торды.

— Вәйт как!.. Бу бит, нәрсә?.. Бу бит... Бу бит — замечательни бит бу! Касыйм малае Исмәгыйл, значит и безнең Кышкар егете — герой пограничник! Менә бит ничек... Сәкинә, әйдә, киттек хәзер үк яннарына, котлап кайтыйк картларны. Стенгазетка да язарга кирәк, районга да хәбәр итәрбез. Замечательни бит бу! Киттек, Сәкинә!

Мин дә аларга иярдем. Ләкин барып җитә алмадым.

Юлда Актырнак очрады. Әллә кайдан гына килеп чыкты да, туп-туры өстемә сикереп, битемнән ялап та алды. Үзе бер алдыма, бер артыма чыгып сикерenә, үзе тоттырмый, әмма ялтырау күзләреннән, койрык болгауларыннан ук күренеп тора: мине үз итеп, дус итеп килгән ул. Бүгенге ташып торган шатлыгымны уртаклашырга килгән.

Актырнак, тоттырмыйча, шулай шаярып йөрде-йөрде дә, бераздан үзе каршыма атылып, алгы тәпиләре белән күкрәгемә килеп басты.

— Беләсеңме, Актырнак,— дидем мин аны кочаклап алып,— моннан ары синең исемең Актырнак булмасын, Караборын булсын, ямe? Әнә бит борынында кара таплар да бар. Караборын бул! Шундый да акыллы эт ул Караборын. Касыйм абзыйны да, Гөлсем апаны да ул гына өйрәтте. Син дә Караборын бул, ямe?

Актырнак-Караборын койрыгын болгый-болгый ризалыгын белдерде.

Икенче көзгә без, бөтен йорт җиһазларыбыз белән бер ат арбасына сыешып бетеп, Олы Мәңгәр авылына күчеп киттек. Әтине ул авылдагы ТБУМнан урта итеп оештырылган яңа мәктәпкә укытучы итеп билгеләделәр.

Караборын безне авылдан чыккач та бик еракка кадәр озата барды.

## ӨЧЕНЧЕ АЛАН

## Ялкау сандугач буламы?

Мәңгәр малайлары белән танышу болай башланды.

Капка төбенә чыгуга, мин малайлар өере уртасында калдым. Тездән генә кыска ыштаным да, зур якалы матрос күлмәгем дә, алгарак чыккан

маңгаем да, хәтта исемем дә бер дә ошамады аларга. Арада берсе — болай да төптән юан, өстәвенә, бүксәсен дә алгарак киергән, маңгай чәчләре кире беткәнләнеп артка бөтеркәләнеп торган малай — барысыннан да уздыра. Менә хихылдый-хихылдый килеп, минем киң матрос якамны башыма ук бөркәндереп куйды бу. Борын эчләрен ачыттырып килеп җиткән күз яшьләрен йотып җибәрдем дә, үзем дә сизмәстән, чәчрәп ябыштым тегеңә.

Төптән юан шушы малайны тукмапмы-тукмап ташладым... дип әйтә алмыйм. Мин бер селтәнгәнче, тегенең әллә сөяк-сеңердән, әллә тимердән укмашкан йодрыгы ике-өч мәртәбә минем ипи шүрлегенә менеп төште, ә инде җиргә егып салып, баш бармагы белән чәчләремне артка сыпыра башлагач, чак кына чучкадай чинап җибәрмәдем... Әмма чинамадым.

Бераздан без икебез урамның ике ягыннан бер-беребезгә йодрык болгыйбыз, бүтәннәр шарык-шорык көлешәләр иде.

— Тетмәңне тетәм әле мин синең! Аяк-кулларыңнан бау ишәм,— ди тегे, бүксәсен киергәннән-киерә төшеп. Исеме — Фәрит икән.

— Күргән сезнең ишеләрне! Бишегез бер йодрыкка сыя,— дип җибәрәм мин дә, әллә тешләнгән телдән, әллә кабарган иреннән саркыган канны түкерә-түкерә.

Әйтешә торгач, безнең бер-беребезгә янау-хурлау сүзләребез бетеберәк китте бугай, тынып калдык. Шунда биялэйдәй иренле, миннән бер кул яссуы озынрак малай — Мөхәммәтхан дигәннәре — кысынкырак күзләрендә җор очкыннар уйнатып, әйтеп куйды:

— Рафаил — Рапай, Рапай — Чапай...

Малайлар дәррәү көлештеләр. Монысы инде килешү көлешүе иде бугай. Шуннан соң алар минем матрос якалы күлмәгемә дә, калку маңгаема да игътибар итми башладылар. Тегесенең дә киерелгән бүксәсе, монысының биялэй иреннәре алай күземә чалынмас булды.

Ә Мөхәммәтханның «Рапай-Чапай» дигәне малайларга артыграк та ошап китте булса кирәк — шул көннән башлап миңа кушамат булып ябышты ул сүзләр.

Хәер, кушаматсыз малай юк та иде бугай Мәңгәрдә.

Мөхәммәтханның үзенең дә кушаматы бар икән — Урыс Мөхи.

Соңыннан малайлар миңа аның бу кушаматка ничек ирешкәнен дә сөйләп бирделәр.

Шулай бер вакыт, узгынчы бер рус агае малайлардан базарлы Әтнәгә чыгып китә торган юлны сорый. Юлны сораганын чамалыйлар малайлар, ләкин ничәме урам, ничәме тыкрык аша узган юлны аңлатып бирергә кайдан рус сүзләре табып бетермәк кирәк? Ләкин арада табучысы да бар икән. Мөхәммәтхан алгарак чыга да кулларын бутыйбутый сөйләп китә. Сүзләр күбесенчә «ский»га бетә, әледән-әле «значит», «понимаешь» дигән була... теле-телгә йокмый, сибә генә бу. Агай да аның аңлатуларыннан бик канәгать була, ахры, күңелле елмаеп, малайның аркасыннан кага да нәкъ дөрес юлдан китеп бара.

Әнә шулай Урыс Мөхи булган икән Мөхәммәтхан.

Шактый бай китапханәсе бар иде Мәңгәрнең, өстәвенә, колхозның кызыл почмагындагы һәм мәктәпнең пионер бүлмәсендәге китап шкафлары да Кышкардагы Сәкинә апаның китап шкафыннан тулырак иде. О, болай да Кышкардан зуррак авыл иде Мәңгәр, ә инде бу китап шкафлары минем дөньямны бөтенләй иксез-чиксез иттеләр.

Ай, никадәр кадерле, никадәр якын алар күңелгә, беренче укылган китаплар. Бала чактан ук дус-юлдаш булып гомергә күңелгә сеңгән китапларын кемнәр генә иң-иң тирән хөрмәт белән искә алмас!

Аннары... Көннәрнең берендә, атларга төялеп, авылга колхоз-совхоз күчмә театры артистлары килеп төшә. Моңарчы радиода гына ишетелгәнчә матур итеп гармун уйнатып, җыр яңгыратып килеп керәләр дә

алар авылга, олы урамны шау-гөрләтеп бер әйләнгәч, клуб алдына килеп туктыйлар. Бирейдә артистларны фатирларга урнаштыру башлана. Без, малайлар, авыл Советы председателенең күзләренә керердәй булып шунда басып торабыз. Безгә дә берәр артистны фатирга кертмәс микән? Кертсә, кичен театрга бушлай барып булачак дигән сүз бит...

Аннары тагын... Кул белән әйләндерә торган авыр динамосын, аппаратларын, түгәрәк тартмалы lенталарын төяп, күчмә кино килә. Тавышсыз кино әле ул вакытта, сурәтләре дә бик үк ачык түгел, кешеләр нигәдер бераз калтырабрак-сикергәләбрәк йөриләр. Шуңадыр, «томанный» дип йөртәләр иде ул вакытта киноны.

Соңрак, район үзәге Әтнәгә барып, тавышлы һәм бик ачык күренә торган киноларны да күреп-күреп кайттык кайтуын. Ләкин беренче күргән әнә шул «томанный картиналар» күңелгә аеруча уелып калган.

Күз алдымда дөньяны киңрәк ача барган акыллы китаплар, сихри театр, кинолар... Бирейдә әлеге малайлык чәкәләш-бәрелешләре ничек бәләкәй булып кала. Ләкин шул ук вакытта, шул ук акыллы китаплар, шул ук сихри сәнгать мине малайлар өмет иткәнчә Чапай ук итмәсәләр дә, барлык кордашларым кебек, Бөек Ватан сугышы солдаты итеп тәрбияләделәр. Йөзгә кызыллык килердәй үтмәдек без ул зур, бик зур сынау елларын һәм монда инде бала чакта ук укыган китапларның, караган спектакльләрнең, киноларның өлеше, әлбәттә, бизмәнгә салып кына үлчәп бетерерлек түгел.

Аннары, күңелгә беренче иҗат очкыннары салучылар да шулар бит инде — беренче укыган китаплар, беренче караган спектакльләр, фильмнар.

Кабынды ул очкын миндә дә... Ничек кенә булды соң әле ул?

Алтынчы класста укыганда, инде уку елы башлангач, мәктәпкә яңа укытучы килде.

Кечерәк кенә буйлы, калын кара кашлары астыннан җитез кара күзләре ут чәчеп тора торган чибәр генә егет. Өстенә кара вильвет куртка кигән, курткасының өске төймәсен чишеп җибәргән дә, аннан ап-ак күлмәк якасы, кап-кара галстугы килешле генә күренеп тора.

— Исемем — Фәхри, фамилиям — Сайкин. Фәхри абый дип йөртерсез,— дип, беренче дәрескә кергәч, үзе белән таныштырды.

Шунда кемнәрнеңдер пышын-пышын сөйләшүләрен күреп алды да озын бармагы белән бик каты өстәл шакып куйды.

— Минем дәресләрдә тәртип бозулар булмас! Минем дәресләрдә ид-деально тынлык булыр...

Һмм... Алдан ук классны кулга алыйм, дилбегәне кулдан ычкындыра күрмим, дигәндер инде, барыбызны берьюлы бик яман орыша башлады бу. «Мин тырышларга гына бик шәфкатьле» ди, «Әгәр тәртип бозучылар булса, карагыз аны!..» ди... Озын бармагы әледән-әле өстәл шакый, болай да очкынлы кара күзләре усал ялтырый...

Класс сагаюлы тынып калды. Үзе теләгән шушы «ид-деально тынлык»ка ирешкәч, укытучыбыз да безне орышудан туктады, горур-канәгать бер кыяфәттә басып калды.

Менә шунда безнең Мөхәммәтхан — тынлык-җитдилекне һич җаны күтәрә алмый торган безнең Урыс Мөхиебез — гадәтенчә ярым пышылдап, әмма бөтен класс ишетерлек итеп әйтеп салды:

— Әтәч Фәхри...

Болай да Мөхәммәтхан авызыннан чыккан һәрбер сүзгә шаркылдарга гына тора идек без, бу юлы да пырхылдап җибәрдек. Укытучыбызның усал күзләрендә хәзер инде, әйтергә кирәк, чын-чынлап дәһшәтле очкыннар кабынды. Кабынды да... шунда ук сүнде һәм ул үзе дә бик яктырып көләп җибәрде.

Укытучы да көлә, без дә көләбез. Без көләбез, укытучы да...

Туйганчы шулай көлешкәч, укытучы бармак аркасы белән күзләрендәге яшьләрен сөртеп алып, әйтте:

— Ну, ребята, насмеялись. А сейчас начнем урок.

Безне рус теленнән укытырга килгән иде ул.

Беренче дәресне шулай сәер генә башлап җибәрсә дә, тиздән ин яраткан укытучыбыз булып китте Фәхри абый.

Грамматика дәресләрен әйтмим, алары гадәттәгечә утә, аларында Фәхри абый шул озын бармагы белән бик еш шак-шок өстәл дә шакый... Ә менә әдәби уку дәресләрендә... Монда инде чыннан да «ид-деально» тынлык урнаша, монда инде бөтен классны сихерли, үз авызына карата иде Фәхри абый.

Менә ул класс журналына кемнәрнең килү-килмәвенә билгеләрен куеп бетерүгә, кисәк кенә урыныннан тора да, арткарак чигенеп, кара такта янына килеп баса, уң кулын өскәрәк күтәрә. Класс болай да тын, ә бу кул күтәрүдән без тагы да сагая төшәбез.

Фәхри абый акрын гына, әмма һәр сүзне тәгәрәтеп кенә чыгарып шигырь сөйли башлый:

Тучи небесные, вечные странники...

Аның тавышы әле моңсу-уйчан, әле усал-нәфрәтле яңгырый. Шушы моңсу-уйчанлык, шушы усал нәфрәт көчәйгәннән-көчәя бара һәм менә...

Нет у вас родины, нет вам изгнания,—

дигән соңгы юлларда бу ике көч, әйтерсең, куәтле диңгез дулкыннары кебек капма-каршы килеп бәреләләр, чәпәләшәләр... Шигырьнең бөтен мәгънә тирәнлеген без, әлбәттә, әле тулысынча төшенеп тә җитмибез, безгә таныш булмаган сүзләр дә бар анда. Ләкин шушы кадәр көчле-куәтле, шушы кадәр матур яңгырый торган шигырь юлларында олы мәгънә ятуын без күңелебез белән тоябыз.

Шигырьне укып бетергәч, Фәхри абый башын аз гына кырын салып, беразга хәрәкәтсез кала, аннары гадәтенчә кискен-кискен атлап, өстәле янына килә.

— Бу шигырьне моннан йөз ел чамасы элек Михаил Юрьевич Лермонтов язган. Безнең бүгенге дәресебез — шушы олы шагыйрь турында.

Фәхри абый башта әле генә укыган «Болытлар» шигыренең татарча мәгънәсен төшендерә, аннары әле русчалап, әле татарчалап шагыйрьнең тормыш юлы турында сөйләп китә. Аннары тагын «Болытлар» шигыренең фәлсәфи асылын аңлата башлый.

Әйе, күңелләр юкка гына кузгалмаган, һәр юлында, һәр сүзендә тирән мәгънә ята икән ул шигырьнең. Никадәр изге, никадәр кадерле ул Туган ил! Ә чын ирек-азатлык Туган иленнән башка мөмкин дә түгел!.. Әнә шул турыда сөйли икән шигырь. Шул ук вакытта шушы кыска гына шигырьдә шагыйрьнең бөтен тормыш юлы да чагыла икән әле.

Күңел гаҗәпләнү, шатлык һәм тынгысыз борчу белән дә тула. Кара инде, нинди хикмәтле, нинди матур нәрсә икән ич шигырь дигәннәре. Шигырьне, гомумән китапларны бөтен тәмен-ләззәтен тоеп, төбенә-нигезенә төшенеп укыр өчен әнә никадәр күп нәрсә дә белергә кирәк икән.

...Шигърият серләрен, әдәбиятның гүзәллеген безнең алла шулай оста итеп ачып-ачып күрсәткән укытучым Фәхри абыйга рәхмәтләрем чиксез минем.

Татар теленнән дә яңа укытучы килгән иде ул елны. Нәфикъ Яһудин дигән.

Юантык кына тыгыз гәүдәле, аксыл-саргылт чәчле, аз гына сипкелле дә битле бу абый, дөресен әйткәндә, башта безгә бер дә ошамады. Фәхри абый кебек, өстәл шакый-шакый безне алай орышмый да ул үзе — маңгай астыннан гына сиңа бер шелтәле-авыр караш ташладымы, үзеңнән-үзең тынып каласың. Кызык чыкканда, Фәхри абый дәресендәге кебек, рәхәтләнеп бер көлешә дә алмыйсың — кызыгы да алай чыгып тормый, аннары Нәфикъ абый үзе дә бер дә көләргә яратмый. Дәрестә генә түгел, башка урыннарда, олылар арасында да без аның көлгәнен-елмайганын күргәнебез булмады бугай.

Олылар үзләре дә Нәфикъ абый турында гаҗәпләнебрәк сөйлиләр иде. Сәеррәк кеше, диләр, берәү белән дә артыгын җәелеп сөйләшмәс, әллә ни аралашмас, фатирындагы бүлмәсенә бикләнеп ала да гел укый, гел ниләрдер яза, диләр. Аннары, үзе егет кеше, үзе... кызларны бар дип тә белми, шул китапларына, шул язуларына баштанаяк чумган, диләр.

Нәфикъ абыйның сәерлекләре турында ишеткән сүзләрдән безнең колакларны иң торгызганы да әнә шунысы иде — гел укуы, ниләрдер язуы. Чыннан да, ниләр яза икән?

Ул арада Нәфикъ абый тирәсендәге серле томан куерганнан-куера барды.

Хәтеремдә, әдәбияттан Кәрим Тинчурин иҗатын үтә идек. Нәфикъ абый драматург турында сөйләп бетергәч, уйчан гына, үз алдына гына сөйләнгәндәй, әйтеп куйды:

— Ә бит мин, балалар, Кәрим ага Тинчуринның үзен күреп беләм. Гаҗәп кеше ул. Үзе шундый гади, ягымлы, кешегә бик ярдәмчел...

Карачы... Дөресен сөйли микән ул? Әллә, юкса, куык кына очыртамы? Бары тик рәсемнәрдән генә күрергә мөмкин булган, шундый матур пьесалар, китаплар язган кешене — язучы кадәр язучыны күреп белгән абый... кинәт, менә безнең каршыбызда басып тора. Мөмкин хәлме бу? Язучы кадәр язучы ул бик акыллы, бик тирән хисле кешеләр белән генә, әйтик, исемнәре газеталарда шаулаган галим, очучы, алдынгы стахановчы ишеләр белән генә очрашып сөйләшә түгел микән?

Нитә, бәлки дөрестер дә? Безнең Нәфикъ абый да нирәк бит... Гел укый, гел яза. Тикмәгә генә түгелдер ул.

Чыннан да, тикмәгә генә түгел икән.

Бервакыт шулай китапханәдә «Совет әдәбияты» журналының яңа санын актарып утыруым иде. Китапханәче Һаҗәр апа бер иптәш кызына пышын-пышын ниләрдер сөйли, ул арада тыелып кына көлешеп тә алалар иде. Пышылдашуларында Нәфикъ абый исеме дә ишетелеп китте дә, мин сагаебрак калдым. Нәрсә сөйлиләр аның турында? Маңгайлары маңгайга терәлгән кызларның елмаюлы иреннәре гел кыймылдый, ә сүзләрен ишетерлек түгел иде.

Менә Һаҗәр апаның түгәрәк көләч йөзе җитдиләнеп калды. Ахирәтләр беразга тын гына утырдылар.

— Беләсеңме, нәрсә,— диде Һаҗәр апа хәзер инде алай пышылдапнитеп тормастан,— иптәш Яһудин язучы икән бит ул. Әллә ничә хикәясе басылып чыккан. Хәзер роман яза икән...

Нәрсә ди ул? Язучы икән, роман яза икән диме? Колакларым дөрес ишетә микән бу сүзләрне?

Ышанасы килми иде моңа. Чөнки, беренчедән, никадәр тырышсам да, мин «Нәфикъ Яһудин» дип имза куелган бер хикәя дә укуымны хәтерли алмадым. Икенчедән, ни бит... Бер дә язучыга охшамаган Нәфикъ абый. Язучы ул алай гади генә кеше түгелдер. Барыннан да бигрәк, күзләре... Күзләре бик үткендер, сине үтәдән-үтә күрә, әнә, Фәхри абыйныкыннан да болайрак ут чәчеп торадыр ул язучының күзләре... Ә Нәфикъ абыйның күзләре исә... гел арган-талчыккан төслерәк карыйлар.

Лəкин Һаҗəр апа ялганлап кына сөйлəмəгəн икəн. Тиздəн «Совет əдəбияты» журналында чыккан бер мəкалəдə Нəфикъ абый турында: «бик өметле яшь язучы» дигəн сүзлəрне укыдым. (Соңрак, хикəялəрен дə очраттым.)

Əнə ничек икəн! Нəфикъ абый əле чын-чын язучы ук булып җитмəгəн, əмма киләчəктə булачак икəн. Əнə, романын язып бетергəч булачактыр инде ул чын язучы, зур язучы.

...Минем өчен хəзер Нəфикъ абый ниндидер бер могҗиза кошы сыманрак затка əверелде. Менə-менə романын язып бетерер дə бөтенлəй үзгəрер ул... Күзлəре ут чəчəр, йөзе кояштай балкыр, гəүдəгə дə мəһабəт-дəү булып үсеп китəр... Хəзергə əле, əнə, романын язып бетермəгəнгə күрə генə, болай гади бер кеше кыяфəтендə йөридер кебек иде.

Дəреслəрендə Нəфикъ абыйның һəр сүзен йотып кына барам, урамда, китапханəдə ул очраса, һəр хəрəкəтен, һəр сүзен күңелгə сеңдерергə тырышам — аның һəр гамəлендə, һəр сүзендə мин хəзергə аңлап кына җиткезə алмаган тирəн бер мəгънə ятадыр кебек иде.

Кичлəрен кино-мазардан кайткан вакытта Нəфикъ абый фатиры янында тукталып кала идем. Əнə, тəрəзəсендə ут яна. Яза Нəфикъ абый, роман яза. Их, романын ничек-ничек язганын бер генə күрсəн икəн!.. Лəкин күренми, тəрəзəгə пəрдə корылган.

Яз, Нəфикъ абый, тизрəк язып бетер романыңны. Язып бетер дə бөтенлəй үзгəреп, безнең каршыга кояштай балкып килеп чык!..

Əнə шулай могҗиза көтеп йөргəндə, Нəфикъ абый бик гадəти генə бер эш кылып куйды — язга таба, тотты да, китапханəче Һаҗəр апага өйлəнде. Бик гади генə итеп, шуннан элек кенə Закир абый белəн Сəрвəр апаныкы кебек итеп, туй үткəрделəр. Хəзер инде еш кына Нəфикъ абый да, башка өлкəнрəк укытучылар кебек, кулына кара сумка асып кибеткə бара, бер көнне колхоз мастерскоеннан, атка төяп, зур гына өстəл, ничəдер урындык алып кайтты...

Нəрсə соң əле бу? Бу эше белəн халык арасында үзе турында йөргəн: «Кызларны бар дип тə белми»,— дигəн сүзлəрне челпəрəмə китердə китерүен Нəфикъ абый, лəкин... Язучы кеше дə, бүтəннəр кебек, өйлəнə, язучы кеше дə, бүтəннəр кебек, азык-төлек, өстəл-урындык ишелəр белəн мəшəкатьлəнеп-нитеп йөри микəнни ул? Болай йөрсə, романын кайчан язып бетерер соң?

Минем эчкə чын-чынлап борчу төште.

Шушы борчу мине караңгы бер кичтə тагын Нəфикъ абыйлар фатиры каршына китереп бастырды.

Тəрəзəдə ут яна иде.

Бик тə күңелле булып китте. Димəк, яза Нəфикъ абый. Өйлəнүенə карамастан, сумка асып, кибеткə йөрүенə, өстəл-урындыклар белəн мəш килүенə карамастан, яза!..

Җиңел-җиңел атлап кайтып барганда, кинəт тукталып калдым.

Карачы, ничек соң əле бу?.. Анысы, дөрес, романын язып бетергəч, бəлки, чыннан да, кояштай балкыр Нəфикъ абыйның йөзе... Лəкин хəзергə əле аның күзлəре арган-талчыккан төсле карый, сумка асып кибеткə дə йөри, ə үзе яза. Киләчəктə чын-чын зур язучы булыр өчен яза. Шулай булгач... Ой, хəтта уйлавы да куркыныч. Шулай да... Мин дə язып карасам, нишлəр икəн? Миннəн дə... Монысын уйлавы тагы да куркынычрак... Миннəн дə язучы чыкмас микəн?..

Караңгы иде, болытлы иде бу төн. Күк йөзендə ае да, болытлары да күренми иде. Лəкин, каядыр болытлар артында, берəр йолдыз атылмады микəн ул төнне? Юкса, мондый хəтəр, бик хəтəр очкын кинəт кенə кайдан килеп төшсен икəн минем күңелгə?

Төште очкын күңелгə...

Бик тә инде тынгысыз очкын иде бу.

Язлар житеп, юллар бераз кипшерүгә, без малайлар, жыйнаулашып, авылдан өч-дүрт чакрымдагы Каенсар урманчыгына барырга бик ярата идек. Барабыз да тәмле каен суы эчәбез, нәни йомыркалар белән тулы кош ояларын карыйбыз, бик тә хуш исле миләүшә чәчәкләре жыябыз.

Каенсарга быел да бардык. Башта барысы да гадәттәгечә, үткән еллардагы кебек иде. Ләкин юк икән, үзгәргән икән быел урман. Каеннар зифа билләренә ак алъяпкычлар бәйләгәннәр быел, алъяпкычларын шундый да чиста итеп, пакь итеп юганнар... Узган ел бу усак яфракчыклары яшел, бары ямь-яшел генә иде. Ә быел... Әнә, аз гына жил исеп китте дә, бөдрә усак ябалдашы күгелҗем, аксыл һәм көмеш төсле яфраклар белән чуарланды. Кара инде, күгелҗем яфраклар, аксыл яфраклар, көмеш төсле яфраклар да була икән ич... Моңарчы бары хуш исе белән генә үзенә җәлеп итә иде әле безне миләүшә. Исе генә түгел, төсе, буй-сыны да никадәр нәфис, нинди гүзәл икән бу чәчәкнең. Нәпнәни бер тәж яфракчыгында гына да никадәр төс, никадәр бизәк. Челтәрле-телле очкайлары шәмәхә-зәңгәр, аннары куксел зәңгәр, аннары аксыл зәңгәр, иң төптә аксыл-саргылт... сап-сары тәртекләре, кып-кызыл җепселләре дә бар һәм бу төсләр барысы да бер нәни таҗчыкка шундый да нәфис бизәкләр булып сыеп беткәннәр... Урманда кошлар сайрый һәм урман шуңа күрә генә матур яңгырап тора кебек иде моңарчы. Юк икән, урманда кошлар гына сайрамый, урманда һәр агач, яңа шыткан һәр үлән, йокыларыннан уянган һәр бөҗәк җырлый, көйли икән.

Болар барысы да күңелне җилкетә, гел елмаясы һәм... нигәдер җылыйсы да килә иде.

Миндәге бу үзгәрешне малайлар да сизенделәр булса кирәк.

— Малайлар, Чапай... юк ла, Рапай исергән... каен суы эчеп. Ничек сөйрәп кайтасы булыр,— ди Мөхәммәтхан, гадәтенчә чын хәсрәткә баткандай чырай белән.

— Минем әле бүген каен суы эчкәнем дә юк,— дим мин, турсаеп.

Дөрестән дә, аккаенның пакь алъяпкычын аз гына ертасым, аз гына да пәке очы тидерәсем килми иде быел.

Малайларның сәерсенүләреннән уңайсызланып, болынга, су буйларына ялгызым гына чыгып китә башладым.

Хәтердә... Менә мин керфекләрен яңа ачкан чәчәкләргә, салкынчасусыл үләннәргә һәм рәхәт хуш исләргә баштанаяк күмелеп-чумып, болында ятам. Чикерткәләре, күбәләкләре, тәти кондызлары белән зыңлап, кыштырдап, пышылдап ниләрдер сөйли миңа болын. Ниләр сөйли? Мин моны сүзләр белән һичничек аңлатып бирә алмыйм. Ләкин нидер сөйли болын.

Бәлки, бер дә билгесез-ерак нәрсәләр турында түгел, менә болар турындадыр...

Ямаулы бишмәтен иң җылы көннәрдә дә өстеннән салмыйча гел ачулы-усал йөргән сабакташыбыз Хөсәен кичә мәктәпкә өр-яңа бишмәт киеп килде. Үзе чәч төпләренә кадәр кызарган, үзенең елмаюлы иреннәре дерелдәп-дерелдәп куя... Аның әнисе Миңлегөл апа, күп бала табып үстергәне өчен, авылда беренче булып дәүләт пособиесе алды. Зурлар әйтмешли, аның әнисе үзе генә белә торган туп-тулы бала-чагалы бу кечкенә өенең зур куанычын бөтен авыл күңелле итеп сөйләде. Иң элек, ике-өченә бер сәләмә бишмәтле балалар барысы да кием-салымлы булган. Ул көнне өстәлдә табагы белән хәлвә өзелмәгән. Ә кичен Миңлегөл апа авыл Советына килгән. Советка мең-мең рәхмәтләр укыган ул, аннары стенадагы зур рәсемгә карап:

— Яшә, иптәш Сталин! Мең яшә! — дигән дә күз яшьләренә тыгылып, бүлмәдән йөгереп чыгып киткән.

Күптән түгел йөгерү, сикерү, граната ыргыту буенча БГТО значогына нормалар тапшырдык. Йөгерүдән, сикерүдән алай сынатмадым, әмма

граната ыргытуда... Дүрт мәртәбә ыргытып карасам да, нормага житәргә тагын ике-өч метр калды.

Минем сулагайлыктан Фәрит рәхәтләнеп көлде.

Әй, гарьлекләре соң!.. Минем инде ПВХО һәм БГСО значокларым бар, монысын да эләктерсәм, өчәү булачак, аннан да бигрәк, БГТОлы малайларны «Яшь Ворошиловча атучы» значогына да норма тапшырырга өйрәтә башлыйлар, анысы инде иң кызыгы булачак иде. Чын винтовкадан төп-төз атарга өйрәнәсең бит!

Мөхәммәтханнарга, Фәритләргә жайлы аларга. Симет суы буенда таш ыргытып уйнап, куллары тәмам остарып беткән. Яр буеннан юка таш сайлап алалар да, «ничә хатыным булыр икән» диеп, су йөзлегенә ыргытып җибәрәләр. Таш су өстеннән сикерә-сикерә оча, ничә мәртәбә сикерсә, янәсе, шунын кадәр хатынын булачак... Безнең Кышкарда исә ыргыткан ташың сикереп-сикереп очардай андый зур су юк иде шул. Мина да монда юка ташларны күбрәк табарга, «булачак хатыннарны» күбрәк санарга кирәк булган. Кем-кем, әмма Фәрит шул киерелгән бүксәсенә БГТО белән «Яшь Ворошиловча атучы» значоклары тагып та, синдә андыйлар булмаса... егыл да үл инде...

Биектә-биектә ак болытлар агыла. Болытларны кыю ертып-ертып карлыгачлар оча.

Шул карлыгачтай канатларын булса икән дә, ерак-еракларга очып китсәң икән хәзер. Оча-оча гына барып житсәң икән... Мәскәүнең үзенә кадәр үк.

Мәскәү! Матур хыяллар, якты өметләр башкаласы! Синдә Кремль, Кызыл мәйдан... Синдә Зур театр, Третьяков галереясы, музейлар... Синдә иң зур галимнәр, язучылар, сәнгать осталары... Шуларның барысын, барысын күреп, ишетеп, капшап йөрисе-йөрисе иде дә... Барып кунасы иде Кремль тәрәзәсенә. Бөек юлбашчы үзе эшләп утыра торган бүлмәнең тәрәзәсенә үк кунасы иде. Кош булып сайрап кына сөйләп бирәсе иде аңа Минлегөл апаның шатлыгы, рәхмәте турында да... бездәге әле күнелне әрнеткән нәрсәләр турында да... Аннары, әйтәсе иде аңа: сүзем — сүз, иптәш Сталин, мин барыбер БГТО значогына да, «Яшь Ворошиловча атучы» значогына да нормалар тапшырачакмын, алай-болай фашистларгамы, самурайларгамы каршы җибәрергә көрәшчеләр кирәк булса, мине дә онытa күрмә әле, диясе иде. Юкса, әнә, Испаниядәге сугышка да тәки барып булмыйча калды...

...Үсмер чакның татлы һәм тынгысыз, борчулы һәм ашкынулы уй-хыяллары! Иге дә, чиге дә юк аларның. Әмма очына чыгасы килә. Очына чыгасы һәм... язасы килә болар турында.

Язасы килә... Ә болай, гел яза да идем инде үзе. Көндәлек язам, мәктәп стена газетасына мәкаләләр язам, шигырьләр чыгарам. Мәктәптә төрле-төрле түгәрәкләр эшли башлавы турындагы бер хәбәрем «Яшь ленинчы» газетасында да басылып чыкты. Аннары тагын, тагын хәбәрләрем басылды.

Газетада чын басма хәрефләр белән үз фамилиянне күрү бик тә инде күңелле иде, ләкин... Матур итеп, чын язучыларча итеп, чын әдәби әсәрләр язасы килә иде шул минем.

Җәйгә чыгуга Фәритләр, Мөхәммәтханнар, Мәгъсүмнәр билләренә зурлар кебек билбаулар буып, аякларына шыгырдап торган чабаталар киеп алдылар да колхозда атлы эшләргә йөри башладылар. Миңа исә, укытучы малаена, андый эшләр кушмадылар. Мин җәяүләп кенә чүп утарга йөрим. Җитмәсә, җыен чәрелдек кызлар, карт әбиләр белән... Гарьлеге никадәр!

Мин, моңа протест йөзеннән, басуга барганда да, кайтканда да әбиләргә, кызларга иярмим. Үз эш-мәшгулем минем: юл буе таш ыргы-

там, балчык ыргытам. Тегеләр әбәткә туктаганда да, су коеныргa төшсәм дә эшем гел шул. Кулны күнектерәсем, граната ыргытуда норма тапшырасым бар бит.

Күңелне тагын бер нәрсә бик борчый. Фәрит рус теленнән күзге сынауга калды да, миңа отряд советында аңа булышуны йөкләделәр. Әмма ничә мәртәбә әйтеп карасам да, малай кулын гына селти. «Җәй озын, өлгерермен әле»,— ди. Кайвакыт: «Әй, эчемне пошырып йөрмәле»,— дип тә җибәрә.

Һәр елдагыча, сабан туйлары алдыннан, физкультура укытучыбыз Хафиз абый малайларны мәктәпкә җыйды.

Без бу көнне һәрвакыт түземсезләнеп көтеп ала идек. Үзенә күрә, кече сабан туе кебегрәк, шаулап-гөрләп тора мәктәп ишек алды ул көнне. Йөгерү, сикерү, баганага менү, пластунча шуышу, турникта уйнау буенча ярышлар уза. Аннары җыйнаулашып Симет суы буена төшеп китәбез — йөзүдән ярышырга.

Быел мин бу көнне аеруча зарыгып көттем. Ярыштагы яхшы нәтиҗәләр БГТО значогына нормалар булып та хисапланачак, ә минем граната ыргытудан ярышасым бик килә иде.

Тырышлыклар бушка китмәгән икән. Әйбәт ыргыттым бу юлы гранатаны!

(Алгарак китеп, шуны да әйтми түзә алмыйм. Соңрак фронтта, әй, бик кирәк булды бу граната ыргытырга өйрәнеп йөрүләр. Бервакыт, нәкъ шуның аркасында гына да исән калдым бугай. Монысы турында — киләчәктәге бер истәлек хикәямдә.)

Шатлыгымның иге-чиге юк иде. Фәрит тә бар ярышларда да алдынгылардан булды. Ләкин малайның бер дә куанганы сизелмәде. Әллә көзге сынауга калуына борчыла микән?

— Фәрит-малай, тырышсаң була икән бит. Мин дә шәп ыргытам хәзер гранатаны. Сине куып җиттем дисәң дә була.

— Һе... Зерә дә уңган малай инде син. Галәмәт!

— Фәрит-малай, әйдәме, син дә көзге сынауга хәзерләнә башла. Әйтәм ич, тырышсаң була икән. Әйдәме, иртәгә үк башла. Мин дә килермен.

Фәрит теш арасыннан гына теселдәтеп төкереп куйды.

— Килеп йөрмә лутчы,— диде.

— Нигә инде?

— Шулай. Эшкә барасым бар минем.

— И малай... Күчми калсаң, нишләрсең?

— Калсын... Мин быел бәлки бөтенләй дә укымам.

— Нигә алай инде, Фәрит?

— Нигә-нигә... Әбигә төймә, апага хөрмә, балдызга сөрмә, ә миңа... төрмә.

— Төрмә-ә! Шундый да такмак буладыры!

— Була икән шул менә,— диде Фәрит кинәт бик җитдиләнеп һәм бөтенләй зурларча тирән көрсенеп куйды.— Син нәрсә беләсең со-оң!— диде дә кулын селтәп читкә борылды.

Берәзгә сүзсез генә утырдык. Икебезнең дә бик яман борыннар сызгыра башлады.

— Сиңа нәрсә? Әтиең укытучы... Укудан башка ни гамең бар? — диде бераздан Фәрит һаман да читкә караган килеш.— Ә минем әти юк шул инде... Өченче ел менә. Әни әйтә, төп таянычым син, ди. Апа бар да бит... Аңа нәрсә? Кияүгә чыкты китте... Тиздән мена ычкынмагае да.

Мин аның әле ни арада шулай зураеп киткән кытыршы-кучкыл кулларына текәлгән килеш тынып калдым.

Аның шушы сүзләре берничә көн буе колак төбемдә әледән-әле яңгырап китә кебек иде.

Һәм менә... Мондый уй-ният башыма ничек килеп төшкәнен һич әйтә алмыйм, мин Фәрит турында әкият язарга булдым.

Хәер, Фәрит турында гына да түгел. Бәлки әле, ничәмә айлар буе күңелгә һич тынгылык бирми азаплаган бар уйларыма да җавап булыр бу.

Язарга, язарга!.. Ятсам-торсам да, кая гына барсам да хәзер уйларымда бары шул гына. Басуда чүп утаганда кызларның чыр-чуы да колагыма керми хәзер, кулларым билчәннәрнең, шайтан таягының әналәрен бөтенләй тоймый.

Башымда инде әкиятнең бөтен эчтәлеге әзер диярлек. Исемен дә таптым — «Ялкау сандугач».

Өйалдындагы иске сандык — минем хәзер эш өстәлем. Басуда безнең түземлелек әллә ни озакка җитми, кояш төшлектән авышуга, авыл юлына таба карый башлыйбыз. Кайтып ашап-эчүгә үземнең «эш өстәлемә» ашыгам.

Язам... Язам да бозам. Күңелдәге шундый да матур сүзләр кәгазь битенә төшә башлагач, нигә болай төссезләнеп-ямьсезләнеп калалар соң әле? Мин тагын язам, тагын бозам... Әнә шулай гел бозып яза торгач, матур гына җөмләләр дә килеп чыга. Әй, күңелле дә була соң андый чакларда!.. Әле матур чыккан бер җөмләнең шатлыгы никадәр, әкиятне бөтенләй язып бетергәч, ничек кенә булмас бу шатлык!

Язып кына бетерим!.. Фәрит тә аңлар аннары. Минем әкияттәге сандугач баласы да, ялкауланып, әнисенең, укытучыларының сүзләрен колагына элмичә, очарга өйрәнми йөри-йөри дә бер көнне кызык була. Ана усал песи һөҗүм итә. Ярый әле, өлкән сандугачлар коткарып калалар үзен.

Язып бетергәч, Нәфикъ абыйга да күрсәтәсе булыр моны. Барып чыкканмы минем әкиятем, кай җирләре килешеп җитмәгән — шулар турында сөйләшәсе булыр аның белән.

Минем инде Нәфикъ абый белән күптәннән бер сөйләшәсем килә, аннан, роман язучы кешедән, язуның серләре турында сорашасым, күңелне борчыган нәрсәләрне дә аңа сөйләп бирәсем, киңәшләр сорыйсым бик килә иде. Ләкин моңа кыюлыгым җитми иде. Инде менә, үзем язган әкият тотып килгәч, шулай җан бушатып сөйләшергә дә юл ачылыр.

Ләкин андый сөйләшү булмый калды...

Әкиятемне язып бетереп, инде моны берәр редакциягә җибәрим микән, юк микән, дип икеләнебрәк йөргән көннәрем иде.

Әти велосипед сатып алган иде ул җәйне. Кибеткә андый нәрсәләр бик сирәк кайта иде әле, кемнәндер кулдан алган. Үзе велосипедта йөри дә белми, машинасын мөгезеннән генә сөйрәгән килеш, күзлекләренә, кечкенә сары мыегына кадәр балкып кайтып керде.

Ләкин әтинең шатлыгы озакка бармады. Йөрергә өйрәнеп маташканда, егылган. Шактый әйбәт барып төшкән, ахры, уң кулын күтәрә дә алмый, сулыш алулары бик кыен, ди.

Район врачлары ни әйтергә дә белмәгәннәр, Казанга барып күренергә кушканнар. Әти велосипедын хуҗасына кире бирде дә шәһәргә җыена башлады. Сулышлары кысып, кулларына бер нәрсә дә күтәрә алмаганга микән, иптәшкә үзе белән мине дә алырга булды.

Әни бик кайгыра, апаның да күзләрендә яшь, ә минем шатлыклар эчкә сыймый. Әкиятемне дә үзем белән алыйм да «Яшь ленинчы» яки «Пионер каләме» редакциясе кешеләренә күрсәтеп карыйм әле.

Казанга инде икенче килүем иде минем. Шунлыктан, шәһәрнең биекбиек зур йортлары, бихисап машиналары, борынны үзеннән-үзе җыерта торган әчкелтем-тыгыз һавасы бу юлы әллә ни шаккатырмады. Хәтта чат саен сатыла торган түгәрәк-түгәрәк морожныйлары да ул кадәр

ук авыз суларын китермәде дияргә була... Барлык редакцияләрнең дә Матбугат йорты дигән җирдә урнашуларын үзем дә язгалап торган адреслар буенча белә идем. Эти, мине дә җитәкләп, үзенең больницасын эзләп йөргәндә, күзләрем гел эзләнә иде. Әнә шул Матбугат йорты дигәннәре очрамасмы?..

Ниһаять, эти, бик озак чират торып, врачка күренеп чыкты. Бик шатланып чыккан. Ике кабырган сынган, бөтенләй пустяк, ай тулганчы ук ялганыр, дигәннәр.

Аннары без, өстенә бик зур хәрефләр белән «Пиво» дип язылган бер ишек төбендә тукталып калдык. Ниләр сөйләштек, ничек килештек — хәтеремдә юк — эти шул ишеккә кереп китте, мин Матбугат йортын эзләп киттем.

Озак эзләдемме, тиз таптыммы — анысын да хәтерләмим... Менә мин шушы изге йортның коридорында йөрим. Ишек саен «Фәлән редакция» дип, «фәлән бүлек», «редактор», «җаваплы секретарь» дип язып куелган. Әгәр кыюлыгым житсә, ул ишекләрнең һәммәсен ачып-ачып карап йөрер идем. Нинди кешеләр икән алар, газета кадәр газета чыгаручылар, матур итеп тә, усал итеп тә, көлкеле итеп тә яза белүчеләр? Хәер, коридор буйлап, кулларына кәгазь тоткан, папка, я портфель күтәргән кешеләр гел үтеп-сүтеп йөри. Тәрәзә төпләренә таянып, икәүләп, өчәүләп сөйләшеп торучылар да шактый. Кем белә, я берәр язучы, я берәр редактор-фәләндер инде алар. Һәркайсыннан да: «Син кем?» дип сорап йөрсәң икән... Авылга кайткач, «мин фәлән язучыны күрдем» дип сөйләргә әмма дә шәп булыр иде.

Йөри торгач, «Пионер каләме» редакциясе» дигән ишек янына да килеп чыктым. Йөрәгем дөп-дөп тибеп куйды. Кара пыялага алтын белән язган кечкенә вывескадан күземне ала алмыйча карап тордым да кире борылдым. Тагын килдем, бу сихри ишек тоткасына үрелергә тагын көчем җитмәде... Шулай йөренгәндә, ул бүлмәдән бер абый бик ашыгып кына чыкты да, ишеген дә ябып тормастан, кызу-кызу китеп барды. Башта коридорның теге як стенасы буена ук басып, бу ачык ишеккә карап тордым, аннары якынрак, якынрак... Менә бусагага ук життем... Орышучы-куучы булмагач, эчкә үк үттем.

Зур, бик зур тәрәзәсен искә алмаганда, гап-гади бүлмә икән. Өч өстәл. Түрдәге өстәл артындагы абый миннән аз гына зуррак ике малай белән сөйләшеп утыра. Ишеккә якын өстәл хуҗасы башын да күтәрмичә яза.

— Ни йомыш, энем? — диде шул абый кинәт язуыннан башын күтәреп.

Бөтен битем, хәтта күзләремә кадәр җылынып китүеннән бик яман кызаруымны сиздем.

— Мин менә... бер әкият язган идем,— дия алдым.

— Алайса, син аны, энә, Алиш абыеңа күрсәтерсең,— диде абый башы белән түр өстәлгә ымлап.— Егетләр белән генә сөйләшеп бетерсен дә...

Шул якка карап каттым да калдым. Алиш абый! Хәреф таный башлавыма аның «Отряд флагы» дигән, «Дулкыннар» дигән, «Ант» дигән китапларын, «Якты күл буе» дигән калын китабын да укыган, матурматур әкиятләре җыр кебек күңелемә сеңеп калган бик яраткан язучының үзе янына ук килеп кергәнмен ич мин! Дөресен әйткәндә, мин бу «Ялкау сандугач»ымны А. Алишка охшарга тырышып яздым да ич инде... Өнем микән бу, әллә төшем микән?

— Утырып тор, энем,— дип, теге абый дәшкәч кенә аңыма килгәндәй булдым, стена буендагы урындыкка барып утырдым.

Ә күзләрем гел Алиш абыйда. Әнә ул, янындагы малайлар белән гап-гади итеп, елмая-елмая сөйләшеп утыра. Шундый итеп елмая... Кара калын кашлары чак кына талпынып куя да ягымлы коңгырт күз-

ләреннән, ап-ак тешләреннән күңелле-якты нурлар сибелә сыман. Нурлар сибелә дә, каршысында утырган малайлар да елмая. Малайлар да елмая һәм... мин дә елмаеп утыруымны сиздем. Гүя Алиш абый минем дә күптәнге танышым, гүя Алиш абый сүз арасында гына миңа таба бер-ике күз ташлавы белән мине дә инде үз итеп өлгергән.

Ни өчен килүемне, кесәмдәге дәфтәремне бөтенләй дә онытгым мин бу минутларда. Бик тә инде күңелле иде, рәхәт иде миңа Алиш абыйга карап утыруларым. Менә аның йөзе җитдиләнде. Калын кашлары бергә кушылдылар диярлек. Ияк очы азрак чокырланып тора икән, бая елмайганда аңысы сизелмәгән иде. Шулай җитдиләнеп, ул салмак кына тавыш белән малайларга нидер сөйли башлады.

Шул чак миндә сәер бер хис уянды. Аңлавымча, Алиш абый каршында утырган ул малайлар Казанныкылар. Сизүемчә, аларның инде биреге беренче генә килүләре түгел. Нинди бәхетлеләр алар, Алиш абыйны гел күреп, аның белән гел сөйләшеп йөрүче малайлар!.. Дөресен генә әйткәндә, ул малайларның әнә шул бәхетеннән көнләшеп утыруым иде минем.

Ниһаять, малайлар урыннарыннан тордылар. Алиш абый да торды, малайлар белән кул бирел күрешге, аларны ишеккә таба озата барды. Малайлар чыгып киткәч, Алиш абый миңа таба борылды.

— Танып бетермимме?.. Кайдан әле син? — диде.

— Мин авылдан килдем. Мәңгәрдән.

— Ә, шулаймы? Исемең ничек әле? — диде Алиш абый һәм бер кулын тидерер-тидермәс җилкәмә таба сузып, өстәле янына алып китте.

Авылыбыз турында, балаларның җәйге яллары ничек үтүе, колхозга ничек булышулары турында сорашып утырды Алиш абый. Аннары ул минем дәфтәрне кулына алды, әкиятнең озынмы-кыскамы икәнлеген чамалады булса кирәк, дәфтәр битләрен тиз-тиз актарып карады, укый башлады... Шуннан соң Алиш абыйның ни әйткәннәрен минем гомергә онытасым юк.

Менә ул башын күтәрде дә сизелер-сизелмәс кенә елмайды.

— Ялкау сандугач дисең, ә?.. Игътибар иткәнең бар микән, халык әкиятләрендә, бигрәк тә халык җырларында сандугач гел уңай образ итеп, үзенә бер сафлык һәм мәхәббәт символы итеп алына. Шулай түгелме?

Мин нәрсәдер мыгырдандым. Юк, игътибар иткәнем юк иде.

— Мин бала чакта ук ишеткән әкиятләремне, җырларны, мәкальләрне бер дәфтәргә яза бара идем. Синең дә юкмы андый дәфтәрең?

Мин башымны тагы да ия төштем. Юк иде минем андый дәфтәрем.

— Ә болай, әйтер фикереҥ әйбәт синең. Чыннан да, ялкау булырга ярамый безгә. Ялкауланыр заман түгел бу,— диде Алиш абый һәм кулындагы карандашына текәлгән килеш, тукталып калды. Калын кашлары тагын бергә кушылды диярлек.

— Юк, ялкауланырга ярамый,— дип кабатлады.

Аннары ул минем кульязмадагы җөмлә кытыршылыклары, уңышсыз чагыштырулар турында сөйләп китте.

— Гомумән, бик нык уйланып, өр-яңадан язып кара әле син әкиятеңне,— диде.— Җиңел генә тумый бит ул әйбәт әйберләр... Менә син малайлар колхозда бик тырышып эшлиләр дисең, БГТОга нормалар тапшырдык дисең, ә укуда ялкауланучылар бар дисең. Нигә алай икән соң? Бу турыда төптәнрәк уйлап карарга кирәктер.

Бу бүлмәдән, гомумән, бу йорттан ничек чыгып киткәнемне аз гына да хәтерләмим. Әмма шунысы бик истә: якты иде, бигрәк тә инде якты, кояшлы көн иде ул.

Аяк атлаулары гаҗәп җиңел иде.

Дөньяга сыймас бу зур шатлыгымның сәбәбен мин соңрак төшендем.

Һәм еллар үткән саен төшенәрәк барам.

Халкыбызның авыз иҗаты җәүһәрләре, авылның үз һавасы кебек, миңа бик тә гади нәрсәләр иде әле аңарчы. Миңа, аларга караганда, китап сүзе кадерлерәк, басма сүз тәэсирлерәк иде.

Алиш абый гади генә итеп мине үз җирлегемә якынайтты. Ай, бәрәкәтле җирлек...

Аннары, бик уйландырды мине бу очрашу.

Күп булса ун минутлык сөйләшүдә әнә никадәр олы гыйбрәт!

Алиш абыйның «Ялкау булырга ярамый безгә ...ярамый!» дигән сүзләрен дә төшенгәннән-төшенә барам.

Кара фашизмның әле үз оясында гына котырынган елларында ук, үзенең «Берлин» дигән, «Ант» дигән хикәяләре белән безгә бу дәһшәтне кисәткән олы йөрәкле язучының бик тә борчылып, сиземләп әйткән сүзләре булгандыр ул.

Шулай булгандыр.

Әйе, ялкауланырга һич ярамый иде.

Шул көзне үк Хасан күле буенда япон самурайлары белән канлы бәрелешләр булды. Аннары, Халхин-гол, аннары фин сугышы, аннары 1941 елның дәһшәтле июнь таңы.

Алиш абыйның шушы сугышта легендар Муса көрәштәше булып, җырлый-җырлый үләчәген, Мөхәммәтхан белән Фәрит кордашларымның да шушы сугышта башларын салачакларын ул вакытта әле кайдан беләсең?..

Аланнар, җиләкле аланнар! Күп әле минем сездә җыячак җиләкләрем!

*Ноябрь. 1969*

Нури Арсланов

# КАЗАГЫСТАН — ТУГАН ЯГЫМ

## Кәрәкәү икмәге[1]

Төрле җирләрнең икмәген
Азмы авыз иткәнем!
Күп еллар, юллар узылган!
Шул нан[2] тәме авызымнан
Гомер буе китмәде:
Киссәң — күбек шикелле ак,
Капсаң — каймак кебек йомшак,
Күңелгә хуш, тәнгә сихәт
Шул Кәрәкәү икмәге.

Сый да хөрмәт Кәрәкәүчә —
Сөтле чәй дә ак икмәк.
Самавырны тынтәргәнче
Нияте — кунак итмәк.
Якты чырай да такта чәй —
Гадәт инде күптәнге,
Ясап җибәрче, җиңгәчәй!
Ашап та туярлык түгел
Шул Кәрәкәү икмәге.

Хуш исле ак икмәк кебек
Ак күңелле кешеләр,
Шушы туфракта көн күреп,
Оя корып яшиләр.
Бер урынына биш кат унсын
Якташларның иккәне!
И кадерле җирем-суым,
Үз иткәнгә тәмледер лә
Шул Кәрәкәү икмәге.

---

[1] Кәрәкәү — Павлодар шәһәренең төрки исеме.
[2] Нан — икмәк.

# Тугайлы Иртеш буйлары

Тугайлы Иртеш буйлары,
Кәрәкәү урамнары!
Таш урамнарда уйнамый
Инде ком бураннары.

Иртеш суы эчеп үстем,
Ни җитә андый суга!
Иртеш суы кебек йомшак
Күңелем, ахры, шуңа.

Иртеш Иделгә дә охшый,
Дулкыннар кагынганда,
Инде Иделгә карармын
Иртешне сагынганда.

Кәрәкәү дигән каланың
Сызылып ата таңнары.
Таң шикелле ачык йөзле
Кәрәкәү татарлары.

Ватаны иркен татарның:
Казанда да Уралда...
Бөтен илдә! Татар, ахры,
Киң күңелле шуңарга.

Читтә дә, төп йортында да
Ямансуламый татар,
Еллар иминчелек булса —
Артык сорамый татар.

Казакъча, русчамы димсең —
Сөйләшеп туймый татар,
Башка телләрне хөрмәтли,
Үзенчә уйлый татар.

Туганнар юк, дигән идем,
Кемгә соң сүз катармын?!
Туган итеп каршылады,
Җик күрмәде татарым.

Урамнардан атлап барам
Мин салмак-сабыр гына.
Ялан аяклы бала чак
Өздереп сагындыра...

Иң беренче мәхәббәттә
Янган чаклар бар иде,
«Гашыйк бала» дип кушамат
Алган чаклар бар иде.

Нәфисәм-бәгырем, чәчләрең
Тарыйсым калган икән —
Күз-керфекләрем талганчы
Карыйсым калган икән...

Иртеш буйларыннан гына
Атлыйсым калган икән,
Шул Кәрәкәүдән Казанга
Кайтмыйсым калган икән...

## Әти белән сөйләшү

Исеп жилләр тараткан безне ил буйлап...
Кайчандыр бер сабый идем йөргән уйнап,
Хәзер инде, ак чәчләрем тарый-тарый,
Йөрим кабер ташларына карый-карый.
Әти — утыз биш яшьлек ир — монда ята.
Мин — алтмышта. Сәер! Ул гел миңа ата.
Ышанмыйм, юк, түгел бу телсезләр иле!
Минә әти күтәрелде, телгә килде,
Торып чыга-чыга иске кабереннән:
— Нихәл, карт! — дип исәнләште, көлеп миннән.
Булган диләр иде шаян табигатьле,
Үзгәрмәгән икән шушы көнгә хәтле!
— Һи, кем белми иде ул чагында безне,
Кызылъярлы [1] скрипкачы Миргазизне!
Саранланса берәү түләп уйнатырга —
Барыбер мәжбүр иде төндә уятырга,
Алып китә иде пар ат белән килеп —
Уенсыз туй бит ул кияүсез кыз кебек...
Ләкин көн дә туйлар булмый, килере аз —
Гаиләне туйдыралмый уйнаган саз...
Шуңа күрә подрядчыда — Миңлебайда
Көндезләрен эшләдек без Меновойда [2].
Бер көнне күп тире элгән сыргавылны [3]
(Жанның шулай әжәл белән уйнавымы?)
Тотып калдым, ычкынганда бер очыннан,
Бавырыма кан савырылды минем шуннан.
Жир алыштыр, дигәч табиб, Иртеш кичеп,
Менә монда — Кәрәкәүгә килдек күчеп.
Шуннан бирле ятам яшел бу кабердә...
Әйбәт булды әле, синең белән бергә
Утырдык без: күрештек тә, сөйләштек тә.
Мин үлгәндә син өч яшьлек бер кечкенә
Сабый идең... Ә хәзер күр — мәһабәт карт!
Синең белән бергә жирдә яшәвем хак:
Синең аша, буыннарга күчә-күчә,
Дәвам итәм хаятымны элеккечә...
Ул елмая: — Син дә минем төслеме,— ди,—
Көләч, шаян, олы жанлы, көчлеме? — ди,—
Кул бирешми саубуллашыйк, салкын кулым...
Хуш, елмаеп-көлеп яшә, бабай-улым!

Сызгыралар жилләр зират кырларында,
Уйнагандай скрипка кылларында:
Ишетәм мин бер дәртле, бер тын-тирбәлүле
Моңлы көйне, әти сызган «Тәфтиләү»не...

---

[1] Кызылъяр — Петропавловск шәһәренең төрки исеме.
[2] Меновой — Меновой двор — тире-яры жыю урыны.
[3] Сыргавыл — озын, нечкә бүрәнә.

Кәрәкәүдән, Иртеш буйларыннан,
Ераклардан килә бу тавыш:
Бер җирдә дә кабат ишетелмәгән
Яңа бер җыр, яңа бер сагыш.

Күз алдыма баса бала чагым:
Карасуга саллар кайталар.
Шул салларны сүтеп, көнлекчеләр,
Көйли-көйли бүрәнә тарталар.

— Раз, ишшо биро-о-м!
Кайда минем Сабира-о-м?!
Кайда минем сабыры-о-м?!
Сабирамны сагына-о-м...
Раз, ишшо биро-о-м!

Ыргакларга эләгеп бүрәнәләр
Яр комында шуа югары...
Саллар ага ерак.
Кешеләрдәй
Ерак аккан саллар юк әле...
Туган илен ташлап, чит җирләргә
«Мал табарга» килгән кешеләр,
Җигелгәннәр әнә бүрәнәгә,
Кара янып, аттай эшлиләр.

— Раз, ишшо биро-о-м!
Кайда минем Сабира-о-м?!
Кайда минем сабыры-о-м?!
Сабирамны сагына-о-м...
Раз, ишшо биро-о-м!

Сабирасы аның кайда икән,
Көтә микән баеп кайтуын?
Белмидер шул салдан — бүрәнәләр,
Тоз күленнән — тозлар тартуын...
Ачы тирдән күлмәк тәнгә ябыша,
Сагышлардан сүрелә ак йөзе,
Эшләп тапкан аның бар байлыгы —
Күлмәгенә чыккан тир тозы...

— Раз, ишшо биро-о-м!
Кайда минем Сабира-о-м?!
Кайда минем сабыры-о-м?!
Сабирамны сагына-о-м...
Раз, ишшо биро-о-м!

# Майра

ПОЭМА

Кәрәкәүдә Майра дигән атаклы кыз, казакъ халкының композиторы, акыны [1] һәм җырчысы революциягә кадәр Кәрәкәү, Семей һәм Омбы [2] өлкәләрендә бик киң танылa. Аның атасы — чала-казакъ, ягъни казакъ белән татар каны аралаш нәселдән була. Оста гармунчы Майра үзе чыгарган җырларны да, казакъ, татар халык көйләрен дә үзе уйнап, үзе җырлый. Бүген дә аның җырлары киң казакъ илендә телдән төшми.

Балдаклары, балдаклары,
Көмештер тырнаклары,
Гармун телләрендә бии
Шул Майра бармаклары.

Артка ташлап матур башын,
Уйнатып толымнарын,
Күргәнем бар шул Майраның
Мин җырлап утырганын.

Күргәнем бар үзе уйнап,
Үзе җырлаганнарын:
Тыңлаучыларның бер көлгән,
Я бер елаганнарын...

Майра — акын, Майра — җырчы,
Майра кайгы тарата.
Татарны да, казакъны да
Авызына карата.

Күп егетләрнең, Майра! дип,
Покысыз таңнары ата...
Үзе чичән [1], үзе сылу
Майра кемне ярата?!

Майрага нәрсә! Мәкан бир
Җырлары, көйләренә.
Таралсын ялкынлы моңнар
Кәрәкәү өйләренә,
Кәрәкәү урамнарына,
Дала, өлкәләренә...
Җыела халык Майрага —
Кымыз дөкәннәренә [2].

Гармун телләренә тиеп,
Бармаклар йөгереп уза,

---

[1] Акын — шагыйрь.
[2] Семипалатинск, Омск шәһәрләренең төрки аталышы.
[3] Чичән — тапкыр телле.
[4] Дөкән — бу урында кымыз сату бинасы.

Майра үзәкләрне өзеп
«Илем-ай» көен суза:

«Кыз баланы хур итеп яратканың-ай,
Мал биргәннең авызына караткаңың-ай,
Сөйгәнемә баралмый бәхетсез калып,
Читлектәге тургайдай алактадым-ай[1],
Илем-ай, илем-ай!

. . . . . . . . . . . . . . . .

Хуш, исән бул, ил-йортым, үскән җирем-ай,
Нар[2] житәкләп җәйләүгә күчкән җирем-ай,
Яратмасын дөньяга миндәй мазлумны,
Бәхетле бул миннән соң үскәннәрем-ай,
Илем-ай, илем-ай...»

Майраның дәрте, халыкның
Моңы ничек кушыла!
— Ни җырласа да килешә,—
Дип куялар,— шушыңа.

Ә Майра сагышка талган
Дымлы күзләргә карап,
Өздерә «Баламишкин»ны,
Гармун телен аралап:

«Калфагым бар, шәлем юк,
Миңа житәр калым[3] юк!
Быел минем сөйгәнем юк,
Инде сөйми хәлем юк».

. . . . . . . . . .

Ирләргә нәрсә! Аларга —
Хозурлап кымыз эчү,
Сөйләшү дөнья хәлләрен,
Аннан калҗынга[4] күчү;
Майра җырларына эреп,
Утыру уйнап-көлеп:
«Итен ашамасалар да,
Шулпасын эчкән кебек...»[5]

Ә Майра җырлый, җыр — аның
Байлыгы, мөмкинлеге:
— Я, кайсыгызга нинди җыр,
Дәртлеме, моңлы көйме?
Үзе «гашыйкларга» таба
Бер шаян караш ташлап,
Өр-яңа чыгарган җырын
Гармунда китә башлап:

«Шул Майра булган җирдә — уен-җыен,
Җыр җырлау Майрага түгел кыен.
Кымызга арак, шәрап куша-куша
Калмады кесәләрдә ялгыз тиен...

[1] Алактау — аптырап каушау, талпыну.
[2] Нар — бер үркәчле дөя.
[3] Калым — кыз өчен бирелә торган мал.
[4] Калжын — юмор, тапкыр сүз.
[5] Қазакъ халык әйтеме.

Майра, Майра,
Кәрәкәүле Майра,
Кызыл телем, сайра,
Сөйгән ярың кайда?»

Чыннан да, тылсымлы Майра,
Сөйгәнең кайда синең?
Син ирек, бәхет, мәхәббәт
Килер, дип көткән идең...

Ашкынып хорафатларга
Каршы ут ачкан сылу,
Җырларың, көйләрең моңы
Җамыннан ташкан сылу,

Азатлык хисе тапса да
Синдә чын яраннарын,
Син азатлыкны, бәхетне
Тик үзең табалмадың...

Үзең юк — моңың янгырый,
Үзең юк — сүзең җырда.
Югалдың кайсы далада,
Адаштың кайсы кырда?!.

Хәзер өр-яңа зур илең!
Син дау күтәргән дөнья —
Искергән гореф-гадәтләр
Калмаган инде монда.

Киң күңелле казакъларның
Дала-үзәннәрендә
Янгырый синең көйләр дә,
Синең үләңләрең[1] дә:

«Майра, Майра,
Кәрәкәүле Майра,
Яшьле күзем, җайна![2]
Кызыл телем, сайра!
Сөйгән ярың кайда?
Майра, Майра!»

1969

---

[1] Үләң — җыр-көй.
[2] Җайнау — ялтырау, ялтыру.

Нурихан Фәттах

# ӘТИЛ СУЫ АКА ТОРУР

ТАРИХИ РОМАН [1]

## Икенче бүлек

### I

Беренче тапкыр бүген күк күкрәде, яшен яшьнәде. Урамнардагы, ишегалларындагы, басулардагы барлык кешеләр, болыннардагы көтүчеләр, урманнардагы агач кисүчеләр, яр буендагы балыкчылар, каекчылар — өлкәннәр, бала-чагалар, тазалар, авырулар — барысы да, барысы да, күк күкрәвен ишетеп, җиргә егылдылар. Көтүдәге атлар, сыер-сарыклар, ашауларыннан туктап калды, этләр, чинап, кешеләргә елыштылар.

Каяндыр көн яктан — Чулманның күкселләнеп яткан иксез-чиксез киңлеге өстеннән, ямь-яшел болыннар, куе урманнар өстеннән башланган яшенле күкрәү, дөбер-шатыр килеп, ачулы мыгырданып, Кызыл Яр катау турысына килеп җитте. Куар оган [2], утлы кылычы белән селтәнеп, биек яр башындагы чыршылыкка сыенган ниндидер албастыны сугып үтерде дә ашыгып төн ягына таба китеп барды. Язгы сулар белән дә агып бетмәгән чир-чорлар, айналар, албастылар, өрәкләр — барысы да Куар оганның бөек чирүеннән куркып, чит җирләргә, чит илләргә юл тоттылар.

Яшенле күкрәү узып китү белән, кешеләр сикерешеп җирдән тордылар, бер-берсен котларга, куанышып биергә, такмакларга тотындылар. Күп тә үтмәде, томалап яңгыр килеп җитте. Яңгыр шактый озак яуды. Ачык җирдә калган кешеләр манма су булдылар. Өйдәгеләр, каралтыкурадагылар исә яңгыр астына үзләре чыгып бастылар. Беренче язгы яңгырның игеннәргә, чирәмнәргә, ут-үләнгә генә түгел, барлык тереклеккә — кешеләргә, терлек-туарга, киекләргә дә ассуы [3] бар иде.

Шулай итеп, Акбүре иленә җәй килде, җылы килде. Янгыр туктагач та кешеләр куанышып өйләренә ашыктылар, учакларын тергезеп

---

[1] Дәвамы. Башы 8 нче санда.
[2] Куар оган — яшен алласы.
[3] Ассу — файда.

жибәрделәр. Чыр-чу килеп урамда балалар чабышып йөрде. Әле анда, әле монда көлгән тавышлар ишетелде. Кичкә таба көнел ачу башланып китте.

Бөтеныру кешеләре онытылып беренче яңгыр туен иткәндә, Күрән би өендә ашыгып юлга җыендылар.

Кешеләргә, бигрәк тә Утташ кам яклыларга күзекмәсен дип, Күрән би Тотышны Чулман аръягындагы Талкысык авылына озатты. Кешеләр, билгеле, сизенми калмадылар. Шулай да, би углының угрылыгын үз күзләре белән күрмәгәч, эчтән тындылар. Күргәннәр-белгәннәр исә май каптылар. Шулай ук Утташ камның да тавышы-өне ишетелмәде. Ул арада Күрән би, артык шауламыйча, шул ук Талкысыкта аркыш[1] җыя башлады. Башта уйлавынча, тавар белән күн якка ул Тотыш угланны җибәрергә булды. Күрән би берьюлы ике куян атарга уйлады: беренчедән, ул яман аты чыгып өлгергән углын усал күзләрдән, алай гына да түгел, үтерелү куркынычыннан саклап калырга; икенчедән, үзенең күптәнге яшерен теләген тормышка ашырырга булды. Углын Талкысыкка озатканда, ата кеше аңа үзенең эчендәге яман чир турында да әйтте. Бар ышанычым синдә, углым, диде. Булдыра алсаң, мина яхшы белекле берәр имче алып кайт, булдыра алмасаң, эч авыртканга белешеп, сорашып им утлары, им сулары алып кайт, диде. Кара аны, акча кызганма — барлык таварыңны биреп булса да, минем теләкне үтәргә тырыш, диде. Атасының теләген үтәргә дип, көзгә исән-аман кайтып житәргә дип, Тотыш ант эчте.

Ерак юлга чыгу алдыннан яшенле яңгыр явып узуны Күрән би изгегә юрады. Карангы төшү белән ул каекларга соңгы кирәк-яракларны төятте дә Талкысыкка Тотыш углан янына чыкты. Ул ана ак юл теләде, тагын үзенең кинәшләрен, теләкләрен кабатлады, аны күкрәгенә кысып, озак кына ычкындырмыйча торды.

— Иртәгә таң ату белән кузгалыгыз, углым,— диде Күрән би, күз яшьләрен сөртеп.— Исән-сау әйләнеп кайтсаң, көзгә башлы-күзле итәрмен. Кайгырма, Тәңкә синеке булыр.

— Атай, күрерсең менә!.. Моннан соң беркайчан да... ышан, атам, миннән дә турылыклы углың булмас! — диде Тотыш, дулкынланып.

— Ышанам, углым,— диде ата кеше.— Күнелем тыныч. Мин сиңа ышанам, углым!

Төн уртасында үз өенә кайтып йокыга яткач та би тиз генә йоклый алмады. Аның күнелен бертуктаусыз нидер борчып, кымыржытып торды. Нишләптер аның эче дә пошкан кебек булды, йокысы да килми сыман тоелды, шул ук мәлдә йокларга да кирәк иде шикелле. Әллә катаудагы җыр тавышлары тынгы бирмәде, әллә эт улаган тавышлар ачуын китерде. Эч пошу, борчылуга бераздан эчтәге чын авыру, сызлану-әрну тойгысы кушылды. Йокыга киттем дигәч тә ул әллә нинди куркыныч төшләр күреп саташты, уяу чагындагы борчулы уйлары исенә төшеп, тагын коты алынды.

Иртән аны ниндидер дөбердәк уятты. Шыбыр тиргә баткан килеш ул сикереп торды, кылычына тотынды, аннары, калтыранып, ишек артындагы дөбердәккә колак сала башлады. Кем булыр бу? Нәрсә кирәк бу авыкта? Кояш әле чыкмаган, әле бик иртә булырга тиеш.

— Кем бар анда? Нәрсә кирәк? — дип кычкырды ул, күпмедер тыңлап, көтеп торганнан соң, ишеккә якынаеп.

— Бу мин, каравылчы Чынташ! — диде тыштагы ир кеше.

— Ни булды? Нигә дөбердәтәсең? — диде би, ишек бигеен ычкындырып.

— Улакчы килде, улакчы! — диде Чынташ.— Ашыгыч битек китергән. Менә.

[1] Аркыш — кәрван.

Би каравылчы кулыннан битекне тартып алды да шартлатып ишеген япты, биген янадан элдерде. Битекне ул ачу белән идәнгә атып ормакчы булды. Каравылчының «ашыгыч» дигән сүзен исенә төшергәч, бу уеннан кире кайтты. Төннек янына килде дә вак-вак пыяла кисәкләре аша үткән таң яктысында ал тамга сугылган, сургычлап ябыштырылган күн тышлы битекне кулында әйләндереп карады. Аннары сургычны ватып, җепне теше белән өзде, аксыл каен тузына төрек иҗекләре белән язылган түбәндәге сүзләрне укыды:

«Атай! Алмыш хан килә. Төшкә монда булыр. Үзән аша күпер салалар. Көче күп. Мин Чулманга чигенәм. Шуннан кайтырмын.

Алай башы Күзәмеш углан».

Күрән бинең чәчләре үрә торды. Куллары, аяклары калтыранды. Суларга аңа тын җитмәде, уйларга уй җитмәде, кыюлык җитмәде. Аның тиз генә өстен-башын киенеп, коралларын алып каядыр чыгасы да килде, хатыннарын, балаларын, ырудашларын булышка чакырып, бөтен катауга, бөтен җир-суына сөрән дә саласы килде. Утлы куздай пешергән битекне кулына алып ул әрле-бирле йөренде, тешләрен шыгырдатты, башындагы чәченә ябышты, ыңгырашып-ыңгырашып алды. Идәнгә егылды да, ике кулын күккә сузып, күз яшьләрен түгеп, ялвара башлады.

— Таңрем! Ата-баба ияләре! Көч бирегез, кыюлык бирегез! Яу килә, яу! — диде.

Яу килә, яу! Алмыш хан килә! Коры җирдән, Чулманның уң ягыннан, урман-сазлар аша, елгалар, чокырлар аша атлы чиру килә!

Булмас ла! Туктале, ялган түгел микән бу? Берәрсенең коткысы түгел микән? Котан өйдә юк, Акбога өйдә юк. Күп ирләр Тотыш белән ерак юлга чыгарга тиеш. Катауда җитәрлек сакчылар да юк. Нинди яу ди әле ул мондый чакта!

Туктале, тукта... нәрсә бу? Шулай итеп, Акбүренең көне төкәндемени? Шулай итеп, Утташ камның каргышлары барып ирешге микәнни?!

О, таңрем! Изге ияләр! Кичерегез... коткарыгыз Акбүрене бу кыраннан, бу талаудан!

## II

Икенче көнне, байракларны җилфердәтеп, каргуларда ургыган кара тетеннәрне тузгытып, катау өстеннән беренче җил — салкынча таң җиле исеп киткәч тә, басу ягында дүрт-биш җайдак күренде. Алар, изге нарат аланыннан килә торган юлдан катау ягына борылдылар да, атларын юрттырып, туп-туры капкага таба юнәлделәр. Болар юл буенда төн кунган кузәтчеләр иде.

— Киләләр, киләләр! — дип кычкырдылар алар койма өстендәге ырудашларына, каядыр артка, урман ягына күрсәтеп.

Койма өстендәге сакчылар кузгалышып куйдылар. Өзек-өзек тавышлар ишетелде, яу якынлашканны белдереп, йөрәкләрне телеп, чыелдык быргылар кычкырды. Койма буенда, ачык җирдә учак ягып төн уздырган ирләр, ашый торган ашларын ташлап, кулларына корал алып, агач баскычлар буенча койма өстенә йөгерделәр. Атлылар атларына атландылар, коралларын барладылар. Койма тышында урның бозылган ярларын төзәтүче, ауган, какшаган баганаларны ныгытучы кешеләр тизрәк эшләрен тәгәлләргә ашыктылар.

Чабып килгән кузәтчеләр урга якынлашу белән, капкачылар күперне төшерделәр, капканы ачтылар да тыштагы барлык кешеләрне эчкә керттеләр. Капка ябылды, күпер янадан күтәрелде, болганчык су өстенә шыбырдап чүп-чар, балчык коелды.

Каравыл өендә йокымсырап утырган Күрән би, тояк тавышлары ишетеп, сискәнеп урыныннан торды.

— Килделәрмени?! — диде ул кисәк кенә, куркып.
— Киләләр! — диде шунда кемдер, басу ягына күрсәтеп.

Шул чакны чыннан да изге нарат аланы ягыннан үр менеп килүче атлылар күренде. Иң элек аларның иртәнге кояш яктысында ялт-йолт килгән сөнге очлары, күк төстәге озынча байраклары калкып чыкты. Аннары әкренләп-әкренләп кораллы ирләрнең тимер алпаклары, ат башлары, калканнар күренә башлады. Үрдән менгән җайдаклар уңга борылдылар, киң юлга төштеләр.

Баштанаяк коралланган, көр-таза атларда нык утырган ул ят кешеләр, ягы[1] кешеләр ашыкмыйча гына, иркен, тыныч кына киләләр иде. Алар күп иде, бик күп иде. Кечерәк төркем-төркем булып, җир астыннан чыккан сыман, сырт итәгеннән менә тордылар, тигез җиргә җәелә тордылар. Бераздан алар богдай чәчелгән җир өстен бөтенләй каплап алдылар. Шул ук мәлдә, тыелгысыз бер көч булып, тигез җиргә җәелеп аккан язгы ташкын булып, катауга таба басып килделәр. Тигез, ачык ялан күз алдында атлар, кешеләр белән тулды. Тигез, ачык, күркәм яланда — катаудагы меңләгән күзләр алдында,— әйтерсең, тиз арада кара урман калкып чыкты, әйтерсең, берничек тә үтеп булмастай тауташ калкып чыкты!

Акбүреләр, койма өстендәге калку урыннардан, ук атар өчен уелган уемнардан, каргу, сырган башларыннан, өй түбәләреннән, багана башларыннан аларның шулай бөтен җирне иңләп, ябырылып килүләрен тын да алмый күзәтеп тордылар. Меңләгән тимер, җиз, көмеш кораллларның, киемнәрнең кояшта ялт-йолт килүеннән кешеләрнең күзләре чагылды; тимер чыңлаган, тояклар дөпелдәгән, ат кешнәгән тавышлардан колаклар тонды. Бертуктаусыз кыймылдаган, ашкынган тыелгысыз авырлыкларның шау-шуына бөтен җирнең өсте дер селкенеп торды.

Беркайчан да бу тикле көч, бу тикле яу күрмәгән акбүреләр куркуларыннан өнсез калдылар. Озакламый менә шул санаусыз ягы белән очрашырга тиеш булган батыр ирләрнең маңгайларына салкын тирләр бәреп чыкты, аркаларыннан табан очларына куркыныч кымырҗык йөгерде.

Байракларын югары күтәреп, иң алдан килгән ирләр төркеме, катауга бер ук[2] чамасы килеп җитмичә, сөрелмәгән, чәчелмәгән тигез җирдә туктап калды. Арттан килүчеләр дә, алдагыларга якынлашып, шулай ук туктый башладылар. Акбүре кешеләренә аермачык булып аларның йөзләре, киемнәре күренде; аларның янау, көлү сүзләре ишетелде.

Юлның ике ягына да тезелгән ир-атлар кинәт кыймылдап куйдылар, як-якка тайпылгандай иттеләр. Юлда, тар аралыкта яхшы тимер күккә атланган бер кеше күренде. Бу кеше йөзләгән, меңләгән ир-атлар арасында таудай калкып, ерактан ук күзгә ташланып тора иде. Ул бик таза, көчле кеше күренә. Башындагы алпагы да, күбәсе дә, калканы да аның көмештән, алтыннан ясалган. Озын муенлы, биек, таза атының йөгәне, ияре, өзәңгеләре шулай ук алтын-көмеш белән бизәлгән. Күбә өстеннән ул ал төстәге кытат[3] бөркәнчек ябынган. Кара сакал-мыегы кыска итеп, түгәрәкләп киселгән. Болай да киң, түгәрәк бите шунлыктан тагын да түгәрәгрәк булып, табактай зур булып күренә иде.

Эре сөякле, бай киемле бу ир-ат Алмыш хан иде.

Ул, атын әкрен генә атлатып, бераз юл буйлап килде дә байраклы төркемнән алдарак туктап калды. Ул арада аның артында, юлда албалап[4] берничә ат җигелгән арба күренде. Арбаны ачык җиргә туктатты-

[1] Ягы — дошман.
[2] Бер ук — атылган бер ук ераклыгы.
[3] Кытат — кытай ефәге.
[4] Албалап — атларны бер-бер артлы тезеп җигү.

лар да берничә кеше ашыгып аннан төргәкләр, баулар, казыклар ала башладылар. Тиз арада хан чатыры — җаваҗ корылды. Җаваҗның акбүреләргә караган ягы ачык калдырылды.

Менә хан атыннан төште, катау ягына карангалап, җаваҗга керде, түргә[1] утырды. Ханның якыннары шулай ук атларыннан төштеләр, җаваҗ тирәсенә җыелдылар.

Тук көрән атка атланган бер яшь ир байракчылар төркеменнән аерылды да катауга таба чабып китте. Атта чабып барган уңайга ул җәясенә ук утыртты, «һай!» дип бер кычкырды да акбүреләр ягына атып җибәрде. Төз атылган ук Басу капка янындагы каравыл өенең ишек башына килеп кадалды. Сакчылардан берсе сикереп укны тартып алды, алды да йөгереп аны Күрән бигә илтеп бирде. Укка каен тузы бәйләнгән, тузга шундый сүзләр язылган иде:

«Мин, Болгар йортның башы Алмыш хан, синең җиреңә килеп урда кордым. Атам Шелке үлгәч, син — минем колым Күрәм би — өч ел миңа калан түләмәдең. Шуны алырга килдем. Өч көндә бирмәсәң, катавыңны җир итәм, ыруыңны юк итәм. Ил белән бирәсеңме, яу беләнме?»

## III

Акбүре ыруында барлыгы ун мең өй санала иде. Болгар ханы Шелкегә Күрән би ел саен өй башыннан берәр кеш түләп килде. Берәр кештән бер елга ун мең кеш, өч елга — утыз мең кеш. Күрән би, Алмыш ханга калан түләргә туры килсә дә, өч елга түгел, никтер бер генә елга түләргә туры килер дип уйлаштыра иде. Өч елга! Унган, беткән, суга аккан өч ел өчен дә калан түләргә! Бу — күрәләтә талау! Талау булмыйча... таларга килмичә, ник килгән ул монда?!

Утыз мең кеш! Каян алырга утыз мең кешне? Булган барлык байлыгыңны чыгарып салыргамы, әллә соң булган барлык көчең белән каршы торыргамы? Катауны алар тиз генә ала алмаячаклар. Тиздән Котан белән Акбога кайтып җитәргә тиеш. Авыллардан кораллы алайлар килә тора. Атарга ук җитәрлек, ашарга азык җитәрлек. Җиңелергә туры килә икән, соңгы чиктә Яр-капка аша Чулман аръягына таярга була.

Нинди күп алар шулай да! Шул тикле ерак җирдән юллар ярып, күперләр салып килгән бу чирүнең, күрәсең, балтачылары да күптер. Урлар аша күпер салып, катауның капкасын җимереп, яндырып керү аларга берни тормас. Шулай булгач... катавың белән, ыруың белән бергә кырылуга караганда, сораганын биреп котылу яхшырак булмасмы?

Соңгы көннәрдә бик нык йончыган, тиешенчә йокламау аркасында йөзе агарынып калган би аксакалларга, кораллы ирләргә күтәрелеп карады.

— Нишлибез? — диде ул, карлыккан тавыш белән.

Башкалар да үзләренә шул ук сорауны бирделәр. Тик беркем дә турысын гына ярып сала алмады. Бармакның кайсын тешләсәң дә авырта, ничек кенә боргалансаң да, башыңа таякның юан башы төшәчәк иде. Тынлык шактый озакка сузылды. Беренче булып Утташ кам авыз ачты.

— Туганнар, ырудашлар! — диде ул, кычкырып.— Мин сезгә әйтә килдем. Мин сиңа да әйттем, би! Колак салмадыгыз. Инде менә күреп торасыз: тәңренең каргышы, авыр кылыч булып, баш өстебездә уйнап тора. Көн-төн эшләнә торган языкларыбыз өчен талау бу! Мондый чакта, куркыныч килгәндә... бөтен ыруның язмышы кыл өстендә торганда... безгә йолык бирергә кирәк. Башкача котылу юлы юк!

---

[1] Түр — монда тахет мәгънәсендә.

Кешеләр сагая калдылар. Утташ камның бөтенләй кирәкмәгән юлдан китүен аңласалар да, бу авыкта аның сүзен бүлдерергә беркемнең дә йөрәге житмәде. Ырудашларының куркынган, таштай катып калган йөзләрен күреп, Утташ кам кызганнан-кыза барды.

— Биргән йолыгыбыз ияләргә барып ирешмәде,— диде ул, аксакалларның әле берсенә, әле икенчесенә карап.— Әрлик хан ялчысы явыз Октуганның күнеле йомшармады. Кичәгенәк төш күрдем. Октуган якамнан алды. «Йолык! Йолык!» — диде ике тапкыр. Мин аны беләм, ике тапкыр әйттеме, ул кеше сорый. Явыз Октуган йолыкка кеше сорый! Үтендем, ялвардым — сүзеннән кайтмады. Шунсыз сезгә котылу юк, ди. Юкса, бөтен жир-суыгыз юкка чыгачак, ди. Бер языклы кеше аркасында бөтен ыру юкка чыгарга тиешме, юкмы — әйтегез шуны, ырудашлар?

— Йолык! Йолык! — дип кычкырдылар Утташ кам янындагы кешеләр.

— ...Октуган явыз... тфү, тфү! Телемә дә аласым килми...— диде Утташ кам, жыламсырагандай итеп.— Канечкеч Октуган... явыз Октуган синең углың Тотышны сорады, Күрән би! Кая качырдың углыңны — кичекмичә тотып бир безгә!

Кешеләр, көчле жил искән чактагы урман кебек, кинәт чайкалып куйдылар. Куллар, ярлыкау сорап, үзеннән-үзе күккә күтәрелде, меңләгән йөзләрдә курку-кот алыну билгесе катып калды.

Майчан аксакал, ачуланып, таягын шакылдатып, койма өстенә менде.

— Ыхым, ыхым,— диде тамагын кыргалап.— Оланнар... ырудашлар, мине тыңлагыз. Сезнең арада мин иң карт кеше. Яшем инде сиксәннән артып бара. Туганнан бирле мин бер генә күрдем йолыкка кеше биргәнне. Бик күптән... унбиш-уналты яшемдә. Ыруыбызның атаклы камчысы Айбаба әйтерие, ни... әшәке... аты корыгыры... Октуган явыз... кешене йөз жылга бер генә сурай, диерие. Әле йөз жыл үтмәгән, ырудашлар.

Кешеләр, жиңеләеп, гөрелдәп алдылар. Майчан аксакалны яклап кычкырган тавышлар ишетелде. Утташ кам яклылар да авыз йомып тормадылар — кычкырдылар, кулларын, коралларын бутадылар. Майчан аксакал жиргә төшкәч, кызып-кайнарланып, өлкән кам яңадан сөйләргә керешә.

— Туганнар, ырудашлар! — диде.— Олуг аксакалыбызның сүзләре сезне буташтыра күрмәсен. Айбаба камчыны мин дә беләм. Белмәскә, минем үз атам, өйрәтүчем лә ул! Илгә яу-кыран килгәндә, йөз ел тулганны көтеп торып булмый, диерие Айбаба камчы. Яу-кыранның кайчан килерен беркем алдан белми. Тагын шуны да онытмагыз, ырудашлар, канечкеч Октуганның йөз елда эше юк. Ул үзенә тиешлесен генә сорый. Шунсыз без аның күңелен күрә алмабыз. Белегез: ыруның язмышы бу!

Тагын авыр тынлык урнашты. Тимер кораллар кулларны, иңбашларны асып төште, тимер киемнәр башларны, күкрәкләрне кысты. Күрән би иәүен чишеп жибәрде, авыр кашлары астына яшеренгән авыр күз карашын кешеләргә йөртеп чыкты.

— Ырудашлар! — диде ул, эчке бер тетрәнү белән.— Капка төбенә яу килде. Безнең борын төбебездә генә, безнең изге жиребездә ул әнә урда корды. Жирем-суым өчен, ыруым өчен мин туган углымны гына түгел, үз-үземне дә кызганмыйм. Теләсәгез нишләтегез — углым да, үзем дә сезнең карамакта. Телисез икән — углымны, телисез икән — үземне... хатыннарымны, башка угылларымны изге эш өчен йолык кылыгыз!

— Кылырбыз да шул! — дип чәрелдәде Утташ кам, янап, куанып.

— Ашыкма, кам баба,— диде аңа каршы Күрән би.— Минем сиңа

бер генә соравым бар. Син әйт безгә: йолыкка кеше биреп кенә Алмыш ханнан котыла алабызмы без?

— Йо-ок! — диделәр акбүреләр бер авыздан.

— ...Без йолыкка кеше биргән өчен генә Алмыш хан үзенә тиешле каланнан баш тартырмы? — диде тагын да би.

— Йо-ок! — диделәр акбүреләр, язгы Чулман сыман шаулап.

— Шулай булгач,— диде Күрән би, күтәренкелек белән,— йолык бирү-бирмәү турында сөйләшкәнче, калан түләү-түләмәү турында сөйләшсәк яхшырак булмасмы?

— Шула-ай! — диделәр коралды ирләр, катауны яңгыратып.

— Алайса әйтегез: утыз мең кеш түлибезме, ягы белән орышабызмы? — диде ыру башы.

Кешеләр тагын тынып калдылар.

— Ыхым, ыхым,— диде Майчан аксакал, янадан таягын шакылдатып.— Оланнар, ырудашлар! Утыз мең кеш безне аяктан җыкмас, ни... аты коргыры... кем... Алмыш ханның кылычы — җыгар. Эт күңеле — бер сөяк. Алсын да китсен!

— Ах, бер генә сөяк булсачы! — диде Күрән би, ачынып.

Майчан аксакал сүзләрен башкалар да яклады.

— Түләргә кирәк!

— Алсын да китсен! — диештеләр кешеләр.

— Юк, түләмибез! — диде шул чакны кемдер, шау-шуны күмеп.

Кешеләр тавыш килгән якка — коймa өстенә күтәрелеп карадылар. Сакчылардан, коралды ирләрдән бер читтәрәк анда баштанаяк коралланган яшь бер углан басып тора иде.

— Тотыш!

— Югалган Тотыш! — диделәр акбүреләр.

Кайберәүләр моны куркып әйтте, кайберәүләр аптырап, кайберәүләр куанып әйтте. Утташ кам, үз-үзен белешмәстән, тыгыз төркем арасыннан Тотыш ягына ташланды.

— Тотыгыз, тот! Аяк-кулларын бәйләгез! — дип кычкырды ул, явыз бер сөенеч белән.

Кешеләр, камга юл биреп, як-якка тайпылдылар, кайберләре, киресенчә, аның юлына аркылы төшәргә тырыштылар. Койма өстендәге кырыс сакчылар урыннарыннан кымшанмыйча басып тик тордылар.

Утташ кам килгән юнәлешкә капма-каршы яктан Тотышка таба икенче бер кеше ашыкты.

— Углым! — дип кычкырды Койтым бикә, кулларын сузып, коймага таба омтылып.

— Углым! — диде Күрән би дә, кузгалмыйча, эчке бер сагыш белән.

— Оланнар, туктагыз! — диде Майчан аксакал, тавыш, ыгы-зыгыны басмакчы булып.

Күрән би быргычыга ым какты. Шул чакны күкне ярып ачы быргы тавышы яңгырап китте.

— Сөйлә, углан! — диде Майчан аксакал, Тотыш ягына таягын изәп, тынлык урнашкач.

— Сөйлә, сөйлә! — диештеләр башкалар да.

— Атам! Анам! Олуг аксакал Майчан баба! Ырудашлар, ил агалары! Тыңлагыз, сезгә сүзем бар! — дип кычкырды Тотыш көр, яңгыравык тавыш белән.— Мин әле ир түгел, шулай да сез миңа сүз бирдегез. Мин әле ир түгел, шулай да мин кулыма корал алдым. Ыруыма куркыныч килүен ишетеп мин, белексез углан, сезнең янга ашыгып кайттым. Элекке ярамаган эшләремнең барысы өчен кичерегез мине, ырудашлар!

— Кичерәбез, олан,— диде Майчан аксакал.

— Кичерәбез, кичерәбез — сөйлә! — диделәр коралды ирләр.

— Менә шул...— диде Тотыш, янадан сүз башламакчы булып. Тик, куанычтан, дулкынланудан, күрәсең, кирәкле сүзен таба алмыйча, бер-

авык тотлыгып торгандай итте.— Күрәсезме, ырудашлар, безнең көчебез житәрлек түгел,— дип кычкырды ул бераздан үзенең аяк астында тынып калган меңләгән кешеләргә карап.— Котан белән Акбога кайтып житсә дә, күршеләрдән булышка алайлар килсә дә, безнең барыбер көчебез артмаячак. Безнең күбебезнең кулында уктан-жәядән башка берни юк. Киемнәр шулай ук таза түгел. Карагыз болгарларга—күбәсез ирне күрерсезме, тимер калкансыз, тимер алпаксыз ирне күрерсезме? Алар нинди яхшы өйрәтелгән... шау-шу юк, ыгы-зыгы юк — мең кешесе бер кешедәй! Көч алар ягында, ырудашлар. Тик шулай да мин утыз мең кеш түгел, ягыга бер тиен дә бирмәскә димен!

Аның бу сүзләре дөрләп янган учакка бер чиләк су сипкәндәй булды. Аста, кешеләр арасында шаркылдап көлгән тавышлар ишетелде.

— Атам, анам! Ырудашлар, туганнарым! — диде Тотыш углан, көлгән тавышларга колак салмыйча.— Моңарчы сез минем бер генә теләгемне дә үтәмәдегез. Яшьлегем, белексезлегем аркасында мин сезгә, ыруга күп кайгы салдым. Инде сезгә бер сүзем бар... бер теләгем бар: тынлагыз! Мин Алмыш ханның иң көчле алыбы белән орышырга телим. Мин бер үзем ыру өчен ягыдан үч алырга телим! Жиңсәм, болгарлар буш кул белән китәр, жиңеләм икән — калан түләрсез!

## IV

Акбүреләр кисәк кенә кузгалып куйдылар, жиңелчә шауларга, гөрелдәргә тотындылар. Тирә-яктан:

— Яшә, Тотыш! Бай бул, Тотыш!

— Коткар ыруны, коткар катауны! — дигән сүзләр ишетелде.

Икеләнгән, каушап калган акбүреләр күңелендә Тотышның сүзләре ышаныч чаткылары кабызып жибәрде. Башлар югары күтәрелде, коралларга куллар ныграк тотынды. Әнә ул Тотыш углан, нинди таза, нинди көчле! Кем белә, жиңеп куйса, калан да түләнмәс, кешеләр дә исән калыр. Жиңелә икән инде, алай үзе атлыгып торгач, әйдә, урыны ожмахта булыр.

Күпчелек шулай уйлады. Тик ата кеше генә икенче төрлерәк уйлады. Үзенең углын ул беренче тапкыр күргәндәй булды. Ул аның көче-батырлыгы белән дә, күңеле белән дә, үзеннән — үз атасыннан гына түгел, мондагы барлык кешеләрдән, барлык ырудашларыннан өстен икәнлеген аңлады. Ул аны — кечәге башсыз углын — үзенең төп яклаучысы итеп тойды. Димәк, ата кешенең күңеле тое[1] булган! Димәк, аңа ышаныч баглап ул ялгышмаган! Бинең күзләренә яшьләр килде.

— Углым! — диде ул, Тотышны кочагына алып.— Бүгеннән башлап син — ир! Әй, ырудашлар, ишетәсезме, Тотыш углым минем ир булды! Мин аның теләгенә каршы килмим, мин аңа ак юл телим, жиңү телим. Орыш, углым, ягы белән, күрсәт ирлегеңне!

— Орыш ягы белән!

— Ак юл сиңа, Тотыш углан! — диделәр аксакаллар.

Күрән би, углының теләген белдереп, болгарларга ук атарга кушты. Болгарлар укны алдылар, битекне укыдылар да ат кешнәгән кебек шаркылдап көләргә тотындылар.

— Ничек көләләр бездән! — диде Тотыш, иреннәрен чәйнәп.

Күп тә үтмәде, болгарлардан икенче ук килеп төште. Каен тузына ике генә сүз язылган иде. Бу: «Бергә өч» дигән сүзләр иде. Акбүреләрнең йөзе каралай янып чыкты. Бергә өч! Димәк, Тотыш бер-бер артлы өч алыпны жиңәргә тиеш, бары шул чагында гына ул жиңүче булып саналачак!

---

[1] Тое — алдан сизү, тою.

Яшь егетнең нык кысылган иреннәре калтыранып китте. Шулай да ул куркуын тиз арада җиңә алды. Су астында озак чумып торганнан соң өскә калкып чыккан кеше сыман, ул озын итеп, күп итеп бер тын алды да:

— Мин орышам! Мин сүземнән кайтмыйм,— диде.

— Юк! — диде Күрән би, болгарларның битеген урталай ертып.— Бу — тигезлек түгел. Бу бернинди йолага да, түрәгә дә туры килми. Алар бездән юри көләләр.

— Мин барыбер орышам, атай,— диде Тотыш, кабатлап.— Мин баш тартсам, алар бездән тагын да ныграк көләчәкләр.

Аның шулай дип әйтүе булды, болгарлар, күрәсең, акбүреләрнең икеләнүен күреп, тагын да ныграк шаркылдап көләргә тотындылар.

— Курыкты!

— Астына җибәрде!

— Алыбыгыз кая — чыксын орышка!

— Сукыр сычканнар, сезгәме соң арысланнар белән алышырга! — дигән сүзләр ишетелде.

Коймa өстендәге кешеләр, ягының көлүенә үртәлеп, эчләре пошып, тын гына басып тордылар. Акбүреләр аптырабрак калган бер мәлдә коймa өстенә Койтым бикә килеп менде. Ул аста кешеләр арасында тоткарланып калган иде. Инде ул түзмәде, кешеләрне ерып-ерып, туры коймага якын килде, каяндыр ирләр алып килгән кучермәле баскыч буенча югары менде.

— Углым! — диде ул, йөрәк түреннән чыккан бер өн белән.— Мин барысын да күреп, ишетеп тордым. Углым, күземнең яругы... бавыр итем, йөрәк маем! Бар, орыш! Мин сиңа изге теләктә булырмын. Бөтен ырудашларың изге теләктә булыр. Күп көттем мин шушы көн килүен. Үч ал ерак бабаң өчен, анаң өчен, ыруларың өчен, углым! Әнә явыз ягы безнең изге җирдә!

Койтым бикә алтын-көмешләр, тимер-җизләр елкылдаган, ят байраклар җилфердәгән якка төртеп күрсәтте. Аның сүзләреннән Тотыш кайбер нәрсәләрне аңлап та җитмәде. Ул бары бер генә нәрсәне аңлады — әйе, ул орышырга тиеш! Анасының ялкынлы сүзләре аның күкрәген бетмәс-төкәнмәс көч белән, куаныч белән тутырды, болгарларның икенче угыннан соң, атасының каршы килүеннән соң күңелендә баш күтәрә язган икеләнү, каушау тойгысы кул белән алгандай юкка чыкты.

— Бергә өч булуына исең китмәсен, углым,— диде Койтым бикә, аның уйларын сизенгәндәй.— Өчкә түгел, өч уңга, өч йөзгә каршы чыгудан да курыкмый торган батыр алып бул, углым! Синең ерак бабаң Кайду алып шундый батыр булды, синең бик еракта калган ерак туганнарың барысы да шундый булдылар. Анаңның туган ыруын туздыручыдан, атаңның туган җирен басучыдан канлы үч ал, углым! Теләгем шул: куркуыңны салып тапта!

— Мин курыкмыйм, анам! — диде Тотыш, елмаеп.

— Куркуын курыкмыйсыңдыр да,— диде Күрән би, үртәлеп.— Бу — тигезлек түгел. Бу — бездән көлү!

— Син ни телисең, би? — диде Койтым бикә, иренә эндәшеп.— Ягыдан син кызгану, тигезлек, изгелек көтәсеңме?! Ул сине таларга, үтерергә, яндырырга килгән, түбәнсенеп шуңа үпкәләргә уйлыйсыңмы?! Күтәр башыңны, күзеңне ач, Күрән би!

— Баш та каткан инде,— диде би, мыгырданып.— Әле өч көн бар, ашыкмыйк, уйлашыйк.

— Уйлашыр чак түгел — илне ягы баскан! — диде Койтым бикә кискен генә.— Углыңны җибәрмәсәң, үзем чыгам Алмыш ханга каршы. Тик, берне үтерсәм, өчкә саналырга тиеш. Җибәр укны Алмыш ягына!

Күрән би авыр башын күтәрде, көрсенеп «язмыш... каргыш» дип мыгырданды да битекчегә карап алды, «Мин орышам. Тотыш» дип язарга кушты.

Койма тышына тагын ук очты.

## V

Тотышка киенергә атасы булышты. Ул аңа үзенең авыр күбәсен, нык, авыр калканын бирергә теләде. Тотыш атасының бер нәрсәсен дә алмады. Ул җиңелчә генә киенергә булды. Өстенә иң элек юка, җинел күлмәк, аның өстеннән кыска тунын киде. Муенына нечкә каешка тагылган кечкенә бүре башы — ыру кумарткысын[1] такты. Кыска тунның күкрәк турысына юка тимер кисәкләре тегелгән иде. Аның өс киемендәге тимер бары шул гына иде. Аннары баш кием — алпагы тулысынча тимердән иде. Алпак башыннан төшеп китмәсен өчен ул ияк астыннан сакалдырыгын бәйләп куйды да кысып билен буды, кылычын такты. Шуннан соң ул бер кулына калкан, икенче кулына сөңгесен алды.

Атка атланыр алдыннан ул йөгереп койма өстенә менде, беренче тапкыр күргәндәй, як-ягына карады; еракта көмештәй җемелдәп яткан Чулманга, татлы исләр аңкытып, ап-ак чәчәккә күмелеп утырган шомыртларга, катау артындагы, чокырлар артындагы зәңгәрсу калкулыкларга, урманнарга күз йөртеп чыкты. Күңеленнән ул үзенең туган җире белән, үзенең барлык ыруы белән — атасы-анасы, туганнары белән саубуллашты. Ул үзенең ерактагы ише белән — Ямгырчы би кызы Тәңкә белән саубуллашты. Ул үзенең үткән бала чагы белән, көн дә күреп өйрәнгән тәбәнәк өйләр, тар урамнар, җилдә-яңгырда караеп беткән коймалар, капкалар белән, кырыс ирләр белән, зәңгәр түтәннәр белән саубуллашты.

Көн кояшлы, җылы иде. Кайдадыр якында гына чыр-чыр килеп кошлар очып йөри, баш өстендә көмеш шөлдер булып, тургай чыңлый иде. Тиздән менә орыш буласына, кемнәрнеңдер озакламый шушы җылыдан, киңлек, иркенлектән аерылачагына әз генә дә ышанасы килми иде. Әле кичә генә бала-чага уйнап йөргән болында, яшел богдай чирәме җәелеп яткан киң яланда күңелләрне тетрәндереп шаулашкан ят, чит, ягы кешеләр барлыгына бөтенләй ышанасы килми иде.

Тотыш юри ул якка карамаска тырышты. Туган җирен күздән кичергәч, ул койма өстенә тезләнде дә ак болытлар күпереп йөзгән биек, зәңгәр күккә карады.

— Тәңрем! Мин, Акбүренең Тотыш атлы угланы, алыплар орышына чыгам. Миңа көч бир, кыюлык, җиңеллек бир, тәңрем! — диде ул, ялварып.— Явыз ягы, керген болгарларның башы киселеп минем аяк астыма төшсен. Сөңгем очлырак, кылычым үткенрәк булсын. Янымда сакчым бул, изге булышчым бул, олуг тәңрем!

Шуннан соң ул атасын, анасын кочты, туганнарын кочты. Аңа Йолдыз-кашканың туганын Ташбәкәлне җитәкләп китерделәр. Йолдыз-кашка кебек, Ташбәкәл дә бөтен ыруда иң яхшы, иң сылу атлардан санала иде. Йолдыз-кашкага караганда ул бераз кечерәк кенә. Шулай да ул көчле, чыдам, житез. Кешечә сөйләшергә аның теле генә юк иде. Тотышны ул тавышыннан түгел, күз карашыннан да аңлый иде.

Алыплар орышына бар нәрсә житеш икәнлекне белдереп, койма, катау ягында быргы уйнадылар. Болгарлар да шуны аңлатып кару[2] бирделәр. Шуннан соң ике якта да, йөрәкләрне җилкендереп, берьюлы уңлап-уңбишләп дөңгер кагарга тотындылар.

---

[1] Кумарткы — бөти.
[2] Кару — җавап.

Менә ашыкмыйча гына ур өстенә күпер төшә башлады, капкалар ачылды, тешкә тиеп чыгырлар шыгырдады, тимер күгәннәр ыңгыраштЫ. Тотыш Ташбәкәлнең тезгенен бушайтып җибәрде, күләгәле капка авызына чабып керде дә кояшлы ачык җиргә — яланга ыргылды.

Ул туп-туры җаваҗга таба карап чапты. Иң элек ул үзе белән орышачак алыпны күрмәкче булды, тик каршыда урмандай калкып торган ир-атлардан башка, аллы-зәңгәрле-сарылы ефәк җаваждан башка бүтән берни дә күрмәде. Бер җиргә тупланган шул тикле күп кешеләрнең тере, кызыксынучан күз карашларын тою аны чак-чак кына каушаткандай булды. Шулай да бу тиз арада юкка чыкты. Ул анасы Койтым бикәнең өндәү сүзләрен исенә төшерде. Ул, әйтерсең, кинәт кенә шушы башлар, сөңгеләр, байраклар өстеннән югары күтәрелде; күтәрелде дә аларга — үзләренең җирен таптап, ия булып, күкрәк киереп торган килмешәкләргә корычтай нык, салкын бер күз карашы ташлап алды. Бу мәлдә ул үзен барлык алыплардан, барлык сөңгеләрдән, кылычлардан көчле итеп, бөек итеп тойды.

Шул чакта ул сөңгеләр, алпаклар урманыннан аерылып, үзенә таба якынлашып килгән болгар алыбын күреп алды. Болгарның бу иң атаклы батырлары Чәкән алпагыт[1] иде.

Чәкән алпагыт богадай таза, арысландай көчле иде. Ул баштанаяк тимергә төренгән, шуңа күрә аның сөнге, кылыч үтәрдәй бер генә йомшак җире дә юктыр кебек иде. Үзенең таза кола· атында ул таштан уеп ясалган баганадай нык утыра. Ул киң битле, зур башлы. Күп орышларда бите-башы яраланып, ямьсезләнеп беткән бу усал, кансыз, коточкыч алпагыт турында: кылыч белән бер сукса, тимер киемле кешене урталай ярып төшерә, дип сөйлиләр иде. Аның белән орышкан бер генә батырның да әле исән калганы юк, дигән сүзләр йөри иде.

Чәкән алпагыт янында Тотыш углан бала-чага кебек кенә күренә иде. Буйга да ул аннан кайтыш, киеме дә, кораллары да батырларныкына охшамаган кебек иде. Болгарлар аның йөзендәге кырыслыгын да, күзләрендәге очкынлы ярсуын да, киеме аша бүртеп торган беләк тычканнарын да күрә алмадылар. Алар бары аның яшь, җинел... өтәләнгән булуын гына күрделәр. Алар аннан эчләрен тотып көләргә тотындылар. Чәкән алпагыт, гыжылдавык бер ямьсез тавыш белән:

— Әй, син, Камырбатыр! Бар, кайтып кит. Синнән өлкәнрәге килсен! — дип кычкырды.

Тотыш эндәшмәде. Аның бары иреннәре генә ныграк кысылды да, куллары гына чытырдатып коралларын тотты. Күк күкрәгәндәй булып яңгыраган көлү тавышларын, йөзенә бәреп әйтелгән мыскыл сүзләрен ул, әйтерсең, ишетмәде дә. Чиксез ачу, үч тойгысы аңа көч бирде, корычтай ныклык бирде.

«Ананның туган ыруын туздыручыдан, атаңның туган ыруын басучыдан канлы үч ал, улым! Теләгем шул: куркуынны салып таптa!» — диде Койтым бикә, аның колак төбендә пышылдап, изге орышка өндәп.

## VI

Алар шулай икесе дә бер-берсенә кара-каршы чабып килделәр. Атлар, арт аякларына басып, усал итеп кешнәп җибәрделәр. Чәкән алпагыт, сары тешләрен ыржайтып, җинел генә, шаярткан кебек кенә сөңгесе белән төртеп алды. Сөңге башы шытырдатып Тотышның тимер калканын тишеп чыкты. Егет агарынып китте. Тиз генә ул калканын тартып алды, Ташбәкәлнең корсагына төртте дә читкә ташланды. Чәкән алпагытның артына чыгып, аны узып китте. Шуннан соң ул кырт кына

[1] Алпагыт — алып, батыр.

кире борылды, сөнге ыргытмакчы булды, тик каршыда гына болгар алыбының ямьсез коточкыч йөзен күреп каушап калды.

Ике батыр тагын да беравык бер-берсенә карашып торгандай иттеләр. Чәкән алпагыт, «сәләмә» батырны бер селтәнүдә сөнге очына элә алмавына ачуы килеп, күрәсең, монысында чынлабрак орды. Ул бик тиз, бик туры төбәде. Ул бик каты бәрде. Яшь егет шулай да аның сөнгесеннән өлгеррәк булып чыкты. Күкрәгенә очлы тимер килеп керде дигәндә генә ул, ияреннән шуышып, унга ташланды. Башы белән ат аягы астына егылып төшмәс өчен, сөнге сабын җиргә төртеп алды да, җилдәй выжлап, тагын алпагытны узып китте. Бераз җир чабып баргач, ул җиңел генә ияренә утырды, өзәңгеләргә ныгытып басты, борылды да, аткан уктай Чәкән алпагытка таба ыргылды.

Аның бу күз иярмәс житезлеген ике якта да күреп алдылар. Акбүреләр куанып гүелдәргә тотынды.

Икенче тапкыр ояткa калу Чәкән алпагытны чын-чынлап котыртып җибәрде. Ияреннән калка төшеп, атының башы өстенә үрелеп, ул, кыя таудан ычкынып киткән иләмсез зур таш кисәге сыман, Тотыш өстенә килә башлады. Күзен кан баскан усал үгез кебек ул дулап, үкереп килде. Монысында ул Тотышның үзен генә түгел, әйтерсең, атыние белән бергә күтәреп ормакчы булды.

Шулай да ора алмады. Тотыш углан үзенә төбәлгән сөнгене калканы белән читкә тайпылдырып җибәрде. Карап торучылар, таң калып, тагын гөрләп алдылар. Болгарлар ягында инде җиңелчә генә киенгән яшь егеттән көләргә беркем батырчылык итмәде. Киресенчә, аның менә шулай җиңелчә киемле булуы, яшьлеге, өлгерлеге аларның күңелендә чын-чынлап соклану тойгысы тудырды.

Өченче кат буш сөнге тотып калган Чәкән алпагыт, ахрысы, кирәгеннән артык кайнарланып ташлады. Ул, ачуына булашып, күрәсең, онытылыбрак китте. Кирәк чакта ул атын борып өлгермәде — аты аны ераккарак алып чапты. Ике яктагы кешеләр, әле генә булган очрашу күренешеннән айный алмыйча торганда, Тотыш углан беркемнең башына килмәгән, көтелмәгән бер егетлек эшләде. Үзенә төбәлгән сөнге башын читкә тайпылдырып, Чәкән алпагытны узып киткәч, ул атын борып тормады: сикереп кинәтияргә басты, артына борылды. Борылды да күз ачып йомган арада сөңгесен еракләша барган җайдакка тондырды. Туры ыргытылган саллы сөнге, тимер киемне, тимер сөякләрне җимереп, киң арканы үтә-сүтә тишеп керде.

Үз көченә, үзенең үлемсезлегенә нык ышанган Чәкән алпагыт сөрлегеп китте, тезгенен тартып, атын кире борды. Тешләрен кысып, соңгы көчен җыеп, ул да сөңгесен ыргытты. Сөнге ерак китә алмады — чынлап, аяк астындагы тузанга барып төште. Атаклы алпагыт, күкрәген тишеп чыккан очлы тимерне кысып тоткан килеш, көчәнеп беравыкияр өстендә утыргандай итте дә барлык авыр киемнәре, кораллары белән гөрселдәп ишелеп төште. Аты туктады, куркынган зур күзләрен уйнатып, кызганыч тавыш белән кешнәп җибәрде. Җайдакның калканы доңгырдап читкә тәгәрәде, алпагы яртылаш туфракка буялды.

Акбүреләр ду килеп шауларга тотындылар. Болгарлар да ду килделәр: кайберәүләр чәчен-башын тырнап җыларга тотынды, кайберәүләр, янап, сүгенеп, катау ягына сөнге күтәрделәр. Тик шулай да беркемнең дә Тотыш угланны яманларга теле бармады. Күпчелек яшь алыпның язмышына соклану белдерде. Кырыс ирләр, орыш-сугыш белгечләре чын батырлык алдында баш иделәр.

Ул арада Тотыш углан үтерелгән алпагыт янына килде, сөңгесен тартып алды — киң аркадан, чишмә булып, куе кан атылып чыкты. Сөңгедәге канны Тотыш Чәкәннең киеменә сөртте. Шуннан соң ул, сөенечennән очынып, катау ягына чабып килде. Тузан туздырып, баш очында сөңгесен уйнатып ул янадан хан җавәжына якынлашты.

— Әй, хан, чыгар икенче батырыңны! — дип кычкырды ул.

Яңа орыш башланганлыгын белдереп тагын быргылар кычкырды, тагын дөңгерләр дөпелдәде. Киң җаваҗ артыннан яланга Будрач сукман[1] килеп чыкты.

Будрач сукман Алмыш ханның Чәкән алпагытыннан кала икенче батыры иде. Чәкән алпагыт үзенең коточкыч көче, кансызлыгы белән, ат өстендә яхшы орышуы белән танылган булса, Будрач сукман икенче яктан атаклы иде. Ул чирмеш, урман кешесе иде, шуңа күрә атта яхшы орыша алмый иде. Аяк өсте орышта исә аңа беркем каршы тора алмый иде. Тотыш белән Чәкән алпагытның орышын күзәтеп утырган Алмыш хан яшь егетнең көчле якларын да, йомшак якларын да тиз арада төшенеп алды. Аның иң зур өстенлеге җиңеллек булса, иң йомшак ягы да шул ук җиңеллек иде. «Җәяүлегә каршы торып карасын әле!» дип уйлады хан, үз алдына көлемсерәп.

— Мин кылыч белән орышам! — диде Будрач сукман.

Тотыш берни әйтмәде, атыннан сикереп төште дә сөңгесен җиргә кадады, кылычын кынысыдан алды. Ташбәкәл, иясе өчен пошынган сыман, кыска гына итеп кешнәп куйды, теләр-теләмәс кенә катау ягына китеп барды.

Ак чырайлы, саргылт кашлы Будрач сукман буйга артык калку түгел иде. Ул бик таза, нык, авыр сөякле иде. Чәкән алпагыт кебек ул да баштанаяк тимергә төренгән, аның да кылыч үтәрдәй бер генә йомшак җире дә юк шикелле иде.

Батырлар, бер-берсен сынап, күзгә-күз карашып тордылар да икесе дә берьюлы кузгалып куйдылар, таптанып алдылар, кылычларын селтәп, ярсып шундук орышка да ташландылар. Тимергә тимер тиеп чыңлаган, мышнаган, дөп-дөп баскан тавышлар ишетелде. Кояшта көзгедәй булып кылыч йөзләре, калканнар ялтырап китте.

Карар күзгә таш тутырылган капчык сыман авыр күренсә дә, чирмеш батыры да бик җитез, өлгер кыланды — андый җитезлекне, өлгерлекне Тотыш аннан бөтенләй көтмәгән иде. Будрач сукманның кулында кылыч уйнап кына торды. Тотыш, кысрыклауга чыдый алмыйча, әкренләп-әкренләп чигенә барды. Будрач исә, яшь егеткә тын алырга да ирек бирмичә, шулай кысрыклап килде-килде дә, кинәт кылычын ике куллап тотып, бар көченә орды. Шундый иттереп орды — кылыч астында кеше түгел, таш булса, таш та урталай ярылып чыккан булыр иде! Тотыш ярылмады—җиргә егылды. Карап торучылар «аһ!» итеп җибәрделәр. Сөенергәме, сөенмәскәме икәнлеген әлегә беркем белмәде. Нык селтәнгән кылычның яртылаш диярлек җиргә батканлыгын, яшь егетнең үлемгә кыл арасы гына торып калганлыгын күргәч, акбүреләр дә, болгарлар да күкрәк тутырып тын алдылар.

Тотыш аягына басты, чирмеш алып ташланганчы тиз арада кылычын, калканын иләде, артка чигенде. Шул ук мәлдә аның күз алдында Тәңкә күренеп китте. Беренче төнне аның белән куышуы исенә төште. Яшьтәшләре белән куышлы, качышлы уйнаганда әле йөгереп, әле туктап, егылып калу, читкә тайпылу, шулай итеп, куучыны алҗытып бетерү алымын яхшы белсә дә, бу авыкта аңа бу ниндидер яңалык булып тоелды. Кылычын күтәреп Будрач сукман яңадан өстенә килә башлагач, ул тиз генә читкә сикерде. Ул моны берничә тапкыр кабатлады. Будрачның ачуы килә башлады. Ул кызып китте. Тешләрен шыгырдатып, кан баскан күзләреннән куркыныч очкыннар чәчрәтеп, ул Тотыш угланны туктаусыз эзәрлекләвендә булды. Тотыш исә әле башын иеп калды, әле йөгереп китте, я булмаса болгар батырының артына чыгарга омтылды. Уңга-сулга боргалану авыр киемле кешегә шактый кыенга туры килде.

[1] Сукман — батыр сугышчы, алып.

Яшь егетнең нишләргә чамалавын ул бик яхшы аңлады, шулай да бер-ни эшли алмады — Тотыш углан тиен кебек житез, тиен кебек тешле, усал иде.

Шулай мачы белән сычкан шикелле куышкан арада, Будрач сукман Тотыш угланның кая, ничек тайпылачагын алдан ук чамалап алды, та-гын бер тапкыр — монысында инде соңгы тапкыр! — кизәнергә булды. Читкә киткән егет исенә килеп өлгергәнче ул аның артыннан килеп тә басты, кылыч сабын тагын ике куллап тоткан килеш, бар көченә селтә-неп тә җибәрде. Монысында ул өстән аска түгел, кайгачлап, уңнан сул-га таба селтәде. Чалгы белән печән чапкандагы кебек, Тотышны кай төшеннән генә булса да урталай кыеп төшермәкче булды. Тотыш углан, кайсы гына якка тайпылса да, ничек кенә егылса да, барыбер аның чал-гысына эләгергә тиеш иде.

Тик ул Будрач сукман уйлаганча уңга да, сулга да тайпылмады, туп-туры аның аяк астына ташланды. Үткер кылыч аның баш өстен-нән ыжгырып үтте. Алмыш ханның икенче батыры, үз кылычы артын-нан ияреп, баскан урынында әйләнгәндәй итте. Шул ук мәлдә бөтен яланны тутырып, йөрәк ачысы белән:

— А-а-а-а! — дип акырып җибәрде.

Тотыш кулындагы үткер тимер астан, корсактан йомшак иткә барып керде, эчәкләрне, бөер-бавырларны кисеп үтеп, күкрәгенә таба шуыш-ты. Сукман кулындагы кылыч, калкан чыңлап җиргә төште. Ак чырай-лы, саргылт кашлы чирмеш алып, авызын ачып, ашыгып тын суыра-суыра, баганадай артка ауды.

## VII

Берьюлы ике батырыннан колак каккан Алмыш хан, Тотыш угланга тын алырга да ирек бирмичә, өченче кешесен чыгарды. Монысы Корыч-Тимер дип аталган яшь, чибәр алып иде. Ул Алмыш ханның чыбык очы туганы булган Алып-Тархан бинең сөекле углы иде. Ул да болгарлар арасында атаклы алыплардан санала иде. Ул инде күп кенә яуларда булган, орышларда катнашкан, җиңгән, бүләкләр алган иде. Холкы бе-лән ул эре, борнай[1] бер җегет иде. Барыс кебек житез, кансыз бу яшь алып бер дә юктан кызып китә, кирәк икән — шундук үзгәрә дә белә иде. Үзенең якыннары аны «ике яклы пычак» дип атыйлар иде. Тотыш углан кебек, ул да җиңелчә генә киенгән иде.

— Мин дә кылыч белән орышам! — диде ул, ялан уртасына чыккач.

Батырларның кара-каршы килеп басулары булды, быргыларның чи-наргa тотынуы булды, шундук орыш башланып та китте. Яшен чаткы-лары чыгарып, тиз арада кылыч йөзләре чәкәшергә тотынды.

Тотыш углан беренче адымыннан ук ялгыш җибәрде. Будрач сукман-ны этләгән кебек, Корыч-Тимерне дә ул этләргә, алҗытырга чамалады. Тик болгар батыры аның бу алымын аңлап, өйрәнеп өлгергән иде инде. Шуның өстенә, Тотыш кебек ул да җиңел сөякле иде, шуның өстенә ул әле әз генә дә көчен түкмәгән иде. Корыч-Тимер Тотыш угланнан бер адым да калышмады. Акбүре батыры нәрсә эшләсә, ул да шуны эшлә-де, ул кая тайпылса, ул да шунда тайпылды, я булмаса, аның алдарга чамалавын сизеп, шундук аның юлына аркылы төште. Тотышка ул кү-тәрелеп карарга да ирек бирмәде.

Тотышның нинди дә булса яңа нәрсә уйлап табарга башы җитмәде — күз алдында ялт-йолт килгән кылыч йөзе торган саен аның эчен пошыр-ды, ачуын китерде. Ул яңадан анасының сүзләрен исенә төшерде, Таң-кәне исенә төшерде, тик инде берни дә аңа баштагы өстенлекне, сал-кын канлылыкны кайтара алмады.

---

[1] Борнай — масая, борын чөя торган кеше.

Ул, алдалап берни дә барып чыкмаганлыгын күргәч, соңгы көчен жыеп, матур кара мыеклы чибәр ягыга каршы ыргылды, аны кысрыклый башлады, бер-ике тапкыр каты гына орып-орып алды. Берсендә Корыч-Тимернең калканы чак-чак кына кулыннан төшеп китмәде, икенчесендә ул, башын саклап, иелеп кала алды.

Акбүре батырының бетмәс-төкәнмәс көченә, ярсуына бөтен катау, бөтен ялан таң калды. Ике якта да тынлык, киеренкелек соңгы чиккә житте.

Кинәт болгарлар ягында бозлы жил исеп киткәндәй булды. Тотыш өстенлекне тулысынча үз кулына алды — Корыч-Тимерне ул чын-чынлап кысрыклый башлады.

Көтмәгәндә ул нәрсәгәдер абынып китте. Корыч-Тимер ач бүредәй аның өстенә ташланды. Аның кылычы Тотыш кулындагы калкан читен уеп төшерде, сул як беләкне кисеп керде дә, сөяккә житеп, тәртелеп калды. Тотыш углан чайкалып китте. «Беттем», диде ул үз-үзенә бик тыныч кына, бөтенләй чит кеше турында уйлаган кебек. Булган бар көчен, ярсуын бер учка туплап ул Корыч-Тимернең аяк астына, муен турысына орды. Болгар алыбы башын иеп өлгерде, бары тимер алпак өсте генә сыдырылып китте дә, киселгән беләктән, киемнәрне чылатып, кайнар кан агарга тотынды. Шул ук мәлдә яшь егетнең күңеленә: «Бетәм!» дигән икенче уй килде. Бар нәрсәне онытып, ул канлы ярасын тотты.

Корыч-Тимер куанып ырылдап куйды, бер селтәнүдә аны юк итмәкче булып, кылычын Будрач сукман кебек ике куллап югары күтәрде. Ярасы белән мавыккан Тотыш угланга яңадан көрәш тойгысы, каршы тору тойгысы кайтты. Үткер кылыч үзенең муенын чабып өлгергәнче ул жиргә егылып калды. Тик монысында ул баягыча ягының әчен айкый алмады. Ярасын ычкындырмаган килеш, сырты белән жиргә терәлеп яткан килеш, ул куш аяклап аңа бары тибеп кенә жибәрә алды. Авыртуга түзә алмыйча, Корыч-Тимер чинап жибәрде, жиргә барып төште.

Жирдән алар икесе дә бер үк мәлдә сикереп тордылар. Тордылар да... Тотышның уң кулы буш түгел иде. Тотышның кулында корал юк иде.

— Ы-ы-ы! — дип үкерде кара мыеклы чибәр алып, куанычыннан нишләргә белмичә.

Ул инде орган да булыр иде, урталай кискән дә булыр иде. Корыч-Тимернең үкерүеннән дә көчлерәк булып, көтмәгәндә Куар оган кукрәп жибәрде.

— Тукта! — дип кычкырды кемдер аның артында гына.

Ул ирексездән туктап калды, артына борылды. Аның каршысында таудай булып Алмыш хан калкып тора иде.

— Тукта! — диде хан, кабатлап.— Син жиндең!

Чибәр алыпның чибәр мыек очы тартышып куйды. Шулай да ул коралсыз Тотыш углан янына килде дә, янап:

— Жыгыл! — диде.

Үзенең жиңгәнлеген белдереп ул кызыл итеге белән аның күкрәгенә басты, кылычын итек башы янына куйды. Сөңгеләр, алпаклар урманы шауларга, чайкалырга тотынды. Акбүреләр, караларына коелып, беравык аңламыйчарак тордылар да барысы берьюлы диярлек кычкырып жыларга тотындылар.

Тотыш жиңелде, Акбүре жиңелде. Нәрсә карап тордың, тәңрем?! Тотыш жиңелде.

Жиңелде. Ул күзләрен ачты, үзенең борын төбендә генә жирәнгеч итек башын күрде, итек башы янында, үзенең бугазына якын төштә коточкыч салкын тимерне күрде. Тимер дә тик тора, итек тә кузгалмый. Тын алуы шундый авыр! Жиңелсә дә, ул әле исән бугай. Әнә ул уйлый, күрә.

Ул жинелде. Ах, нинди кыен, нинди оят очлы тимер белән итек табаны астында тын алып, күреп, уйланып яту!

## VIII

Орыш тәкәнде. Языга[1] үлек күмүчеләр чыкты. Кан, тузан эчендә аунап яткан Чәкән белән Будрачны алар күтәреп алдылар, арбага салып, каядыр алып киттеләр.

Үлгән батырларны алар урман арасына алып барачаклар, аларның киемнәрен, коралларын салдырып алачаклар. Коралларның иң яхшыларын — ханга, калганнарын — кайткач хатынына, я булмаса туганнарына бирәчәкләр. Кием-салымнарын алар үзләренә калдырачаклар. Үлекләрне күмеп тормаячаклар, ник дигәндә — монда батырларның туган җире түгел. Болгарлар киткәч тә аларны монда чит кешеләрнең бүре, козгыннарның мыскыллавы бар. Төнлә беркем күрмәгәндә алар үлгән алыпларны ачык, калку җиргә алып барырлар да, баганага терәп бастырган килеш, утын ягып яндырырлар. Кайнар көлне күккә очырырлар. Шулай итеп, болгарларның кыю батырлары мәңгелеккә — күккә ашачак.

Яландагы үлекләрне алып китү белән, орыш урынына имчеләр чыкты. Алар яралы Тотыш янына килделәр, аның киселгән беләген карадылар; яраны яхшылап салкын су белән юдылар да, киселгән иткә яра ташы кырып салдылар, шуннан соң беләкне ныгытып бәйләп куйдылар. Шул эшләрне башкаргач, төсе качкан, агарынган яшь егетне кабыкка салдылар, күтәреп шулай ук аны да каядыр алып киттеләр.

Ике як арасында кыскача гына сөйләшү булып алды. Күрән би Алмыш ханның катау янындагы яланнан үзе урда корган җиргә — Тәкәшүр болынына кайтып китүен теләде. Тиешле бурычны дүрт көндә үзем илтеп түләрмен, диде. Алмыш хан үз чирүенә шундук кире борылырга боерык бирде. Болгарлар, тузан туздырып, әкрен генә чигенә башладылар.

Тотыш углан көн ягына алып китәргә тиешле таварлар Талкысыкта тукталып калган иде. Күрән би андагы барлык таварны, кешеләрне кире катауга чакыртты. Инде каядыр җир читенә аркыш җибәрүнең дә, кемнәр беләндер сату-алу итүнең дә беркемгә дә кирәге юк иде. Ул җиңелде. Бетте. Бер теләге дә тормышка ашмады. Эх, эчендә нидер шулай борып авыртмаса да, яшәве алай ук кыен булмас иде! Бетте. Аны, әйтерсең, урталай бөгеп ташладылар, аны, әйтерсең, кисәкләргә өзгәләп ташладылар — бер өлеше тегеләр ягында калды, бер өлеше менә бу якта. Соңгы ышанычы — Тотыш углы да аның теләкләрен аклый алмады. Юк, ул үзен чын ир итеп, алып ир итеп күрсәтте, шулай да аннан аңа ни ассу?

Кич катауга Котан белән Акбога кайтып төште. Акбүреләр күбәеп киттеләр. Кешеләрнең бераз күңелләре күтәрелде. Яу килгәндә читтә калган ирләр, калан түләмичә, төнлә болгарларны барып басарга, бөтен ояларын туздырырга кирәк, диделәр. Ыру башы кул гына селтәде. Аның инде бер нәрсәгә кулы бармады, бер нәрсәгә кыюлыгы җитмәде.

Икенче көнне иртүк катаудан болгарларга калан өчен бер көтү сарык озатылды — җиңүчеләргә иртәнге ашка ит булды. Шуннан соң Басу-капкадан бер-бер артлы олаулар агыла башлады. Изге алан авызы янында аларны болгар кешеләре каршы алдылар, хан урдасына тикле озата бардылар. Алмыш ханның теркәүчеләре, агычылары тиреләрне, күннәрне, балларны, чүлмәк савыт-сабаны, ашлыкны җентеклап карап, тикшереп алдылар. Бозылган, ертылган, тишелгән нәрсәләр кире

---

[1] Язы — ялан, буш җир, мәйдан

кайтарылды, алынганын санап, аерым беликләргә язып бардылар. Алынган тавар өчен акбүреләргә тамгалы барчак [1] бирелде.

Ике көн эчендә акбүреләрнең бурычы тулысынча түләнеп бетте. Сыгылып торган киштәләр яңадан турайды, таварлыклар бушап, иркенәеп калды. Агычылар авыр, калын ишекләрне иңеләй ачып җибәрделәр. Эт, бүре башы төсле итеп ясалган зур йозаклар, авызларын ачып, ишек кылдауларында эленеп тордылар. Бер почмактан икенче почмакка шыр идән буйлап күселәр йөгереп узды. Билләренә алъяпкыч бәйләгән чуралар, бик эшлекле кыланып, чүпле идәннәрне, таварлык алларын себерделәр, шунда ук чыр-чу килеп чыпчыклар чүпләнде.

Әйе, таварлыклар бушап калды. Таварлыклар белән бергә Күрән бинең күңеле дә бушап калды. Ул нәрсә уйларга да, нәрсәгә барып тотынырга да белмәде. Анда сугылып, монда сугылып йөргәч, ул Басу-капка ягына юнәлде. Соңгы олаучының кайтуын койма өстендә көтеп торды, хан теркәүчеләре биргән тамгалы барчакны күздән кичерде.

— Тотыш турында әле дә берни ишетелмиме? — диде ул олаучыга.

— Юк, беркем берни белми,— диде олаучы.— Алар безнең белән җүнләп сөйләшмиләр дә.

Би артык сорашып тормады, атына атланды да өенә кайтып китте. Җиңелүе, таварлыкларының бушап калуы өчен күңелен игәгән кайгысы йомшарга да өлгермәде, аны инде яраланып теге якта калган углы өчен борчу тынычсызлый башлады. Ни булды аңа? Ник бирми аны Алмыш хан? Үлмәде ич ул! Үлсә, аны шундук кире бирерләр иде. Яраланды, аны имчеләр алып китте. Шулай булгач... Барып сорарга, ягы алдында баш иярга туры килер микәнни?

Үз урдасына якынлашып килгәндә, аны арттан бер җайдак куып җитте.

— Алмыш ханнан илчеләр килгән, би. Катауга кертүне сорыйлар,— диде җайдак.

— Илчеләр түгелдер алар, шымчылар,— диде би.— Теләнчегә көлә карасаң, ямаулык сорар. Тагын ни кирәк аларга?

Ул тун күнчегендәге барчакларны яңадан карарга, бармакларын бөгеп, түләнгән каланның күпме чыгуын яңадан санарга тотынды. Бер тиен артык түгел, бер тиен ким түгел! Чыннан да, ни кирәк аларга? Ул кире капка ягына борылды.

Капка каршында, урлар артында атка атланган өч ир тора иде. Койма өстенә менгән бине күргәч тә алар, ягымлы кыланып, баш иделәр, үзләрен катауга кертүне сорадылар.

— Сезне түгел, сезнең ханыгызны да мин катауга кертмәдем,— диде би, кукыраеп, кырыс кына.— Минем колак ерактан да ишетә. Әйтегез, ни йомыш?

— Безнең йомышны капка төбендә әйтмиләр, өйгә барып әйтәләр,— диде илчеләрнең берсе.

— Сез болай да минем өемдә,— диде Күрән би.

Илчеләр, бер-берсенә карашып, кинәшеп алдылар.

— Алайса, тыңла, Күрән би,— диде сакаллы карт, алгарак чыгып.— Болгар йортның башы Алмыш хан...

— Юк, Хазар йортның, изге каганның колы... илтәбире [2], Болгар йортның башы...— дип төзәтте Күрән би.

Илченең йөзе бозылып китте. Ул тагын үзенең юлдашларына карап алды да, өзелгән сүзен ялгап:

— ...Болгар йортының башы Алмыш хан сине, Акбүре ыруының башы Күрән би, хатыннарың, балаларың, туган-тумачаларың, якыннарың белән ашка чакыра.

---

[1] Барчак — квитанция.

[2] Илтәбир — Болгар ханның Хазар каганына бәйле икәнлеген аңлата торган титулы.

— Миннән талап алган байлыгын күрсәтергәме? — диде би усал итеп.

Ул үзенең илчеләр белән алай тупас сөйләшмәскә тиешлеген бик яхшы аңлады, шулай да берни эшли алмады. Әкренләп-әкренләп аның күңелендә бар нәрсәнең астын өскә китерә алырлык ачу-ярсу тойгысы кабара барды. Үзенең җиңелүе өчен ул, әйтерсең, илчеләрдән үч алырга җыена иде.

Аның тупаслыгына илчеләрнең ачуы килде.

— Күрән бине башлы, белекле дип сөйләгәннәрне — чын булмады бу,— диде илче карт.— Илчегә үлем юк. Без синә әйтергә кушылганны гына әйттек. Әйтү бездән, тыңлау-тыңламау — синнән. Алмыш хан синең белән татулашырга тели. Монысын да әйтергә боердылар. Сау бул, Күрән би.

— Сау булыгыз,— диде би теләр-теләмәс кенә.

Илчеләр, атларын борып, ашыкмыйча гына китеп бардылар. Алар көнбатышка таба, урман артында кичерәя барган кызыл-саргылт кояшка каршы киттеләр. Аларның алгы яклары, ян яклары утлы куз төсле кып-кызыл булып, аркалары кап-кара булып күренде. Артларыннан әз генә дә калышмыйча, иләмсез зур күләгәләре сөйрәлеп барды.

Илчеләр китеп баргач, бинең тагын да эче поша башлады. Илчеләрдән Тотыш турында сорарга башына килмәве өчен ул үз-үзен сүгеп ташлады. Аннары ул үзеннән талап алган икмәк белән үзен сыйларга җыенган Алмыш ханны, башлаган эшен җиренә җиткермичә кайтып киткән Ямгырчы бине сүкте. Шуннан соң ул бер дә юктан башын чайкап, авызлык тимерләрен чылтыраткан атын сүкте. Башка сүгәр нәрсә табылмады. «Тәңренең каргышы... Картайдым, беттем...» — дип уйлады ул, авыр сулап, караңгы бер төшенкелеккә бирелеп.

Кичке ашны, башка көннәрдәгечә, «ак өй» дип йөртелгән зур өйдә ашадылар. Ашка аның хатыннары, өлкән балалары, туганнары — барлыгы утызлап кеше җыелды. Барысы да үзләрен үлек чыккандагы кебек, кыен, уңайсыз сизделәр. Сөйләшми генә ашадылар, сөйләшми генә таралыштылар. Койтым бикә ашка бөтенләй килмәгән иде. Аны чирләп урында ята, диделәр.

Би аштан соң Койтым бикә өенә китте. Бикә, башын юеш сөлге белән урап, таудай өелгән мендәрләр, йомшак тиреләр өстендә ятып тора иде.

— Белештеңме, исәнме, үлеме? — диде бикә, беренче сүзе итеп.

— Кай җирең авырта? — диде би аңа.

— Мин синнән Тотышны сорыйм,— диде бикә, ыңгырашып.— Углың бүре базында калсын да, ничек таза булмак кирәк?!

— Шул гынамыни? — диде би, юри исе китмәгән сыман.

— Тагын ни? — диде бикә, башын калкытып.— Тире, күн? Бал? Утыз мең кешене син бер кышта табасың, югалган углыңны табарсыңмы?

— Югалмаган,— диде би, шул ук ялган бер пошмаучанлык белән.— Күреп тордың ич: имчеләр бәйләделәр, алып киттеләр. Беркая булмас.

— Шымчы җибәрергә кирәк — барсын, күрсен, сөйләшсен,— диде бикә.

— Шымчы? — диде би.— Әлерәк кенә Алмыш ханнан илчеләрме, шымчыларммы килде. Безне ашка чакырган, керген!

Койтым бикә, күзләрен зур ачып, аягына торып басты, башындагы сөлгесен атып бәрде.

— Син аларны борып җибәрдеңме?! — диде ул.

— Җибәрдем,— диде би.

— Кайчагында син минем эшемә кысыласың, би,— диде бикә, кызып.— Ашка чакырганнар икән, иң элек минем белән киңәшергә. Барасыңмы? Бармыйсыңмы? Үзем китәм!

— Үзең?!

— Үзем! — диде бикә, нык итеп.— Углым янына! Сакчылар бир. Җә Алмыш ханның канын коеп, углымны үзем белән алып кайтам, җә углым янында торып калам.

— Син беркая бармыйсың! — диде би, хатынының юлына аркылы төшеп.

— Үз углым янына барудан мине беркем тыялмас! — диде бикә.

## IX

Кан коймыйча гына ирешелгән җиңүгә багышлап Алмыш хан зур туй ясады.

Акбүреләрнең соңгы олавы урдага килеп җиткәндә, көтүчеләр урман буендагы болыннан һай-һулап бер көтү җылкы куып кайттылар. Сугымчылар атларны тота бардылар, тотылган берсен суя тордылар. Шунда ук тиресен тунадылар, эчен алдылар, юан бүкәннәргә салып, җылы итне чаба тордылар.

Чулман ярына килеп терәлгән ике сырт арасындагы киң болын өстендә әле анда, әле монда учаклар кабынды. Кычкырып көлгән, җырлаган, сүгенгән тавышлар ишетелде. Болын уртасында түгәрәкләнеп тезелеп утырган йөзләрчә ак тирмәләр, чатырлар арасында кораллы, коралсыз кешеләр кайнашты. Кешеләрнең аяк астында иснәнеп этләр чабышып йөрде. Урдадан читтә, урман буйларында, койрыкларын селтәп, бер-берсенә сыенеп, я булмаса үзара ызгышып, иксез-чиксез күп атлар йөрде. Юл өстендә, урман буйларында, Чулман ярында ханның, чирүнең тынычлыгын саклап, каравыллар йөреп торды.

Менә тиздән караңгы да төшә башлады. Көн батыш ягындагы урман читенә үкәлеп-ягылып калган кызыллык кай арададыр төтендәй очып юкка чыкты. Ерактагы урманнар, караеп, куерып, болынга, кешеләргә таба якынрак күченделәр. Тәкәшүр болынының Чулман ягында, бик зур болыт сыман булып, аксыл томан күтәрелде. Тирә-якны салкынча эңгер-меңгер чорнап алды. Үзләренең вак-төяк эшләре белән ыгы-зыгы килгән җир кешеләренә күктән җем-җем итеп йолдызлар күз кыстылар, бармак янадылар.

Авыр, озын юлдан соң, төрле кыенлыклардан соң болгарлар беренче тапкыр тынычлап, иркенләп туй иттеләр: туйганчы ашадылар, исергәнче эчтеләр, күңелләре булганчы җырладылар, биеделәр. Тик шунысы гына бераз эчне тырнады — калан түләгән Акбүре ыруының бер генә авылын да талап булмады. Хан таламаска боерык бирде.

Шау-шу, җыр-бию, уен-көлке төне буена тукталып тормады. Учакларда утлар янды, учакларда итләр кыздырылды. Дөпелдәгән, тыпырдаган аяклар астында мәңге тыныч, мәңге бөек җир йокымсырап ятты. Якында гына кешеләрнең кайгысын да, куанычын да... каннарын да, сөяк-санакларын да бик күп күргән, бик күп юган мәңге тере, мәңге бөек Чулман акты.

Чулман буеның чык каплаган яшел болынында, бер-бер артлы килеп юкка чыккан санаусыз җәйләрнең берсендә, санаусыз төннәрнең берсендә җиңүчеләр туй иттеләр...

Алмыш ханның мең кеше сыйдырышлы тирмәсендә аш-су башкаларныкына караганда да күңеллерәк, шау-шулырак булды.

Тирмә эчтән икегә бүленгән иде. Түгәрәк тирмәнең ишектән кергәч тә уң ягында — кечерәк өлешендә хатын-кызлар тора иде, бөтен өй эченең дүрттән өч өлешен алып торган сул ягы — ханның үзенеке, ирләрнеке санала иде. Монда хан үзенә килгән кешеләр белән, кунаклар белән очраша, шунда ук аш-сулар, төрле уеннар, күңел ачулар уздыра иде. Зур якның урта бер җирендәрәк, бөтен тирмәне тотып торган биек терәктән арырак, төрле төстәге ефәкләрдән баш өстенә киң чыбылдык корылган иде. Чыбылдык астына, иран, әрмән келәмнәре җәелгән җир

идәндә, сырлап, алтынлап бизәлгән биек түр утыртып куелган иде. Түрнең утыра торган җиренә рум ефәге капланган иде.

Шулай итеп, чакырылган кунак килмәде. Килмәсә килмәс! Кешеләр дә, кунаклар да ялыгып бетте — башларга кирәк.

Иң яхшы киемнәрен киенгән, чумаклар [1] йоласы буенча башына чалма ураган Алмыш хан, исле май исләре аңкытып, алтын-көмеш каптырмаларын ялтыратып, эчкәре бүлмәдән кунак бүлмәсенә — зур якка чыкты. Бераз гына калышып, аның артыннан Айкын хатын чыкты, аннары дүрт карачы [2] чыкты, биләр чыкты. Бераздан тирмәгә әкренләп-әкренләп кунаклар керә башлады.

Алмыш хан, йомшак итекләре белән йомшак кына басып, түр янына килде, кызыл тун итәкләрен җыештырып, биек урынга утырды. Ханның сул ягына, йомшак келәмгә, аякларын бөкләп, Айкын хатын утырды. Ире кебек ул озын буйлы, таза, симез бер хатын иде. Аның барлык киемсалымында — әле анда, әле монда, күк йөзендәге йолдызлар төсле булып, чын ташлар җемелдәшә иде. Тары бөртегедәй утлы ташлар аның өс-баш киемнәренә генә түгел, каюлы йомшак читек табаннарына да тегелгән иде — аякларын бөкләп утыргач, ул ташлар ялт та йолт килеп торалар иде. Аның ак, түгәрәк муенын бизәкле әрә төймәләр тезелгән матур муенса кысып тора иде. Башына ул чит-читләренә ас тиресе тотылган кечкенә очлы бүрек кигән иде. Бүрек астыннан чыгып торган ак, матур колакларына авыр алкалар тагылган иде.

Ханның уң ягына карачылар утырды. Алар да иң яхшы киемнәрен киенгәннәр, чәчләренә, сакал-мыекларына исле майлар сөртенгәннәр иде. Аларның да киемнәреннән алтын-көмешләр, чын ташлар ялтырап күренә иде.

Карачылар янына ыру башлары, хан-агасы, субашы урнашты. Айкын хатын ягына олы кунаклар, өлкәнрәк туган-тумачалар утырды. Түр алдына, чатыр уртасындагы терәккә табарак, зур бер төркем булып, Алмыш ханның унлап баласы — ир угланнар, кыз угланнар утырышты.

Болгар ханының башка туган-тумачалары, тарханнары, алыплары, аксакаллары, битекчеләре — барысы да үзләренә тиешле, билгеле урынны алдылар.

Кунакларның күпчелеге ирләр иде. Арада хатын-кызлар да, яшьләр дә, картлар да бар иде. Аларның барысы да күзнең явын алырдай ачык төстәге, төрле төстәге озын киемнәр кигәннәр, барысы да йомшак урыннарга аякларын бөкләп утырганнар. Алмыш хан белән Айкын хатыннан кала барлык кешеләр ялан баш иде — очлы бүрекләре, калпаклары култык астына кыстырылган иде. Ирләрнең дә, хатын-кызларның да чәчләре озын иде; икешәр-өчәр, дүртәр-бишәр үремнәргә үреп, аркаларына сузып салынган иде.

Кешеләр тавыш-тынсыз гына утырыштылар, тавыш-тынсыз гына көтә башладылар. Барысының да күзе уртага — биек түрдә калкып утырган олы кешегә текәлде.

## X

Кунаклар урнашып беткәч, Алмыш хан үзенең уң ягына борылды да бер читтә, карангыдарак басып торган кемгәдер ым какты. Ашыгып аның янына чандыр гына бер кеше — өй-агасы килеп җитте, баш иде.

— Китер,— диде хан әкрен генә.

Ачыккан кунаклар утырган урыннарында кыймылдашып алдылар, төкерекләрен йоттылар, борыннарын тарттылар. Ул арада ишегә ике ягыннан тотып, ике кеше тирмәгә зур гына өстәл кертте. Өстәлгә чигүле

[1] Чумак — мөселман.
[2] Карачы — министр.

ак ашъяулык җәелгән, ашъяулык өстенә — сай читле көмеш табак, табакка кыздырылган ит куелган иде.

Исле май, тир, сөрем исләрен күмеп, болындай киң, күк түбәседәй биек тирмә эченә кыздырылган ит исе таралды. Үзара сөйләшү, йөткерү, борын тарту тынып калды. Меңләгән күзләр, тирә-яктагы бар нәрсәне онытып, хан каршындагы өстәлне күзәттеләр.

Алмыш хан җиң очларын кайтарып куйды да, кайнар ит өстенә каплап ланган ак җәймәне алып, өй-агасына тоттырды. Көмеш табактагы пычагын алып, ярты арт санның иң тәмле, иң йомшак җиреннән бер кисәк ит кисте. Беркемгә карамыйча ул беренче кисәкне кабып та җибәрде. Шуннан соң икенче кисәкне, өченче кисәкне кисеп алды, ашады. Өченче кисәктән соң дүртенче кисәкне кисеп алды. Булары бөркеп, майлары тамып торган бу зур гына кисәкне ул үзенең хатынына сузды. Чыбылдык артыннан шундук кыска аяклы өстәл чыгардылар, өстәлне Айкын хатынның алдына куеп, тезләре өстенә ак сөлге җәйделәр.

Хатыныннан соң Алмыш хан үзенең уң ягындагы карачыларның берсенә ит кисеп бирде. Карачыга да аерым өстәл, сөлге, табак чыгарып куйдылар. Шулай итеп, хан үз тирәсенә ярым түгәрәкләнеп утырган якыннарына, кунакларына ит өләшеп бетерде дә аерым төркемдәге балаларына тарата башлады. Хан кулыннан ит алган барлык кешегә аерым өстәл бирелде. Кешеләр, бер-берсенә катнашмыйча, бер-берсенең эчен пошырмыйча, тыныч кына үз алларына ашый бирделәр.

Күз ачып йомганчы Алмыш хан бер арт санны ботарлап та ташлады. Көмеш табакта ялтырап бары күсәктәй дендер сөякләре генә торып калды. Сөякләрне ашчылар алып чыгып киттеләр. Анысы караларга, кыз-кыркынга, теләнчеләргә...

Сөяк-санак өелгән табакның күз алдыннан югалуы булды, аның урынына икенче табак белән икенче арт санны китереп, тагын хан алдына сузып салдылар. Алмыш хан анысын да бүлгәләргә тотынды. Аның кулында пычак уйнап кына торды. Шул ук авыкта унлап ашчы, көмеш табакларга салып, тагын зур-зур ит кисәкләре алып чыктылар, тиз-тиз атлап, тар аралыклардан арткарак уздылар. Аларга каршы икенче яктан өстәлләр китерделәр.

Ит күтәреп, өстәл күтәреп, кунаклар арасында тыз-быз чабып йөрүләр тиздән тынып калды. Кунаклар, алларына иелгән көе, бирелеп, онытылып, тәмле, яшь ит ашадылар, сөяк кимерделәр. Кемдер шунда өстәлгә куелган пычакка бәреп, җилек кагарга тотынды, кемдер, бик белекле булып: «ит ашасаң — тешкә керә, ашамасаң — төшкә керә», диештереп, каз каурые белән тешен казыштырды. Кайберләре, балаларга булыр дип, ашалып бетмәгән кисәкләрен куеннарына тыгып куйдылар.

Түшәменнән идәнгәчә төрле төстәге ефәкләр салынып төшкән, ак киезләренә төрле ау күренешләре, чабып барган атлар, үгезләр, бүреләр, боланнар төшерелгән, төрле бизәкләр белән чуарланган биек-якты тирмә эчендә берьюлы меңләгән авыз чапылдады, итләр чәйнәлде, көмеш табакларга тиеп сөякләр, пычаклар шакылдады. Җиңүчеләр туй иттеләр...

Тышта, төн карасын ярып, багана башларындагы пыскыйларда карамайлар янды. Хан тирмәсе тирәсендә, короллар тотып, сакчылар йөренеп торды. Ишек янында бераз гына тукталып тордылар да, алмашлап «теге якка» — пешекчеләр, ашчылар, аякчылар кайнаша торган якка барып әйләнделәр, ашыга-ашыга калдык-постыкларны ашадылар. Шунда ук теләнчеләр, аксак-туксаклар, каралар... тамагы ач башка төрле ыбыр-чыбыр ялманды. Алар инде башка тирмәләр, башка учаклар янында булырга да өлгергәннәр, анда да сөяк-санак кимергәннәр, я булмаса бер-ике кабымлык ит эләктергәннәр, кайберләре исә тамак чылатып та алганнар. Чынында инде аларның тамагы күптән туйган. Аларның бары хан табагыннан, хан кулы тигән сөяк-санаклардан гына

авыз итәселәре килә. Аннары алар туйның иң кызган чагын көтәләр. Анда инде башкасы да тамып куячак. Ачы бал, буза... мул булып тамачак. Акбүреңә җиңгән Алмыш хан, күңеле йомшарып, аяк астында чуалган «бәдүнгә» бүләк өләшә калса, анысы инде тагын да яхшырак булачак! Йа тәңрем, ханыбызның күңелен юмарт кылгыл, ашчыларны, сакчыларны сукыр кылгыл!

## XI

Хан тирмәсенең тышкы ишеге кинәт ачылып китте, утка баскан песидәй ашыгып, ишектән өй-агасы килеп чыкты. Аның чандыр буен, салынып төшкән озын мыегын күрү белән, кулларына сөяк тоткан сакчылар майга буялган авыз читләрен ялмаштырып, тизрәк читкә тайпылдылар. Ярлы-ябагай, аксак-туксак, тилгән күргән чебиләр кук, як-якка сибелде. Караңгыга китеп постылар да, уттай янган бүре күзләрен елтыратып, өй-агасының яңадан биек, комсыз, убырлы тирмә эченә кереп юк булуын көтә башладылар. Өй-агасы исә тиз генә кереп китәргә ашыкмады.

— Комыш! Серкәч! — дип кычкырды ул, кемнәргәдер кул изәп.

Аякчылар — Комыш белән Серкәч — якындагы чатырдан зур корсаклы агач чапчаклар күтәреп чыктылар. Чапчакларның берсен ишек төбенә утыртып куйдылар, икенчесен туп-туры хан өстәленә кертеп утырттылар. Шул ук мәлдә икенче яктан икенче аякчылар көмеш аяклар алып керделәр. Алмыш хан үзенең алтын аягын кулына алды, чапчакның бөкесен ачып җибәрде дә нечкә билле, зур авызлы аякка күбекләнеп торган сычук агызды. Беренче аякны ул үзе эчте. Тамагын кырыштырып, авыз читләрен сөрткәләп, икенче аякны тутырды. Монысын ул эчмәде, тулы килеш кулына тотып, аягүрә басты. Ул баскач, башкалар да урыннарыннан тордылар.

— Туганнар! Агай-эне... Ил агалары, кунаклар! — диде ул яңгыравыклы көр тавыш белән.— Бүгенге олы җиңүгә багышлап күңел ачыйк!

Шул сүзләрне әйткәч, ул кире урынына утырды. Аның артыннан бүтәннәр дә утырдылар. Бөтен чатыр эче тынып калгач, шул ук тулы аякны тотып, болгар ханы икенче тапкыр урыныннан торды. Кунаклар да торды. Хан баштагы сүзләрен яңабаштан кабатлады. Шуннан соң ул тагын утырды.

Өченче кат аягүрә баскач, күңел ачу турындагы сүзләр кабатлангач, яңадан утыргач, сычук белән сыйлану башланды. Ачы балны хан, ит өләшкәндәге кебек, кунакларына үзе агызды. Ханнан ераграк утырган кунакларны аякчылар сыйлады. Алар ханны күзәтеп кенә тордылар: йорт башы бал агызса — агыздылар, туктаса — туктадылар. Аннан узып берни эшләнмәде.

Барлык кунаклар да беренче кат сычук эчкәч, кемнедер эзләп Алмыш хан кунакларга күз йөртеп чыкты.

— Корыч-Тимер, кил бире! — диде ул, каядыр читкә, тирәктән уң яккарак кул изәп.

Үз атын ишетеп, көяз, чибәр егет атылып урыныннан торды, бер-ике сикерүдә хан каршына барып та житте. Ул аның аягы астына егылды.

— Тор. Мә, тот шуны,— диде хан, кулындагы көмеш аякны җиңүчегә сузып.

— Олтаның булыйм, ханым-атам! — диде Корыч-Тимер.

Хан биргән аякны ул, әһ тә итмичә, авызына каплады да, эре генә елмаеп, кунакларга борылып карады, тагын нәрсәдер көткән сыман, беравык урынында тоткарланып торды. Шуннан башка берни әләкмәячәген аңлап, йөзендәге елмаюын сүндермичә, ул әкрен генә үз урынына юнәлде. Кунаклар аңа кызыгып-көнләшеп карап калдылар. Читтәрәк, ерактарак утырганнар исә җиңүченең яман атын саттылар.

Яшь алыпны сыйлаганнан соң хан кунакларга икенче кат сычук агызырга тотынды. Икенче аяктан соң кунакларның йөзләре ачыла, телләре чишелә төште. Кешеләр үзара кычкырыбрак, иркенләбрәк сөйләштеләр. Аларның күңелләрен, билгеле, ике аяк сычук кына күтәрмәде. Аннан да бигрәк, бүген йорт башының йөзе якты иде. Менә ул шаяртып янындагы карачыга нидер әйтеп куйды, карачы елмаеп җибәрде. Ханның шаяртуы кунакларга караңгы төндә кояш балкып киткәндәй тоелды. Кешеләр кыюлана төштеләр, кычкырыбрак сөйләшергә, гөрләшергә тотындылар. Яшь, матур тавышлы ниндидер хатын-кыз, барысына ишетелерлек итеп, чыңлатып көлеп җибәрде.

Торган саен туй кыза барды. Аякчылар кунаклар арасында йөгереп кенә йөрделәр.

## XII

Алмыш хан елмаеп тагын өй-агасына кул изәде. Өй-агасы тавыш-тынсыз шундук күздән югалды. Күп тә үтмәде, сорнай, думбыра, курай, кубыз ише уен кораллары тотып, арткы ишектән көйчеләр килеп керде.

Алар барысы да ирләр иде, барысы да бер төслерәк итеп киенгәннәр иде. Аларның ярлы гына туннары да, башларындагы очлы бүрекләре, аякларындагы итекләре дә хан кунакларыннан аерылып тора иде.

Көйчеләр, кыр казлары шикелле бер-бер артлы тезелеп, түр янына килделәр, ханга баш иделәр, бүрекләрен салып, тезләнгәндәй иттеләр, янадан билләрен турайттылар. Артларына борылып алар кунаклар белән дә баш иеп, бил бөгеп исәнләштеләр, аннары, аякларын бөкләп, йомшак паласларга тезелешеп утырдылар. Көйчеләр җиңелчә генә коралларына чиртеп алдылар, барысы да бердәм булып йорт башын, аның кунакларын котлап, көй башлап җибәрделәр.

Мең кешелек болындай өй эче, базар кебек шаулаган, гөрләгән өй эче, тыңларга җыенып, тып-тын калды. Кешеләр күз алдында үзгәрделәр. Күршеләр онытылды, хан онытылды. Ашау-эчүләр, кайгы-куанычлар — барысы да каядыр юкка чыкты. Күз алдында — артта, алда, ян-якларда — бөтен тирмә эчендә бары көчле, моңлы көй дә, бер үк теләк белән янган бер үк тойгылар белән тибрәнгән күңелләр генә торып калды.

Котлау көйләреннән соң, бары җиңү туйларында гына яңгырый торган «Без җиңдек» дип аталган сугышчан көй уйналды. Көйчеләр үз чамаларын белеп кырыс кешеләрнең каткан күңелләрен шулай кузгатып алдылар да туктап калдылар. Пыскыйлардагы утларны, югарыдагы төннеккә үрләгән сөрем баганаларын тетрәндереп, чатыр эчендә көчле алкыш яңгырады, мактап әйтелгән сүзләр ишетелде. Алмыш хан, күрәсең, чамадан тыш күңеле нечкәреп, көйчеләргә бакыр ярмаклар чәчте. Аннан күрмәкче кунаклар да җиң очларына тыгылдылар, чылтыратып акчалар сиптеләр.

Җинел көйләрдән соң көйчеләр бер-ике озын көй уйнадылар. Болары Алмыш ханның иң яраткан көйләре иде. Аларны ул бары зур туйларда гына, аннары күңеле аеруча күтәренке чакларда гына уйната иде. Ин ахырда ул аягына басты, Лачын көйчегә — көйчеләрнең өлкәненә — үз кулы белән сычук бирде.

— Бай бул, ханым,— диде Лачын көйче, эчеп, баш иеп.

Бүтән көйчеләрне аякчылар сыйлады. Алар идәнгә, келәм өстенә чәчелгән акчаларын җыештырдылар да, тезелешеп ишеккә юнәлделәр.

Көйчеләрдән соң хан тирмәсенә ике кеше килеп керде. Алар да ханга баш иделәр, тезләнгәндәй иттеләр, аннары кунаклар ягына борылып, кунаклар белән дә исәнләштеләр дә, нык яктыртылган ачык урында, бер-берсенә кара-каршы баскан килеш тынып калдылар. Болар чәчәннәр

иде. Алмыш ханның бүгенге җиңүенә багышлап алар кошуг [1] әйтергә тиешләр иде.

Аларның берсе — тыныч-салкын йөзлесе — урта яшьләрдән узган, инде картая, симерә башлаган бер кеше иде. Аның чал кергән озын чәчләре бер генә үремгә үрелгән. Өстенә ул сарыга манылган озын итәкле алача тун кигән. Бил каешының көмеш каптырмасына җиз сандугач сурәте төшерелгән иде. Бу исә аның сандугачтай татлы телле, булдыклы чәчән икәнлеген белдереп тора иде.

Чәчәннәрнең икенчесе тар күкрәкле, чандыр гына, йолкыш кына яшь бер егет иде. Аның дымланып торган зур, зәңгәр күзләре тынгысыз иде. Ул, әйтерсең, үзенә үзе урын тапмый иде. Ул мондагы беркемгә дә туры карамый — житез күз карашын әле түшәмгә, әле үзенең итек башына, әле чыбылдыклардагы төрле бизәкләргә юнәлтә иде. Үзе тик кенә басып торган шикелле күренсә дә, думбыра тоткан нечкә ак бармаклары аның ирексездән кыймылдап-кыймылдап ала иде. Аның ябык бит очлары бер кызара, бер агара — күрәсең, хан алдында аның әле беренче чыгышы иде.

Кошуг әйтүне өлкән чәчән Турай башлады. Алтын бизәкле биек түр ягыннан күзен алмыйча, ул, сорнаена чиртә-чиртә, җиңел генә такмакларга тотынды. Кошугының башында ул Алмыш ханга, аның ише Айкын хатынга, ханның туган-тумачаларына, балаларына исәнлек-саулык теләде. Аннары карачыларга, биләргә, ыру башларына, тарханнарга исәнлек, бөтен Болгар йортка байлык, тынычлык теләде. Шуннан соң ул Алмыш ханның «кайнар чүлләрдән бозлы тагларгача» булган иксез-чиксез биләмәләрен санап чыкты; аның кул астында булган, аңа калан түләгән улусларны: чирмешләрне, мукшы, ар, башгыртларны, угызларны, кыпчак, каңгылы, буртасларны телгә алды. Аннары болгарларның иң атаклы биләрен, ыру башларын, тарханнарын, алыпларын санады. Аларны ул яхшы өердәге яхшы атлар белән чагыштырды. «Өернең дә иң башында... яхшылардан яхшысы — син, көчленең дә көчлесе — син, башлының да башлысы — син, Алмыш хан, син — атабыз, йөрәгебез, башыбыз, күз өстендә кашыбыз», диде. «Тәңре каргаган Хазар каганы булмаса... Бөек Этил, Чулман, ике тиңгез арасындагы Каф тавы — урманнар, язылар, улуслар — барысы да синең кулда булыр ирде, диде... Алла сиңа бетмәс-төкәнмәс көч бирсен, байлык бирсен, ягыларың җиңелсен — барчасы аяк астында калсын», диде.

Турай чәчәннең кошугы шулай бик озын, бик күңелсез булды. Монда утырган кешеләрнең күбесе аның нәрсә әйтерен алдан ук белеп торалар иде. Шулай да алар бик түземлек белән тыңладылар. Алмыш хан, киресенчә, таныш сүзләрне беренче ишеткән кебек, бирелеп, онытылып тыңлады — үзен мактаганны, бигрәк тә «иксез-чиксез» биләмәләрне, үзенә калан түләгән ыруларны телгә алганны ул аеруча ярата иде. Турай чәчән санап киткән «биләмәләр»нең күбесе чынында әле аныкы түгел, ул бары аларны яулап алу турында гына уйлый иде. Бу «иксез-чиксез биләмәләр» турындагы сүзләр чынында болгарларның үзләре өчен түгел, чит илләрдән килгән кунаклар өчен — Хәрәзем, Хытай, Синд, Рум [2], Багдад якларыннан килгән сатучылар өчен әйтелә иде.

Менә Турай чәчән кайберәүләргә билгеле, кайберәүләргә билгесез булган нәрсәләрне санап чыкты да соңгы җиңүне мактауга күчте. Чатыр эчендәге җиңелчә гөрелдек тынып калды. Колаклар үрә торды, күз карашларында кызыксыну билгесе күренде. Ни әйтер икән, нинди яңа чагыштырулар, нинди тапкыр сүзләре белән куандырыр икән өлкән чәчән бүген аларны?

---

[1] Кошуг — шигырь.
[2] Хәрәзем — Урта Азиядәге (хәзерге Кара-Калпак АССР) бер дәүләт; Хытай — Кытай; Синд — Һиндстан; Рум — Византия.

Кунаклар гына түгел, моңарчы Турай чәчәнгә күрәләтә ачуы килеп, үртәлеп торган яшь чәчән дә сагая калды. Думбырасының кылыдай тартылган нечкә муенын сузып ул үзенең юлдашына текәлде.

— «Акбүренең Тотыш атлы эттән туган...» — дип башлады Турай чәчән, сорнаеп чиртеп.

— «Акбүренең Тотыш атлы арысланы!» — диде яшь чәчән, аның сүзен бүлдереп.

Бу сүзләрне ул бераз гына ашыгып, үртәлеп әйтте. Турай чәчәннен йокы китергеч көйләвенә күнегеп оеп утырган кешеләр кинәт сискәнеп киттеләр. Барысы да чандыр яшь чәчәнгә борылды. Яшь егет аларның кызыксынуын шундук тоеп алды, чатнап торган яшь тавыш белән чакчак кына каушап, җилкенеп кошуг әйтә-әйтә, думбырасын ныграк чиртә башлады. Турай чәчән, кызарынып-бүртенеп, аның белән сүз көрәштерергә итеп караган иде дә булдыра алмады. Яшь егетнең тавышы торган саен ипләнә, ныгый барды, тапкыр сүзләре, урынлы чагыштырулары атылган ук кебек, утлы тимердән чәчрәгән очкыннар кебек, чатыр эченә туктаусыз сибелүендә булды.

Ул күрәләтә Тотыш угланны мактады. Бер яуда да җиңелмәгән, болгарларның терәге булган Чәкән алпагытны, Будрач сукманны «күккә олактырган», «үлем белән ук атышкан», «күп ирләрне таң калдырган» яшь бөркетне мактады. Әле аны көчле барыс белән, әле кызыл төлке белән, бүре, шоңкар белән чагыштырды.

Яшь егетнең кыюлыгына кунакларның исе китте. Бераз гына куркып, пошынып, тын да алмый алар тыңлап утырдылар. Хан каршында әле беркемнең дә мондый туры, чын кошуг әйтергә батырчылык иткәне юк иде! Каян килгән бу? Кем моның атасы, анасы? Кайсы ырудан, кайсы улустан бу чәчән?!

Чәчәннең теле телгә йокмады, кулы кулга йокмады. Шулай ул меңләгән кешене кызган табада утырткандай, авызына каратып, очкынлы сүзләрен як-якка чәчте-чәчте дә сүзне кинәт икенче якка борып җибәрде: Чәкән алпагыт белән Будрач сукманның үлеменә кызгану белдерде, Алмаш ханның, бөтен Болгар йортның кайгысын уртаклашты. Шуннан соң күзләрен күккә текәде дә: бу — тәңренең язмышы, хан, диде; карт агачны аударганга урман корымый, диде, карт урынына яшьләр үсә, аталарның кылычын балалары ала, «Чәкән үлсә — Тотышың бар, Будрач үлсә — Корыч-Тимер», диде дә йорт башына байлык-саулык теләп, тынып калды.

Соңгы сүзләре белән ул кузгатылган тынычсыз күңелләрне бераз гына йомшарткандай итте. Шулай да ханны узып беркемнең дә кул чабарга кыюлыгы җитмәде. Болындай тирмә эчендә меңләгән ирләр, илме, яумы буласын белмичә, тыннарын кысып, шым гына утыра бирделәр. Алмыш ханның йөзен кара болыт басты. Ул да, башкалар кебек, нишләргә белмичә, тораташтай катып тик утырды. Соңгы орышта үзенең батырлары үлгәч тә ул бу тикле аптырашта калмаган иде бугай!

Тын кысып, йөрәкне учка йомарлап утыру шактый озакка сузылды. Менә хан утырган урынында кымшанып куйды, җиң очыннан ярты уч чамасы бакыр акча алды да теләр-теләмәс кенә чәчәннәр аягы астына сипте. Ул чәчәннәрнең икесенә дә сычук бирергә кушты, аннары үзе ашыгып буза чиләгенә тотынды — аның бар нәрсәсен онытып эчәсе килде.

## XIII

Яшь чәчәннең кошугы Алмыш ханның болай да күңел түрендә генә торган кайгысын кузгатты. Аның күз алдында шундук орыш күренешләре яңарды. Яшь чәчән, әле генә үткән канлы орышны күз алдына бастырып, әйтерсең, болгарларның макталган алыпларын икенче кат үтереп чыкты! Аның туры, тапкыр сүзләре йөрәген телеп-телеп алды, өтеп-

өтеп алды. Алай гына да түгел, ханга ул үзе Тотыш углан булып тоелды.

Туйның ямен җибәрмәс өчен, ул тешен кысып булса да түзәргә булды. Шулай да туйның яме инде бозылып өлгергән иде. Кешеләрнең күңелен буза гына күтәрә алмады.

Тирмәдә озак кына киеренке тынлык сакланды. Ханның холкын яхшы белгән өй-агасы, аяк очларына гына басып, түр янына килде дә, ниндидер зур, яшерен сере бар кебек, аның колагына нелә төште.

— Рум базарганының яшь кызлары бар... Күрсәтсен шуларны? — диде ул, пышылдап.

— Күрсәтсен,— диде хан, кушыла язган калын кашларын бер-берсеннән аерып.

Хан янәшәсендә, чит ил кунаклары арасында утырган рум базарганы зур корсаклы, юан, озын бер кеше иде. Аның нявен, ияк асларын, чигәләрен — башының күз-колактан, авыз-борыннан кала барлык буш урынын кара сакал-мыек, чәч-төк каплаган иде. Шул куе чәч-төк, сакал-мыек урманы арасыннан кыя таудай булып аның зур, кәкре борыны тырпаеп тора иде дә, барлык нәрсәне ашардай булып, комсызланып карый торган ак бәбәкле шар күзләре елтырап күренә иде. Аның симез, юан муенына нечкә генә алтын чылбыр, чылбыр очына — кечкенә алтын тәре тагылган иде.

Өй-агасының әйткәнен төшенеп алгач та ул, зур, симез куллары белән тезләренә таянып, шактый җинел аягына басты, шактый җинел атлап, ишеккә юнәлде.

Бераздан ишек янадан ачылды. Ачык ишектән караңгы төн кисәге, караңгы төн кисәгендә — кызлар шәүләсе күренеп калды. Шул ук мәлдә колакларга тыштагы җыр тавышлары килеп бәрелде. Кызлар бер-бер артлы тирмә эченә керә тордылар, аллы-кызыллы, яшелле келәмнәр җәелгән киң сукмак буенча уртага, хан утырган түр каршысына килә тордылар. Уртадагы көчле яктыдан, ут яктысында ялт-йолт килгән алтын-көмешләрдән, чын ташлардан аларның күзләре чагылды. Бу тикле яктыга, бу тикле бай киемнәргә, алтын-көмештән дә, чын ташлардан да көчлерәк янган утлы карашларга тиз генә күнегә алмыйча, алар күзләрен йомдылар, башларын иделәр.

Алар барысы да яшьләр, озын буйлылар иде. Аларның барысының да күзләре зур, кайсыныкы кара, кайсыныкы зәңгәр иде. Озын чәчләре, нечкә кашлары карга канатыдай, пыскый корымыдай чем-кара иде. Озын сылу муеннары яңа сауган сөттәй ап-ак иде. Өсләренә алар итәкләре бик үк озын булмаган, үтә күренмәле зәңгәрсу ефәк бөркәнчекләр бөркәнгәннәр иде. Аларның өстендә, башында, аягында шул юка бөркәнчектән башка бүтән берни юк иде. Юка бөркәнчек аша аларның яшь, сылу буйлары, алмадай тыгыз күкрәкләре, сыгылмалы билләре — тәңре яраткан барлык төгәл, тулы сыннары күзгә бәрелеп тора иде.

Ишекнең бу ягында кызларны карап, санап кертеп торган, баштан-аяк кара киемле рум базарганы, «җитте!» дигән кебек, тыштагы кемгәдер кул изәде, ишекне япты да койрыктагы кыз артыннан килә башлады. Аннары, уртага тезелгән кызлар арасыннан хан катына чыкты да баш орды.

— Болгар йортның олук каны,— диде ул, төрек сүзләрен ватып-җимереп,— мена синга минен тавар. Без, рум базарганнары, кол кызларны сездән... болгарлардан яратып алабыз. Минен илдә, Румда, Кустантин торамызда болгар кызларын яратып алалар. Сездекедәй шибәр кызлар беркайда юк, олук кан! Мин синга кояшта пешкән өз кыздарымды алып килдем. Бик сылударын. Тәлим иллә рдән җыйдым синен үчен, олук каным! Барлыгы унжиде баш. Үчесе юлда өлде, салкынга чыдамайча. Булары иң чыдамдары, сылудары. Чирләре юк. Теш-

ләре, күзләре таза. Берсе дә кылынмаган. Кылыклары юаш, күндәм. Кул эшен, үй эшен, жырны, биюне беләләр, думбыра чирталәр. Бишесе Румнан, дүртесе Лангабардан[1], әнә каршындагы иң көркәме — Андалустан[2], аннары тагын икәү бар... Бишесе төрекчә белә.

— Күрсәт,— диде хан, базарганның мактавына гына ышанмыйча.

Юан корсаклы рум сатучысы үз телендә кызларга нәрсәдер әйтте. Бер тирәгәрәк өелешеп торган кызлар кыймылдап куйдылар. Берәүләре, түр яныннан узып, олуг кунаклар каршыннан атлап киттеләр, икенче берәүләре әле генә кергән ишеккә таба атлагандай иттеләр дә борылгалап кире килделәр. Кайберләре исә баскан урыннарында торып калды. Алар, очарга жыенган кошлар сыман, ак беләкләрен як-якка сузып жибәрделәр. Өсләрендәге бөркәнчекләре, жиңел генә жилләнеп, идәнгә очып төште. Йөзен кара сакал-мыек баскан рум базаргяны, юан, симез куллары белән аларның билләреннән, беләкләреннән тотты, әле алай, әле болай боргалап, ханга аларны яхшырак карарга булышты, тегесен-монысын әйтеп торды.

Алмыш хан аны бик үк тынламады да — кол кызлар сайлауда аның белеме житәрлек иде. Рум сатучысы чыннан да ялганламый иде, ахрысы. Тавар чыннан да яхшы иде.

— Минеке! — диде Алмыш хан, рум кешесе әйткән Андалус кызын ошатып.

— Бай бул, олук кан! — диде базарган, бишкә бөгелеп.

— Калганнарын чыгарып тор, иртәгә көн яктысында карармын,— диде Алмыш хан.— Тияре турында да шунда сөйләшербез.

— Мин сиңа әйтмәдемме, олук кан? Мин боларды сатмасмын! — диде базарган, кара чытырман арасыннан эре ак тешләрен елтыратып.

— Сатмыйсың?!

Рум кешесе ханның соравын ишетмәскә салышты. Чылбыр очындагы кечкенә алтын тәресен уч төбендә сикерткәләп, ялагайланып, көтмәгәндә ул Болгар ханын мактарга тотынды.

— Олук кан! — диде ул.— Синен илен зур, жирен-суын көп, байлыгын житәрлек. Бу салкын якларда сез, болгарлар, барлык телләр[3], улуслар арасында алга киттегез. Сине, олук Алмыш кан, безнен Рум илендә яхшы беләләр. Рум кайсары[4] синен мән туган булырга тели. Башка беркайда очрамас бу сылу кыздарды ул синга бүләккә жибәрде!

Базарганның соңгы сүзләрен ишетү белән, ханның да, кунакларның да йөзләре яктырып китте. Болгарлар, үзләренең ханнары өчен куанып, кукыраеп, бер-берсенә карашып алдылар, телләрен шартлаттылар. Рум кайсары нинди шәп бүләкләр жибәргән, ә! Кара син аны! Кызлары ла, кызлары, бер кашык су белән йотарлык! Уттай янып торалар! Ул күзләр, ул кашлар, ул буйлар! Ах!.. Болгар ханының мондый бүләк алганы юк иде әле. Изгегә генә булсын эшләр, тәңрем-аллам!

Мондый чибәр бүләкләргә Алмыш ханның үзенең дә авызы ерылазып калды. Шулай да ул үзенең олылыгын сакларга тиеш булды. Ул бары тамагын гына кырып куйды да сакалын гына сыйпаштырды. Рум кешесенә ул үз кулы белән агызып сычук бирде.

— Рум кайсарының иле тыныч, байлыгы мул булсын! — диде хан.

— Бай бул, олук кан! — диде базарган, елмаеп.— Кайсарның синга тагын битеге бар, тагын...

— Иртәгә,— диде хан, кулын селтәп.

Базарган баш иде, елмаюын сакал-мыек арасына яшерде дә, чыгарга кушып, кызларга баш какты. Кызлар, иңбашларына бөркәнчекләрен

[1] Лангабар — Италия.
[2] Андалус — Испания.
[3] Тел — монда милләт мәгънәсендә.
[4] Кайсар — император.

каплап, вак-вак атлап ишеккә таба китеп бардылар. Аларны рум сатучысы гына түгел, хан кешеләре дә озата чыктылар.

— Корыч-Тимер! — диде Алмыш хан, яңадан яшь батырны чакырып.

Корыч-Тимер, киек сизгән аучы кебек, бүләк төшәсен сизенеп, алдындагы өстәлен-ниен аударып урыныннан торды да, күршеләренә бәрелә-сугыла, түр янына ташланды.

— Бу кызны мин сиңа бүләк итәм,— диде хан, башын иеп, яктыда, урта бер җирдә басып торган кол кызга күрсәтеп.

— Бай бул, ханым! Күп яшь бирсен сиңа тәңрем... алла! — диде Корыч-Тимер, куанычыннан кояштай балкып.

Ул, ханның әйткәнен дә көтмәстән, куйчы капкан бүре кебек, бүләген кочагына алды, кешеләр арасыннан, зур чатыр аша үз урынына чапты. Алмыш ханның юмартлыгы, яшь егетнең чиксез куанычы башкаларга да йокты. Туй янадан баштагы күтәренкелегенә кайтты. Кызмача хан кызмача кунакларга тагын бер аяк буза агызырга кушты.

Җиңү туе шау-гөр килде.

## XIV

Сырт өстендәге юлдан сулга борылып, вак куаклар янына килеп җиткәч тә, Койтым бикәне болгар күзәтчеләре туктатты. Унлап ир-ат каяндыр караңгыдан килеп чыктылар да тавыш-тынсыз гына аларның юлларына аркылы төштеләр, төрле яктан уратып алдылар.

— Ым?[1] — диде күзәтчеләрнең алдагысы, сөңгесен югары күтәреп.

— Мин — Акбүре ыруының башы Күрән бинең хатыны,— диде бикә, көттеребрәк, битенә капланган бөркәнчеген чак-чак кына ачып.— Мин Алмыш ханга барам.

— Үзең генәме? — диде бер күзәтче, күрәсең, алай башы.

— Үзем генә,— диде бикә.— Болары минем сакчыларым.

— Сезне бүген туйга чакырганнарые, шунда барасыңмыни? — диде алай башы.

— Мин болай гына барам. Минем улым Тотыш — хан кулында.

— Тотыш?

— Ә-ә! — диештеләр күзәтчеләр үзара гөрелдәшеп. Аларның бу гөрелдәшүләрендә Тотышка карата олылау сизелде.

— Алайса, син Тотыш алыпның анасымыни? — диде алай башы, кызыксыну белдереп.

— Мәнә ичмасам орышты! Күпме яшәп шундый батырны күргәнем югые.

— Чәкәнгә каршы чыгарга йөрәге җиткән үзе генә дә батырлык!

— Үзе шундый яшь, чибәр! — диештеләр күзәтчеләр.

— Сез мине җибәрәсезме? — диде Койтым бикә.

— Нирәк шул,— диде алай башы.— Ярар, барыгыз. Алай Тотышның анасы да булгач.

Төнге күзәтчеләр, аларга юл биреп, як-якка таралдылар. Койтым бикә үз кешеләре белән тавыш-тынсыз гына кузгалып китте. Алар берничә адым ераклашырга да өлгермәделәр, алай башының арттан:

— Әй, туктагыз әле! — дигән тавышы ишетелде.

— Мәнә Кудаш сезне озатып куяр,— диде алай башы, якынаеп.— Юкса, хан урдасына җиткәнче сезне адым саен туктатачаклар.

— Озатсын,— диде бикә.

Аларны чыннан да адым саен диярлек туктаттылар: әледән-әле караңгыдан каравылчылар килеп чыкты. Алар барысы да ым сорадылар. Озатучы аларга бер-ике сүз белән генә әйтте дә, төнге кунаклар

[1] Ым — пороль.

янадан кузгалып киттеләр. Хан тирмәсе янында Кудаш аларны каравыл башына тапшырды. Каравыл башы Койтым бикәне юлдашлары белән аерым тирмәгә алып керде. Ул аларга көтеп торырга кушты.

— Минем турыда ханга җиткерәсенме? — диде бикә.

— Юк,— диде каравыл башы.— Сезне туйга чакырдылар. Килмәдегез. Соңга калган беркем хан тирмәсенә кертелми. Аш-су беткәнче, кунаклар таралганчы көтеп торырга туры килер.

— Алай икән...— диде бикә таркау гына, бөтенләй икенче бер нәрсә турында уйланып.

Кайчанга тикле көтәргә? Кунаклар әллә таң атканчы таралышмаслар. Юк инде, көтәргә икән, көтәргә! Кайчанга чаклы булса да. Ул монда буш кул белән кайтыр өчен килмәде. Кайда булыр аның углы? Кайдадыр шушында... Ничек коткарырга аны? Ничек алдарга сакчыларны? Ничек катауга кире кайтарырга? Кайткач нишләргә? Туктале, нишләптер башы буталды әле аның. Кайчан бетәр бу туй, кайчан ул аны... ханнымы, углынмы күрә алыр?

Койтым бикәнең күңеленә шундый уйлар килде. Тотышны коткару өчен үзенең нишләргә тиешлеген ул әле булса ачык кына күз алдына китерә алмады. Ул бары аны йолып алырга тиешлеген генә, үзен, углын, ыруын — ике ыруын да! — утка салган явыз кешене күргәч, аны нидер эшләтергә тиешлеген генә аңлады. Ул әледән-әле куенына кулын тыгып, кәзлек [1] сабын тотып-тотып карады. Ярый әле аны тентемәделәр!

Көтеп тору Койтым бикә уйлаганча ук озакка сузылмады. Төн уртасы узып, җәйге караңгылык тарала башлаганда, хан тирмәсеннән җиңелчә шаулашып кунаклар чыкканы ишетелде. Каравыл башы, Алмыш хан йокларга ятканчы дип, ашыгып, Койтым бикә турында әйтергә китте.

Күп тә үтмәде, каравыл башы кире килде, бикәне хан янына алып китте. Тышкы ишектән кергәч тә бикә иң әлек ак киезләр җәелгән тар гына аралыктан барды, аннары сулга борылды, уңга борылды да, кечерәк кенә дүрткел бүлмәдә туктап калды. Бүлмәдә бизәкле нечкә баганалар башына утыртылган пыскыйлар янып тора иде. Там буена йомшак утыргычлар куелган, идәнгә бизәкле киез җәелгән иде.

Каравыл башы, каршыдагы ишеккә башын тыгып, керергә ярыйммы икәнлеген сорады, шуннан соң ул, башын кире алып, керергә ярағанлыгын әйтте. Бикә аның нәрсә әйткәнен аңламады, йомшак урынында оеп тик утырды. Бу серле тирмәдә, тышкы яктан бернинди тавыш-тын ишетелми торган бу киезләр арасында, үзенең барлык күңел тынычлыгын алган явыз кеше янәшәсендә ул кинәт үзгәрә башлады. Тиктомалга аның аяклары карышты, куллары авырайды, йөрәге никтер куркып-өркеп тибәргә тотынды.

Иа тәңрем, нәрсә бу? Барлык тереклек иясендә була торган бер курку-өркү генәме бу?.. Үзеңнән көчлерәк, баерак булган барлык кешеләрдән курку-өркү шикелле генә курку-өркүме, әллә соң монда тагын бүтән нәрсә дә бармы?

Койтым бикә урынына берекәндәй утырганда, каршыдагы ишек үзе ачылып китте. Чүлмәккә кычкырган сыман калын, көр тавыш белән таныш кеше:

— Кем бар анда? Керсен! — дип кычкырып җибәрде.

## XV

Алмыш ханның «яшел бүлмә» дип аталган йокы бүлмәсе әле генә бикә утырган дүрткел бүлмәдән икеләтә, өчләтә зур иде. Тамнарга тоташ яшел ефәкләр эленгән. Түшәмнән дә, чыбылдык кебек булып,

[1] Кәзлек — хатын-кыз хәнҗәре.

ык төстәге яшел ефәк салынып тора. Идәнгә бизәкле зур иран пала-
жәелгән. Ишеккә каршы якта имән агачыннан сырлап, матурлап
алган кин, биек ятак урыны калкып тора иде. Ятак турысына ак
эккә кара белән, гарәп ижекләре белән изге сүзләр язып эленгән иде.
унда ук түшәмнән көмеш чылбырга тагылган алтын эт башы да
ылынып тора иде. Болгар ханының тынычлыгын чумак йоласы да,
рек йоласы да бергәләп саклыйлар иде.

Әлеге зур ятак урынын, ятак янындагы тимерле тартманы, тартма
тендәге котычыкны санамаганда, «яшел бүлмә»дә башка берни юк
е. Аннары идәннең урта бер жирендәрәк бизәкле багана башында,
ıскыйда — чүлмәк савытта чырт-чырт килеп кара май яна иде. Кара
ıйның кара сөреме, баш өстендәге яшел чыбылдык янындагы ачык-
ıктан үзәк төннеккә таба суырылып тора иде.

Алмыш хан, бай киемнәрен салмыйча, ике кулы белән биленә тая-
ıп, ятагында утырып тора иде. Койтым бикә, үзе дә сизмәстән, тетрә-
п китте: ул шундый яхшы белгән яшь Алмыш углан танымаслык
лып үзгәргән иде! Орыш көнендә ул аны ерактан гына күргән иде.
ıнында ул аңа ныклап карамаган да иде. Тәңрем, нинди кансыз бу
мыш дигән нәрсә! Элекке яшь нараттай таза, сылу Алмыш углан бо-
к-сатаклы карт имәнгә әйләнгән. Бите, күз кабаклары шешенке. Кор-
гы үскән, симез. Ярый әле: сакал-мыегын чумакларча матурлап,
гәрәкләп кистергән.

Күрән бинең өлкән хатыны ятактагы кешегә таба бер-ике адым
лады да, йола саклап, башындагы бүреген салды, тезләнде. Алмыш
ıнның йокламаудан, күп эчүдән бөтенләй йомыла язган күзләренә
р күтәрелеп карады да коры, нык бер тавыш белән:

— Мин, Акбүре ыруының башы Күрән бинең хатыны Койтым
ıкә...— дип сүзгә башлады.

Нәрсәдер исенә төшерергә тырышып та, төшерә алмыйча, кашларын
ıыергалап, аптырап утырган ханның йөзе кинәт ачылып китте.

— Койтым! — диде ул, урыныннан торып.

Иңбашыннан тотып ул бикәне аягына бастырды; күрәсең, сычук
ıзуыннан айный алмыйча, элеккечә аны кочагына алмакчы булды. Бу
ıичектер бөтенләй көтмәгәндә булды. Койтым бикә ике куллап аны
теп жибәрде. Зур, авыр ир кеше чак-чак кына чайкалып китте. Ул,
ıызарынып, биленә таянды. Чын-чынлап ачуланырга да, ачуланмаска
а белмичә, ул үзенең мәңгелектән кире кайткан яшьлегенә — ут-ял-
ıнлы, тере, сылу яшьлегенә карап торды.

— Койтым! — диде ул, яратып, ягымлы итеп.

— Мин сиңа үтенеч белән килдем... Болгар йортының... Алмыш хан,—
иде Койтым бикә никтер буталып, кабаланып.

— Чынмы бу, синме, Койтым?! — диде Алмыш хан, әле булса исенә
илә алмыйча.

— Бу — мин,— диде бикә, үз-үзен тынычландырырга тырышып.—
Онытма, син Алмыш углан булмаган кебек, мин дә Шелке ханның кыр-
агы түгел. Мин — Күрән бинең хатыны.

«Күрән би» сүзен Алмыш хан беренче тапкыр ишеткәндәй булды.
Бу сүз аның кайнарлыгын сүрелдереп жибәрде. Әйе, әйе, Күрән би,
Сотыш углан... Каравыл башы әйткәнне шул — бинең хатыны, дигән
де. Катаудан килгән. Би хатыны. Каян килеп эләккән ул монда? Ниш-
ләтми язмыш кешене! Әйе, кырнак иде, инде әнә би хатыны булган.
Алтынны юлга ташласаң да алтын, шүрлеккә куйсаң да, утка тотсаң
да алтын! Койтым бикә түгел, Алтын бикә! Нишләп Күрән бине
ıызганды соң әле ул? Туздырасы калган оясын, аласы калган тартып
хатыннарын, кызларын. Ах, кем белгән аның болай булырын!

— Алайса, син Күрән бидә? — диде ул бераздан, елмаеп, бикәнең
күзләренә карап.— Белмәдем, монда әлегрәк килгән булырыем.

— Ярый әле элегрәк килмәгәнсең,— диде бикә.

— Менә килдем, таптым! Алам! — диде Алмыш хан, эчке бер омтылыш белән.

— Инде соң,— диде бикә салкын гына.

— Соң түгел!

— Соң! — диде бикә, ачуына ирек биреп.— Синең атаң Шелке минем туган ыруымны туздырды, атамнан-анамнан аерды. Инде менә син килдең минем икенче оямны туздырырга. Син миңа кан-яшь, кайгы алып килдең. Минем икенче туган ыруымны да син кара кайгыга салдың. Шулай булгач, ничек итеп син миңа «соң түгел», дип әйтә аласың? Моннан унтугыз ел элек мин берни аңламыйдырыем. Инде мин күп нәрсәне аңлыйм. Мин — Күрән бинең хатыны — сиңа үтенеч белән килдем. Тыңлыйсыңмы мине, Алмыш хан?

— Сөйләп кара,— диде хан.

Ул, күрәсең, истәлекләреннән дә, исереклегеннән дә айный башлады. Кисәк кенә ташкын булып калкып чыккан күңел тойгылары аның шулай ук ташкын булып тиз арада кире чигенде.

— Мин... Тотыш угланның анасы...— диде бикә.

— Тотышның?!

— Әйе. Син аны миңа кайтарып бир. Үлеме, тереме — кайтарып бир. Үтенечем шул.

Койтым бикә, тынын кысып, туктап калды. Алмыш хан да тып-тын булды. Җентекләп, нидер чамаларга тырышып, ул чибәр хатынның агарынган йөзен күзәтте.

— Синеке? — диде ул, үз алдына сөйләнгән сыман. Аннары башын калкытты да, бөтенләй чит кешегә, ханга әйләнеп: — Синеке генә түгел, минеке дә! — диде.

Аның «минеке»сен Койтым бикә үзенчә аңлады.

— Юк, синеке түгел! — диде ул, кычкырып.— Түгел! Мин бик яхшы беләм — түгел! Бир улгымны миңа! Яралы килеш, үле килеш... теләсә ничек кайтарып бир. Мин шуңа килдем, шунсыз китмим!

— Китмә,— диде хан тыныч кына.

Аның бу тынычлыгында буй җитмәслек көч, бөеклек сизелде. Беренче тапкыр бикә аны — үзе янындагы бу ир кешене — язмыш билгеләгән олуг хан итеп тойды.

— Мин сине кумыйм,— диде хан, шул ук тынычлыгын саклап.— Канымда, хатыным булырсың. Углың белән кал. Би хатыны булуга караганда, хан хатыны булу яман түгел.

— Миңа углым кирәк. Тотыш кирәк! — диде бикә, күз яше сизелгән бер йомшаклык белән.

— Синең углың миндә тотык булып калачак,— диде хан.

— Күрән би тотыклыкка сиңа башка углын бирер,— диде бикә.

— Миңа Тотыш углан кирәк,— диде хан.

— Бир Тотышны миңа, бир! — дип кычкырды бикә көчсез бер ярсу белән.

Кинәт ул кулын тун изүенә шудырды, кәзлек сабына тотынды. Ти ул аны кыныдан суырып чыгарырга да өлгерә алмады, таза ир кеше аның нишләргә чамалавын күреп, беләгеннән җиңел генә кысып тотты тез чүктерде.

— Белексез! — диде ул, ачусыз гына мыгырданып.

Бикә егылып китте, башы идәнгә бәрелде. Үзенең көчсезлегенә булдыксызлыгына ачыргаланып ул тыела алмыйча җыларга керешт Ул шактый озак җылады, барлык ачу-ярсулары, барлык тойгылары юылып чыкканчы җылады. Үкси-үкси торып утырды да үзенең ба очында аякларын аерып басып торган коточкыч кешегә ялынычлы кү зәрен текәде.

— Алмыш... углым, үтермә мине... бир углымны! — диде.

Берни аңлатмый торган таштай йөзен үзгәртмичә, Алмыш хан, беек тәңре кебек (тфү! тфү!), явыз айна [1] кебек, албасты кебек, югарыдан аңа карап торды.

— Мин әйттем: ул синең генә улгың түгел,— диде хан.— Мин аны үлем тырнагыннан тартып алдым. Мин! Корыч-Тимернең кылычын мин тотып калдым. Син аны тапкансың, мин аны үлгәч терелттем. Шулай булгач, Тотыш алып... Тотыш арыслан синеке генә түгел, минеке дә!

«Менә нәрсәне әйтә икән ул!» дип уйлады бикә үз алдына, ниндидер бер тынычлык белән. Аның эченә җылы йөгерде. Тотыш алып... Тотыш арыслан! Алмыш хан үзе шулай ди!

— Алайса, син аны үтермәячәксең?! Коллыкка сатмаячаксың?! — диде ана, пышылдап, елмаеп.

— Ул миндә тотык булып калачак,— диде хан, кабатлап, аңлатып.— Ике елдан соң ул синең янына исән-сау килеш кайтыр. Аның урынына тотык итеп миңа Күрән би үзенең бүтән углын җибәрер. Югыйсә, үзенә тиешле каланны да менә шулай яу белән килеп алырга туры килә.

— Син... сүз бирәсеңме? — диде Койтым бикә.

— Сиңа тагын нинди сүз? — диде хан.— Алмыш ханның сүзе бер булыр!

— Алайса, тагын бер үтенечемне тыңла,— диде бикә, аягына басып.— Углымны күрергә булмасмы?

— Ник? — диде хан, уйлангандай итеп.— Кочаклашып җылашыргамы? Үтерәсең киләмени? Аның янына имчеләр сине түгел, мине дә кертмәйләр. Кайгырма, миннән аңа кырын күз карашы булмас.

— Бай бул, сау бул, Алмыш хан! Бай бул, сау бул, углым Тотыш! — диде Койтым бикә, җинел сулап.

Койтым бикә, китәргә җыенып, бөркәнчегенә тотынды.

— Иреңә әйт: килсен, баш орсын. Җирелек белән берни кыра алмас,— диде Алмыш хан.

— Әйтермен,— диде бикә.

— Туктале,— диде хан, ишеккә таба борылган бикәне туктатып.

Ул иплəп кенә ике куллап аның башыннан тотып алды.

— Чынын гына әйт әле: Тотыш... минем углыммы? — диде ул, ярым пышылдап.

Хан аның ярым сөрмәле, тере, яруклы [2] күзләренә сынап, яратып карады. Койтым бикәнең башы әйләнеп киткәндәй булды. Беравык ул, ни әйтергә белмичә, тотлыгыбрак торды.

— Юк,— диде аннары, шулай ук ярым пышылдап, башын чайкап.

## XVI

Чулман буена яу чыгар алдыннан Алмыш хан чит ил сатучыларын тоткарласа да, соңыннан, уйлана торгач, бу эшнең үзе өчен бик үк ассулы түгел икәнлеген аңламый булдыра алмады. Борын-борыннан килгән базар юлын бикләргә тырышу ул Этил суын буарга тырышу белән бер иде. Кечкенә инеш, елга суларын буып булса да, Этил, Чулман суларын буу ул кеше кулыннан килә торган эш түгел иде, билгеле. Шулай итеп, Алмыш хан үз кулыннан килмәстәй эшкә тотынганлыгын аңлады.

Беренчедән, чит ил сатучылары Чулман буена керә алмасалар, моның авырлыгы Чулман буенда яшәүчеләргә генә түгел, аның үзенә дә

[1] Айна — явыз рух, иблис.
[2] Ярук — нур.

төшәчәк иде. Бу инде тамгалыктан керә торган байлык бермә-бер кимиячәк, дигән сүз иде.

Икенчедән, Болгар ханы чит ил сатучыларын Ага-базардан ары җибәрми икән, аларны тота икән, кыса икән, дигән сүз таралса, ул чагында инде бу якларга килергә нинди генә сатучы атлыгып торыр икән? Бу инде Болгар йортның агылыклары [1], таварлыклары бушап калачак, Болгар йорт көчсезләнәчәк, ярлыланачак, дигән сүз булыр иде.

Алмыш хан тиз арада үзенең ялгышын төзәтергә булды. Чулманның ун ягына чыгу белән ул Әтил буена югарыга үрләргәме, кире кайтып китәргәме, я булмаса шунда гына алыш-биреш ясаргамы дип аптырап, Ага-базарда җыелып яткан базарганнарга, сартларга төн ягына юл ачык икәнлеген белдерде. Тик ул беркемгә дә үзеннән узып китәргә ярамаганлыгын кисәтте. Кайберәүләр, кызыксынып, зуррак табыш алмакчы булып, чиру артыннан коры юл белән киттеләр, кайберләре су юлын сайлады. Шулай итеп, язгы ташуда ук килергә тиеш булган чит ил сатучылары, соңлап булса да, Акбүре җиренә дә килеп җиттеләр.

Туйдан соң икенче көнне Алмыш хан әлеге чит ил сатучылары белән очрашты. Сатучылар аңа бүләкләр китерделәр, үзләренең күпме, нинди тавар алып килүләрен, кая баруларын әйттеләр. Хан аларның каекларын, олауларын тикшереп чыкты, үзенә тиешле уннан бер өлешне алды да Акбүре җирендә, шулай ук Чулманның түбән агымында сатарга, алырга ирек бирә торган ал тамгалы ярлыклар тапшырды. Иран, таҗик, гарәп, әрмән сартлары, хазарлар, румнар, җөфүтләр, берберсен узарга тырышып, Кызыл Яр катауга ашыктылар. Кайбер сатучылар, монда гына тоткарланып тормыйча, вак елгалар буйлап, кара урман эчендә яшәүче төрле ят, кыргый ырулар арасына юл тоттылар.

Кызыл Яр катауда ун көн буена зур базар булды. Базарга якынтирәдәге авыллардан, урманнардан, Чулман аръягыннан күп кешеләр килде. Җиңелү кайгысыннан нишләргә белмәгән акбүреләргә, әйтерсең, янадан кот керде. Күрәсең, сату-алучылар килү куанычыннан, шулай ук хатынының сүзләренә күнеп, Күрән би Алмыш ханга бил бөгәргә килде, аңа мәңге турылыклы булырга кылыч үбеп ант итте.

Шундый ыгы-зыгылы көннәрнең берсендә Алмыш хан кайсардан үзенә бүләккә кол кызлар алып килгән рум базарганын чакыртты. Аның кире юлга чыгар алдыннан, барлык эшләрен бетереп, бераз ял итәсе, аүга чыгасы килә иде.

— Кайсар җибәргән битек синдәме? — диде ул рум сатучысына.

— Миндә,— диде рум кешесе, куенына тыгылып.

Хан битекне кулына алды, тамгасын, сургычын карады.

— Төрекчә язганмы, румчамы? — диде.

— Төрекчә дә, румча да,— диде сатучы.— Үзем укыйм?

— Тылмач укыр әле,— диде хан.— Телдән генә әйт: кайсар ни тели?

— Мин сиңа, олук кан, кызлардан тыш, ике кисәк рум ефәге, өч кисәк юка йон тукыма, биш тун, бер келәм, чирек батман кипкән йимеш алып килдем. Шуннан тыш биш кисәк сабын, им сулары алып килдем.

— Миңа житкерделәр,— диде хан.— Рум кайсарына миннән байлык, саулык әйт. Илегез тыныч булсын, кайсарыгыз күп яшәсен.

— Рум кайсары сиңа да шуны ук тели, олук кан! — диде алтын тәреле кеше, ханга баш орып.

— Бүләкләрең төбендә ни ята — минем шуны беләсем килә,— диде хан, базарганга туры карап.

— Бүләкләр төбендә, олук кан, алтын ачкыч ята,— диде рум кешесе, Алмыш ханга шулай ук сынаулы күз карашы ташлап.

— Синең түшеңдәге кебек алтын ачкычмы? — диде хан.

---

[1] Агылык — хәзинә саклана торган урын.

— Шул үзе,— диде кара кеше, алтын чылбырдагы алтын тәресен кулына алып.— Шундый ачкыч мән бөек Рум кайсары синен күңелен ачмак була, синен күңеленгә мәңге яктылык салмак була.

— Минем күңелемне ачып, анда яктылык салып, ул нишләмәкче була соң? — диде Алмыш хан.— Нишләп ул шулай минем күңелне кайгырта соң әле? Әллә үз күңелен кайгыртамы?

— Әйе, әйе, үз күңелен дә! — диде рум кешесе, елмаеп.— Бөек су юлында барлыкка килгән олуг йорт мән, синен йорт мән кайсар кызыксына. Болгарны син, олук кан, зурайттын, ныгыттын. Болгарны бездә күп телгә алалар. Рум кайсары синен мән якынлашырга тели. Моның сезгә дә, безгә дә чук-чук ассуы булыр.

— Сезгә нинди ассуы булыры анлашыла,— диде Алмыш хан.— Сезне бер яктан гарәпләр, икенче яктан хазарлар борчый, өченче яктан — урыс тынгы бирми. Сезгә булышчы кирәк, таяныр көч кирәк. Андый көч сезгә генә түгел, миңа да кирәк! Алтын ачкычка өстәп Рум кайсары миңа күпме акча бирә? Аның ачкычы белән, бүләккә җибәргән кызлары белән мин үз торама койма да кора алмыйм, ягыларымнан да саклана алмыйм.

— Рум кайсары, сиңа, олук кан, койма кормага, таш сарайлар салмага белекле кешеләр җибәрә ала,— диде рум кешесе сак кына.— Акча ягына килгәндә, ни... мин кайсарга җиткерермен.

— Син кайсарга җиткерерсең дә, кайсар сиңа җиткермәгән шул! — диде хан, ачы көлемсерәп.— Сине монда җибәргәндә ул иң кирәген оныткан. Рум йорты бай, Рум йорты бөек, көчле! Андый йорт белән туганлашкан өчен генә дә сез, кыргый болгарлар, тәнрегә изге теләкләрегезне юлларга тиешсез! Сез безгә кирәк чакта көч бирегез, безнең ягыга каршы сугышып кан коегыз, шуның өчен без сезгә менә шул ялтыравык ачкычны бирәбез, шуның өчен сез рум йоласын тотып, безнең кайсарга иртә-кич изге теләк, чук-чук яшьләр теләрсез! Шулаймы?

Кара йөзен караңгылык баскан рум кешесе беравык эндәшми утырды. Үзенең туган иле Румга карата, рум йоласына карата әйтелгән туры сүзләр, кимсетелүле сүзләр аның ясалма ягымлылыгын юкка чыгарды. Күңеленнән ул бөрешеп калды. Аның бу кыргый илнең кыргый башлыгы алдында үз йортының, үз кайсарының йөз аклыгын саклап каласы килде.

— Олук кан,— диде ул, шактый бер корылык белән,— Рум йорты — мәңгелек! Барлык аҗундын өзәге — Кустантин, барлык йортларның, илләрнең атасы — Рум. Рум йоласы — иң изге йола [1], иң туры йола.

— Син аны кайсарың алдында сөйлә,— диде Алмыш хан, тыныч бер өстенлек белән.— Румның мәңгелек чаклары үтте инде. Күршеләрнең канын эчеп, сөлектәй симереп күп яшәде сезнең Рум. Юк, сез инде артта калдыгыз. Төрек улусларын үзара ызгыштырып, ачлар, ялангачлар канынннан алтын сарайлар салу, байлык җыю үтте инде. Хазарлар, болгарлар булышка килмәгән булса, моннан ике йөз, өч йөз ел элек үк инде сезне гарәпләр баш аркылы чөеп ыргыткан булырые. Беләм мин сезне, сезнең йолагызны! Сиңа чаклы да килделәр миңа рум йоласына аудармакчы булып. Аларга да мин әйттем: акча бирегез, акча! дидем. Миңа аякка басарга кирәк, миңа җөфүт каганнан котылырга, янымдагы ягы ырулардан сакланырга кирәк. Мин нык булсам, минем йортымда сезнең йола да ныгый алачак. Шулай булгач, сезнең йоланы көчәйтү өчен мине көчәйтергә кирәк түгелмени? Мин башкаларга да шуны әйттем. Алар да синең кебек: кайсарга җиткербез, диделәр. Кайсар миңа ни җибәрде? Икейөзле, ялганчы ул рум йоласы!

Рум кешесенең йөзе тартышып куйды, алтын тәресен кысып тоткан килеш ул үз телендә нидер мыгырданып алды.

---

[1] Рум йоласы — монда: христиан дине.

— Алай рум йоласы да ошамагач, синенчә нинди йола яхшы сун?— диде ул сизелеп торган бер көлемсерәү белән.— Чумак йоласымы, әллә җөфүт йоласымы?

— Минем өчен төрек йоласыннан да яхшысы юк,— диде хан.— Шулай да мин сезнең макталган Румыгыздагы кебек, беркемне дә кысмыйм. Сез барлык аҗунда бары рум йоласы гына булырга тиеш, дип уйлыйсыз. Барлык телләр, барлык улуслар бары рум йоласына гына, рум кайсарына гына табынырга тиеш, дисез. Үзегездән башка улусларга сез кыргыйлар итеп карыйсыз, үзегезнең йоладан башка йолаларны ягы дип беләсез. Сез тиңгездә бер генә балыкны, урманда бер генә киекне, болында бер генә чәчәкне калдырмакчы буласыз. Әтилдә төрле балыклар иркенләп йөзгән кебек, урманда төрле киекләр яшәгән кебек, болында төрле чәчәкләр, төрле ут-үләннәр үскән кебек, минем йортта да төрле йолалар, төрле телләр, төрле ырулар иркенләп яши. Болгарда чумаклар да, җөфүтләр дә, рум йоласын, төрек йоласын тотучылар да бар.

— Син минга ачуланма, олук кан,— диде рум кешесе, янадан ягымлыланып.— Мин синга кайсарның өтенечен генә тапшырдым.

— Мин инде күп уйладым,— диде Алмыш хан.— Сезнең йола минга кул түгел. Үзем мин бөтен көчем белән чумак йоласына күчтем. Йола алыштырудан бигрәк, миңа бүген акча кирәк, акча! Кустантинга кайтып житсәң, кайсарга минем изге теләкләремне житкер.

— Мин әле тиз генә кайтып китмәсмен,— диде рум кешесе.— Минем үз эшләрем бар... сату-алу... Синнән каршылык булмаса, монда...

— Алтын ачкыч таратырга уйлыйсыңмы? — диде хан, көлемсерәп.

— Әйе, андый уем да бар,— диде тәреле кеше.

— Миннән каршылык юк,— диде Алмыш хан.— Бүгеннән башлап бөтен Чулман буе — шушы югары өлешеннән... Кызыл Яр катаудан алып тамагынача минем кул астында. Биар белән Болгар арасында, урталыкта, беркемгә дә буйсынмыйча, баш бирмичә килгән Акбүре миңа бил бөкте. Менә шул җирдә син үзең теләгәнчә йөри аласың, үз йолаңа өнди аласың. Минем кул астында нинди кыргыйлар яшәгәнен, ничек яшәгәнен үзең күрерсең. Башың булса, үз иленә кайткач минем йорт турында белик язарсың. Ал тамгалы ярлыкны бирерләр. Ак юл сиңа, рум кунагы.

## Өченче бүлек

### I

Тотыш шактый күп канын югалтты. Орыш бетеп, имчеләр яраны бәйләгәндә, ул инде аңын җуеп бара иде, ул инде төш белән өн, үлем белән тереклек арасында тартыша иде. Шул көенчә имчеләр аны урдага алып кайттылар, ялгыз тирмәгә урнаштырдылар. Янына агач күбәтә белән су, богдай көлчәсе куйдылар да шыпырт кына чыгып киттеләр. Яралы батырны явыз ияләрдән саклау өчен алар, тирмәне әйләндереп, җиргә эт теше белән сызык сыздылар. Барлык им-том шуның белән төкәнде. Кояш җир астына төшеп, яңадан күк читеннән килеп чыкканчы аңына килә икән, куйган азыкны ашап, суны эчә икән — димәк, терелачәк; аңына килми икән, анда инде берни эшләп булмый — суны да, көлчәне дә ияләргә бирергә туры киләчәк. Шулай итеп, аның азыгы да, суы да, коты да үзенә булмаячак.

Имчеләр шулай дип уйладылар. Шуңа күрә, төн узып, таң атканчы аның янына беркем аяк басмады. Икенче көнне кояш чыгып, җирдә яңа көн тугач кына, яралы батырның үлеме-тереме икәнлеген белү өчен тирмәгә баштанаяк акка киенгән, битенә битлек каплаган имче карт

керде. Ул иң элек көлчә белән суга күз төшерде, аннары егетнең аяк-кулларын капшап карады. Сулы күбәтә дә, көлчә дә үз урынында иде. ишь алыпның аяк-куллары да, култык аслары да жылы иде. Димәк, ул әле исән.

Имче карт суны жиргә түкмәде, киресенчә, егетнең иреннәрен көч-ләп ачты да аңа үзе белән алып килгән, имләтелгән берничә тамчы кымыз эчерде. Тотыш, нидер әйтмәкче булып, авызын кыймылдатты, кашларын жыерды.

Дүрт көн буена аның янына шулай таң ату белән Байтал имче кил-де, дүрт көн буена аның аяк-кулларын, култык асларын карап-тикше-реп, авызына кымыз салып китте. Дүрт көн буена Тотыш күзен дә ачып карый алмады, бары кашларын гына жыерды да иреннәрен генә кый-мылдатты. Бишенче көнне аның күзгә күренмәс күбәләк булып якында гына очып йөргән коты кире авызына керде. Үлем белән яшәү арасында тартыш төкәнде. Яралы егет күзләрен ачты, югарыда тирмәнең ачык төннегенә аша якты күк кисәген күрде, якында гына ниндидер ят та-вышлар ишетте. Көн яктысын да, тавышларны да ул нишләптер беренче тапкыр — туганнан бирле беренче тапкыр күрә-ишетә шикелле тоелды. Бу бик кызык тойгы иде, шулай да бик үк ят нәрсә дә түгел иде. Ул инде кайдадыр шулай күкне дә күргән, тавышларны да ишеткән иде бугай. Әйе, ул кайчандыр яшәгән иде. Димәк, ул яңадан яши башла-ды! Менә шулай түбә төннегенә карап яту, кайдадыр якында гына кешеләр сөйләшкәнне, атлар кешнәгәнне ишетү нинди куанычлы икән!

Әкрен генә аны жиңел, татлы бер тойгы — күңел тибрәткеч бер җылылык, йомшаклык биләп алды. Бу жылы, йомшак тойгы, дулкын булып, аның бөтен буена таралды, аяк очларына барып житте. Шушы татлы йомшаклыкка, жылылыкка бирелеп, тирә-якка колак салып, ул шын гына урынында ятты. Тавышлар бер ерагайды, бер якынайды, әле тоташ гөрелдек булып, әле аерым-аерым сүзләр булып ишетелде.

Бераздан ул үзенең кайдалыгы, нишләп ятуы белән кызыксына баш-лады. Үзенең яралы икәнлеген исенә төшерде — сул як беләгендәге яра кинәт сулкылдап-сулкылдап авыртырга тотынды. Бу авырту кайгысы аның барлык үткәнен — чынында берничә көн элек кенә булган, тик аның үзенә кайчандыр бик-бик күптән булып узган шикелле тоелган күренешләрне күз алдына китереп бастырды. Аның торасы килде, кая-дыр китәсе, нидер эшлисе килде. Ул чыннан да урыныннан кузгалды, тик, башы әйләнеп, кире урынына ауды. Ул шыбыр тиргә батты. Ул яңадан аңын жуйды.

## II

Бер-ике көннән Алмыш хан урдасы, Акбүре жиреннән кузгалып, кире көн ягына таба юл тотты. Тотыш углан яткан ялгыз тирмәне, сү-теп тормыйча, киң арбага — каңгыга урнаштырдылар. Арбага албалап атлар жигелде. Меңләгән ат, арбалар, меңләгән терлек-туар, Чулман буеның шау чәчәктә утырган болыннарын таптап, түмгәкләрне, куак-ларны сытып-изеп, тирә-якны шау-шу белән күмеп, түбән таба агылды-лар. Көчле ташу алып киткән йомычка кисәгедәй, шушы меңләгән ат, кеше, арба, күтәрмәләр арасында Тотыш углан да каядыр кыймылдады.

Урданың кайчан, ничек кузгалып китүен ул бөтенләй сизмәде — ул, күрәсең, йоклаган булгандыр. Күзләрен ачып жибәрсә, яткан урыны-ның як-якка тирбәлүен, бер урында гына тормыйча тирбәлүен сизгәч, баштарак берни аңламады. Белмәссең, әллә шулай жир әйләнә, әллә аның башы әйләнә!

Шулай да ул бераздан үзенең кемнәр беләндер каядыр китеп барга-нын төшенә алды. Шул ук мәлдә беләктәге яра үзен сиздереп куйды.

Авырту тойгысы, ачы әрнү булып, йөрәген кузгатып җибәрде. Аны кая-дыр алып китteләр! Кая? Нишләтергә?!

Туган өй, туган ыру, катау кайдадыр еракта калды. Атасыннан-анасыннан аерып аны алып киттеләр...

Аның җылыйсы, кычкырасы килде, кемгәдер үпкә белдерәсе килде. Тик ул берни эшли алмады. Кымшана да алмады. Әллә аны бәйләп ташлаганнармы соң? Ул, чыннан да үзен бәйләгәннәрме, юкмы икәнле-ген белергә теләп, таза кулына таянып, урыныннан торырга тырышып карады. Тора алмады. Шуннан соң ул үзен бәйләгән бауны капшап карамакчы булды. Кулы аның сулы чүлмәк белән агач күбәтәгә тиеп китте. Барлык тойгыларны җиңеп, шундук ачлык тойгысы баш калкыт-ты. Ул калтыранган кулы белән күбәтәдәге көлчәне алды да комсызла-ныш ашарга кереште. Бераз гына көйгән, катып ташка әйләнгән богдай көлчәсен тиз арада юкка чыгарды. Шуннан соң ул түгә-түгә нечкә муенлы чүлмәктән су эчте.

Тынычланып ул күзләрен йомды. Арба әкрен генә барды да барды. Тәгәрмәчләр туктаусыз шыгырдады, кешеләр сөйләште, шөлдерләр, авызлык тимерләре чылтырады. Кайдадыр көлгән яшь тавышлар ише-телеп китте. Шулай да нинди күңелле тирә-якны тоеп, ишетеп йомшак арбада бару! Кая барса да барыбер түгелмени аның өчен? Барсын гына, тик бер урында гына тормасын.

Искәрмәстән ул яңадан йокыга талды.

Кичкә таба атлар, арбалар туктап калдылар. Тавышлар басыла төште. Әле анда, әле монда учаклар ягылды, кыздырылган ит, май исләре таралды. Тотыш шул татлы исләрне йокы аралаш диярлек сизеп алды, күзләрен ачты да, үзен бөтенләй савыккан кешегә санап, урынын-нан ук торып утырды.

Шул ук мәлдә диярлек күтәрмә ишеге ачылып китте. Кызгылт кояш яктысында сирәк сакаллы бер картның, урталай бөгелеп, киез ишектән килеп кергәне күренде. Күзләрен зур ачып, кызыксынып Тотыш аның үзе янына килүен көтте.

— Уяндыңмы, балам? — диде Байтал имче, йомшак кына итеп.

Тотыш карап тик торды. Имче карт та, күрәсең, аның ни дә булса әйтүен теләмәде. Сынап ул яралының сулган, агарынган йөзенә кара-ды, йомшак бармаклары белән тагын аның аяк-кулларын тоткалады, аннары шулай ук йомшак кына итеп яра урынын капшап-капшап кара-ды да урынга ятарга кушты.

— Мин кайда, имче баба? — диде Тотыш.

Үзенең тавышы аңа бик көчсез булып ишетелде.

— Син минем кунагым, балам,— диде Байтал имче.

— Минем ашыйсым килә,— диде Тотыш, сабый бала сыман җылам-сырап.

— Син инде үзенә тиешлесен ашагансың, балам,— диде имче баба, буш күбәтә белән чүлмәккә күз төшереп.— Сина күп ашарга ярамый.

— Мин терелдем. Минем ашыйсым килә! — диде Тотыш, үпкәләп.

— Шулайдыр, балам,— диде имче карт, чүлмәк белән күбәтәне кулына алып.— Күзеңне ачкансың, сөйләшә аласың — котың үзеңдә. Иртәгә таңгача түз, балам. Бары да тәңре кулында.

Бу сүзләрне ул ничектер коры итеп, боергандагы кебек итеп әйтте. Тотыш аннан ялынып та, ялварып та берни ала алмаячагын аңлады. Аның картка ачуы килде. Ул аның тизрәк чыгып китүен көтә башлады. Байтал имче тоткарланып тормады: яралы егеткә тыныч йокы теләде дә арты белән чигенеп ишектән чыгып китте.

Тотыш янына ул Алмыш хан кушуы буенча килде. Югыйсә, төштән соң, бигрәк тә кояш баеганда ул яралы, авыру кешеләр янына керүне өнәп бетерми иде. Байтал имче туры хан янына китте.

— Торып утырган. Тиздән аягына басар,— диде ул ханга.
— Болгар-торага кайтып житкәнче ул аягына басмаска тиеш,— диде хан.
— Син әйткәнчә булыр, ханым,— диде Байтал имче, баш иеп.

### III

Көндез йоклап туйгангамы, карыны ач булгангамы, әллә инде имче карт белән сөйләшү күңелен борчыганга, кичтән Тотышның йокысы килмәде. Аның кайсыдыр жире авыртты, кайсыдыр жире сызланды, әрнеде — ул инде моны баштагыча чын итеп, ачы итеп тоймады. Аның күңелендә моңарчы үзен бик үк сиздермәгән бер кызыксыну уянды. Болгарлар аны каядыр алып баралар. Яралы булгач, ник аны туган жирендә генә калдырмадылар икән?

Аның кызыксынуы артканнан-арта барды. «Нинди жир бу, кайсы төш бу?» диде ул үзенә үзе. Чулман еракмы, Кызыл Яр катау кайсы якта калды? Тышта, кыр арба янында каравыл бармы, әллә соң имче аны, әле булса көчсез дип уйлап, үзен генә калдырып киттеме?

Аның тикшереп карыйсы килде. Ул тышта тавышлар басылганны, урда йокыга талганны көтеп ятты да ишек янына шуышып килде. «Көч юк. Ашыйсы килә,— дип уйлады ул, күңелен кытыклаган уен кире кагып.— Юк, булмый әле. Көч юк... баш әйләнә».

Ул, колакларын үрә торгызып, ишек төбендә беравык тыңлап ятты. Тышта шылт иткән тавыш та ишетелмәде. Якында гына каравылчы булса, аның йөренгәне ишетелер иде. Юк, ишетелми. Алай гына да түгел, аның арбасына якын жирдә бөтенләй бернинди тавыш-тын ишетелми. Димәк, арба янында беркем юк. Болгарлар аны үзләренең арбаларыннан, чатырларыннан читкә туктатканнар, ахрысы. Шулай булгач, төшәргә дә берәр жиргә качып калырга! Чулман гына якын булсын, анда инде күз күрер!

Яралы егет идәнгә жайлап утырды да, ыңгырашмаска тырышып, ишек бавын чишмәкче булып, ярыктан кулын тышка сузды.

Кинәт ул сискәнеп, тетрәнеп китте. Яшен суккандагы кебек, күз аллары яктырып, гөлт итеп китте. Аның коты алынды. Башына кан бәрде, йөрәге атылып чыгардай булып тибә башлады. Ул үзенең урынына ничек барып ятканлыгын да сизми калды.

Нәрсә булды соң әле бу? Анда, тышта аның кулы икенче бер кеше кулына тиеп киткәндәй булды. Әйе, әйе, аның кулы кеше кулына тиде! Ул моны бик яхшы тойды. Албастының кулы андый кайнар, йомшак булмас. Сакчы кулы дисәң, сакчы кулы да андый булмас — аның кулы каты, тулас булыр иде. Кем булды бу, нәрсә булды? Сакчы булса, ул берәр нәрсә әйтер иде. Бу берни әйтмәде... әйтми дә. Әнә, тып-тын.

Аның күңеленнән бер-бер артлы әллә нинди куркыныч уйлар узды. Ул, дер-дер калтыранып, урыныннан кузгалмыйча ята бирде. Үзен саклау өчен, бала чагында өйрәнгән каргышларын исенә төшерергә тырышып карады, тик күңеленә берни килмәде. Нишләргә белмичә ул шактый озак тынып ятты.

Көтмәгәндә тышта ниндидер серле тавышлар ишетелеп китте: кемдер ишек бавын чишәргә тырыштымы, киресенчә, әллә ныгытып бәйләмәкче булдымы — Тотыш аера алмады. Шунда ук ниндидер каты нәрсәгә чүлмәк кебек нәрсә тиеп китте.

Шулай да егет түзмәде, барлык батырлыгын бергә жыеп:
— Кем бар анда? — диде.

Аның тавышы үзенә дә ишетелмәде. Ул кычкырыбрак соравын тагын кабатлады.

— Тотыш... синме? — диде тыштагы ниндидер нәрсә, пышылдап.

Бу ниндидер нәрсәнең калтыранып чыккан пышылдавык тавышы яралы егеткә бик йомшак, бик ягымлы булып ишетелде, бу, билгеле, имче дә түгел, сакчы да түгел иде. Ул ниндидер... кыз кеше булырга тиеш иде. Яшь егетнең эченә җылы йөгерде — чын кеше идеме ул, албасты идеме — аның өчен барыбер кебек иде. Тыштагы ул шикле кызга аның «әйе, бу мин — Тотыш», дип кычкырасы килде, шулай да әле булса аны нидер тыеп торды.

— Тотыш, мин сиңа ашарга китердем,— дип пышылдады ят кыз, бераз тынып торганнан соң.

Тотыш барыбер кузгалмады. Карангыдан күзен алмыйча ул бөтен күңеле белән бергә укмашып, тынын кысып ятуында булды. Ул арада тыштагы ят кеше ишек астыннан эчкә ниндидер авыр нәрсә куйды. Ач кешенең борынына шундук пешкән ит исе килеп бәрелде. Ул түзмәде, ишек янына килде, капшанып карады. Кулы ниндидер төргәккә тиде. Утка төшкәндәй ул шундук кулын кире тартып алды. «Юк, ярамый!» диде ул. Шул ук мәлдә тышка колак салды: анда инде бернинди кыштырдык та, пышылдау да ишетелмәде. Күз буу булмады микән бу? Күрәсең, шулайдыр.

«Күз буу? — дип уйлады ул бераздан, шикләнеп.— Алайса, нишләп соң ул итнең исе килә?!»

Ачлык тойгысы, кызыксыну тойгысы куркудан, төрле шикләрдән көчлерәк булып чыкты. Ул яңадан капшанып әлеге төргәкне табып алды, сүтте, андагы зур гына ит кисәген комсызланып ашарга да керешә. Бу инде каткан көлчә кебек кенә булмады. Авыз тутырып ит ашагач, тоткын егетнең күңеле күтәрелеп китте. Ачлык тойгысы, авыртыну тойгысы онытылды.

«Болай булгач, качам да качам инде!» — дип уйлады Тотыш, кыюланып.

Шулай да ул кача алмады. Әле генә ирекkә омтылган уйлары-теләкләре, бөтенләй көтелмәгән бер каршылыкка очрап, бөтенләй көтелмәгән юнәлештән китеп барды: үзе дә сизмәстән, ул ят, серле кыз турында уйлый башлады.

Юк, ул уйламады да. Үзенең ягымлы, серле пышылдавы белән, кайнар, йомшак кулы белән ул аның күңеленә керде дә утырды. Сиздермичә, сорамыйча шулай ук аның барлык уйларын, теләкләрен үзе теләгән юнәлешкә борып җибәрде. Алай гына да түгел, ул аның йөрәген дә, әйтерсең, бөтенләй башкача эшләтә башлады. Тиз арада ул аны биләп алды, буйсындырды, тез чүктерде. Ялгызлыктан, тоткынлыктан, авыртынудан интеккән яшь егетне кулга алу өчен аңа бернинди тырышлык кирәкмәде.

Кем булыр ул? Чын кешеме ул, әллә кешегә әйләнгән берәр изге ияме? Килерме иртәгә, килмәсме? Яралы яшь егетне шундый сораулар борчыды. Ул көтәргә булды. Ул тизрәк төн узып таң атуын, көн узып караңгы төшүен көтте.

## IV

Менә икенче көн дә туды. Кара тауларны, урманнарны кичеп, җиде кат җир астыннан, җиде кат күк артыннан үтеп, яңа көн туды. Мондый якты көнне Тотышның әле беркайчан да күргәне юк иде бугай, мондый куркулы-өркүле, мондый тынгысыз төнне беркайчан да үткәргәне юк иде бугай. Таң аткач, аңа никтер төш җитмәс шикелле булып, төш җиткәч, никтер кич булмас шикелле тоелды. Кич булгач исә караңгы төшми аптыратты. Беркайчан да беркемне дә аның шулай өзелеп, сагынып көткәне юк иде бугай.

Тышта, ишек янында кыштырдык ишетеп ул кинәт дерт итеп китте. Урыныннан торды да сагаеп тыңларга тотынды. Күтәрмәнең киез ишеге

ачылуга, кичәге кебек, кызгылт кояш яктысында имче картның сирәк сакалы күренде. Яшь егетнең өстенә салкын су койгандай булды. Ул, күңелсезләнеп, кире урынына ауды. Иртән килеп киткән имчене ул инде тагын килер дип уйламаган иде.

Байтал имче көндәгечә аның кулларын-аякларын капшап карады, маңгаена кулын куеп торды. Иртәнгегә караганда, аңа яралының маңгае кайнаррак тоелды.

— Башың авыртмыймы, балам? — диде ул аңа.

— Юк,— диде Тотыш.

— Яраң сызламыймы, балам? — диде имче карт, төпченеп.

— Юк,— диде Тотыш.— Мин инде терелдем, имче баба. Минем жиргә төшәсем, үз аягым белән йөрисем, йөгерәсем килә. Кайчан мине иреккә чыгарырлар?

— Анысын мин белмим, балам,— диде карт.

— Алайса, ашарга бирегез! — диде Тотыш.

— Анысы минем ирекtә түгел, балам,— диде имче баба.

Тотышның башка сүз көрәштерәсе килмәде. Имче картның ни әйтсәң дә, нәрсә сорасаң да, бер үк сүзне кабатлаячагын ул инде бик яхшы төшенеп алды. Аның, бернигә карамыйча, каядыр чыгып йөгерәсе килде, үзен менә шунда урынга беркеткән ярасын бәйләре-ниләре белән ботарлап ташлыйсы килде. Ах, кем иде, кем булды ул! Бер үзе бөтен ыруны саклап калмакчы булды. Бер үзе болгарларның алыпларын кырып салмакчы булды! Ул җиңелде, катау таланды... талангандыр. Кемнәр исән, кемнәр үле икән анда? Ниләр булды икән анда ул югында? Исән калган ырудашлары көлде микән аннан, көләләр микән, ачуланалар микән аңа? Каян алырга бетмәс-төкәнмәс көч, каян табарга беркайчан да сынмый торган, бар нәрсәне кырып сала торган кылыч? Явыз ягыдан ничек үчне алырга? Тәңрем, терелт тизрәк, көч керт тизрәк, чыгар иреккә! — менә шулай аунап, интегеп ятуга караганда, туган йортың, туган ыруың, атаң-анаң өчен сугышып үлү мең артык!

Икенче кыштырдыкны ул бик тыныч каршылады. Баштарак ул никтер үпкәләп, киреләнеп: «Ашарга китерсә дә алмыйм!» диебрәк тә уйлады.

— Тотыш... Тотыш? — диде серле кыз, кичәгечә ягымлы, калтыравык бер тавыш белән пышылдап.

Аның бу пышылдавын, инде таныш булып, якын булып әйләнгән пышылдавын ишетү белән, никтер, кемгәдер үпкәләгән яшь егетнең күнеле эреде дә куйды. Аны татлы кайнар дулкын күмеп китте. Сөенеп, ашыгып ул ишек янына килде.

— Синме? Килдеңме? — диде ул, пышылдап, кызның кулын тотып.

Кыз кулын кире тартып алмады — күндәм генә, йомшак кына тик торды. Егетнең кинәт башы әйләнде, йөрәге суга башлады. Ул үзенә серле кул аша искиткеч куаныч тойгысы белән искиткеч көч, әлерәк кенә үзе теләгән иксез-чиксез көч бирелгәнлеген тойды. Ул, телдән язган кебек, берни эндәшә алмыйча, үз алдына елмаеп торды да торды.

— Мин сиңа тагын ашарга китердем,— диде кыз.— Пешкән ит... кымыз. Тизрәк терел, Тотыш!

— Мин терелдем! — диде егет, төштәге кебек, куанып.

— Мин китәм,— диде кыз.— Читтә сакчылар йөри. Синең каңгы янына имчедән башка беркем килергә тиеш түгел. Мин китәм. Күрсәләр...

— Китмә! Сөйлә берәр нәрсә,— диде Тотыш, аның тавышын ишетәсе килеп.— Кем син? Мин терелдем. Иртәгә киләсеңме?

— Тырышырмын,— диде кыз.— Сау бул, Тотыш, мин китәм.

— Килсәң, миңа ук-җәя китерәсеңме? Булса — кылыч?

Кыз кинәт тынып калды.

— Мин куркам,— диде ул бераздан сүлпән генә.

Тотыш аның тавышындагы үзгәрешне сизми калды.

— Беркемгә дә әйтмә: мин моннан качарга булдым! — диде ул ашыгып, пышылдап.

— Сине нык саклыйлар,— диде кыз.

— Булдыра алсаң, кылыч китер — мин аларны искәрмәстән кырып салам! — диде яралы егет, батыраеп.

— Мин куркам,— диде кыз, кабатлап.— Мин китәм, күрерләр...

— Туктале, тукта,— диде егет, аны беразга гына булса да үз янында тотмакчы булып.

Шулай да ул аны артык кыстарга да базмады — ул аның үзе аркасында сакчыларга юлыгуын теләмәде. Аннары кызның корал алып килү турында берни әйтмәве дә ничектер искәрмәстән аның кыюлыгын сүрелдерә төшкәндәй булды. Ул ишек янында беравык тыңлап торды да кире үз урынына барып ятты. Бик ашыйсы килсә дә, нишләптер бүген кыз китергән азыкка тиз генә тотынасы килмәде. Бүгенге очрашу ул дигәнчә, ул теләгәнчә булмады шикелле. Аның күңелендә энә очыдай гына борчылу, пошыну торып калды. «Корал турында, качу турында әйтеп ялгыштым, ахрысы»,— дип уйлады ул бераздан, көрсенеп. Болгар кызына ышанып серен чиште! Эх, тишек авыз!

Икенче көнне кыз бөтенләй килмәде. Кайгыдан Тотыш нәрсә уйларга да белмәде. Онытыла башлаган ярасы яңадан кузгалды. Күңел ачысына, эчне борып торган ачлык тойгысына тагын үзәкләргә үтә торган икенче бер әрнү-үкенү тойгысы кушылды. Төнне ул йокламыйча уздырды. «Иртәгә килер әле»,— диде ул, үз-үзен юатып.

Кыз «иртәгә» дә, «иртәгә» соңыннан да килмәде. Суга төшкәндәй юк булды. Көндәгечә аның янына иртә-кич Байтал имче килде, аңа ач-тан үлмәслек ашарга-эчәргә китерде, аның теге-бу төшләрен капшаштырды да бер үк сүзләрне әйткәләп китеп тә барды. Килгән саен ул аңа: «Озакламый савыгырсың, балам», диде, тик ул әйткән «савыгу»-ның әле бер дә очы-кырые күренмәде. Ул көннәр буена бер үк урында аунап ятты. Тора-бара аның өчен бөтен нәрсә тоныкланып, төссезләнеп калды. Истәлекләр ерагайды, тойгылар көчсезләнде, тынгысыз уйлары шулай ук каядыр качышып, таралышып беттеләр. Көндез кояш кыздырса да, янгыр яуса да, кангы тәгәрмәчләре ка<sup></sup>ылмага батса да, якында гына җайдаклар шаулашса да, аның өчен барыбер иде. Ул, әйтерсең, тормыштан, аҗуннан аерылып калган иде.

Кыз исә һаман килмәде... Югалды, юкка чыкты.

«Ныклап торып аякка гына басыйм!» дип уйлады ул кайчакларда, кемгәдер, нәрсәгәдер янап. Ныклап торып аягына басса, үзенең нишләячәген ул үзе дә анык кына күз алдына китерә алмады. Янау еш кына сагынычлы әрнүгә әйләнде. «Барыбер табарга, күрергә тиешмен мин аны!» дип уйлады ул иң ахырда, үзен шулай ялгыз ташлап киткән, үзеннән шулай җиңел генә йөз чөергән кансыз кызга чиксез бер үпкә белән.

Ни генә булмасын, кыз барыбер килмәде. Чынлап та югалды, юкка чыкты. Күрәсең, ул чын кеше дә булмагандыр.

Шулай итеп, көн артыннан көн үтте, төн артыннан төн үтте. Атларга атланган, арбаларга, кангыларга утырган Болгар иле, бөтен Чулман буен тутырып, болыннарны, кырларны таптап, урман-суларны кичеп, үзенең төп җиренә таба кыймылдады. Юл өстендә таланган, яндырылган катаулар очрады; кешеләре ядан куркып, урман араларына, Чулман аръягына качып киткән буш авыллар очрады. Кайбер җирдә, киресенчә, Алмыш ханга буйсынуларын белдереп, ит, икмәк, тоз күтәреп, каршыга кешеләр чыкты. Җиңүчеләрне елмаеп каршы алдылар, йодрык күрсәтеп озатып калдылар.

Акбүре жиреннән кузгалып китүләренә бер ай чамасы булды дигәндә, болгарларның мең кешелек иравылы [1] Ямгырчы би жиренә барып керде. Ямгырчы би яши торган Шуран катаудан Болгар-торага нибарысы алтмыш-җитмеш чакрым ара калган иде.



## V

Чулман буен яуларга чыгар алдыннан Алмыш хан үзе белән бөтен йортын-илен кузгатмады. Ул бары үзенең биш йөз кешелек көчен генә алды. Болгарларның күпчелеге, шулай ук Алмыш ханга турылыклы ырулар барысы да үзләренең төп жирләрендә: жәйләүләрдә, авылларда торып калдылар. Билгеле, Болгар-тораны — ханбалыкны, Ага-базарны саклау өчен ул кораллы чирү калдырмый булдыра алмады. Шулай ук чик буйларында да күп кенә сакчылар калды. Чирүнең күпчелек өлешен Алмыш хан шулай да үзе белән яуга алды. Ник дигәндә, бу арада гына Болгарга яу килер дип куркыр урын юк иде. Бөтен Этил буена курку салып, авыл-тораларны талап, яндырып йөрүче урыс-улаклар да соңгы елларда тынып калдылар. Моннан биш-алты ел элек хазарлардан качып котылган юлбасар урысларның соңгы көчләре белән болгарлар арасында бик каты сугыш булды. Бер көн эчендә болгарлар утыз меңләп урысны Этилгә турап агыздылар. Шуннан бирле Этил буе тынычланып калды. Менә шуңа да Алмыш хан үзенең төп көчләрен Чулман ягына яуга алып чыкты да.

Алмыш ханның ягылары, билгеле, урыслар гына түгел иде. Урыслар ерахта, алар каяндыр өстән, урман-сазлы җирләрдән төшәләр иде. Алмыш ханның ягылары монда якында гына да — үз йортында, күршетирәдә дә житәрлек иде. Алар аның борылганын гына, тезгенне йомшартканын гына көтеп торалар иде. Чак-чак кына ялгыш бастымы, чак-чак кына күзен ачып карамадымы — алар шундук аны тартеп егарга, ботарлап, өзгәләп ташларга гына торалар иде. Шулар арасында иң көчлесе, иң усалы — Суар бие Килдеш би иде. Ярый әле узган кышны Алмыш хан аның белән татулык анты эчте. Юкса, йөрер иде иркенләп менә болай Чулман буенда! Шулай ук бүләрләр дә эттән туган нәрсәләр. Бүләр белән Суар талаша. Бүләрдә әле Болгар кайгысы юк.

Менә шуларны уйлап-чамалап Алмыш хан бик зур эшкә тотынды. Беркемгә сиздермичә кыш буена көч туплады, үзендәге барлык балтачыларны жыеп, моңарчы күз күрмәгән, колак ишетмәгән сал-күпер ясатты. Юри, күз буяу өчен ул Болгар-тораны икенче кат койма белән уратып алам, шуңа агач кистерәм, дип сүз таратты. Аннары, язга чыгу белән тагын, буйсынмаган башгыртларга каршы яуга чыгам, дигән икенче ялган таратты. Шулай итеп, беркем берни сизенмәде. Шулай итеп, утырды төп башына Бүләр, Суар! Бөтен Чулман буе аның кулында, бер йодрыкта. Бүләр белән Суар киләчәктә дә үзара талашалар икән, берәм-берәм аларны да кабып йоту, тез чүктерү берни булмас.

Куанмасаң да куанырсың — күпме көч, күпме байлык артты! Әнә барысы да олау-олау булып арттан иярен килә. Коллар, терлек-туар, алтын-көмеш, тире, богдай...

Кайчакларда ханның күңелен шундыйрак масаюлы уйлар биләп алды. Андый чакта аның комсызлыгы тагын арта төште. Аның еракка төбәлгән ач күзләренә Чулман буе гына түгел, хазары-ике белән, тиңгезләре белән бөтен Этил буе, кыпчак далалары күренә башлады. Мондый чакта аның йөгерек уйларын берни дә туктата алмады, шулай

[1] Иравыл — авангард.

да ул бөтенләй үк онытылып та китмәде. Татлы уйларга караганда, күз алдындагы чынбарлык усалрак та, тынгысызрак та иде. Шуңа күрә дә, күңеле күпме генә күтәренке булмасын, үз өенә якынлашу белән, аның бер дә юктан эче поша башлады. Аның тизрәк кайтып җитәсе, үз оясын исән-имин күрәсе килде. Тик, күңеле ашыкса да, аяклары артка өстерәде. Ике-өч чакрымлык койрык булып сузылган олауларны, көтүләрне артта калдырып, берничек тә ул үзе генә алдан чаба алмады. Шунлыктан, чирү бик әкрен кыймылдады, ат аягы белән түгел, сыер, сарык аягы белән кыймылдады.

Алмыш ханга буйсынган биләр арасында Ямгырчы би иң ышанычлыларыннан санала иде. Бүтәннәр кебек ул калым түләүне дә соңга калдырмый, хан үзенә көч сораса, я булмаса бирәр җиргә чакырса, беркайчан карышып та тормый иде. Шуның өстенә ул, Алмыш хан кебек, үзе теләп чумак йоласына күчкән иде. Ямгырчы би шулай үз кеше булганга да Алмыш хан Чулман аша сал-күперне аның катавына якын җирдә салды. Хан белән икәүдән-икәү генә сөйләшкәндә Ямгырчы би сал-күпергә тимәскә, киресенчә, болгарлар яудан кайтканчыга тикле уң як ярны үз көчләре белән саклап торырга сүз бирде. Үз ягыннан Алмыш хан Ямгырчы бине киләчәктә, бернинди тамгалык алмыйча, Этил буйлап аска да, өскә дә тавар белән тоткарлыксыз үткәреп җибәрергә, аннары Чулман буенда таланган байлыктан телем чыгарырга булды.

Алмыш хан үзе иравыл белән иде. Ямгырчы би җиренә аяк басып, төштән соң ачык, калку җиргә кермән коргач ул, үзенең якын кешеләрен җыеп, киңәш ясады. Киңәштә нишләргә кирәклеге турында сөйләштеләр. Терлек-туар белән, олаулар белән сал-күпер аша чыгу озакка сузылачак иде. Аларны чирүдән алда чыгару яхшырак булырмы, арттан чыгару яхшырак булырмы? Алмыш хан көчне икегә бүләргә булды. Мең кешелек иравыл, өч меңлек уң кул белән ул тиз арада кузгалып китеп, сал-күпердән чыга башларга уйлады. Үзенең көчен, олауларны, терлек-туарны сакларга ул урта кул белән сул кулны, чагдавылны[1] калдырырга булды. Алмыш хан иравыл, уң кул белән Чулман аша чыгып, сул як ярга урнашкан арада, көтүләр, олаулар чыга башларга, кораллы ир-ат исә иң ахырдан кузгалырга тиеш иде. Барлык арт илгә баш итеп хан үзенең өлкән улы Тәкин угланны калдырды.

## VI

Кичүгә Алмыш хан икенче көнне таң алдыннан килеп җитте. Бер ярдан икенче ярга сузып, саллар өстенә салынган йөзмә күпер үз урынында иде, күперне саклау өчен калдырылган болгарлар да, Ямгырчы би ирләре дә исән-сау иделәр. Аяк астында — куе урман белән капланган текә яр кырыенда — иртәнге кояш яктысында, елкылдап-җемелдәп, иксез-чиксез су җәелеп ята иде. Юан арканнар белән яр читләрендәге баганаларга тарттырып бәйләп куелган сал-күпер, агым уңаена сыгыла төшеп, киң Чулманны билбау сыман буып ята иде. Елганың уртасын узгач, теге якка таба ул инде чыбыркы койрыгы шикелле нечкә генә булып күренә. Анда, теге якта, зәңгәрләнеп тар гына яр сызыгы беленә; яр сызыгы өстендә, ап-ак төрткеләр булып, ак чатырлар, тирмәләр күренә иде.

Каршындагы шушы күренешне күрү белән, Алмыш ханның тамак төбе кытыкланып, кымырҗып куйды. Үз өенә, үз җиренә юл ачык булганга, җәйге таң шундый якты, шундый җылы булганга, аның күңелен искиткеч бер куаныч, күтәренкелек биләп алды. Үзенә көч, байлык, җиңү биргән, сал-күперне яман күзләрдән, яман куллардан саклап

[1] Чагдавыл — арьергард (гаскәрнең койрыктагы өлеше).

калган тәңрене олылап ул кулларын югары күтәрде, тыелгысыз бер өн белән кычкырып җибәрде. Ул әле аллага ничек ялварырга да белми иде. Өсте-башы тузанланган, арыган-йончылган, шулай да авызы колагына җитеп елмайган килеш, ул җитез генә җиргә төште, бүреген салып, Чулман аръягына, кояш чыккан якка карап, маңгаен җиргә орды.

Менләгән кешеләр шулай ук куанычлы өннәр белән җирне-күкне яңгыратып кычкырып җибәрделәр, атларыннан төшеп, маңгайларын җиргә ордылар. Яр өстендәге чатырлардан кешеләр йөгереп чыкты. Туганнар, танышлар бер-берсен табып, җылаша, сөенешә башладылар.

Куаныч ыгы-зыгысы кими төшкәч, ерак юлдан кайткан болгарлар чатырлар корып җибәрделәр. Илдә иминлек булуын белеп күңеле тынычланган Алмыш хан, баштагы уен үзгәртеп, арт ил килеп җиткәнче, үз атларына, кешеләренә бераз ял бирергә булды.

Болгарларның кайтуын түземсезлек белән көтеп торган Ямгырчы би, бер көтү җылкы, ун кисмәк буза, ачы бал алып, тиз арада хан янына килеп җитте.

— Җиңүең белән котлыйм сине, хан! — диде ул, ялагайланып.— Бүгеннән башлап син минем олы кунагым, ни телисең, шуны ал — барысы да синеке!

Алмыш хан тартынып тормады. Күчтәнәчкә дип китерелгән җылкыларны шундук суйдылар, тунадылар да кыздыра башладылар. Аш-су күңелле узды. Җиңүчеләр ашадылар, эчтеләр, мактандылар. Аннары йокыга аудылар. Йокыдан тордылар да яңадан ашадылар, эчтеләр, су керделәр.

Ял итү, күңел ачу икенче көнне, өченче көнне дә тукталмады. Болгарлар, киргәннән артык туарылып китеп, башаяк йөрделәр. Таларга, көчләргә күнегеп киткән кайберәүләр, ханның боерыгын онытып, якындагы авылларга ауга чыктылар. Казаякларны курку, ачу биләп алды: кешеләр, яклау эзләп, үзләренең ыру башларына килделәр. Ямгырчы би, юатып, коралланырга кушып, аларны кире озата торды.

— Көтеп кенә торыгыз, озакламый без аларның үзләренең бугазыннан алырбыз! — диде ул аларга.

Күңел ачуның өченче көнендә Ямгырчы би Алмыш хан тирмәсенә килде. Алар арасында тагын икәүдән-икәү генә сөйләшү булды.

— Юлың уңдымы, ханым? — диде би, хан биргән бузаны эчеп җибәргәч, яраргa тырышып.

— Уңды, би,— диде Алмыш хан.— Моннан соң Чулман Әтилгә түгел, минем калтага коячак.

— Оуу! — диде Ямгырчы би, көлеп.— Синең калтаң шундый зур булыр дип башыма да китермәгәнием. Җыртылмасмы, ханым?

— Җыртылса, менә мондый энә булганда, теләсә нинди җыртыкны да тегеп була,— диде хан, билендәге кылычына тотынып.

— Шулай, шулай, ханым,— диде би, аның сүзен җуплап.— Эш энәдә генә тормый... җебе кирәк, тегүчесе кирәк, дигәндәй... синекедәй нык-лы кул да кирәк. Алла сиңа моннан соң да күп яшь бирсен, байлык, саулык бирсен, ханым!

Алмыш хан, мактау сүзләренә күңеле булып, тыйнак кына тамак кырып куйды. Көн-төн эчүдән аңгы-миңге утырса да, Ямгырчы бинең тикмәгә генә килмәгәнлеген ул бик яхшы аңлады.

— Үзеңә тиешле телемне [1] алырга килдеңме? — диде ул үзе беренче булып.

— Әйе, ханым, телем дисәң дә була, кулагы [2] дисәң дә була,— диде Ямгырчы би.

[1] Телем — сугышта яулап алынган байлыктан сугышта катнашучыларга бирелә торган өлеш.

[2] Кулагы — процент.

Алмыш хан, Ямгырчы бинең ялагай йөзен беренче тапкыр күргәндәй, кызарынган күзләре белән аңа сынап карады.

— Күпме сорыйсың... ни сорыйсың? Акчалатамы, таварлатамы? — диде ул.

— Синең калтаңда күпме байлык барлыгын мин белмим,— диде би, ерактан уратып.

— Син түгел, аны мин үзем дә төгәл генә белмим,— диде хан.

— Шулай булгач, миңа тиешле кулагы да төгәл була алмый,— диде Ямгырчы би, шундук элеп алып.— Син миңа уннан берне бирмәкче булганыең.

— Шулай да булсын,— диде хан, тыелып кына.

— Үзең әйтеп торасың, ханым: юлың унган, калтаң калынайган,— диде би.— Шулай булгач, миңа тиешле кулагы да...

— Күпме сорыйсың: турысын әйт! — диде хан, түземлеген җуя башлап.

— Турысы шул, ханым...— диде Ямгырчы би, утка ташланырга җыенган кеше сыман,— бир миңа кызың Аппакны!

Алмыш хан кинәт урыныннан сикереп торды.

— Ап-пак-ны?! — диде ул, Ямгырчы бинең елмаюлы оятсыз күзләренә карап.

— Әйе, Аппакны,— диде би, башын иеп.

— Аппакны мин беркемнән тартып алмадым,— диде хан.— Ул минем үз кызым!

— Мин аңа шикләнмим, ханым,— диде Ямгырчы би.— Шулай да ул миңа тиешле кулагына торырлык, дип уйлыйм.

— Син... би, авызыңны улчәп ач !— диде хан, кашларын җимереп.— Аппак турында синең белән сөйләшү булмаячак. Аппакка торырлык бернинди кулагы юк, бернинди байлык юк! Аннары, алдан килешү буенча, мин сиңа кулагы түгел, телем бирергә тиешмен. Әйт, ни кирәк — колларммы? Көтүләрме? Тиреме? Алтынмы? Җирме? Ни кирәк?

— Аппактан башка миңа берни кирәкми,— диде Ямгырчы би, нык итеп.

— Юк! — диде Алмыш хан.

— Йә Аппакны бирәсең, йә мин синнән аерылам,— диде би тыныч кына, янап.

Алмыш хан, зур корсагын угалап, шаркылдап көләргә тотынды.

— Куркытты! Үтерде! Аерыл! — диде ул, мыскыллап.— Китә бир! Китеп кая барырсың икән? Кара аны, юлыма аркылы төшә күрмә,— башсыз калырсың.

— Белексез сүзләр сөйлисең, хан,— диде Ямгырчы би.— Киявең булырга теләгән бер кешене кисә башласаң, кызың ирсез кала күрмәсен!

— Җитте! — диде Алмыш хан, аяк тибеп.— Аппак турында тынынны чыгарма! Соңгы кат әйтәм: ни сорыйсың?

Чак-чак кына кайгылы, чак-чак кына ачулы, күңеле кырылган бер төстә Ямгырчы би башын иде.

— Сау бул, ханым, мин киттем,— диде ул.

— Кит! — диде хан, кулын селкеп.

## VII

Барысы да Ямгырчы би алдан уйлаганча булып чыкты. Алмыш ханның чибәрлеге белән бөтен Болгар йортка, бөтен Әтил буена атагы таралган гүзәл Аппакны үзенә бирмәячәген ул алдан ук белде. Алай гына да түгел, Аппакны үзенә тиешле телем өчен алу турында уйлап та карамады. Ул башкачарак уй йөртте. Аңа телем дә, Аппак та аз, аңа Алмыш ханның бөтен байлыгы кирәк иде! «Туктале, бише белән алыр-

мын әле мин үземә тиешлесен!» — дип уйлады ул күңелленнән, ханга янап. Тик менә анын шул гына әчен пошырды: Чулманның теге ягында әле булса кара төтен күренми иде. Ерακта, Болгар-торада ниләр бар икән? Әллә суарлар сүзләрендә тормадыларм ы?

Үз кешеләре янына ул ачулы йөз белән килде.

— Алмыш хан биргән аегын [1] үтәмәде! — дип кычкырды ул үз кешеләренә.— Алмыш хан казаякларны алдады. Үзебезне канга батырганчы таярга кирәк моннан. Күперне ташлагыз, тизрәк Шуран катауга кайтыгыз.

Бинең сүзләре казаякларга житә калды. Алмыш ханның ничек алдавын алар төпченеп тормадылар. Шундук ачулы шау-шу, кычкырыш башланды.

— Ит яхшылык, көт яманлык!

— Ханга ышанма, Әтилгә таянма,— диештеләр ирләр, ачулы мыгырданып.

Казаякларның тавышлануын болгарлар да ишетеп тордылар. Ханның үз сүзен үтәмәвенә, казаякларның алдануына аларның да эче пошты, шулай да алар ачыктан-ачык Ямгырчы би кешеләрен яклый алмадылар. Киресенчә, ханга, болгарларга каршы әйтелгән усал-усал сүзләрне ишетеп, алар да кыза башладылар. Ике арада әйткәләшү, янау, сүгенү тавышлары ишетелде.

— Яндырырга кирәк күперне!

— Таларга кирәк олауларын!

— Болгарлар үзләре безнең авылларны талый! — диештеләр ачулы казаяклар.

«Ныграк шаулагыз — ныграк сугышырсыз!» дип уйлады Ямгырчы би үз алдына.

Казаяклар ашыгып урман ягына юл тоттылар. Аларны беркем тоткарламады.

Ямгырчы би китеп күп тә үтмәде, Чулманның аргы ягында күккә ыргылып кара төтен күтәрелә башлады. Казаяклар белән булган ызгыштан соң тынычланып житә алмаган болгарлар кара төтенне тиз генә күрмәделәр дә. Күргәннәр иде, әле генә булган шау-шудан да көчлерәк бер тавыш белән, курку, шомлану белән шауларга тотындылар. Казаяклар онытылды, барлык күзләр аргы якка текәлде. Ни бар, ни булган анда? Кем белән кем сугыша?

Куркыныч килүен белдереп, шундук быргылар чинарга тотынды. Бөтен кермән аякка басты. Һай-һулап, кычкырып көтүчеләр болыннан атларны куып китерделәр. Ирләр кулларына коралларын алдылар, атларына менделәр.

Шул чакны сал-күпердә бу якка таба чабып килүче җайдак күренде. Кулына ул кара төтен чыгарып янган кисәү башы тоткан иде. Ярга чыгып, үр башындагы Алмыш хан янына килеп җитәр-житмәс ул, тамак ярып:

— Яу килә, яу! — дип кычкырып җибәрде.

Хан янына менеп житкәч, ул ачыклабрак сөйләде: Болгар-торадан улакчы килде, диде. Суар бие Килдеш ханбалыкны камап алган, анда бик каты сугыш бара икән, диде. Мондый сүз ишетеп, Алмыш хан лачт итеп жиргә төкерде дә, Килдеш бинең атасын-анасын, бабаларын искә төшереп, катлап-катлап сүгенергә тотынды.

Шул авыкта ханнан арттарак торган ирләр арасында тагын ниндидер ыгы-зыгы башланды. Барысы да артларына борылып карадылар. Көнчыгышта, олы юл өстендә ниндидер тузан болыты күтәрелгән иде. Бу дүрт күз белән көтеп торган олаулар, көтүләр булырга тиеш иде. Кешеләрнең йөзе яктырып китте. Алмыш ханның күз карашында тыел-

[1] Аек — вәгъдә, биргән сүз.

гысыз бер көч-омтылыш, ныклык чаткылары күренде. Олауларның кичүгә килеп житүен көтеп тормастан, ул ир-атларга теге якка чыга башларга боерды.

Бер-ике көн эчендә көч җыеп, ял итеп алган атлар, пошкыра-пошкыра, сөзәк, киң юлдан аска ыргылдылар. Ташлы, тигез җиргә — яр читенә килеп төштеләр дә, кешнәп, авызлыкларын чәйнәп, суга тартылдылар. Тик бу юлы аларга Чулман суын татып карарга туры килмәде,— дөп-дөп басып, вак ташларны, каты балчыкларны изертеп, бәреләсугыла, кысыла-төртелә арттан бертуктаусыз башка атлар төшә тордылар, алдагыларны кысрыклый тордылар. Алдагылар исә, арттан куалаган тыелгысыз көчкә буйсынып, биек араталар арасына барып керделәр дә баскан саен тирбәлеп тора торган басмаларда кинәт тынып-юашланып калдылар, шак-шок басып, куркып-өркеп, су уртасыннан коры җиргә таба омтылдылар.

Күпер авызында тыгыз койма булып торган атлы чавышлар [1] ир-атларны салга икешәрләп кенә, билгеле бер ара саклап кына керттеләр. Кайберәүләр күпергә алданрак эләгергә, кайберләре, киресенчә, арттарак калырга тырышты. Кайберсенең судан куркып аты чыгымчыларга тотынды. Чавышлар бернигә карамадылар: киреләнгән атларга да, кешеләргә дә озын колга белән тондырып кына алдылар.

Дүрт мең кешелек чирү бары кич карангы төшкәндә генә чыгып бетте. Соңгы ир-атлар яр астына төшеп ятканда, арттан олаулар, көтүләр килеп җитте. Алмыш хан, арт илне саклап килгән ике мең ир-атка, шулай ук аз гына да тоткарланып тормыйча, үзе артыннан сул якка чыга башларга боерды. Тәкин углан иртәгә якты көздә олаулар, көтүләр белән күпердә озак тоткарланып тормас өчен, ир-атларны төне буе чыгарырга — күпме булдыра алса, шул чаклы чыгарырга булды. Шулай итеп, төне буена сал-күпердән атлар, кешеләр туктаусыз агылды. Хан күче янында, олаулар, көтүләр янында Тәкин углан белән бер-ике мең ир-ат калды. Алмыш хан кебек, Тәкин углан да бу яктан куркыныч килер дип башына да китереп карамады. Алмыш хан кебек, башка бик күпләр кебек, ул да бары оятсыз суарлар турында гына уйлады. Ачуланып китеп барган Ямгырчы бине нишләптер барысы да исләреннән чыгарып ташладылар. Аннары, Тәкин углан аның хан белән бозылышып китүен белмәде дә, ишетмәде дә.

Алмыш хан төнне сул якта кунды. Таң атар-атмас борын торып болгарлар ат менделәр, ярсып, оран салып [2], ханбалыкка юнәлделәр.

## VIII

Көннәрдән бер көнне Тотышның ярасы бөтенләй төзәлеп бетте. Яшь егет аягына басты. Аңа инде каңгы өстенә куелган күтәрмә генә тар, кысан була башлады. Байтал имче ашарга-эчәргә элеккегә караганда күбрәк китерә башлады, шулай да аның җиргә төшерү турындагы сүзләрен ишетмәмешкә салышты: хан боерыгын бозарга аның кыюлыгы җитмәде.

Алмыш хан олауларны артта калдырып, кичүгә таба кузгалып киткәч тә, Байтал имче Тотышның үтенечен Тәкин угланга җиткерде. Яралы егет инде савыкты, миннән эш китте — үзегез теләсәгез нишләтегез, диде. Тәкин углан атасының боерыгын белә иде. Шулай ук ул таза-сау егетне — батыр егетне имче карт карамагында гына калдыруның да бик үк яраган эш түгел икәнлеген аңлый иде.

— Ярар, имче баба,— диде ул Байтал картка.— Аның иленә инде кош та очып кайта алмаячак. Сак куярбыз, җиргә төшерербез.

Шул ук кичне, олаулар ялга туктагач, Тотыш өчен аерым тирмә

[1] Чавыш — гаскәрдә тәртип саклаучы.
[2] Оран салып — кычкырып.

кордылар. Бер ай чамасы кангыда киез өстендә аунап килгәннән соң Тотыш җиргә аяк басты. Аягы астында нык, каты җирне тоеп, куанычыннан ул елмаеп җибәрде, балаларча сикергәләп алды, күкрәгән киерде, кулларын селтәде. Тирә-яктагы дулкын-дулкын калкулыкларны, урманнарны, болыннарны күрү; туганнан бирле таныш, якын күк читен — кызарып баеган кояшны, эрегән алтын белән өретелгән сыман болытларны, озын кулагаларне күрү анда искиткеч бер күтәренкелек, сөенеч тойгысы тудырды. Аның еракта караеп күренгән урман буйларына, кояшның соңгы яктысы төшкән калкулык сыртларына йөгереп барасы килде, иркен болында утлап йөргән атлар арасында, йомшак утләндә аунйысы килде. Бу мәлдә ул үзенең тоткын икәнлеген бөтенләй онытып җибәрде.

Аңа дип корылган тирмә иркен генә иде. Идән уртасына учак ягылган иде. Учак өстенә казан-ни асылмаган иде. Бу бары беренче тапкыр корылган тирмә эченнән явыз иләрне куалап чыгару өчен генә ягылган учак иде. Ишектән кергәч тә, каршы якта, учак артында төрелгән урынҗир өелеп тора иде. Шунда ук вак-төяк савыт-сабалар күренә иде.

Тотыш үзенең тирмәсенә бер генә күз ташлады да янадан тышка чыкты. Ишек төбендә ул ниндидер ят кеше белән очрашты.

Чем-кара чәчле, кара тут йөзле бу кеше Тотыштан калкурак та, өлкәнрәк тә иде. Төсе-бите белән ул кояшлы яклардан Этил-Чулман иленә тавар белән килә торган базарганнарга охшашрак иде. Тик аның өсте-башы бер дә аларныкы кебек бай түгел иде. Өстенә ул кыршылып беткән кыска тун, тире өм [1], башына исә колакчынлы куян бүрек кигән иде. Матур кылыч борыны астында нечкә генә кара мыегы салынып тора. Матур кара күзләрендә юашлык, монсулык сизелә иде.

— Исәнме, Тотыш,— диде ул, тыйнак кына баш иеп.

Иелгәндә аның бүрек колакчыны ачылып китте. Шул чакны Тотыш аның уң колагы юк икәнлеген күреп алды. «Кол!» дип уйлады ул үз алдына. Ник килгән соң ул монда?

— Исәнме,— диде ул, бер дә юктан елмаеп.

— Мине сиңа җибәрделәр,— диде кол.

— Кем? — диде Тотыш, чамадан тыш ашыгып, кычкырып.

Аның күңеленә шундук: «Әллә теге кыз микән?» — дигән бер уй килгән иде.

— Тәкин углан,— диде кол.

— Шулаймыни? — диде Тотыш, кинәт сүрелеп.

Беренче карауда кызгану тойгысы тудырган бу кисек колаклы кеше анда чиркәнү шикелле нәрсә уята башлады. Ул аның монсу-юаш йөзенә дә, киселгән колагына да карамаска тырышты.

— Минем атым — Торымтай,— диде юаш кеше.— Мин — Алмыш ханның колы.

— Мин аның тоткыны,— диде Тотыш.

— Юк, син аның тоткыны түгел, тотыгы,— диде Торымтай, төзәтеп.

— Сиңа миннән ни кирәк, Алмыш ханның колы? — диде Тотыш коры гына.

— Мине сиңа Тәкин углан җибәрде,— диде Торымтай, яшь егетнең кискенлегенә аптырагандай итеп.

— Ник җибәрде?

— Бүгеннән башлап — мин синең колың.

— Тоткынның колы булмый! — диде Тотыш ачу белән.— Бар, кит, Тәкин угланга шулай диген.

— Тоткынның колы булмаса да, тотыкныкы була,— диде Торымтай.— Кума мине, Тотыш алып. Төне-көне терлек арасында аунауга караганда, синең колың булу миңа мең артык.

— Кал алайса,— диде Тотыш, кулын селтәп.

[1] Өм — ыштан, чалбар.

## IX

Торымтайның тирмәсе якында гына иде. Ул, жиңел-жиңел атлап, үз өенә кереп китте, аннан бер кулына чүлмәк-казан, икенче кулына ниндидер агач чиләк белән ниндидер төенчекләр тотып чыкты. Тиз арада ул Тотыш тирмәсе янында учак җайлап җибәрде — таган ясады, казанга су салып кайнарга утыртты. Шуннан соң кыл иләктә тары ярмасы юды.

Тотыш, җиргә сузылып яткан килеш, тавыш-тынсыз гына аның эшен күзәтте. Юк, ул аның эшен генә дә күзәтмәде, ул тирә-якны — кешеләрне, тирмәләрне, төтеннәрне, утлап йөргән терлекләрне күзәтте. Аның ирекне иркенлекне сагынган күз карашы, беркайда да тоткарланып тормыйча, бер нәрсәдән икенче нәрсәгә йөгерде. Бар нәрсәгә ул яратып, сокланып карады. Күрәсең, шуңа күрәдер, ул үзе дә кемнендер үзен яратуын, иркәләвен теләде. Ул үзен тулысынча иректә итеп, берни белән чикләнмәгән, тыелмаган итеп тойды, шулай да аның кемгәдер сыенасы, кемнеңдер канат астына керәсе килде. Шул ук вакытта бу иксез-чиксез киңлек, бу иркенлек аңа сыенып өчен тар булып тоелды. Аның күңеле каядыр икенче төрле киңлеккә, икенче төрле иркенлеккә ашкынды. Тик бу икенче төрле киңлекне-иркенлекне ул үзенең туган җире ягында — артта калган Кызыл Яр катау ягында эзләмәде, аның күзләре бөтенләй капма-каршы якка — көнбатышка текәлде. Анда, соңгы кояш яктысы төшкән серле калкулыклар артында аңа теге серле кыз бардыр шикелле тоелды. Никтер ул аны еш кына ике аяклы, ике куллы кешеләр арасында — менә шушында якында гына йөргән кешеләр арасында очратырмын, дип түгел, кайдадыр алда, томанлы, билгесез күк читендә очратырмын, дип уйлады. Кайчагында, киресенчә, ул аңа артта гына качып-посып торадыр шикелле булып, кинәт борылып карадың исә, шундук аның белән күзгә-күз очрашырсың шикелле булып тоелды.

Тик ул көткән кыз арттан да, алдан да килеп чыкмады. Көннәр үтте дә үтте. Кая булды ул? Шулай ук бөтенләйгә юкка чыкты микәнни? Ул берни белмәде.

Әкренләп кояш сүнә барды, күк читенең бизәкләре куера, үзгәрә, алмашына барды; җирдәге төтеннәр кимеде, тавышлар тоныкланды. Җир өстенә кичәгечә, былтыргыча, моннан йөз ел, мең ел элеккечә, аксыл томаннары белән, чикерткә чыңнары, серле пышылдау-уфылдаулары белән, йомшак кына булып, җәйге караңгылык төшә башлады.

— Тотыш, аш суына,— диде Торымтай.

Тотыш карулашмады. Кыюсыз гына атлап кол аның янынарак килде, үзенең сүзләрен кабатлады.

— Ә? — диде егет, сискәнеп.

— Аш суына...— диде тагын да Торымтай.

Тотыш, урыныннан торып, чатырга кереп китмәкче булды. Торымтай аның юлына аркылы төште, кулындагы комганга күрсәтеп:

— Юынып алыйк,— диде.

— Мин инде юынуны онытып бетердем,— диде Тотыш, үзенең агарып калган кулларын караштырып.

Ул, беләкләрен сызганып, су чәчрәтә-чәчрәтә, юынырга тотынды. Кулына, битенә салкын су тигәч, кинәт үзгәреп киткәндәй булды. Шундук туган ягы күз алдына килде, киң Чулманны иңләп-буйлап йөзүләре, ярдан сикереп суга чумулары исенә төште. Эчне пошырган, күңелне әрнеткән моң-сагыш онытылды, аның урынына, усал мачы булып, бөтенләй икенче уйлар тырнашырга тотынды. «Качарга кирәк моннан, качарга!» дип уйлады ул, үз алдына үртәлеп.

Юынып бетәр-бетмәс ул билен турайтты, юаш кына, күндәм генә басып торган Торымтайның кулындагы сөлгене тупас кына тартып алды

да кабаланып сөртенергә тотынды. Торымтайга ул ашардай булып карады. «Алмыш ханның колы!» дип уйлады ул, сыңар колаклы кешегә карата җирәнү тоеп.— Әнә шулай колаксыз калганчы, ычкынырга, сыпырырга кирәк моннан!»

— Кем тешләде колагыңны? — диде ул, күрәләтә мыскыл белән.

Яшь егетнең мондый тупаслыгына, искәрмәстән үзгәрүенә Торымтайның күңеле кырылды. Уңайсызланып ул күзләрен түбән иде, ыкмык итте.

— Яуда чаптылармыни? — диде Тотыш, көлеп.

— Мин әйттем: мин — Алмыш ханның колымын. Миннән көлмәвеңне үтенәм, Тотыш — диде кол.

— Кол шул, кол! — диде Тотыш.

Сөртенгәч ул сөлгене җиргә атып бәрде, үз алдына тузынып чатырга кереп китте. Өй эче эссе иде. Көйрәп яткан учак яктысында, идәнгә җәелгән ак киездә ниндидер табак-савытлар күренә, өйдә ниндидер аш-су исе килә иде. Ашыйсы килсә дә, Тотыш табын янына утырып тормады — холыксыз балалар кебек, үпкәләп, урын-җир өстенә менеп ятты.

«Ике ел буена шул сыңар колак Торымтай кебек кол булып яшәргәме! — дип уйлады ул, кем беләндер сүз көрәштергән сыман.— Терлек арасында аунаргамы, кемнәрнеңдер кулына су салып торыргамы?! Юк, беркайчан да булмас!»

Кемдер якында гына: «Син кол түгел, тоткын түгел, син — тотык!» дип пышылдаган кебек булды. Тотыш, сискәнеп, як-ягына әйләнеп карады. Өй эчендә аның үзеннән башка бүтән беркем дә юк иде. «Тоткын белән тотыкның аермасы нидә соң?» диде ул үз-үзенә. «Тотыкның колагын кисмиләр», диде кемдер, карулашып.

«Әйе шул, минем колакларым исән! — дип уйлады ул, сөенү шикелле бер нәрсә тоеп.— Мин — Торымтай түгел, Торымтай — мин түгел. Мин иректә. Минем үз колым бар».

Иректә, димәк, кайчан да булса ул кешеләр арасында иркенләп йөри алачак! Очратмас микәнни шулай да ул теге серле кызны?

Тотыш ашап туйганда, башын түбән иеп, тавыш-тынсыз гына Торымтай килеп керде. Тавыш-тынсыз гына табынга якынлашты, бушаган савыт-сабаларны җыештыра башлады. Аның бик нык күңеле кырылганлыгы әллә каян күренеп тора иде. Тотышка ул кызганыч булып тоелды.

— Утыр, аша. Кайда йөрисең? — диде ул аңа, җиңелчә шелтә белән.

— Мин ашадым,— диде кол.

Тотыш, чүлмәктән ачы бал агызып, аңа сузды.

— Алайса, эчеп җибәр,— диде.

Торымтай көрсенеп куйды, үпкәсен-ачуын бер юлы йотып, елмайгандай итте дә, калтыранган кулы белән сычук тулы аякны алды.

— Тотыш алып кулыннан сычук алмак — зур сөенеч. Мең яшә, би углы! — диде ул күңеле тулып.

Аның бу мактау сүзләре Тотышка никтер ялагайлану булып тоелды. Үч иткәндәй, шунда ук аның кисек колагы күренеп китте. Тотыш, үзе дә сизмәстән, чыраен сытып куйды. Юк, ошамагач ошамый аңа бу кол! Аның әле беркайчан да мондый юаш, мондый түбәләнгән кешене күргәне юк иде. Акбүредә дә коллар бар иде. Тик аларның коллыгы нидә икәнлеген Тотыш бик үк аңлап та җитми иде. Алар, ыруның башка игенчеләре кебек, иген игәләр, балыкчылар кебек балык тоталар, аучылар кебек ауга йөриләр иде. Тик баштарак алар телне белмиләр иде дә, акбүреләргә ничектер бик үк катышмыйлар иде. Юк, алар анда беркайчан да хатын-кыз эше белән дә булашмыйлар. Кайда гына булмасын, алар ирләр белән. Аларның үз алачыклары, үз куышлары бар. Үзләренең хатыннары, балалары бар. Аларның колаклары да исән.

Тик коллыкка эләгүнең беренче елында аларның чәчләре генә алынган була. Чәч нәрсә ул — баш кына исән булсын!

— Каян син? Ничек бу көнгә төштең? — диде Тотыш, үзенең колына эндәшеп.

Торымтайның күз карашы элеккедән дә ныграк моңсуланып калды, мыек чылгыйлары калтыранып китте. Күрәсең, ул мондый сорау көтмәгән иде. Ул, нәрсә әйтергә белмәгәндәй, беравык тынып торды да, тирән көрсенеп:

— Мин алыстан,— диде.— Син юнырга оныткандай, мин дә үземнең уйгур булдыгымны онытканмын. Моннан ун ел элек мине беренче тапкыр Күчәр базарында кол итеп саттылар. Бурычын түләргә атамның акчасы җитмәде. Шул. Мин үзем теләдем сатылмакка. Еглашып аерылдык. Мине Сәмәркәнд сарты алды. Ул тагын бер җөфүткә сатты. Кулдан кулга күчеп, менә бу якка килеп чыктым. Шул... Сүләсәң сүз бетмәс. Монда менә өченче ел...

## X

Алар озак кына сөйләшеп утырдылар. Торымтай сөйләде, Тотыш тыңлады. Тотыш элек тә чит җирләрдә, чит илләрдә булган, күпне күргән кешеләрнең сөйләгәннәрен тыңларга ярата иде. Андый кешеләр күз күрмәгән, колак ишетмәгән илләр, торалар [1] турында, ят, кызык эшләр, яулар турында сөйлиләр. Аларның сүзен җомак [2] тыңлаган кебек бирелеп тыңлыйсың. Чит илләр, чит җирләр турындагы сүзләр шулай ук күңелдә нииндидер теләкләр, омтылышлар тудыра. Кешеләр сөйләгән серле, куркыныч, күңелле җирләрдә үзеңнең дә буласың килә башлый.

Торымтайның сөйләгәннәреннән соң да шулай булды. Тотыш, үз колының туган якларын, ул булган төрле ят җирләрне күз алдына китереп, уйланып, онытылып утырды. Авыкның [3] узганын алар сизмәделәр дә. Тышта инде караңгы төшкән иде бугай. Торымтай соңгы кат көрсенде дә чыгып китәргә теләк белдерде.

— Бүген мин сиңа кирәкмәмдер? — диде ул Тотышка.

— Юк, китә бир,— диде Тотыш уйчан гына.

Торымтай, тыныч йокы теләп, мыштым гына чыгып китте. Ул үз тирмәсенә кереп тормады, каядыр ары китеп барды. Бүген Тәкин углан, яр буенда үзе генә калгач, аш-су ясый иде. Анда акмаса да тамарга тиеш. Торымтай шунда ашыкты.

Тотыш, үзенең колы чыгып киткәч тә, урынына ятмыйча, учак янында озак кына уйланып утырды. Ул да үзенең үткән көннәрен исенә төшерде. Үткән көннәрдән бигрәк, үзенең Тәңкәсе турында уйланды.

Әйе, аның Тәңкәсе дә бар иде ич әле! Нишләп моңарчы уйламады икән соң ул аның турында? Төштәге кебек килде дә, күренде дә юкка чыкты. Кайда икән ул? Бармы ул җир йөзендә, әллә юкмы? Кайда алар бергә качып яткан урыннар? Үз куышына сыендырган, аерым тирмә корып биргән балыкчы кайда? Булганмы алар, булдымы, әллә барысы да уйдырмамы болар? Нәрсә соң ул тормыш, тәңрем? Яшиме соң кеше чынлап, әллә шулай мәңге төш күрәме? Әле генә шушында утырган Торымтай кайда? Болай да тынгысыз күңелгә коткы салып, борчу салып киткән теге кыз кайда?!

Ул уфтанып куйды. Учакка утын өстәде. Аның шулай уйланып, моңаеп таңга тикле утырасы килде. Аның инде күптән, бик күптән менә шулай учак янында изрәп утырганы юк иде. Нинди күңелле, нинди җылы-моңсу монда! Әллә тормыш шушы үземе соң, тәңрем? Түбә

[1] Тора — шәһәр.
[2] Җомак — әкият.
[3] Авык — вакыт.

өстендә — тирмә, каршында — утлы күз. Тагын ни кирәк сиңа, кеше баласы?!

Шулай утыра торгач, тышта аңа ниндидер кыштырдык ишетелгәндәй булды. Аның колаклары үрә торды. Ул, әчке бер курку-каушау белән, тынын кысып көтә башлады. Үзенең шул тикле куркаклыгына аның исе китте. Ул берни эшли алмады — каушаудан аның куллары, аяклары калтырана башлады.

Кемдер кыюсыз гына ишек бавын тарткалады.

— Керегез, кер! — дип кычкырды егет, урыныннан торып.

Ишек ачылып китте, өйгә ниндидер карачкы килеп керде. Бу — Торымтай түгел иде. Карачкы беравык ишек төбендәрәк торды да кыюсыз гына бер-ике адым алга атлады. Тотыш, керүчедән күзләрен алмыйча, артка чигенде. Ул, саллырак берәр нәрсә тапмакчы булып, идәнгә күз төшереп алды: учак янындагы утын кисәкләреннән башка берни юк иде.

— Син кем? Кем кирәк сиңа монда? — диде ул.

— Миңа... Тотыш кирәк,— диде карачкы, сынып-өзелеп чыккан бер тавыш белән.

Тотыш аның каушавын, калтырануын бөтенләй сизмәде, ул бары аның: «Тотыш кирәк», дигән сүзләрен генә ишетте.

— Нигә кирәк ул сиңа? — диде ул, кычкырып.

Аның маңгаеннан салкын тир бәреп чыкты, иреннәре кипте. Йа тәңрем, ни булды соң әле аңа? Нигә, нилектән шулай кисәк кенә коелып төште соң әле ул?

Карачкы эндәшмәде. Тотыш та тынып калды, көтә башлады. Ул карачкыны аерыбрак күрә башлады. Чынында ул аны монда кергәч үк... кергәнче үк күргән иде бугай инде. Тик... Әйе, буйга ул ирләр кебек озын түгел, иңбашы да ирләрнеке кебек түгел. Тавышы да икенче төрле иде бугай.

Алар, нәрсәдер көткән сыман, баскан урыннарында кузгалмыйча тик тордылар. Карачкы тамак кырды, бер-ике адым учакка таба атлады да, кинәт битендәге бөркәнчеген ачып җибәрде. Көтмәгәндә күзенә көчле яктылык төшкән сыман, йөзенә кисәк кенә ялкын бәрелгән сыман, Тотыш исе китеп, аһылдап җибәрде. Аның каршысында, тулган айдай балкып, сокландыргыч гүзәл бер кыз басып тора иде. Ул да аның кебек каушаган иде, ул да аның кебек тынычсыз иде. Аның да оялчан күзләре, алып егетнең күзенә туры карый алмыйча, бер йомыла, бер ачыла иде. Ап-ак бит очларында җиңелчә генә алсулык уйный иде. Юка бөркәнчеге аша аның калку күкрәге сизелер-сизелмәс кенә тирбәлеп тора иде. Аның серле, яруклы күз карашыннан ниндидер яктылык бөркелеп тора сыман иде. Киемнәреннән юка чәчәге иседәй җиңел, татлы ис тарала иде. Ул үзе дә болан баласыдай җиңел, житез сыман, учактагы ялкындай кайнар сыман иде.

— Мин сиңа... ашарга китердем... Тотыш,— диде ул, тотлыгып, сулуы кабып.

Ул өйнең табак-савыт торган төшенә килде, өстендәге бөркәнчек итәге астыннан көмеш күбәтә белән көмеш комган чыгарды. Шуларның барысын да савыт-саба янына утыртып куйды. Билен турайтканда качып кына, яшертен генә Тотышка бер күз карашы ташлап алды. Тик Тотыш аның бу угрылыгын күрми калмады. Бераз гына дымсу, бераз гына томанлы, тере күз карашы яшь егетнең йөрәгенә ут үрләтеп җибәрде.

— Теге... синмени ул? — диде Тотыш, пышылдап.

— Мин... — диде кыз, шулай ук пышылдап.

— Мин сине көттем,— диде егет.— Нигә килмәдең?!

— Җибәрмәделәр,— диде кыз, башын иеп.

— Кемнәр?

— Курыктым...— диде кыз.— Сизсәләр, күрсәләр... Ярамый...
— Кемнәр җибәрмәде соң? — диде Тотыш, соравын кабатлап.
— Иям,— диде кыз, көттеребрәк.
— Ашарга да ул җибәрдеме?
— Ул.
— Кем соң ул? — диде егет, төпченеп.
— Аппак...— диде кыз, пышылдап.
— Аппак?! — диде Тотыш.— Алмыш хан кызымы?

Кыз баш какты. Тотыш аптырап каушап калды. Алмыш хан кызы ана ашарга-эчәргә җибәргән! Ник? Яратамы, кызганамы? Үзеннән калган калдык-постыкнымы? Димәк, бу кыз аның карасы... асравы, йомышчысы?

Ул искәрмәстән айнып киткәндәй булды. Үзендә ул күңел кайту сыман бер нәрсә тойды. Бу гүзәл кызның кара булуы өчен түгел, монда тагын икенче бер кеше барлыгын белгән өчен ул күңел кайту шикелле нәрсә тойды. Кем белә, ул икенче кеше артында тагын өченче кеше дә бардыр! Хан кызы Аппак, имеш. Аның туган җирен килеп баскан ханның, үзен менә тоткын итеп кулга алган ханның, каргалган канечкеч ханның кызы, имеш! Юк булгач, юк!

Күзләрдәге дымлы әлпә юкка чыкты, тамырларда ургып аккан кайнар кан бозга әйләнде.

— Мин тереллдем, миңа берни кирәкми,— диде ул кызга, тыныч бер салкынлык белән.

— Алырга кушты... күчтәнәч...— диде кыз, баштагыдан да ныграк каушап.

— Миңа хан кызыннан бернинди күчтәнәч кирәкми! — диде Тотыш, шактый тупас итеп.

— Ул сине ярата, Тотыш! — диде кыз.

Ул моны ничектер ыңгырашып әйтте. Аның тавышында курку да, ялыныч та, ярсу да сизелде. Шулай да ул егетнең күңелен кузгата алмады. Бары ишетеп кенә белгән ниндидер кызның яратуы турындагы сүзләр күз алдында басып торган тере кызның гүзәллеге янында бөтенләй көчсез булып яңгырады. Алай гына да түгел, үзенең яратуын карасы аша белдереп яткан хан кызына карата егет күңелендә кире тойгы кузгалды.

— Мин — Алмыш ханның тотыгы,— диде ул, кыздан күзен алмыйча.— Инде аның кызының тоткыны буласым юк!

— Ул сине ярата, Тотыш! — диде кыз, ашыгып, кабатлап.

— Мин аны яратмыйм! — диде Тотыш, усал итеп.

Ул кыз китергән күбәтә белән комганны алды да кире бирмәкче булды. Кыз алмады.

— Кирәге юк хан кызының калдыгы! — диде егет ачу белән.

Ул күбәтә белән комганны идәнгә орды. Көмеш капкач, чынлап, ыңгырашып, читкә тәгәрәде, ашамлык көлгә түгелде. Комганның нечкә муеныннан, киселгән бугаздан аккан кан сыман голт-голт килеп, ачы бал агып чыкты.

Кыз, кулы белән битен каплап, чыркылдап кычкырып җибәрде. Кырт борылды да, итәгенә ут капкандай, ишеккә ташланды.

## XI

Тотыш бик соң исенә килде. Исенә килде дә шулай ук ишеккә ташланды. Кара мачы булып, шундук аның юлына карангылык аркылы төште. Ул чатырыннан берничә адым читкә киткәч тә туктап калды. Күзләрен зур ачып як-якка каранды. Тавышларга, төрле кыштырдыкларга колак салды. Кычкырырга, кызны чакырырга аның йөрәге жит-

мәде. «Аңсыз! Белексез! Туң баш!» — диде ул, үз-үзен сүгеп, әрнеп, үкенеп.

Карангылык, билгесезлек алдында аптырап, кая барырга белмичә ул торды-торды да, күзе иләнә төшкәч, каядыр кузгалып китте. Аның әйгә кирәсе килмәде. Аның ярсыган, өзгәләнгән күңеленә киез тирмә эче генә түгел, әйтерсең, барлык күк эче дә, барлык җир йөзе дә кысан иде. Аңа йөрергә, каядыр барырга кирәк иде, аңа тик тору, утыру, яту ярамый иде. Тирә-якта адым саен ягы тирмәләре барлыгын да, төнге кирмәнне бик зур тимер коршау сыман итеп каравыл уратып алганлыгын да ул бик яхшы белде. Шулай да ул тирмәләрдән дә, күзгә күренмәгән каравылдан да курыкмады. Үзенең кая барып чыгасын бөтенләй белмәстән, караңгы төннең күзенә туры карап алга атлады. Ул үзендә искиткеч бер җиңеллек тойды. Аяклары җиргә тисә тиде, тимәсә тимәде. Юк, ул йөгермәде, ул әкрен генә барды. Ул аны куып җитмәкче булып, аны янадан күрмәкче, очратмакчы булып барды.

Кайда булыр ул? Кая китәр? Ул шушында гына, шушы тирәдә генә булырга тиеш. Ул әле генә аның янынннан чыгып китте. Өй эчендә аның татлы исе, күз алдында — күркәм, гүзәл төсе торып калды. Карачкы тирмәләр, әйтегез — кая китте ул? Күктәге болытлар, карачкы калкулар, әйтегез — кайда ул? Куаклар, түмгәкләр, яшермәгез, әйтегез — кайсы юлдан кайсы якка китеп барды ул серле кыз? Сез белергә тиеш аны. Сез күрергә тиеш аны. Андый кызны күрмәү-белмәү язык булыр!

Ул чыклы үлән ерып барды. Ян якта очлы кара өйләр калды, йөк тулы арбалар, каңгылар калды, кайдадыр атлар пошкырды, кайдадыр этләр өрде. Әйтерсең, ул берни күрмәде, берни ишетмәде. Әйтерсең, саташып йөрде. Ул, әйтерсең, ниндидер үләләр кирмәне аша барды. Ул, билгеле, өйләрне дә, йөк төялгән арбаларны-каңгыларны да читләтеп үтәргә тырышты. Кайбер төштә кинәт җиргә ятты, кайбер төштә посып, тыңлап торды. Төнге каравылга эләкмәүдән аны ниндидер моңарчы билгеле булмаган бер тойгы саклап барды.

Күп тә үтмәде, ул ниндидер наратлыкка барып керде. Ылыслы нарат ботаклары аның битеннән сыйпап-сыйпап алды. Борынына таныш ылыс исе килеп бәрелде. «Әллә кирмәннән чыктыммы?» дип уйлады ул, артына борылып. Тирә-ягына ул берничә тапкыр ныгытыбрак карады, ныгытыбрак тыңлап торды. Күзгә күренмәс тимер кыршау, тимер кыршау эчендәге өйләр, кешеләр, арбалар — барысы да артта калган иде бугай. Тонык кына тавышлар ул яктан килә иде, сирәк-мирәк утлар да ул якта җемелди иде. Алда — тынлык, бушлык, карангылык.

Туктале, котылды түгелме соң ул? Тоткыннан, коллыктан котылды түгелме соң?!

Әйе, әйе, котылды.

Котылды!

Кинәт аның тыны бетте, аяк буыннары йомшап калды. Уттай янган күзләре белән ул тагын артына борылып карады. Карады да бар көченә чабарга тотынды. Ят җир булса да, урманда аңа куркыныч түгел иде. Урманны ул белә иде, урман аның күптәнге танышы, якынындашы иде.

Аның битенә, кулына чыбык очлары тиеп китте, аяклары җирдә яткан ниндидер агачларга, корыган төпсаләргә төртелде, ниндидер кечкенә чокырларга батып-батып китте. Ул, бернәрсәгә карамыйча, йөгерүен белде.

Шулай күпмедер йөгергәч, ул урманның сирәкләнә башлавын, җир өстенең түбәнәюен шәйләде. Ул янадан туктады, як-ягына җентекләбрәк карарга тотынды. Караеп тын гына утырган агачлардан башка берни дә аера алмады, шулай да эчке бер сиземләү буенча, аннары якын-тирәдәге тыгыз, куе тынлык буенча ул үзенең чыннан да камалу-

дан ычкынганлыгын аңлады. Аның аз гына булса да тынычлап ял итеп аласы килде. Тик аяклары аны бертуктаусыз алга өстерәде.

Алда урман яктырганнан-яктыра барды. Каяндыр үтеп кергән яктылыкта төз нарат кәүсәләре, бер-берсеннән аерылып, аермачык булып күренделәр. Таң атарга әле иртәрәк иде бугай. «Каян килә бу яктылык?» дип уйлады Тотыш, исе китеп.

Яктылык үтеп кергән яктан аның борынына салкын су исе килеп бәрелгәндәй булды. Бераз баргач урман бетте, тирә-як ачылып, яктырып китте. Тотышның аяк астында төнге Чулман җәелеп ята иде.

Чулман! Бөек елга, туган елга! Чынмы бу, ялганмы! Син өндәдең, син чакырдың мине, син коткардың тоткын углыңны! Сагындыңмы Тотыш углыңны? Менә килдем, менә таптым сине! Без яңадан бергә, изге үзән! Бергә булыйк, аерылмыйк мәңге, Чулман!

Ниндидер ботак-сатакларга тотынып ул текә ярдан аска төште. Талгын гына чайкалып, агып яткан су янына килде, иелеп битен, кулын юды. Аннары ул бер-ике адым эчкәрәк керде. Аяк тамырлары бүйлап, кытыклап, татлы бер дулкын йөгерде. Ул тынычланып калды. Бар кайгылар, борчулар онытылды.

Чынмы бу, ялганмы? Аның күз алдында, аның янында, ялангач аякларын иркәләп, сыйпалап, үз телендә нидер гөлдер-гөлдер килеп, йомшак, көчле салкынча су акты да акты.

## XII

Шулай онытылып, суга, иркенлеккә таң калып торганда, кайдадыр якында гына «чык!» дигән тавыш ишетелеп китте. Ташка таш тидеме, тимергә тимерме... Куркытылган киек кебек колакларын үрә торгызып, Тотыш артына борылып карады. Яр буе инде яктыра башлаган иде, шулай да әле бар нәрсәне аермачык күрерлек түгел иде. Аннары яр башында, өскә ишелеп төшәрдәй булып, биек, калын урман капланып утыра иде. Яр астында, таудай булып, ауган агачлар, ишелгән ташлар, балчык кисәкләре өелеп ята иде. Шунлыктан Тотыш, күпме каранса да, якын-тирәдә шикләнерлек берни дә күрә алмады.

Иплән кенә ул коры җиргә чыкты, тыңлаудан-караудан туктамыйча, якындагы агач-таш өеменә таба атлады. Өем артында ниндидер йокылы ирләр тавышы ишетелеп китте. Тотыш туктап калды, ауган агачлар арасыннан муенын сузып, тагын да ныграк бирелеп тыңлый башлады. Анда, өем артында кемнәрдер бар иде. Иренеп кенә, теләр-теләмәс кенә алар нидер сөйләнгәндәй итәләр иде. Алар үзләре күренмиләр, аларның бары шул йокымсыраган ялкау тавышлары гына ишетелә иде.

Кемнәр булыр бу — болгар сакчыларымы, балыкчылармы — кемнәр?

Әле генә шундый якын булып, аңлаешлы булып тоелган Чулман юкка чыкты. Аяк астында төпсез, караңгы, куркыныч су барлыкка килде. Ник килде соң әле ул монда? Качып килдеме, адашып кына килеп чыктымы? Ялгышмады микән ул тоткынлыктан качып? Тоткынлыктан? Тирмәдән чыгып китү генә тоткынлыктан котылу була ала микән әле? Ул үзе монда булса да, күңеле аның анда калды түгелме соң?! Әйе, күңеле аның барыбер тоткынлыкта калды. Аны аннан коткармыйча торып, ничек итеп тулысынча иректә булмак кирәк? Йөрәккә ут салып киткән ул кызны яңадан очратмыйча торып, ничек итеп җирдә тынычлап яшәмәк кирәк?!

Алайса, кемнәрдер тотып алганчы, моннан да качаргамыни, яңадан үз тирмәнә әйләнеп кайтыргамыни?

Тотышның күңеленә шундый каршылыклы уйлар килде. Ни генә булмасын, аның бу килеш, коралсыз килеш беркемгә дә күренәсе кил-

мәде. Ул кайдадыр чит җирдә, чит ырулар арасында иде. Аңа чыннан да үз тирмәсенә кире кайтудан яхшысы юк иде бугай.

Ул инде борылып кирегә китмәкче дә булган иде, посып тыңлап торган җиреннән кузгала да башлаган иде,— шул чакны көтелмәгән бер нәрсә булды. Ул баскан коры агач кинәт шартлап сынып китте. Йокымсыраган тирә-якны сискәндереп, таң алды тынлыгында олы тавыш яңгырады. Шул ук мәлдә диярлек Тотышның колак төбеннән генә сызгырып ук очып китте. Каяндыр аяк астыннан — әллә агач-таш өеме арасыннан, әллә яр буеннан ниндидер кешеләр атылып чыкты. Чыктылар да чыбык-чабык арасында буталып калган ят егетне эләктереп тә алдылар.

Бу нәрсәләр бөтенләй көтмәгәндә булды. Тотыш исенә килергә дә өлгерми калды. Коралпы кешеләргә ул бернинди каршылык күрсәтә алмады. Көчле ирләр, бернинди тавыш-тын чыгармыйча, аның куллары-аякларын бәйләделәр дә агач-таш өеме артына — үзләренең куышлары янына алып киттеләр.

Монда аларны икенче кешеләр каршы алды. Болары да барысы да кораллы ирләр иде. Аларның алпакларына каз каурые беркетелгән иде. Ямгырчы би белән бергә Кызыл Яр катауга килгән ирләрнең дә алпакларына шулай ук каз каурыйлары кадалган иде. Казаяклар кулына эләгүен аңлап, Тотыш тынычланып калды. Шулай да ул монда сөенергә дә, сөенмәскә дә белмәде. Нишләп яталар икән соң болар монда җыйнаулашып? Балыкчылармы болар, әллә юлбасарлармы?

Монда, Чулман яры дугайланып эчкә кергән җирдә, су өстендә унлап көймә тора иде. Шунда ук берән-сәрән кешеләр күренә иде.

— Кем син? — диде аңа куыш янындагы ирләрнең берсе.

— Кулны чишегез,— диде Тотыш.— Авырта.

Ирләрнең берсе мыскыллап көлеп куйды.

— Авыртамыни? — дигән булды.

— Минем кулым яралы,— диде Тотыш тыныч кына.

Ирләрнең өлкәне, сорау алырга җыенганы, бәйләнгән кулны чишәргә кушты.

— Качса әле! — диде мыскыллап көлгән ир, мыгырданып.

— Синнән дә куркаграк булырга тәңре язмасын,— диде Тотыш, үчекләшеп.

— Син кем — озын колакмы? [1] — диде ирләрнең өлкәне кырыс кына.

— Озын колак? — диде Тотыш исе китеп. Үзенең казаяклар өчен чит-ят түгел икәнлеген белгәнгә, ул, беравык көттереп торды да, ирләрнең берьюлы авызларын томаламакчы булып: — Беләсезме, мин кем? Мин — Акбүре ыруының башы Күрән бинең углы Тотыш,— диде.

— Күрән би углы? — диде ирләрнең өлкәне, Тотышны баштанаяк күздән кичереп.— Би углына монда ни калган? Кая атың, кая шаең? [2]

— Хо! — диде мыскыллап көлгән ир.— Күрән би углы, имеш! Би угыллары белән безнең белешлек юк. Би янына алып барырга кирәк — таныса ул таныр.

— Би йоклый булыр,— диде икенче бер ир, сүзгә катышып.— Нәрсә шуның белән ваклашып торырга, аяк-кулларын туракларга да, балыкларга ыргытырга! Беткәнмени Чулман буенда каңгырап йөргән сукбай. Берәр нәрсә чәлдермәкче булып, иснәнеп йөриде́р.

— Күрсәтермен мин сиңа сукбайны! — диде Тотыш ярсып, үзен мыскыллаучыга борылып.

Ирләр аны-моны уйлап өлгергәнче ул әлеге ирнең якасыннан эләктереп тә алды этеп тә җибәрде. Йокысыннан арынып җитә алмаган каз-

---

[1] Озын колак — күзәтүче, шымчы.
[2] Шай — корал һәм сугыш киемнәре.

аяк ире арты белән дыңк итеп җиргә барып төште. Башка ирләр шундук коралларына тотындылар. Кемдер арттан Тотышның яңадан кулларын тотып алды, кемдер бау белән бәйләргә тырыша башлады.

— Менә, карагыз! — диде Тотыш, уң кулын алга сузып.

Аның урта бармагында көмеш йөзек елтырап күренде. Йөзек кашына Акбүре ыруының тамгасы сугылган иде. Казаяк ирләре яхшылап карасалар, тамганы күрми калмаслар иде, билгеле. Тик аларның күзе, тамгадан бигрәк, көмеш йөзеккә төште. Ул арада арты белән җиргә барып төшкән ач яңаклы ир аягына басты да искәрмәстән егеткә сугып җибәрде. Шуны гына көткән кебек, ирләрнең икенчесе аның бармагындагы йөзеген суырып алмакчы булды. Тотыш ачу белән кулын тартып алды, көмешкә кызыккан иргә берне тондырды да, ач яңаклыга аягы белән типте. Алар икесе ике якка барып төштеләр. Шау-шуга шул чакны читтәге кешеләр җыела башлады. Күз алдында кылычлар ялтырап китте.

— Туктагыз! — диде ирләрнең өлкәне, үз кешеләрен тыеп.

— Илтегез мине Ямгырчы бигә,— диде Тотыш.— Аңа минем сүзем бар.

— Сүзе бар, имеш! — диде ач яңаклы, яңадан аягына басып, бәйләнмәкче булып.

— Илтергә кирәк,— диде ирләрнең өлкәне.— Ниткән эш бу? Бер йөзек өчен талашып, бөтен эшне бозуыгыз бар.

— Йөзеге барыбер үземә. Ул минем авызны канатты,— диде йөзеккә ябышкан ир, канлы авызын тоткалап.

— Әйдә киттек! — диде ирләрнең өлкәне, Тотышка эндәшеп.— Башың исән чакта үкчәңне күтәр. Юкса, йөзегеңне түгел, әллә нәрсәңне каерып алырлар бу башкисәрләр.

## XIII

Үз тирмәсендә ялан аяклы, ялан башлы Тотышны күреп, Ямгырчы би шаккатты. Каршысында басып торган яшь егетнең чыннан да Тотышмы, түгелме икәнлеген белергә теләгән сыман ул аны тоткалап карады. Алай да ышанып җитмәгәч, аны яктыгарак алып килде.

— Менә,— диде Тотыш кулындагы әлеге дә баягы йөзеген күрсәтеп.

Ямгырчы би йөзеккә карап та тормады.

— Әйе, Күрән би углы... Тотыш...— диде ул, үз алдына сөйләнеп.— Минем киявем... буласы кеше, качкын, угры, бозык Тотыш!

— Юк! — диде Тотыш, кызарынып.

— Ха-ха! Нәрсә «юк?» — диде Ямгырчы би, көлеп.— Атаңнан, ырудашларыңнан качып котылдым, дисең инде, ә? Юлбасар булдым, сукбайга әйләндем, дисең инде, ә? Ха-ха! Күрән би углы Тотыш! Минем кызымны аздырып йөргәндә яхшыемы — менә каптың инде кармакка! Синең аркада әнә чирләп ята. Син боздың аны, син! Тиреңне тунап, телгәләп, утлы табада кыздырып... мин сине... Ха-ха, би углы Тотыш! Кияү балакай!

Ул шулай кинәт кабынып, үз алдына тузынды-тузынды да әрле-бирле йөренеп алды, туктады, тагын йөренеп алды, тагын туктады, билләренә таянып, ач бүредәй тешләрен шыгырдатып, үз кулына җиңел генә килеп капкан киеккә карап торды.

— Кызык,— диде ул бераздан, басылгандай итеп.— Шушы көнгә төштем, дисең инде, ә? Ничек ычкына алдың соң син ырудашларыңнан? Атаң качырдымы, анаңмы? Утташ кам белми әйтмәгән икән: йоланы таптый, түрәне тотмый, дип. Инде таптый алмас, ха-ха! Минем сүзне тыңламады. Үзенә үпкәләгәндер. Син әле белмисеңдәдер, сөекле киявем, Алмыш хан синең йортыңны-илеңне пыр туздырып ташлады ич!

.атавыгызның көлен күккә очырды, атанны-ананны, туганнарынны, ۥрудашларынны турап чүплеккә, Чулманга ыргытты.

— Ялган сөйлисең, би! — диде Тотыш.

— Ха-ха! — диде Ямгырчы би, шаркылдап.— Ялган? Син бер дә иңа ышанмыйсың әле, кияү. Мин сиңа ишеткәнемне сөйлим: Алмыш ан Чулман буен яулап кайтып килә!

— Мин сиңа күргәнемне сөйлим, би: Алмыш хан синең борын төбеңә утыра! — диде Тотыш.

— Күргәнне! Туктале, тукта... Алмыш хан карчыгадай барып сезең ояны туздырганда, син әллә агач башында карап тордың, унган гет?

— Әйе, карап тордым,— диде Тотыш теләмичә генә.— Шулай да син йлаганча карап тормадым, би.

— Әт-тә-тә-тә! Кызык, яман кызык,— диде Ямгырчы би, чын-чын-ап кызыксынгандай итенеп.— Алайса, сөйләп җибәр, углан — нинди хилләр ташлады сине монда? Сөйлә, сөйлә, тартынма, син минем кияем... буласы кеше лә!

Ямгырчы бинең мыскыллы сүзләрен Тотыш бер агарынып, бер кызарынып тынлап торды. Ул аны болай булыр дип башына да китереп арамаган иде. Ул аның янауларыннан әз генә дә курыкмады, шулай а ул аңа үзенең бу якларга ничек килеп чыгуын аңлатуны кирәк тапы. Үз башыннан кичкәннәрнең ул барысын да сөйләмәде. Ул бары Кызыл Яр катаунын, Күрән бинен, анасының исәнлеген, акбүреләрнең Алмыш ханга калан биреп котылуларын гына әйтте дә үзен хан тотык итеп ылып китүен генә әйтте.

— Синең җирдә туктап торганны белдем дә тоттым да качтым,— иде ул, үзенең качуын шулай җиңел генә аңлатып.— Минем сугышаым килә, Алмыш ханнан үч аласым килә. Синнән башка кем корал бирер миңа, би?

Соңгы сүзләрен ул кискен бер омтылыш белән, эчке бер күтәренкелек белән әйтте. Ул сөйләгәннәрнең берсе дә кеше ышанмаслык булмаа да, яшь егетнең бу чын күңелдән әйткән сүзләре бинең соңгы шикләрен юкка чыгарды.

— Син... Күрән би углы Тотыш... әле син шулай корал да тота беләеңмени? — диде ул әкрен генә, бөтенләй үзгәреп.— Мин сине белмим. Әегездә сине башбаштак дип... ни... ы... сүз тыңламый торган бала, дип сөйләделәр. Кызыл Ярдан буш кул белән кайтып киткәндә мин синнән, атаңнан үч алырга, дип үз-үземә сүз бирдем. Мин үчлекле кеше. Инде иенә үзең кармакка килеп капкач... Юк, Тотыш углан, мин кире уйладым. Минем дә, синең дә ягы бер — Алмыш хан. Аның сыртын сындырмыйча торып, миңа тынгы булмаячак. Туганымнан бирле мин болгарларга каршы астыртын эш алып барам, туганымнан бирле мин кылыч күтәрергә җай көтеп тордым. Менә ул җай килде! Акбүреләр үземне аяк астына салып таптагач, бик күңелем төшкәнне. Ни булса да булыр дип, мин язмышны үзем генә сынап карамакчы булдым. Мин сиңа корал бирсәм, йөз кешелек алай бирсәм, син нишләрсең, Тотыш углан?

— Болгарларга каршы уктай атылырмын, би! Өсләренә арысландай ташланырмын, бугазларын чәйнәрмен!

— Антмы?

— Ант! Ант! — диде Тотыш, кайнарланып.

Ямгырчы би кылычын кыныдан тартып чыгарды да яшь егеткә сонды.

— Үп! — диде.

Тотыш, кылычны ике куллап тоткан килеш, кайнар иреннәрен салкын тимергә тидерде.

— Биргән антымны бозсам, бу күк күрсен, кызыл чыксын![1] — диде ул.

Ямгырчы би кылычын кире алды, шартлатып кыныга салды да, шундый кискен үзгәрештән соң тиз генә исенә килә алмагандай, идән буенча йөренеп килде, күкрәгеи киереп, аякларын аерып яңадан Тотыш алдында туктап калды.

— Менә без килештек, Тотыш углан, — диде ул, бушанып, җинел сулап.— Инде мин сине чыннан да үземнең киявем дип саный алам.

— Кияү булгач...— диде Тотыш тыйнак кына.

Ямгырчы би аның сүзен бөтенләй ишетмәде дә.

— Мин сиңа әйтеп бетермәдем, Тотыш углан,— диде ул, тавышын әкренәйтә төшеп.— Мин сиңа барысын да әйтеп бетерергә тиешмен. Мин бүген, кояш чыгу белән, яу башлыйм. Минем кешеләрем урман араларында, яр буйларында минем боерыкны гына көтеп торалар. Искәрмәстән мин болгарларның олауларын басып алачакмын, ирләрен турап ташлаячакмын. Алмыш хан үзе теге якта. Чирүенең күбесе чыгып китте. Тәкин угланны мин аны... Чулман буеннан талап алган байлыгын... бер тиенен, төлкесен калдырмыйча... Аргы якта Алмыш ханны суарлар кисәчәк. Ике ут арасында, ха-ха! Тәңрем, аллам, миңа юлдаш булыгыз!

— Мин ул олауларның кайдалыгын беләм,— диде Тотыш.

— Белсәң, сиңа бурыч шул — син олауларны, үз атаңның... бөтен Чулманның байлыгын... Аннан да бигрәк, безгә аның кызы Аппакны кулга төшерергә кирәк, аның барлык көчен — хатыннарын, балаларын кулга төшерергә кирәк.

— Аппакны? — диде Тотыш, ялгыш ишеткән сыман, кабатлап.

— Әйе, Аппакны! — диде Ямгырчы би, йодрыкларын йомарлап.— Аппак бер үзе Болгар йортка тора. Алай-болай җиңелсәк тә, Аппак безнең кулда калырга тиеш!

## XIV

Ямгырчы бинең кешеләре яшеренгән җирләреннән — урманнардан, чокыр-чакыр араларыннан чыгып, болгарларның төнге каравылына ташланганда, Тәкин углан да, аның ирләре дә берни белми йоклап яталар иде. Казаяклар, көчле ук яңгыры яудырып, болгарларның үзәк юл өстендәге каравылын кырып салдылар да шауламыйча, мыштым гына эш итәргә, дигән боерык булуына да карамастан, коточкыч тавыш, шаушу куптарып, йокылы тирмәләргә, чатырларга, олауларга, болындагы көтүләргә ташландылар.

Яу чабып өйрәнгән, чыныккан болгарлар бик тиз уяндылар, аякларына бастылар. Өлгергәннәр атларына атланды, өлгермәгәннәр атсыз калды. Яшел урманнар, болыннар өстендә яңа көн туып килгәндә, ике арада канлы сугыш башланып китте.

Күктәге тургайларны, җирдәге күбәләкләрне куркытып, ямьсез тавышлар белән кешеләр кычкырды, өркеп атлар пошкырды. Чык тамчыларыннан арына алмыйча, авыраеп утырган чәчәкләрне таптап, тупас аяклар йөгерде. Баш очында үткер тимерләр уйнады. Котлары алынган хатын-кызлар, бала-чага җылашып, шашынып, кайсы кая качарга тотынды. Болын буйлап, мөңгерәп, кычкырып, пошкырып, төркем-төркем сарыклар, атлар чабышып йөрде.

Казаякларның бер өлеше кечү янында болгарлар белән сугышканда, икенче өлеше, каекларга утырып, су өстеннән сал-күпергә якынайды. Болгарларның күпер өстендәге каравылы коры җирдәге каравылга караганда уяурак булып чыкты. Төне буена ир-атларны чыгарып торганга, алар әле булса аяк өстендә иде. Казаякларны алар күпергә якын

[1] Ягъни: күк тимер тәнемә кереп, кызыл кан агып чыксын.

а җибәрмәделәр — ук атып, таш ыргытып, кире бордылар. Ике каек ндырылды, унбишләп кеше үтерелде. Яр буйлап килгән җәяүле каз-якларның исә барысы да кырып салынды.

Башта ук эшнең үзе уйлаганча барып чыкмавына Ямгырчы бинең ик нык ачуы килде. Теләсә кая таралган кешеләрен җыймакчы, бергә упламакчы булып ул туктаусыз кычкырынды, сүгенде, янау сүзләре удырды. Комсызлыктан күзләренә ак-кара күренмәгән ирләрне алай а тынлата алмагач, чавышлар җибәрде. Кораллы ирләр белән сугы-уны онытып, таларга тотынган кешеләрне чавышлар сөңгеләр белән уалап, куркытып йөрделәр. Тик бозылган эшне инде чавышлар гына өзәтә алмады. Җылы кан күргән ерткычлар кебек, казаяклар барысы а диярлек бай олауларга ябырылдылар. Күзләре томаланган кешеләр рбаларны, каңгыларны аударып ташладылар, тире, кием-салым, са-ыт-саба, ашлык тутырылган капчыкларны, төргәкләрне элэктереп лдылар да тизрәк таю ягын карадылар. Күтәрә алганы икешәр-өчәр исәк күтәрде, күтәрә алмаганы, юлында очраган бар нәрсәне ватар-а, кырырга тотынды. Арбаларга ат җигәргә тырышкан болгарларга өңге кададылар, атларның аякларын кистеләр, тәртәләрне, киергеләр-е кырдылар. Икенче бер җирдә кораллы ирләр, кыйный-кыйный шыгып, урманга көтү кудылар.

Казаякларның күпчелеге талауга бирелсә дә, Ямгырчы бинең үз нындагы яхшы өйрәтелгән, чыныккан ирләр — йөзләп кеше үз-үзлә-ен аямыйча сугыштылар. Бу яктагы болгар ирләрен тулысынча кырып алуның булмас эш икәнлеген күреп, Ямгырчы би үзенең барлык көчен зәккә — күк төстәге байрак кадалган биек тирмәгә таба юнәлтте. лмыш ханның иң зур байлыгы, мактанычы Аппак шунда булырга иеш иде.

— Казаяклар-арысланнар! Таптагыз болгарны, сытыгыз көчекләр-е! — дип кычкырды Ямгырчы би әледән-әле, үз ырудашларының күңе-ен күтәреп.

Үзе ул барысыннан да яманрак сугышты. Сөңгесе белән әле бер гының эчен айкады, әле икенчесенең эчен айкады. Каяндыр якыннан ына килеп чыккан болгар егете сөңге сабын кисеп төшергәч, ул элек-едән дә яманрак ачу белән, кылычын тартып чыгарды.

Казаякларның бер йодрыкка тупланган бердәм, күмәк көченә чы-ый алмыйча, таркалган болгарлар әкренләп-әкренләп биек тирмә ягы-а чигенә бардылар. Аларны бер яктан Ямгырчы би кысса, икенче як-ан Тотыш углан кысрыклый иде. Тотыш янында йөз кешедән нибары-ы иллеләп кеше торып калган — башкалары үлеп, таларга таралышып еткәннәр иде.

Үзәктәге боҗра кысыла барган саен, болгарлар да, ярсыбрак, ныг-ак каршылык күрсәтә башладылар. Баш өстендә кылычлар, сөңгеләр елтәнде. Ярсып кычкырган, өндәгән, каргаган тавышлар, тимер чыңы, тлар кешнәве — барысы да бергә кушылып, коточкыч бер шау-шу ту-ырды. Ике яктан да ирләр, атлар, киселгән урман кебек, туктаусыз ырыла тордылар.

Сугышның иң кызган бер чагында, ике як та, бер-берсенең бугазы-а ябышып, бер-берсен таптап үтәргә тырышкан бер мәлдә, болгарлар расында Тотышның күзенә бер таныш кеше чалынып калды. Ул кеше ораллы түгел иде. Ул, кораллы ирләрдән качып, кая керер тишек тап-ыйча, тирмәләр арасында әрле-бирле сугылып йөри иде. Тотыш, үзе-ең казаяклар ягында икәнлеген онытып:

— Торымтай! — дип кычкырды.

Колак тондыргыч тавыш, шау-шу арасында Торымтай, ахрысы, бер-и ишетмәде — кулындагы ниндидер агач табакны калкан сыман итеп откан килеш, тиз генә бер тирмә артына кереп яшеренде. Тотышның емгә кычкыруын якындагы казаяклар ишетеп, аңлап алдылар. Агач

калканлы Торымтайның кая качканын күреп калган бер казаяк мыскыллап көлде дә шул якка ук атмакчы булды. Тотыш, аркылы төшеп:
— Атма! — дип кычкырып җибәрде.
Нык тартылган кереш ычкынып китте. Тотыш кылычы белән бар көченә селтәнеп җибәрде — эле генә авызын ерып, Торымтай ягына ук аткан ирнең сул кулы беләзек турысыннан киселеп төште. Казаяк ирекан ага башлаган кисек кулын икенче кулы белән кысып тотты да кычкырып җыларга тотынды.
Тотыш, болгарлар тезмәсен өзеп, Торымтай янына ашыкты. Торымтайга дип атылган ук читкә киткән иде, ахрысы — агач «калкан» җирдә аунап ята, Торымтай үзе шуышып чатыр астына кереп бара иде.
— Торымтай! — дип кычкырды тагын да Тотыш.
Коты алынган кол, үзенең өстенә басып килгән атлы ирне күреп, телсез-өнсез калды. Шулай да ул Тотышны танып алды, куанычмы, куркумы белдергән бер өн чыгарды да, үз-үзен сакламакчы булып, кулларын битенә якын китерде. Тотыш атыннан иелеп, аның якасыннан эләктереп алды, аягына бастырды.
— Курыкма! — дип кычкырды ул аңа.— Аппак кайда... кайсы тирмәдә?
— А-а-а-а...— диде Торымтай, теле тотлыгып, күзләрен акайтып.
— Алмыш хан кызы Аппак кайда? — диде Тотыш, соравын кабатлап.
Торымтай аңлап алды, Тәкин угланның биек тирмәсеннән бер йөз адым чамасы читтәрәк, үндарак утырган яшел байраклы тирмәгә төртеп күрсәтте.
Тотыш бүтән сораштырып тормады, атын борды да, юлына аркылы төшкән болгарларны уңга-сулга селтәп, Торымтай күрсәткән тирмәгә ташланды. Болгарларның тезмәсен өзгән унлап казаяк та аның артыннан иярде. Шул чакта болгарлар ягында буталыш булып алды. Аларның көче икегә бүленде. Ир-атларның бер өлеше өзелгән тезмәне яңадан торгызырга теләп, казаякларны эчкә үткәрмәскә тырышты, икенче өлеше Тотыш артыннан куа китте.
Ул арада Тотыш, бернинди каршылыксыз диярлек, яшел байрак эленеп торган тирмә янына килеп тә җитте. Тирмәне саклаучы болгарлар казаякларны агулы уклар атып каршыладылар. Тотышның калканына берьюлы ике ук килеп тиде; тиде дә чык-чык итеп читкә китте. Казаякларның берсе, эчен тотып, аты өстенә капланды, икенчесе, авыр капчык сыман, артына авып төште.
— Сытам! Изәм! — дип кычкырды Тотыш, тамак ярып.
Кемдер шунда аңа төбәп сөңге ыргытты. Тотыш иелеп калды, яныннан гына очып барган сөңгене кылычы белән урталай кисеп төшерде. Моны күреп торган болгарлар ахылдап куйдылар, каушап калдылар. Казаяклар исә, бүре талаган бурзайлар сыман, кыюланып, шашынып, болгарлар өстенә ябырылдылар.
Тотыш атыннан сикереп төште дә ишек янында таптанган болгарны артка чиктерде, ишек бавын кисеп, эчкә атылып керде.

## XV

Тирмә эчендә ул ирләр киеме киеп, кулына кылыч тоткан бер кыз белән очрашты. Түбәдәге ачык төннектән киез өйгә иртәнге яктылык төшә иде. Идәндә урын-җир — мендәр, юрган, кием-салым ише нәрсәләр аунап ята. Котычыклар, турсыклар ачылган, я булмаса урыннарыннан кузгатылган. Кемнендер монда ашык-пошык нидер эзләгәнеме, нидер яшергәнеме әллә каян күренеп тора иде.
Чит ир килеп керү белән, кораллы кыз кылычын күтәрде, аңа каршы атламакчы булды. Шул чакны аның кылычы да, калканы да шакылдап

дәнгә төшеп китте. Тотыш та кoралларын чак-чак кына төшереп җибәрмәде. Аның алдында... аның танышы, аның сөеклесе, аның гүзәле басып тора иде!

Шундук аны өермәдәй булып, бер-берсенә капма-каршы уйлар-тезәкләр биләп алды. Иң элек аның күнелендә көчле ялкын булып сөенеч ойгысы кабынды. «Менә мин сине тагын таптым!» дип әйтәсе килде аның. Шул ук мәлдә ул үзенең Ямгырчы бигә ант биргәнлеген, аның колы, ялчысы икәнлеген исенә төшерде. Ялкын сүнде, тимер кoраллар выраеп калды. Ул үзенең тирә-яктан ягылар белән чолгап алынганлыгын, шуңа күрә, бернәрсәгә карамыйча, ашыгырга, башкарасы эшен тизрәк башкарырга тиешлеген аңлады.

— Аппак кайда? — диде ул, кызга туры карамаска тырышып.

— Аппак кирәкмени? — диде кыз, мыскыллы көлемсерәп.— Аппак кирәкми, дигәнием түгелме соң?

— Әйт, кайда ул? — диде Тотыш, кырысланып.

Кыз ялт кына кылычын алды, башын югары күтәрде.

— Аппак юк,— диде ул, матур иреннәрен кысып.— Аппактан җиләр исте!

— Кая китте? Әйтәсеңме, юкмы? — диде Тотыш, аның өстенә килеп.

— Аппак кирәк булган, Аппак! — диде кыз, шыр-шыр көлеп, аның авын бөтенләй күрмәгән сыман.

Тыштагы шау-шу көчәя төште. Тотыш, кызны онытып, тиз генә артына борылды. Ярый әле борылды — ишектән, этешә-төртешә, сөңгеле ике ир кереп ята иде. Тотыш, алар күзенә күренмәс өчен, читкә тайпылды да, ишек янына килеп басты. Сөңгеле кешеләр аның кайдалыгын шамалап өлгергәнче, ул, ян яктан ташланып, аларның берсенең сөңгесен, икенчесенең калканын бәреп төшерде. Ирләр куркып кире чигенделәр.

Тотыш алар артыннан тышка ташланды. Монда тавыш, ыгы-зыгы тагын да ныграк көчәеп киткән иде. Сакчы болгарларны туздырып, үтерәсен үтереп, таптыйсын таптап, Аппак тирмәсенә казаяклар ябырылган иде. Тотыш алар арасында иң алда Ямгырчы бине күреп алды.

Сугыш исереклегеннән күзе маңгаена менгән, тилергән-шашынган Ямгырчы би, яшел байраклы тирмә каршысына атылып килде дә атының тезгенен кисәк кенә тартып җибәрде.

— Аппак... булдымы? — дип кычкырды Ямгырчы би, тыны бетеп.

— Аппак юк,— диде Тотыш.

— Юк?! — диде Ямгырчы би, кыргыйларча чинап, күзләрен акайтып.— Ялганлыйсың, юлбасар!

Бер кызудан ул кылычы белән Тотыш ягына селтәнеп җибәрде. Тотыш башын иеп калды. Кылыч аның алпагына кадалган каз каурыен кыеп төшерде.

— Би, үз каурыеңны үзең кистең! Минем сиңа антым юк! — диде Тотыш, агарынып.

Ямгырчы би аның сүзләрен ишетмәде дә — кулларын бутап үзенең ярудашларын изге көрәшкә: болгарларның теләсә кая сибелгән көчләрен юк итәргә, беркемне дә кичүгә җибәрмәскә өндәде.

— Күтәрегез тирмәне! Эзләгез! Җир тишегеннән табыгыз Аппакны! — дип кычкырды би.

Шуны гына көтеп торган казаяклар, дәррәү кубып, яшел байраклы тирмәгә ташландылар.

Шул чакны Тотышны кемдер, әйтерсең, кинәт алыштырып куйды, әйтерсең, кемдер аңа канат бирде, тау-ташларны күтәрә алырлык, Чулман суын буа алырлык чиксез көч бирде!

— Җибәрмим! — дип кычкырды ул, казаякларның юлына аркылы төшеп.— Тәнре белән ант итәм: җибәрмим.

— Кисегез шуны, чабыгыз! — дип җикеренде Ямгырчы би үзенеләргә.

Көтелмәгән каршылыкка очраган казаякларның ачулары килде. Берсе шунда «сатлык» егеттән көлеп, сүгенеп алды, икенчесе, аны җиңел генә сөңге башына күтәрмәкче булып, якын ук килде.

Алмыш ханның алыплары белән орышкандагы кебек, Тотышны изге бер үч-ярсу тойгысы, саклык-уяулык тойгысы биләп алды. Тегендә, алыплар орышында, үз артында туган атасы-анасы, туган ыруы барлыгын тойган булса, монда ул үз артында, тирмә эчендә үзенең сөйгәне барлыгын тойды. Бу тойгы аңа корычтай ныклык бирде, үз-үзенә, үзенең изге эшенә бетмәс-төкәнмәс ышаныч бирде. Шул көч, шул ышаныч булганда, ул каршысында ун түгел, йөз түгел, мең ир-ат булса да, әз генә дә шыртламас кебек иде. Үз алдында очлы сөңгеләр, үткен кылычлар күреп, ачулы ырҗайган йөзләр, ерткыч күзләр күреп ул тамчы да каушамады.

Үзенә беренче булып якынаеп килгән ирнең сөңгесен ул искәрмәстән бәреп, кулыннан төшерде. Сөңге иясе кабаланып кылычына тотынды. Тик кылычын суырып чыгара алмады — туры ыргытылган сөңге, яртылаш күкрәгенә батып, аны шундук артка чөйлектерде.

Казаякларның ырҗайган авызлары йомылып калды, ерткыч күзләрендә шүрләү билгесе күренде. Алдагылар ирексездән чигенеп куйдылар, арттагылар сүгенә башладылар.

Тынычлыгын аз гына да югалтмаган Тотыш, үтерелгән казаякның үзе сугып төшергән сөңгесен эләктереп алды да тагын берәрсе каршы килсә, кадарга чамалап, кире ишек янына чигенде.

— Антын бозды! Тере килеш алыгыз шуны! — дип кычкырды Ямгырчы би, үз кешеләре арасыннан алгарак ерып чыкмакчы булып.

— Иң элек син боздың, би! — диде Тотыш, каурые киселгән алпагына күрсәтеп.

Казаяклар яңадан кыймылдашып куйдылар. Күсәкләр, сөңгеләр яңадан югары күтәрелде. Тотышны уратып алган ярым алка кысыла башлады. Алар күп иде, көчле иде. Бер кешене, күпме генә көчле, күпме генә батыр булмасын, таптап-изеп китү алар өчен, әйтерсең, берни тормый иде.

— Тирмәне әйләндереп алыгыз — анда тагын кемдер бар! — дип кычкырды би.

Тотыш, борылгандай итеп, ярым ачык ишектән эчкә күз ташлап алды. Анда ул сөеклесенең куркудан агарынган сылу йөзен күреп калды.

— Тотыш, бирешмә! Без икәү! — диде кыз.

Аларның соңгы сулышлары якынлашканда, тәңре аларга изге кулын сузды. Казаяклар төркеме артында кинәт ниндидер шартлау тавышы ишетелде. Казаяклар, куркып, артларына борылдылар. Кемдер тамак ярып:

— Артка төштеләр! — дип кычкырып җибәрде.

Ямгырчы би ирләре, аны-моны карамыйча, аңламыйча, буталып, бер-берсен этеп-төртеп кайсы-кая качыша башладылар.

Тотыш, иясез бер атны тотып алды да, сикереп атланды да, сөрән салып кычкыра-кычкыра, качучылар артыннан куа китте. Казаякларга бу җитә калды. Алар артларына борылып карарга да куркып, талангаң чатырлар, тирмәләр, ауган арбалар-каңгылар арасыннан, үтерелгән атлар, кешеләр өстеннән әлдерделәр генә. Төрлесе төрле җирдә бүленеп калган, я булмаса әле анда, әле монда казаяклар белән сугышып яткан болгарлар, Ямгырчы биңең качуын күреп, Тотыш артыннан ияրделәр.

*Дәвамы бар.*

## Шамил Мәхмүдов

•

Дөнья шул ук, үзгәрмәде әллә ни:
элеккечә әйләнә җир туктамый,
элеккечә үлем бер ни җәлләми.

Тыныч көндә туа рәссам-сынчылар,
хәвеф килсә — яуда ирләр көч сынар,
кара көндә калкып чыга шымчылар...

Элеккечә зур ачышлар дан ала,
асыл булып кала асыл нәрсәләр,
яшәү исә иң кадерле санала...

Зур гаугалар, кузгалышлар чорында
әллә шуңа микән уйлый кешеләр
ерак галәм киңлекләре турында.

### Мәңгелек сәфәр

«Җир — кешелекнең бишеге генә».
*Э. Циолковский.*

Кайчандыр, борынгыда (ул чак турында
бабайлар бабаларыннан ишеткән),
чыкканбыз чиксез-ахырсыз сәфәргә —
кайчандыр, һинд җиреннән, туган бишектән,
һәм киткәнбез җир буйлап төркем-төркем,
кайда бетәр бу юл, белми анысын беркем.
Туган йорт булган безгә чатыр-арба,
кайда туктасак, шул җиргә без ватан дигәнбез;
бу юл мәңгелек; шул юлда тугаңбыз, үлгәнбез,
шул юлда бәхет, тынгы тапканбыз, көлгәнбез...
һәм гүя без түгел,— җирдән-җиргә күчүче,—
ә бу дөнья үзе, мәңге алышынып, үзгәреп,
узган безнең яныбыздан;
һәм без беләбез, тәгәлләнмәс бу бөек юл
җир читенә җиткәч тә;
күчмәлек — безнең канybызда!
Килер көн, ачарбыз мәңге бикле галәм ишеген,
таралырбыз йолдызларга,
нәкъ җирдә таралган кебек;
җир ул — кешелекнең бары тик бишеге.

# Кояшка

Таянып нык тэрэге — жиргэ,
күтэрелэ һэркөн Кояш,
гүя гигант һэйкэл
тоташ бакырдан...

Юк, кешелэр дөньясында
син булгансың, Кояш, иң әүвэл
һэм булырсың ахыр да!

Алдый алмас күзне буш бизэклэр,
син булганда төшмэс кеше хатага —
юкка гына фиргавеннэр, корольлэр
үзен кояш диеп атаган!

Без белэбез,
утлы кызыл байрактай
янган шушы кояш астында
ала безне көн
кайнар кочагына,
сала утлы тормыш учагына,
табып һэркемгэ
үз эшен, үз сөюен, үз күркен.

Югары күтэреп кулларны,
сине, Кояш, сэламлибез һэр көн!

Җирдэ вакытлы кунак, юлда юлчы,
мин килдем, мин китэрмен,
сиңа булган мэхэббэтне, Кояш,
мин улыма мирас итэрмен.

●

Чирек гасыр — аналарның кипми күз яше,
чирек гасыр — тол хатыннар уяналар саташып,
э балалар үсте атасыз...

Чирек гасыр — бүгенге көн белэн сугыш арасы,
чирек гасыр — йөрэклэрнең бетми ярасы,
чирек гасыр — эзерлилэр янасын...

Чирек гасыр — олы дөнья өстендэ
шомлы шэүлэ булып
тора агулы яшел болыт...

Чирек гасыр — аш аш, йокы йокы түгел...
Чирек гасыр — күзлэрдэ өмет, сагыш...
Чирек гасыр — сугышсыз сугыш...

Чирек гасыр — эш тик бер нэрсэдэ —
хэл ителэ бер мэсьэлэ:
дөнья кэл буламы, гөл буламы?..

## Төнге уникे

Бөтен әдәплеләр, адәм рәтлеләр —
гөнаһсызлар, уйсызлар, сабыйлар
төндә йокысызларны иш итмиләр.
Бар дөньяда
сәгать төнге уникене сукканда —
ишетмиләр.

Ә калганнар,
тормышлары көйсезләр,—
соңлап кайткан эчкечеләр, өйсезләр,
йөремтәлләр, диваналар, даһилар —
ишетәләр ярты төннең билгесен
һәм саныйлар сәгатьләрне, «аһ!» диләр;
берәүләргә — вакыт бик аз,— житми,
бүтәннәргә — чиксез озын,— үтми...

Төн яртысы — димәк, башлана гына
титан хезмәт, газап, илһам вә аһлар;
алда — тулы бер төн, таңга кадәр,—
биеклекләр, түбәнлекләр, гөнаһлар...

(Фәкать әдәплеләр генә йолдан
чыкмыйлар!)

Сәгать суга уникене. Төн уртасы.
«Әүлиялар» йоклыйлар.

•

Бик күп нәрсәләр бар — мин яраткан,
оныттыра алар чуар дөнья ваклыгын.

Мизгелләрдән — яратам мин алтын көзне,
агачлардан — каеннарның сөттәй аклыгын;
кешеләрдән сөям туры сүзле, тынгысызларны,
хәтта картлар мыжуы ала алмый мазамны,
үзем дә бер тынгысыз жан,
уйланаммы, шигырь язаммы,—
үз гамемдәй, дөнья гаме белән мин янам;
кайчак куркып, ярты төндә мин сискәнеп уянам...
Яратам мин имин хәбәрләрне,
сагыш чигәм, соңлап калса дусым хатлары,
гадәтем бар —
озак итеп укыйм кабер ташларында
мин белмәгән кешеләрнең исем-атларын...

Кубекле дулкыннар кага чал ташларга,
бигрәк тә кичләрен,
үз төсе — кызылга буяганда шәфәкъ
ерак диңгез өсләрен...

Ярсу атлар сыман, җилә ак дулкыннар,
ялլары — купшәк кебек.
Ялгыз акчарлаклар кычкыра моң сызып,
нәкъ менә кеше кебек...
(Акчарлаклар — үлгәннәрнең җаны, диләр,
бу сүз, бәлки, дөрестер?
Сайладылар микән алар күк диңгезне
тар булганга җир өсте?)

Нинди моңсулык бу? Акчарлаклар мәллә
кич тынлыгын бозганнар?
Хәтеремә килә
кайчандыр дөньядан
сагышланып узганнар...

...Утыра ялгызы ят диңгез буенда
бунтарь шагыйрь Назон. Ни икән уенда?
Шагыйрь сөйли. Сүзләрендә — әллә хикмәт,
әллә сөрген сагышы?
Аңлап булмый, сөйли кебек үз-үзенә,
тоnык кына тавышы...

Җавап бирә башка шагыйрь,— гасырлар да,
үлемнәр дә юк сыман.
Җәллад балтасына башын тоткан килеш
шагыйрь илен юксына...

Мин тыңлыйм тын гына. Юк бу сәер гәптә
зарлану да, үпкә дә.
Шагыйрьләр бит алар горур халык, түзә
авырга да, күпкә дә...

...Кубекле дулкыннар кага чал ташларга,
кубекле тормыш дулкыннары...
Алып килә алар заман, язмышларның
фаҗигасен, моңнарын.

## Эз

Аера икән барыбер
безне мәңгелек сызык,—
безнең өн тере калудан
безнең өчен ни кызык?

Тиеш мәллә яшәргә без
йөрәккә сагыш төяп —

янэсе, онытыла, диеп,
бу көндәлек вак-төяк?

Ник соң әле шулкадәрле
борчылабыз икән без —
калсын дипме бездән соң да
күренекле бирәр эз?

## Стәрле юлы

Күпер башы, борылмадан китә шоссе —
иске Стәрле тракты.
Җил уйнатып уза зәңгәр автобуслар,
сәфәрләре, бәлки, еракты р...
Тәрәзәләре өлге-өлге ак пыяла,
эчләрендә күпме юлчы кеше бар?
Кайда юл тоталар ул юлчылар,
барысыныңмы ашыгыч эше бар?
Тизләтәдер, бәлки, кыска отпускылар,
бәлки, үлем түшәгендә кемдер ятадыр,
соңгы кабат күреп калыйм диеп,
улы-кызы шулай ашыгып кайтадыр?!
Беләсе иде, юлчыларның барысының да
вакыты шулай тар микән?
Шул ашыгыч эш-йомышлар арасында
бер булса да ашыкмаган юлчы,
бер булса да гашыйк бар микән?
Беләсе иде, уйлары ни — эш-йомышмы,
әллә күңел тулы якты теләкме?
Сумка-чемоданы һәрберсенең
шыгрым тулы күчтәнәчме, бүләкме?
Бүләк булса, кемнәр көтә икән —
карт анамы, әллә матур яр микән?
Әгәр уенчыклар булса балаларга,
нинди икән, матурлар микән?
Күпер башы борылмадан үтә шоссе —
иске Стәрле тракты.
Җил уйнатып уза зәңгәр автобуслар,
кайгы төяп узганнары сирәктер...
Бу шат юллар, иминлекләр заманында
беркем тормый юл читендә моңаеп...
Минем дә бар шат җәйләрдә шат юлларым,
мине дә бит көтәләрдер, мөгаен.

## Камил Мостафин

●

Батырны бит белә әллә кемнәр...
Хәтерлиләр аны якты көннәр,
онытмыйлар аны кыен төннәр,
һәм кешеләр аны хәтерлиләр.

Берсе аның классташы булган
букча асып йөргән вакытта.
Икенчесе аны очраштырган
кырык беренчедә окопта.

Әллә кемнәр, әйе, әллә кемнәр
аның битен, йөзен хәтерлиләр,
кигән киемнәрен хәтерлиләр,
һәм сөйлиләр алар, һәм сөйлиләр:

— Шаян иде үзе, наян иде,
тапкыр сүзле иде ул егет.
Кара кашлы, кара күзле иде,
ачык йөзле иде ул егет.

Батырны шул әллә кемнәр күргән,
батырны шул әллә кемнәр белгән...
— Нинди иде, син дә сөйлә,— диеп,
килеп сорадылар әнисеннән.

Килеп сорадылар әнисеннән,
ә әнисе аның карт инде...
— Нинди иде соң ул, батыр улың?..
— Җилкәсендә миңе бар иде...

## Тиен

Мин урманда тиен күрдем, тиен күрдем,
сары түгел, соры иде никтер тиен,
койрыгы да соры иде, ямьсез иде.
Кигән кебек иде тиен иске кием.

Ул басмаган иде агач ботагына,
чикләвек тә ашап тормый иде үзе.
Сукмагымны кисеп үтте тиз-тиз генә,—
күреп алдым аның нәни елтыр күзен.

Өйгә кайткач, тиен күрдем, дип мактандым...
— Ул соң нинди тиен иде? — диде улым.
— Әйдә рәсемен ясап күрсәт, әти,— диеп,
Кәгазь белән карандашлар бирде улым.

Мин ясадым төрле-төрле кызык рәсем,
мин тырыштым, ул тормыштан чыксын диеп...
Бу рәсемдә зур ботакта чикләвеген
ашап тора иде матур сары тиен.

И шатланды минем улым, и шатланды,
миңа әйтте:
— Бигрәк охшаткансың икән!
...Әкиятнең дә чынбарлыкка охшаганын
минем көләч нарасыем каян белгән?

•

Июнь төннәрендә яшен яшьни,
ә карчыклар гаҗәп төшләр күрә:
үлгән уллар, үлгән кызлар керә
карчыкларның кыска төшләренә.

Алар йоклап яткан бүлмәләрдә
яшен яктысында пәйда була
кырык икенчедә киткән кызлар,
кырык беренчедә киткән уллар.

Һәм елмаеп куялар карчыклар,
ак кулларын сузып улларына,
сак кулларын сузып кызларына...
Чал карчыклар таңда ята йоклап...

Чал карчыклар күрә балаларын,
һәм һичкем дә җирдә белми шуны...
Яшь әтәчләр генә кычкыра да
таңда була кыска очрашуны,

һәм карчыклар шунда уяналар,—
кыен сорау туа күзләрендә...
Кем аерып алды балаларын,—
төшми кебек әле исләренә.

Әтәчләрме? Ничек сузып-сузып,
канат кагып җырлый алар әнә...
...Тик аларны яшен сугар иде,
әгәр гаеп булса әтәчләрдә!

## Кое

Таныш авыл.
Таныш агач кое.
Соры чыпчык кунган тирәккә.
Бер яшь егет иелеп
бөтен юа
кое суын коеп
чиләктән.

Битен сөртә,
аннан тәмләп эчә,—
кое янын инде күл иткән.
Күз кырые белән
миңа карый:
бу, янәсе, тагын кем икән?

Ә мин туктап торам...
Һичкем мине
белми монда, чөнки чит җирле.
Язмыш дигән нәрсә
бу авылга
ялгыш кына мине китерде...

Эчеп туя егет...
Кулларымны
ак чиләккә сузам:
— Бир әле.
Чылбыр чыңлый. Чиләк төпкә оча.
Һәм су белән тула чиләгем.

Мин тотынам эшкә,
таныш эшкә,—
әйләндерәм кое сабын мин.
Мин бу эшне әле онытмадым,
мин бу эшне
шундый сагындым!..

Чупылт-чупылт итеп,
су чайпала,
чиләк чыга инде коедан...
Мин су эчмим.
Минем су эчәсем
килә кебек кенә тоелган.

Һәм калдырып тулы чиләкне мин
юлдан атлыйм...
Юлым, һай, ерак...
Сау бул, егет!
Ә ул әнә һаман
карап тора миңа аптырап.

Уйлыйдыр ул, шаять, сәер бу, дип...
Кайдан килсен аның уена,—
монда узган
көннәремә сусап
иелүем иске коега...

## Зиннур Насыйбуллин

# Исем турында баллада

Аннан бары исем сорадылар,
Сорадылар кыска бер исем:
— Исемен генә әйт тә, син —
азатсың,
Кит,— диделәр,— кая телисең.

Дәшмәде ул.
Акча күрсәттеләр,
Җирдә оҗмах вәгъдә иттеләр,
Мең хәйләне эшкә җиктеләр,
Тик бер исем аннан көттеләр.

Эндәшмәде кеше.
Янадылар,
Җәзаларны санап бирделәр,
Җәза коралларын күрсәттеләр:
— Исемен әйт! Кем ул? — диделәр.

Эндәшмәде...
Сабырлыгын җуеп,
Сукты палач бөтен көченә
Ике кулы бәйле кешегә.

Көтте палач,
Кискән агач кебек,
Корбанының авып төшкәнен.
Ләкин кеше явыз ерткыч йөзгә
Төкерде тик сынык тешләрен...

Күз алдында учак дөрләттеләр,
Кыздырырга тимер тыктылар,
Каны белән, җаны белән бергә
Аннан исем, исем сыктылар.

Түзде кеше.
Газап авазына,
Нәфрәтенә төелеп, үчена,
Авызындагы каны белән бергә
Исемне дә йотты эченә...

Исеменә йөрәк сүзе кушып,
Менә бүген шушы кешене
Хөрмәтлисе иде дә бит!
Ләкин
Белгесез шул аның исеме.

## Канәгать

Эреле дә ваклы уңышларның,
Хаталарның җыеп барысын,
Үзне чагылдырган күзгә кебек
Чагылдырды бүген намусым.

И канәгать булыр иде күңел,
Алга илтсә әгәр һәр сәгать.
Тик бүген мин бары үз-үземнән
Риза булмавымнан канәгать.

## Урал

Куенында бетмәс хәзинәсен
Өләшә ул бөтен илемә.
Үзе бары билбау булып кына
Уралган ул илнең биленә.

Ике якта — ике зур континент,
Алар гүя үскән бер төптән.
Урал тавы ике материкны
Затлы металл белән беркеткән.

## Этюд

Якты кояш ялбыр болытның
Ертыгына кереп кысылган.
Җиргә төбәп сирәк керфеген,
Мөнсу гына карый ул шуннан.

Күк гөмбәзе төшкән әйләнеп
Юллардагы нәни суларга.
Шикләнәсең (нинди тирәнлек!)
Басарга да хәтта шуларга.

Җилне кыйный шәрә ботаклар,
Баганалар шомлы гөжлиләр.
Үксез калган тутык яфраклар
Тукталырга урын эзлиләр.

Күңелдәге нечкә кылларга
Сагыш булып алар кагыла.
Чирле сыман барлык табигать,
Сабышкан ул гүя сарыга.

Тирә-якта моңсу сүрәнлек
Сөйли сиңа үсеш туктавын,
Тик Җир-ана күккә төбәгән
Уҗымнарның яшел укларын.

Ишетәдер алар яз маршын
Ачы җилләр шавы аркылы.
И табигать, синең яшьлекнең
Кайда башы, кайда ахыры?!

# Тарикъ Фэттах

## Сөләйманның беренче җыры

Ашага-Сталь[1] баткан тынлыкка,
Халык каплап алган мәйданны.
Халык тыңлый гади җырларны
Һәм бу җырлар ошый халыкка.

Халык та нәкъ җырчы шикелле,
Я шат ул, я кайгырган сыман...
Дикъкать белән тыңлый Сөләйман,
Картның җыры җанга сөйкемле.

Ала алмый ярлы Сөләйман[2]
Сагышлы һәм уйчан күзләрен
Шул узгынчы — моңлы җырчыдан:
«Бу сүзләр бит минем сүзләрем!».

Ул моңа шулкадәр сөенә:
Җиргә тама кайнар күз яше,
Аның нидер килә әйтәсе,—
Ул җыр эзли!.. Кайта өенә.

Сакля тәрәзәсен ачуга —
Кошлар моңы бакча түреннән.
Чын күңелдән, йөрәк төбеннән:
Кинәт шул чак очып җыр чыга.

Бер-бер артлы тезә Сөләйман,
Җаны көләч, йөзе балкулы.
Йөрәгендә җырлар ялкыны
Кабына да, бер зур ут сыман,

Урманнарга үрли, ярларга,
Тирә-якны кинәт яктыртып,
Халык акылын, уен балкытып,
Тарала ул ерак тауларга.

●

*Камил туганым истәлеге*

Нигә ерттым үлем конвертын,
Бергә чаклар исемә төште.
Керфекләрем болыт булды да
Күз яшьләрем битемә төште...

Ул егылды утлар эчендә,
Соры каска калды моңаеп.
Кыска булса да бу яшь гомер,
Бәетләргә, дастанга лаек.

---

1 Авыл исеме.
2 Сөләйман Стальский.

## Көтәм

Көтәм сезне, язгы күлләр
Аккошын көткән кебек.
Һәр якты көн үткән саен
Ел үтеп киткән кебек.

Сагынуларны җырлап йөрдем
Белмичә, аңламыйча,
Үз гомеремдә күңелемдә
Бер татып карамыйча.

Хәзер кадалды йөрәккә
Сагыну тигәнәге,
Үткән көннәрне уйлыйм да
Мин хәсрәт чигәм әле.

Яралылар хәят суын
Эчеп терелгән кебек,
Сагышлардан арынырмын
Мин дә бер сезне күреп.

Игенче ашлык урырга
Көтеп алгандай көзне,
Истәлекләргә бирелеп,
Өзелеп көтәм сезне.

## Зәңгәр күзләр

Я не хочу любви твоей,
Я не могу ее присвоить;
Я отвечать не в силах ей,
Моя душа твоей не стоит.

*К. Ф. Рылеев.*

Юлдашларым: «Бер дә йокламадың,
Төнне уяу чыктың»,— диделәр.
Алар минем зәңгәр күзле кызга
Гашыйк булганымны белмиләр.

Бөдрә чәчләр, зәңгәр күзләр диеп,
Белми җырлап йөргән икәнмен:
И күрсәгез иде зәңгәрлеген
Күзләренең назлы иркәнең.

Алар минем чиксез хыялымны
Очырдылар аккош күленә.
Бу күзләрдә күлләр тирәнлеге,
Чишмәдәге пакьлык күренә.

Йөрәктәге иң саф ниятләрне
Шул күзләрдән укый аласың,
Бер карашы белән имләр иде
Газапланган ирнең ярасын.

Зәңгәр күзле кызның исемен дә,
Кемлеген дә сорый белмәдем,
Тик бер килер көндә кавышачак
Егетеннән аны көнләдем.

## Ибраһим Абдуллин

# АРЫШ СОХАРИЕ

НӘСЕР



Һәр кемнең дә дуслары була. Һәм төрле дуслары була: сүз күтәрүчеләре һәм юкка да үпкәләүчеләре; колын муенына аскан кыңгырау сымак шалтыравыклары һәм онытылганда бер генә елмая торганнары; хәтереңне саклап тормый бәреп әйтә торганнары һәм күңелеңне китмәс өчен гел комплимент кына сибүчеләре; синең белән утка-суга керерлекләре һәм син батканда яр башында, башын кырын салып, карап торганнары; синең өчен җанын, сөйгән ярын бирерлекләре һәм җаның белән сөйгән ярыңны тартып алырлыклары була.

Төрле дуслар бар дөньяда. Ләкин аларның күбесен ярсып аккан дәрья аша салынган тар басмадан чыкканда яки башыңа кайгы ишелеп төшкәндә генә аңлыйсың икән. Әнә шуңа кадәр бөтенесен дә тиң, бөтенесен дә тигез күреп, бер бизмән белән үлчисең һәм бөтенесен дә саф су төсендәге бриллиант дип уйлыйсың.

Ә менә бер дустымны... Юк, аны дусларым исемлегенә кертә дә алмыйм. Ул йөрәгемнең түрендә түгел, алгы ягында, таныш-белешләр арасында гына йөрде. Без аның белән сирәк очраштык — онытылганда бер генә. Очрашканда да «исәнме-саумы, эшләр барамы, бара» дип бер-ике сүз алышабыз да шуның белән вәссәлам. Менә шуннан торды, әйтергә яраса, безнең дуслык. Бер рюмка шәрап та эчмәдек үзе белән. Ул гел ашыкты, ул гел эшлекле булды. Андый кешеләрне гадәттә сохари дип йөртәләр.

Сохари... Хәер, арыш сохарие — арыган, ачыккан чакларда хәл кертүче, күңелне күтәрүче бердәнбер солдат тәгаме бит ул.

Кинәт, аяз көндә яшен суккан шикелле, йөрәк чире мине аяктан екты, һәм, беләсезме, хәлемне белергә иң беренче булып, кем килеп житте? Сохари дустым. Атнага якын караватым янында китмәде.

Кинәт башыма кара кайгы ишелеп төште. Менә кичтән генә бөтен табигать чәчкәдә утыра иде, ә иртән, әйтерсең, бөтенесен кырау суккан. Кичә генә күк чалт аяз, дөнья нур белән тулган иде, ә иртән гүя кояш тотылган, дөньямны сөрем баскан...

Дусларымның күбесе моны белмәде, ә кайсы берәүләре, белмәмешкә сабышып, урамның икенче ягына янтайды. Ә сохари дустым... күптән күрешмәгән, очрашканда «исәнме-саумы» дип кенә китә торган дустым ялын, диңгезен ташлап, минем яныма очып кайтып төште. Юк, жәлләмәде ул мине. Сызланмады ул минем кайгымны уртаклашыр өчен.



8*

«Бөгелмә. Бөгелгәнне тагы да ныграк бөгәләр һәм озак сындыралар», дип аркама сугып, аркамны турайтты. Ә икенче көнне Кара диңгез ярына очып та китте.

Ә башка вакытта, күңел күгем кояшлы чакта, йөрәгем тыныч һәм талгын типкәндә, эшләрем ходка киткәндә, югала да куя. Әгәр очраклы очрашсак, исәнме-саумы һәм вәссәлам.

Төрле дуслар була дөньяда...

Берәүләре белән йөрәк хәлләре турында, икенчеләре белән халыкара хәл турында сөйләшергә, берәүләре белән разведкага барырга, икенчеләре белән кызлар янына йөрергә мөмкин. Төрле дуслар була дөньяда. Ләкин солдат сохарие кебекләре күбрәк булса, дөнья да, дөньяң да матуррак һәм җиңелрәк булыр иде.

# ЮЛЛАРЫҢА ЧЫГАМ ЕЛ САЕН...

НӘСЕР

Әзләреңне эзлим юллардан.
Бер генә сүз әйтер өчен.

Муеныңа сарылып, бер генә тамчы күз яшемне тамызыр өчен. Җилдә ярылган кайнар иреннәреңнән бер генә үбәр өчен. Кайтыр идең киткән җиреңнән. Син бит: нинди көнне китсәм, шул көнне урап кайтырмын, көт, иртәме-соңмы, барыбер кайтырмын, дип ышандырган идең. Ә мин: «Көтәрмен», дип вәгъдә биреп калдым. Мин вәгъдәмдә тордым, тик син генә сүзеңне сүз итә алмадың.

Озатканда, син мине үбәргә иелгәч, халыктан тартындың. Мин дә аяк очларыма басып үбәргә үрелгәч, әдәпсезлек булыр дип, кыймадым. Кайтсаң иде киткән юлларыңнан, бер кешедән тартынмый, моңарчы үбелмәгән иреннәремнән өзлексез үбәр идең... Чәч толымнарымны сүтеп үрер идең. Мин бит аларны һаман кисми саклап йөртәм. Син озын толымнар ярата идең. «Шул толымнарны сүтсәң, су анасына охшыйсын», дип сыйпый торган идең чәчләремнән. Юк, ана була алмадым мин, бәгырем. Ир арысланнары каршыма килеп тезләнгәндә дә мин йомшамадым, көтәм әле, дидем.

Хәзер инде син сүтеп үргән толымнарыма ак бөртекләр аралашты, син сыйпаган маңгаема буразналар сузылып ятты. Кулларым да, элекке кебек, йомшак, нәфис түгел. Гомер буе ирләр эше эшләп, алар да ирләр кулы шикелле булды. Бармак ярыкларыма туфрак сыланып сеңде, сабынлап юсаң да бетми ул. Хәер, нигә аны бетерергә... Син бит туган җиреңнең туфрагын өзелеп ярата торган идең. Печән чабып арыгач, баш астыңа берни салмыйча, башыңны җиргә куеп, йоклап китә торган идең. Ә мин... тын алырга да кыймыйча, синең тын алышыңны тыңлап утыра идем. Син, сабыйлар сыман, иреннәреңне чутылдатып йоклый торган идең. Син төшеңдә елмая идең. Бәлки, шул чак без синең белән болында куышып йөргәнбездер, бәлки, болытларга утырып, җиһанны гизгәнбездер...

Төшләр матур иде. Өннәребез дә матур булыр төсле иде. Ләкин төшләребезне дә, өннәребезне дә сугыш урлап алып китте.

Син туган туфрагың өчен, баш очындагы ак болытлар өчен башыңны шул туфракка салдың. Ә мин менә егерме биш ел буе куеныңны суытмыйча сине көтәм.

Челтәр карны тишеп, умырзаялар баш калкытканда, күкләр безнең булачак балаларыбызны санаганда көтәм мин сине.

Болында дәртле чалгы тавышы чыңлаганда, каенның сагыштан саргайган яфраклары өзелеп төшкәндә көтәм мин сине.

Бар ачуын миннән алырга тырышып, ачы җилләр тәрәзәмә килеп бәрелгәндә, шаян яңа ел карлары яуганда көтәм мин сине.

Елның һәр көнендә, һәр сәгатендә, төшемдә дә, өнемдә дә көтәм мин сине. Үз мендәрем янына синә да мамык мендәр салып, ишегемне бикләми көтәм мин сине. Мичтән эссе икмәк алгач, икебезгә ике телем кисеп көтәм мин сине.

Егерме биш ел буе ел саен син киткән көнне, сызылып таң атканнан алып кояш баткангача көтәм мин сине. Җирдәге һәм күктәге юллардан күземне алмый көтәм мин сине. Бәлки күктәге юл — Киек каз юлы түгелдер, ә синең кебек туган ярларын, сөйгән ярларын дошманнан сакларга киткән солдатларның ак юлыдыр, ә андагы һәр йолдыз сагыштан урап кайта алмаган батырның сүнмәс истәлеге булып янадыр.

Юк, мин бәхетсез түгел. Ярата белгән, гомере буе берәүне генә ярата белгән кешеләр бәхетсез булмый ул. Мин әле һаман көтәм. Син сыйпап үстергән чәч толымнарым чаларганчы, синең янына китеп, исемсез йолдызга әйләнгәнче, кайтыр юлларыңа чыгып көтәчәкмен. Ул юлга тузан төшермәячәкмен. Ул юл, Киек каз юлы төсле, һәрвакыт балкып торачак. Ватаны өчен, сөйгәне өчен газиз башларын салган солдат юллары сүнми ул. Андый юллар мәңге якты, нурлы була...

# АППЕНДИЦИТ

ЧӘНЕЧКЕЛЕ ДИАЛОГ



— Я, Зарифуллин, үзеңнең кемлегеңне күрсәт әле: бүген нинди көн?

— Ничек — нинди? Чәршәмбе.

— Ә башыңны ныграк эшләтеп карасаң?

— Ә-э-э, «пятиминутка» көне.

— Тагын, тагын кыймылдатып карале миеңне.

— Минем өстәлдәге календарьда башка нәрсә «төртеп» куелмаган.

— Их син, йомры баш, кара каш! Ә һәр айның беренче чәршәмбесен директор нинди көн дип атады?

— Һәй, әттәгенәсе, чәршәмбе — тәнкыйть көне.

— Ә синең бу өлкәдә эшләр ничек тора? Ягъни мәсәлән, тәнкыйть фронтында.

— Зарланганым юк. Эштә түрәләр каезлый, өйдә бичә иги. Айга бер генә тапкыр түгел, көн саен дип әйтерлек.

— Ә син үзең?

— Ничек үзең?

— Үзең тәнкыйтьлисеңме?

— Кемне?

— Кемне кирәк, шуны.

— Ә ни файда?

— Ничек — ни файда? Син, нәрсә, Зарифуллин, тәнкыйтьнең көчен һәм әһәмиятен аңлап җиткермисеңмени?

— Көчен... һы-һы-һыы... Минә минем бичә мине егерме алты ел буе иги, ягъни мәсәлән, тәнкыйтьли. Син фәлән дә фәсмәтән. Кайчан шул трубка суыруыңны ташлыйсың? — ди. Ә мин сүз бирәм, чак-чак кына ант итмим, ә менә бөтенләйгә ташлый алмыйм. Менә сиңа тәнкыйть!

— Хөрт, Зарифуллин.

— Сөйләмәгез инде.

— Тәнкыйть, Зарифуллин, алга этәрүче көч. Тәнкыйть, беләсең килсә, Зарифуллин, антибиотик ул, төрле йогышлы чирләрне һәм... кара тапларны бәрә, егып үтерә. Аңлыйсыңмы шуны, юкмы?

— Сез мине кемгә санныйсыз?

— Аңлагач әйт әле, Зарифуллин, иртәгә нинди көн?

— Чәршәмбе.

— Тагын?

— «Пятиминутка» көне.

— Тагын?

— Тәнкыйть көне.

— Шулай булгач, син иртәгә шул «пятиминутка»да яндырырлык-көйдерерлек тәнкыйть белән чыгыш ясарга тиешсең.

— Ә нигә? Ярам да салам.

— Дөрес, Зарифуллин! Яр да сал. Хәзер тәнкыйть өчен кыерсыта торган заманнар үткән инде. Ә... тәнкыйть утыңны кемгә юнәлтмәкче буласың?

— Директорга. Эреләнде. Танавын чөйгә элеп йөри башлады. Кешеләрне искә алмый.

— М-мөмкин. Директорны да тәнкыйтьләргә мөмкин. Хәтта югарырак утырганнарны да... Тик... Карале, Зарифуллин, әллә директорны хәзергә калдырып торыйкмы? Әйдә аны югарырак торучылар тәнкыйтьләсен. Ә син түбәнгәрәк төш.

— Алайса... Производство бүлеге начальнигын...

— Тр-рр. Завком члены. Әйтергә яраса, номенклатурный кеше.

— Ул чагында... Баш бухгалтерны пешерәм. Соңгы вакытта еш кына мин аны...

— Мин дә син күргәнчә күргәлим, әмма... ул директорның квартирына преферанс уйнарга йөри. Әгәр ул-бу булса, директор сине...

— Һа-һы-һыы... Бәлки, завхозны эссе мичек белән чапкаларгадыр? Ул бит, әйтергә яраса...

— Аллам сакласын! Больницадан чыкканына атна-ун көн дә юк. Ай буе алкоголизмнан дәваланып ятты бит. Ә син аны үзеңнең тәнкыйтең белән... Юк, юк, я тагы элекке эшенә салышыр.

— Бер дә булмаса, АХО начальнигын утлы табада биетәм. Эшкә бармак аша карый, ялкау...

— Отвод. Аның болай да кайгысы башыннан ашкан. Үткән атнада хатыны ташлап китте.

— Ал-лай... Алайса... Прорабны шүткеләп алырга кирәк. Аның аркасында ремонт ярты елга сузылды.

— Менә аны мөмкин. Мөмкин генә түгел, кирәк. Әмма...

— Ә нигә әмма? Ә нигә аннан куркырга? Ул ачу саклый торган кеше түгел. Мин аны биш-алты ел буе беләм.

— Эш анда түгел. Аңлыйсыңмы, Зарифуллин, аның әбисе, русча әйткәндә, тещасы хәл эчендә ята. Ә безнең халыкта әбиләр кияүләре өчен җаннарын фида кылырга торалар, син кияүен тәнкыйтьләрсең, ә әбисе — асыльяр, хуш инде...

— Ул чагында...

— Ул чагында... Уйлашыйк, Зарифуллин, уйламый эшләгән — авырмый үлгән, ди.

— Ә мин уйладым.

— Уйладың? Кемне?

— Сине, профсоюз алласы.
— М-мине?
— С-сине шул. Һәр сөягеңне барлап чыгам.
— З-ззарифуллин! А-ашыкма! Утыр әле. Сөйләшик, серләшик.
— Сөйләштек, серләштек. Җитте. Тәнәфес бетеп килә. Йөрәк ялгап алырга кирәк. Ярый, хуш.
— Ашыкма, диләр сиңа, итәгеңә ут капмагандыр. Утыр әле диванга. Шулай. Карале, мин сиңа кем? Дошманыңмы? Тәгәрмәчеңә таяк тыгаммы? Бүләктән мәхрүм иткәнем бармы? Ихтимал, ял йортына путевка бирми калганмындыр? Әйттерәсең килсә, мин сине бер туганым кебек яратам. Ә син шуның өчен мине бөтен халык алдында рисвай итмәкче буласыңмы?
— Урынлы тәнкыйтьләү — рисвай итү түгел, иптәш профком председателе.
— Урынлы? Нәрсә, эреләндемме? Янып-көеп эшләмимме? Хәмер һәм бичәләр белән шаяраммы?
— Әлек син ботаклы агач шикелле идең, ә хәзер тешләре сынган тырма кебек, шоп-шома. Әлек син атакага күтәрелгән солдат сымак идең, ә хәзер оборонада посып ятасың. Менә шул хакта сөйләячәкмен!
— Кая чабасың син, Зарифуллин? Бик ачыксаң, әнә минем кефир белән бутербродны ашап ал. Син мине дөрес аңла, Зарифуллин туганкаем, мин тәнкыйтькә каршы түгелмен. Ярый, син мине тәнкыйтьләдең дә ди. Әгәр минем белән ул-бу булса?
— Ничек ул-бу?
— Ихтимал, «Скорая помощь» машинасын чакыртырга туры килер.
— Төшенмим.
— Төшендерәм. Миндә хронический аппендицит.
— Ә кемдә юк ул?
— Их, Зарифуллин, Зарифуллин, шәфкатьсез кеше икәнсең син. Минем ике тапкыр приступ булды инде. Син менә мине пешекләп чыгарсаң, ә ул шартлады ярылды. Аппендицит бик югары нерв системасы белән бәйләнгән. Ул чагында... сезгә гадәттән тыш профсоюз җыелышы үткәрергә туры килер...
— Чынлап та...
— Ә син мине шаяра дип уйладыңмыни? Бер-беребезне саклый белмибез шул без, иптәш Зарифуллин...
— Ә иртәгә нинди көн әле, иптәш профком?
— Чәршәмбе көн, иптәш Зарифуллин.
— Ә директор һәр айның беренче чәршәмбесен нинди көн дип атаган иде, иптәш профком?
— Беләм, иптәш Зарифуллин, беләм, ләкин...
— Я, я, кыюрак, кыюрак!
— Тәнкыйть көне, Зарифуллин.
— Ә кемне тәнкыйтьләргә, иптәш профком? Директорнымы?
— Ы-ыы...
— Производство бүлеге начальнигынмы?
— Ю-ук... У-ул директор белән...
— Беләм, картле уйный. Завхоз ярамый, яңа гына психбольницадан чыккан. АХО начальнигын хатыны ташлап киткән.
— Д-дд-дөрес.
— Ул чагында син генә каласың инде, профком.
— Д-дөрес түгел. Ап-ап-аппендицит. Ш-шартлавы бар.
— Ә кемне генә тәнкыйтьләргә соң? Әлеге дә баягы, идән себерүче апаны да дворник картнымы?
— Ә тәнкыйть ничә төрле була?
— Ничә төрле? Астан һәм өстән, уңнан һәм сулдан. Дүрт төрле.
— Тагын, тагын?

— Башка юк, бугай.

— Ә самокритика? Үз-үзеңне тәнкыйтьләү? Бу бит иң файдалы, иң принципиаль тәнкыйть. Кем үз-үзенә тәнкыйть күзлегеннән карый, шул кешенең һәрвакыт тәне таза, күңеле көр була. Самокритика ул, Зарифуллин, антибиотик ише генә түгел, ул... поли-ви-та-мин! Поливитаминсыз — тән, самокритикасыз — җан зәгыйфьләнә. Хәзер син мине аңладыңмы, Зарифуллин?

— А-аңладым... бугай...

— Аңласаң, мә сиңа текст, мә «кызыл почмак» ачкычы, бүлмәгә кереп, бикләнеп утыр да шушы язуны ятла. Иртәгә киңәшмәдә беренче булып сикереп тор да... үз-үзеңә тәнкыйть уты ач! Бер кемгә карама, яндыр, көйдер. Мә бишне, уңыш телим!..

# ЯКАСЫННАН АЛЫП БУЛМЫЙ...

САТИРА



Һ-ии, хәзерге бюрократ бюрократмыни ул! Вәт элек бюрократлар бар иде ул, ичмасам. Кара дерматин белән тышлаган ишеккә: «Шәхси йомыш белән килүчеләр атнага ике тапкыр: җомга һәм пәнҗешәмбе көннәрдә икедән өчкә чаклы кабул ителә», дип язылып куелган була. Калган көннәрне түгел, шул ук көнне ярты сәгатькә генә элегрәк яки соңрак килсәң, күзеңнән чишмә булып кайнар яшьләрең аксын, машинкада тукылдатып утырган кызыл тырнаклы, кандай кызыл иренле кызыкай сине ишеккә якын да җибәрмәячәк. Ярый, ярты картаеп булса да кара дерматинлы ишекне ачу бәхетенә ирештең ди. Ә ул бүлмәдә кем утыра? Урамда чеңлә булуга карамастан, кара китель кигән, ниндидер кәгазьгә караган булып башын өстәленә игән Фәлән Фәләнович.

— Саумысыз, иптәш...

Җавап юк. Кычкырыбрак исәнләшәсең. Баш кыймылдап куя, әмма өн чыкмый. Шуннан син йомышыңны сөйли башлыйсың. Дәшәргә ашыкмый. Тик шәлъяулык чаклы кулъяулык кына такыр башны әйләнеп чыга да галифе чалбары кесәсенә бүлтәеп кереп урнаша. Син ни эшләргә белмисең. Чигәңә кан бәрә, йөрәк менә-менә күкрәкне җимереп чыгар да... Юк, йөрәкнең күкрәкне җимереп чыкканын көтмисең, тегенең янына киләсең дә: «Мин сиңа кем: кешеме, баганамы?» — дип, өстәлгә тондырасың. Графинга кидереп куелган мескен стакан ыңгырашып куя. Хуҗа да каушап калмый: «Ә мин сиңа кем?» — дип ике потлы гер чаклы йодрыгы белән өстәлгә кундыра. Стакан графин башыннан очып ук төшеп, челпәрәмә килә. Шуннан тотынасың рәхәтләнеп әрләшергә... Мин кара савытына ябышам. Ул таш пресс-папьены эләктерә. Бугазга бугаз киләбез. Шыбыр-шыбыр килеп төймәләр коела.

— Резолюция сук!

— Сукмыйм!

— Мин синең өстеңнән жалоба язам!

— Берне түгел, уны яз!

— Газетада фельетон бастырып, адәм көлкесенә калдырам.

— Тукта, тукта...

Теге лап итеп креслосына утыра һәм кулы ручкага үрелә.

— Ну кеше дә икәнсең...

— Ә син? Һы-һы-һы...
— Һа-һа-һа...
— Мә бишне. Бигайбә.
— Бигайбә.
— Ә хәзер...
Кабинет ишегенә: «Шәхси йомыш белән килүчеләр көн саен теләгән вакытта кабул ителә», дип путаллап язып куелган. Ишекне ачарга өлгермисен, тан кояшыдай елмайган түр иясе сикереп тора.
— А-а, кемне күрәм! Утырыгыз. Юк, юк, диваннан. Тартасызмы? Хәл-әхвәл? Семья?
— Рәхмәт. Мин, иптәш директор...
Ә ул кулын синен кулбашына куя да:
— Яңа анекдотны ишеттенме? — дип мәзәк сөйләргә тотына.
Син, эш кешесенең вакытын алмас өчен, тиз генә йомышыңны сөйли башлыйсың.
— Гафу итегез, вак мәсьәлә белән борчымыйм, иптәш директор...
— Вакмы, эреме, бөтенесе дә мөһим. Кулымнан килгәнне генә түгел, килмәгәнен дә эшләргә әзермен. Сөйлә.
— Газ колонкасын алмаштырган иделәр. Инде ике атна үтте, һаман газ бирмиләр.
— Ә нигә ул газ? Ата-бабаларыбыз гомергә газсыз яшәгән бит. Ә купмешәр яшәгән? Минем бабай йөз дә алтыда үлгән. Газ гомерне кыскарта ул,— лирик тенор кыңгырау шикелле чылтырый.
— Бәлки, шулаен шулайдыр да, әмма кер юарга, бала-чаганы юындырырга кирәк бит әле...
— Иртәгә газың булыр. Тагы?
— Башка йомышым юк, гафу итегез инде...
— Үтенмә. Без халык мәнфәгатьләрен күзәтер өчен куелган.
Канатланып чыгып китәсең. Шундый игътибарлы бала тапкан өчен директорның анасына рәхмәт укыйсың, секретаренен кулын үбәсең.
Ләкин... Бер көн үтә, бер атна үтә... Ә газның ялкыны түгел, исе дә юк. Тагы теге татлы тел янына китәсең.
— Мөмкинме, иптәш директор?
— Ник мөмкин булмасын. Юк, юк, диваннан рәхим ит. Хәл-әхвәл? Семья? Нинди газ? Ә-әә... Һаман бирмәделәрмени? Мин аларны... Зинһар, гафу ит. Бу минем гаеп. Приказны бирергә генә түгел, үтәлешен дә тикшерә торырга кирәк. Бүген үк, бүген үк булмас, иртәгә үк газлы булырсың. Бар, борчылма, йөрәгеңне сакла.
Тагы бер көн, бер атна үтә, әмма газның ялкыны түгел, исе дә юк. Каннарың чемер-чемер итә. Тешләрең тешкә бәрелеп шыгырдый. Йодрыкларың үзләреннән-үзләре төйнәлә. «Барам да бугазыннан алам...» Алдың пычагым! Ишек ачылу белән сикереп торды, секретарен чакыртып, ике стакан лимонлы чәй керттерде һәм шундый оста итеп юкә чәй какты, бөгелә-сыгыла рәхмәт әйтеп чыгып киттем... Хәзер инде янына барырга да кыймыйм. Шундый игелекле кешене ничек борчыйсың инде.
Ә элек... вәт ичмасам бюрократлар бар иде! Аска иелгән баш, жимерелгән каш, кара китель, кара галифе... Керәсең, якалашасың һәм... йомышыңны йомышлап чыгасың. Ә хәзерге бюрократлар бюрократмыни ул! Күзгедәй ялтырап торган полированный өстәл, өстәленә таш прессапье урынына шырпы юанлыгы ике-өч шариковый ручка... Якасыннан да алып булмый, житмәсә, өстендә нейлон күлмәк — кул шуа. Ә элек... элекке бюрократларга житми инде ул!

## Эдмунд Гюнтер

*Немец шагыйре*

# Бары бер сүз...

Минем кебек ул да ятты үлем көтеп,
Өстендәге тоткын киемен кәфен итеп,
Үз тиресе белән өртеп газиз җанын.
Беркемнән дә яклау, ярдәм эзләмәде,
Үлем иде томан аша күзләгәне,
Тик йөрәге шул хәлдә дә типте аның.

Безне үзе белән бергә тартты үлем.
Һәр адымың өчен монда, һәрбер сүзең
Өчен һәрдәм үлем белән янаганда,
И карыйсы килгән иде туган илнең
Кояшы елмаеп торган якты көген!
Сизсәләрме,— җәза хәтта уйлаганга...

Эндәшмичә ятты дустым, чөнки минем
Аның өчен аңлашылмый иде телем,
Тик сүзсез дә тойдым җаны әрнүләрен.
Һәм аңладым — җитми әле сүзләр генә,—
Хәлсез дусның тына барган йөрәгендә
Соңгы жылы кан тамчысы йөгергәнен.

Ә бер төнне сүрән генә янган утның
Яктысында мин баракны үтеп чыктым,
Сүз кушарга газапланган туганыма.
Югарыдагы ятаклардан текәлделәр
Безгә таба курку белмәс, тонык күзләр,
Чагылдылар утның саран нурларында.

Хәлсезләнгән, ярым тере гәүдә күрдем,
Аңлашырга аның телен белми идем,
Аңлашырлык сүз эзләдем туганыма.
Барысы әзер, яктырганчы китү кирәк
Икәнлеген аңа аңлатырга теләп,
Бары бер сүз пышылдадым колагына.

Кочаклаштык бертугандай,
Шушы кичтә
Ул сүз безне туган итте мәңгелеккә.

Шул сүз белән хәлсез тәнгә юл таптым мин.
Ярым үле, ярым тере, бу минутта,
Көчкә-көчкә җан саклаган скелетта
Кинәт пәһлеван йөрәген уяттым мин.

Ул ихтыяр, ул көч аңа каян килгән,
Әй, кадалды ташка, ватты кәйлә белән —
Ярасыннан, йөрәгеннән йөгерде кан...
Һәм җылынды йөрәк каны белән идән,
Тик ул барды алга, үзсүзлелек белән
Һәм ычкынды Освенцимның тырнагыннан.

Освенцимның коймаларыннан арьякта
Иң беренче азатлыкны тойган чакта,
Күрдем ирләрнең дә үксеп елаганын.
Бозлы яңгыр хәлсез тәнне җылытканда,
Онытырга мөмкинме соң җанын барда
Шаян җилнең уныш теләп үпкән чагын.

Тимер чыбык киртәләре калгач артта,
Шул яшенле төндә дустым туфракка
Капланды да үпте җирне, калды тынып...
Үпте озак, иреннәре бетте канап.
Бара алмас сыман иде алга кабат,
Җирдә һәрбер ташны үбеп чыкмый торып.

Өч төн буе ашыктык без Көнчыгышка.
Ант иткәндәй сугышчы канлы сугышка
Кергән чакта, өч төн буе тәкрарлады
Аңлашырга ярдәм иткән шул бер сүзне.
Иң куркыныч, авыр минутларда безне
Шул сүз генә тормышка кайтара алды.

Ул бит аны факел итеп йөрәгендә
Саклап килде, нығып үзе көннән-көнгә,
Көн яктысы күрде анда, күрде үзен...
Тынычлык өчен көрәшне күрде анда.
Юккамыни соңгы тапкыр хушлашканда
Шул бер сүзне кычкырды ул —
«Ленин!» сүзен.

МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВ
тәрҗемәсе

Сөббүх Рафиков

# ТАШ БИЛГЕ

ОЧЕРК

Бу яклар минем язмышым белән бәйләнгән.
Бу яклар минем туган оям.

Ватан үзең туган өйдән башлана. Ишекне ачып чыгасың, басу капкаларын артта калдырасың, авыр юлларын үтеп, пароходка яки поездга, яки самолетка утырасың. Анда да синең Ватаның, синең үз офыгың — җире дә синеке, күге дә.

Ул сиңа — һава, ул сиңа — су, ул сиңа — ипи һәм тоз. Синең әниең алдыннан төшеп, тәпи йөри башлау белән барлык тормыш юлларың шуннан салынган, ниһаять, очар канатларың шунда ныгыган.

Әмма, ата-бабаларың, җиде тамырың гомер кичергән, үзең туган тирәләр — сиңа иң кадерлесе, иң мөкатдәсе. Тормыш дулкыннары кешене кайларга гына ташламасын, ул әлеге шул үзенең күзләре беренче тапкыр дөнья яктылыгы күргән, ана сөтен беренче йоткан урынын һәм аның әйләнә-тирәсендәге төшләрне мәңге күңелендә саклый, йөрәк түрендә кадерләп йөртә. Бу Чаллы яклары да шулай минем өчен. Шушы Чаллыга барсам, күңелләремә әллә нишләп китә. Киндер ыштан, киндер күлмәк кигән малай чакларым, чабаталы егет чакларым каршыма йөгереп килерләр сыман тоела. Ләкин кая инде? Яңадан кайтмаска әллә кайда адашып калган үткән гомерләреңнең койрыгын тотып кара син?

Чаллыга беренче мәртәбә үзебезнең күрше мулла Гыйлван (мулла дигәч тә, мулла түгел, кырыктартмачы шаян гына бер кеше иде ул) белән килдем. Көз көне иде. Гыйлван абзый, Хөснетдин картлардан ат алып, казнага сатарга ашлык алып барды. Моңарчы авылдан чыкмаган мин фәкыйрегезгә, үзәк урамның ике ягы буйлап тезелеп киткән, әллә ничә кат чыбык уралган телефон баганалары, анда-санда күренгән ике катлы йортлар, эреле-ваклы кибетләр искиткеч яңалык иде. Алар барысы да тиңдәшсез кебек иде миңа. Инде тау башына салынган элеваторны күргәч, тынымөнем бетте. Мондый олы бина дөньяда берәү генәдер дип уйладым мин. Сөт күбеге кебек кабарып пешкән калачны да беренче тапкыр шушы кечкенә шәһәрдә авыз иттем.

Ул чагында нэп еллары иде. Хосусый сәүдә, ситса-комач сатучылар һәм башка сәүдәгәрләрнең кайнап торган заманы. Егерме алтынчы елда инде мин, кулаклардагы авыр эштән качып, шушы шәһәргә килдем һәм Карл Маркс исемендәге икенче баскыч татар мәктәбенең беренче төбенә (5 классына) укырга кердем. Монда инде минем өчен бәхет капкалары ачылды.

Ул вакыттагы Чаллының мөгезеннән тотып алырлык, республика халкы алдына чыгып сөйләрлек әллә нәрсәсе дә юк иде. Кечкенә электр станциясе. Кичләрендә

тонык кына янган утлар, элеватор һәм ящик арбаларга җигелгән атлар... атлар... Без, малайлар, Камадан пароход килүләрен бик яратып, ничә карасак та туймыйча, еш кына пристаньга төшә идек. Пристаньда баганага кадаклаган бердәнбер вывеска елданел яңара торган иде: «Юлчылар игътибарына! Кызыл Гаскәр урамында Барый Абдуллинның мөсафирханәсенә рәхим итегез!» Шул таныш вывескага рәсеме төшерелгән бер катлы, хәзер инде бүрәнәләре каралган агач йорт әле дә шәһәр бакчасы (элекке базар) чатында тора.

Тагы нәрсә?

Мин җәйге тәгътыйль (каникул) вакытларында Кама буйларын, андагы мәктәбебезне, сабакташларымны, укытучыларым: Кыям Хисаметдиновны, Зәки Алиевне, Имаметдин Хәйдәревне, Галимҗан Таймасовны, Нәҗип Заетовны, Шиһап Шәһәртдиневне, Рәүф Мәүҗүдовны, Хаҗи Айдашевны һәм Яковлеваны (без аны апа дип йөртә идек), ә кыш көне туган авылымны, аның кешеләрен өзелеп сагына торган идем.

Сулар актылар...

Еллар үттеләр...

Мине дә тормыш җилләре кайларга гына ташламады! Шулай сагынып һәм моңсуланып, шатланып һәм кайгырып, эшләп һәм ашап, көндез хәрәкәттә булып, төнне йоклап, ни хәтле озын юллар, ни хәтле гомерләр артта калды, ни хәтле исемнәр онытылды, ни хәтле яңалары пәйда булды. Ә тормыш һаман кайный, туктаусыз бара, бара, бара! Кешеләр аның агылышына үзләре юнәлеш бирәләр.

Кеше дигәнең бүгенге көн, бүгенге вакыйгалар белән яши. Рухлана. Аның күңелендә бары яшьлек, бары алга талпыну гына һәрвакыт хуҗа булып тора. Беребезне дә читләтеп үтми мондый хис. Безнең Чаллы да кеше күңеле, кеше йөрәге кебек гел яшь, гел үзенә тартып тора. Еллар аны үстерәләр, куәтләндерәләр. Монда Европада иң зур автомобиль заводы салыну хәбәре, тылсымлы кош кебек, бик күп җирләрне айкап чыкты.

СССР Министрлар Советының «Кама автомобиль заводы төзүнең беренче чираттагы чаралары» турындагы карарында шундый юлларны укыйбыз без: «Чынлыкта заводларның бөтен бер комплексы булачак бу предприятие Казаннан 280 километр ераклыктагы Чаллы шәһәре районында төзелә. Ул авыр йөк ташый торган дизельле двигательләр эшләп чыгарачак.

...Кама автозаводын төзү белән берләттән, шул ук елларда (ягъни 1970—1974 елларда. Ред.) төзүчеләр хәзерге Чаллы шәһәрчеге урынында берничә йөз мең халкы булган зур шәһәр салачаклар».

СССР хөкүмәте карарында әйтелгән бу сүзләрнең мәгънәсе гаять тирән, тамырлары нык, нурлары гаять якты. Бу киң колачлы гигант бөтен илебез өчен, бигрәк тә безнең Татарстан республикасы өчен ифрат зур вакыйга! Моның шулай икәне шушы зур төзелешкә багышлап үткәрелгән (21 февраль, 1970 ел) өлкә партия оешмасы активы җыелышында Татарстан өлкә партия комитетының беренче секретаре иптәш Фикрәт Әхмәтҗан улы Табеевның докладыннан да күренә:

«...Шунысы характерлы: Кама автозаводын салу өчен иң күп эшләр башкарган елда көнгә бер миллион сумнан күбрәк акча тоту билгеләнә. Илебезнең капиталь төзелеш тарихында әле моның тиңдәше булганы юк иде».

Шушы саран гына әйтелгән, шушы кыска гына сүзләр зур төзелешнең йөзен бик ачык билгелиләр.

Үзе яши торган урыннан артык ерак түгел шундый зур төзелеш башланганны ишеткәч, минем кебек каләм тибрәткән кеше ничек итеп түзеп кала алсын соң! Һич юк! Төн агартып кар яуганда булмасын, язгы тургайлар җырлап акканда булмасын, төзүчеләр — үз куллары, тырышлыклары белән, үзләренә онытылмас һәйкәл салучылар үз яннарына тарттылар мине. Чаллыга һәр баруымда яңалык сулышының арта баруын тоям, аның гайрәте арта баруын күреп куанам. Яңа кешеләр күрәм анда. Шунда алган тәэсирләрне, күңелгә кереп утырган кешеләрне һич кенә дә оныта алмыйм. Бәхәссез, бу яклар, мондагы олуг төзелеш белән тормышларын, язмышларын бәйләгән каһарман кешеләр турында, яшьлек, сафлык өреп торган яңа повестьлар, романнар да туар.

Аларны кем язар?

Бу тиклесе — киләчәк эше.

Ә мин хәзерге күргәннәрдән чыгып, кайнар эздән сөйлим, кайнар эздән язам.

...Кырлар уртасында зур соры таш ята. Цементтан коелып ясалган бетон таш ул. Анда бер генә кыска җөмлә: «Здесь будет построен «Камский Батыр».

Бүре булып улаган зәһәр кышкы салкын җилләрнең дә тешләре үтми аңа. Аны йөгерек кар сулары да, яңгырлар, бозлар да юа алмый. Аның үзенә генә хас соры төсен кояш нурлары да уңдыра алмый.

Ул — мәңгелек!

Ул — тиңе булмаган гигантның яралгысы.

Ул — меңләгән каһарманнарның уйларын, хисләрен беркеткән таш билге!

Ул — нигез ташы!

Ул — мәңге таркалмас!

Кырлар уртасында язулы таш ята...

* * *

Без бәләкәй чакларда малайлар өчен иң зур мәртәбә атка атланып йөрү, иң зур һөнәр ат җигә белү иде. Әйтик, төпсез ыштан кигән малай читән коймага үрмәләп менә дә әтисе яки абыйсы йөгәненнән тотып торган җирән алашага яисә кола бия җилкәсенә атлана. Бала малны сулауга алып төшә, аның артыннан шатлыклы авазлар ишетелеп кала:

— Фәлән абзыйның малае кул астына керә башлаган. Ат ярата. Йорт җанлы булыр. Малай кеше шул инде ул, керәшче булыр, йөгерештә узар...

Шундый сүзләргә күңеле күтәрелгән малай, мактауга йөрәге җилкенеп, атның сыртына йөгән очы белән тамызып та ала. Моңарга кәефе киткән һәм сыртында кем барганын чамалаган мал шомыраеп, арт санын сикертә. Малаебыз җиргә гөмберт... Мондый чакларда инде җылавы да, көлүе дә бергә була.

Хәзерге малайларны ат кызыксындырмый. Аларның бар белгәннәре машина, комбайн, трактор. Тәпи йөри башлау белән машиналар тирәсендә чуалалар. Бу хәл Бикчәнтәй авылындагы (Минзәлә районы) Фатих абзыйның уртанчы улы Фәнүсне дә читләтеп узмады. Ул бик яшьли туган колхозында шофер булып эшли башлады. Армиягә алынгач та шул һөнәре буенча хезмәт итте. Моннан дүрт кенә ел элек, солдат хезмәтен тутырып кайткач, егетне комсомол путевкасы белән Пермь өлкәсенә эшкә җибәрделәр. Анда ярты елдан артыграк эшләгәч, күңеле тәки кунты бит аның. Туган якларындагы зур үзгәрешләр турында радиолардан ишетеп, газеталардан укып, тотты да кайтты ул Түбән Кама ГЭСы төзелешенә. Армиягә киткәнче үк тәртипле, эшчән һәм әйткән сүзендә тора торган егет иде ул. Ә Совет Армиясе кешене тагы да төгәллеккә, тагы да кыюлыкка һәм тырышлыкка өйрәтә, килмәгән якларны китереп кайтара бит ул. Фәнүс Фатиховның элекке әйбәт сыйфатлары тагы да тулыланып китте. «Камгэсэнергострой»ның автотранспорт хуҗалыгы җитәкчеләре дә егетнең бу якларын тиз төсмерләделәр, тиз күрделәр. Килеп беркадәр эшләгәч тә аңа «КРАЗ-256» маркалы йөк машинасы бирделәр. Мондый олы машинада әле аның беренче генә эшләве иде. Бик тиз дуслашып китте ул бу киң күкрәкле, куәтле, бер талпынса җирләрне селкетерлек баһадиры белән. Инде шуннан чыгып уйлап карасаң, безнең Фәнүс ташыган балчык, ком, бер дә арттырмый гына әйткәндә, үзе бер тау хәтле булыр. Хезмәт күрсәтү срогы чыккач, аңа шундый ук икенче машина бирделәр.

...Ул өйләнде.

Чаллыда автозавод төзеләчәген ишеткәч, туган якларга, бу кечкенә шәһәргә мәхәббәтләре тагы да артты аларның. Бер көнне, эшкә барганда, Фәнүснең үзе кебек үк озын гәүдәле, күзләреннән яшьлек уты, тормыш дәрте сирпеп торган Мәрьямә әйтә салды:

— Берничә елдан безнең монда дүрт йөз мең кеше булачак!

— Әйе,— дип күтәреп алды Фәнүс,— бу бит хәзерге Казан халкының яртысына якынлаша дигән сүз.

— Хәзер инде гел шушында торырбыз, яме?

— Шушында автозаводта эшләп, синең белән балалар үстерербез, өнисе.

Мондый сүзне әле гомерендә беренче тапкыр диярлек ишеткән Мәрьямнең кинәт кенә бит алмалары алсуланып китте, озын керфекләре аска карады.

— Бигрәк инде, ничек оялмыйсың?

— Аның ниндиояты булсын? Егет белән кыз тормышларын бергә кушсалар, өйләнчесен кот тә тор инде аның. Бер бездән генә калмаган.

— Фәлсәфә сатарга яратасың да инде,— дип елмайды Мәрьям.

Өстенә кышка хас җылы чалбар, сырган пиджак кигән Мәрьямнең зифалыгы арта барган кебек күренде Фәнүскә. Уң кул якта, әле яңарак кына салынып беткән зур йорт алдына килеп җиткәч, туктадылар. Мәрьям шул йортка кереп китте. Фәнүс үз юлы белән атлады.

Менә бит гомер дигәнең нинди тиз һәм сизелмичә генә үтеп тора. Әле күптәнме соң, кичләрен Мәрьямне кызлар тулай торагына озата бара иде. Аны берәр көн күрми торса, йөрәге кайный, эче поша иде. Шулай мәхәббәт утында янып-көеп йөрүләренә, бер уйласаң, әле кичә генә кебек. Ә ныклабрак карап баксаң, аларның башлы-күзле булуларына ике ел тулып килә бит инде. Башта икесенә ике тулай торакта торырга, аеры-чеере яшәргә туры килде. Аннары эшләре җайланды. Яңа өйләнешкәннәр, яшь гаиләләр өчен җиткерелгән зур йортта аларга да квартир бирделәр.

Бүген декабрьның (1969) унөче. Көн кояшлы. Офык читеннән түбәннән генә йөзгән кояшның утлы тасмалары Кама аръягындагы урманнарны нурга күмгән. Һава салкынча һәм коры. Тик менә кыш була торып, кары гына юк диярлек. Тәмам кыш кергәч, җиргә ябылган ак юрганга яз сулышыдай бер җылылык өрде. Яңгырлар яуды. Булган кар шуның белән сызды да бетте. Кыш булгач, кыш булу яхшы. Карсыз кыш үләнсез җәйне хәтеренә китерде Фәнүснең.

Ул гаражга кереп, машинасын да кабызырга өлгерә алмады, аны конторага чакырдылар. Автотранспорт хуҗалыгы начальнигы кабинетында партоешма секретаре Шоширин да бар иде. Начальник М. И. Баранов Фәнүс Фатиховка үз өстәле каршында урын тәкъдим итте. Ничектер начальникның да, секретарьның да кыланышлары бәйрәм тантанасындагы чакларны хәтерләтә. Автотранспорт хуҗалыгы начальнигы Баранов җылы гына тесте сөйләп китте:

— Иптәш Фатихов, сез безнең алдынгы шофер, коммунистик хезмәт ударнигы. Ярыш алдынгысы...

«Бу ничек инде, минем бер үзем белән «җыелыш» уздыралар»,— дип уйлады Фатихов.

Ә Баранов үз сүзендә булды һәм кинәт кенә шундый сорау куйды:

— Безнең монда автомобиль заводы төзеләчәге турында беләсез инде сез?

— Беләм, Михаил Иванович.

Баранов ашыккан да сыман, үзенең тавышы күтәренке һәм ышанычлы:

— Бүген автозаводны төзи башлыйбыз. Дөресрәге, автозавод өчен юл төзи башлыйбыз. Беренче путевканы сезгә бирергә булдык. Рәхим итеп алыгыз!

Бу җылы, бу тантаналы сүзләрне ишеткәч, Фәнүс Фатихов бер буйга үсеп киткәндәй булды. Дулкынланудан аның җиңелчә генә башы әйләнеп китте. Ул, начальнигы үз кулы белән биргән путевканы кулына алгач, һәр икесенә дә карап әйтте:

— Ышанычыгыз өчен рәхмәт!

Шул гына булмады, кабинетка Михаил Носков белән Гыйният Галиев тә килеп керделәр.

Шушы өч кешедән торган беренче экипаж тиздән куагалып та китте.

Киң кыр.

Офык читләре зәп-зәңгәр.

Талгын гына салкынча җил исә.

Иң алдан Фатихов машинасы киң күкрәге белән һаваны ярып бара. Аның артыннан тимер аркан белән беренче машинага тагылган Галиев машинасы. Бу ике куәтле машина треллерга (тагылма арба) салынган Носков экскаваторын тартып баралар. Җир нык туңган булуга да карамастан, машиналар артында тәгәрмәчләр эзе кала. Юлда бер генә мәртәбә дә тукталмыйча, автозавод салыначак урынга килеп тә җиттеләр. Экскаваторны треллердан төшерергә күп вакыт узмады.

Кырдагы сөрелгән тип-тигез җир өстендә бәс аклыгы, кырау төшкән кебек. Уң якта урман каралып ята. Шул урыннан өлле ни ерак түгел Кама киңлекләре җәелә.

Тезелеш җитәкчеләре дә шунда кайнашалар. «Спецстрой» начальнигы Валентин Прокофьевич Борисов, урта гәүдәле, кысыграк күзле, тиз-тиз йөрүчән кеше, эшне ничек башлап җибәрергә кирәклеген әйткәч, сүзен төйнәде:

— Егетләр, аякларыгыз җиңел булсын! Башланды!

Шул сүзләр әйтелүгә, моторлар гөрелтесе көчәя барды. Геодезистлар утырткан казыкларга карап, бульдозерлар юл сызып киттеләр. Алар артыннан Носков идарәсендәге экскаватор җир йомшарткыч җайланмаларын ходка җибәрде. Җир яхшы ук тирән каткан булса да, куәтле җайланмага әллә ни каршылык күрсәтә алмады. Йомшарган җир күзгә күренеп үсә барды. Менә, ниһаять, автомашиналарга төярлек балчык өеме дә күзгә күренеп үсеп чыкты. Шунда инде, экскаватор чүмече астына беренче булып Фәнүс Фатихов машинасы килеп керде. Менә беренче чүмеч вакланган, йомшартылган туң балчык унике тонна сыйдырышлы кузовка дөперт итеп төшеп тә утырды. Аннан бер-бер артлы икенчесе, өченчесе, дүртенчесе... Машина тиз тулды.

Беренче юл!

Беренче балчык!

Беренче адым!

Фәнүс Фатихов машинасы артык ерак булмаган үзәнлеккә элдерде. Тиздән авыр йөк машинасының кузовы күтәрелеп, автозавод җиреннән алынган беренче балчык салмак кына җиргә бушатылды.

Шуннан башланып китте. Фатихов салган беренче эздән башка машиналар да балчык төяп үзәнлеккә агылдылар.

Кеше күңеле үзе бер дөнья бит ул! Булачак гигант җиреннән беренче балчык алган Фәнүс Фатиховның үз гомерендә әле болай нык дулкынланганы ай-һай булдымы икән! «КРАЗ»ының иркен кабинасында, рульгә кулын салган хәлдә, ул үзен дөньяда иң бәхетле итеп хис кылды. Әлегә машиналар кайнашып, кышкы җилләр сызгырган бу урыннар хәзер үк очы-кырые күренмәгән зур-зур корпуслар, тимербетон пулатлар чуарлаган бер төстә күренделәр аңа. Нинди мәһабәтлек! Башлары күккә тигән торбалардан күксел төтеннәр чыгып тора кебек. Ул үз-үзенә сөйләнеп куйды: «Минем туган якларыма бөтен Союзның күзе төбәлгән. Нинди зур адымнар белән үсә ул. Иге-чиге күренмәгән олы кала, олы завод!..»

Татлы уйларга бирелеп, киләчәкнең зәңгәр күзләренә карап сөйләшә-сөйләшә, Фәнүс, әйтерсең лә, дөньяда һәммәсен дә онытты. Ул гадәти эшләгәндә кулындагы сәгатенә карап-карап ала торган иде. Моны да исеннән чыгарып җибәрде. Вакытның ничек узганын, көннең ничек авышканын да абайламый калды. Бары тик аны алмаштырырга икенче кеше килгәч кенә, ул сменаның бетүен чамалады. Кабинага җәйләп кына кереп утырган юантыграк урта гәүдәле Вәсим Сәйфуллин да үзгәргән кебек:

— Сөен, малай!

— Әйтәсе дә юк!

Тиздән вахта машинасы, автозавод җиренә беренче сукмак салучыларны утыртып, Камгэс поселогына юнәлде.

Әллә ничек кенә шунда иртәнге хисләр һич тә тынычланмадылар, саекмадылар. Фәнүс җиңел адымнар белән квартирына кайтып керде дә аш-су әзерләп йөргән Мәрьямнең нечкә биленнән кочып алды, аны күтәреп, бүлмәне әйләнеп чыкты. Мәрьям аның кулларыннан ычкынырга теләсә дә, булдыра алмады:

— Аю! Җибәр! Исерек дисәң, аракы исе килми, сиңа ни булды?

— Белсәң иде, безнең шундый шатлыклы көн бүген, Мәрьям!

— Тынычлан да, тәртип белән генә сөйлә, пажалысты.

— Беләсеңме, миңа нинди зур ышаныч күрсәттеләр!

Фәнүс, онытылмас көннең хисләрне нечкәрткән, күңелләрне дулаткан якты тәэсирләре турында яңа эздән тукми-чәчми сөйләп биргәч, Мәрьямнең исе-акылы китте. Иренең күңел кайнарлыгы аңа да күчте.

— Шунда мине дә алып барып күрсәт әле.

— Күрсәтермен! Ник күрсәтмәскә.

Һәр көнне эштән кайткач, алар булган яңалыкларны уртаклашалар. Сөйләрлек сүз табылмый калмый. Фәнүс белән эшләүчеләрнең күбесен Мәрьям күреп белмәсә дә, иренең сөйләве буенча таныш ул алар белән. Фәнүс тә шулай ук Мәрьям белән

эшләүчеләрне ишетеп белә. Үз чиратында, Марьям дә яңа йортта эчке эшкәртү-бизәү эшләренең җырлап баруы турында сөйләп чыкты. Ул көнне тәэсирләр шул хәтле мул булды, хәтта кинога барырга да соңга калдылар.

Көннәр йомгагы сүтелә торды.

Төзелеш мәйданында техника көннән-көн зурая барды. Беренче балчык алган җирләргә беренче бетон түшәлде.

Беренче көннәрдән үк өч сменага бүленеп эшлиләр иде. Бер көнне Фәнүсне алмаштырырга тиешле Вәсим Сәйфуллин сменага килмәде. Ул авырый икән. Бүтән кеше юк. Нишләргә?

Фәнүс, автохуҗалык җитәкчеләренең тәкъдимнәрен көтеп тормастан, шул көнне икенче сменада да эшләргә калды. Мондый хәл биш көн кабатланды. Биш көн дәвамында таза гәүдәле, киң җилкәле, тыныч карашлы, сабыр холыклы Фәнүс, ару-талуны белмичә, эчке бер ялкын, эчке бер ашкыну һәм зур теләк белән авыру иптәшен алмаштырды.

Әйе, әле күптән түгел генә «борынлап чыккан» юл төзелеше үсә бара. Йөзләгән яшьләр арасында Фәнүс Фатихов та үзенең куәтле «КРАЗ»ын иярләгән хәлдә, төзелеш офыгын киңәйтү өчен тартыш алып бара, алгы сызыктан бер генә адым да чигенми.

Шушы тыйнак һәм бер күрүдә истә кала торган кеше белән сөйләшкәндә үзеңне яшәреп киткән кебек тоясың. Андыйлар башкалар күңеленә дә дәрт сала.

Мин аңа сораулар бирдем:

— Киләчәк көннәргә планнарың ничек?

— Автозавод салу. Шушында төпләнеп калу.

— Тагы?

— Читтән торып укырга да исәп бар.

— Хезмәт хаклары ничек төшә?

— Ике йөзнең өстендә. Ике йөз илле — өч йөз сумга да сикерәбез.

Фәнүс Фатихов, бүген маңгай тирен түгеп эшләп, тагы да яктырак киләчәккә кыю адымнар белән баручы меңнәрнең берсе. Андый кешеләрнең җилкәләре көчле, чыдамлыклары җитәрлек. Ышанырга була мондый гайрәтле егетләргә, таянырга була аларның иңенә!

* * *

Карлы юеш аягын кага-кага, җирне иңләп, апрель атлый инде. Мин кышкы чиләнең салкын көннәрендә бу тарафларда йөргәндә, иң кырыйдагы биш катлы йорт әле салынып бетеп кенә килә иде. Менә инде аны тәмам җиткергәннәр дә, өске катларга кешеләр күченгәннәр, беренче катта — «Камгэсэнергострой»ның кадрлар бүлеге. Дөрес, кышын да бу беренче катның шактый өлешенә кадрлар бүлеге урнашкан, йортта бер яктан эчке эшкәртү-бизәү эшләре бара, шул вакытта анда чемодан-төенчекләре белән килгән кешеләрне дә кабул итәләр, баш ерып чыга алмаслык ыгы-зыгы иде. Кадрлар бүлегенә койрыкланып чират төзелгән, коридорлар тулы халык. Шау-шу. Мин ул чакта урындагы җитәкчеләр исеменә яхшы ук телле-тешле сүзләр дә ишеттем:

— Аэропорттан шәһәргә әйберләребезне күтәреп килә-килә телләребезне аркылы тешләдек.

— Килүчеләрне нигә бераү дә каршы алмый?

— Урамнарга нигә бер язу да куелмаган?

— Комсомол вәкилләре кайда?

Әйтә китсәң, байтакка җыела иде шундый ризасызлыклар. Күрәсең, урындагы иптәшләр уйларын җитезрәк йөртә башлаганнардыр. Аннары өстән дә азмы-күпме кыздырганнардыр үзләрен, хәзер инде килгән кешеләрне кабул итүдә беренче айлардагы каушап калулар сизелми.

«Камгэсэнергострой» идарәсе башлыгы урынбасары Хәниф Шәйхетдинев кабинетында да кышкы шау-шулар ишетелми. Хәниф Шәйхетдинев — урта буйлы, калын

жилкәле, чыраенда әлмаю сызыклары сирәк сүрелә торган урта яшьләрдәге кеше — көр тавыш белән сөйләшә. Сөйләшерлек тә шул! Аның җитәкчелегендәге кадрлар бүлеге шушы сизелмичә генә үткән тынгысыз айлар эчендә ничә мең кешене кабул иткән, эшкә урнаштырган. Шәйхетдинев белән сөйләшеп китәбез:

— Кәефләр ничек, Хәниф туган?

— Язгы көннәр кебек.

Автомобиль заводында эшләргә килүче хәзер кышкы уңайсызлыкларның берсен дә татымый. Аэропортка килеп төшүчеләрне махсус билгеләнгән автобус каршылый. Шушы ук кадрлар бүлеге урнашкан бинада медосмотр үтү өчен врач кабинеты бар. Паспорт өстәле эшли. Әйберләрне саклау бүлмәсе дә бик уңайлы. Теләгән кеше менә дигән кызыл почмакта газета-журналлар укый ала, теләсә шашка-шахмат уйный. Кыскасы, кеше ерактанмы-якыннанмы килгән — аңа каш җыерып утырырга туры килми. Буфеты да, ашханә дә шунда янәшә генә.

Шәйхетдинев белән икәү ишегенә «Хатлар бүлеге» дип язылган бүлмәгә керәбез. Дүрт өстәл. Аларның һәрберсендә хатлар... хатлар... Хәниф Шәйхетдинев өстәл артында утыручы хатын-кызлар белән таныштыра мине. Алар арасында бүлек мөдире Валентина Петрова башкалардан беркадәр өлкәнрәк. Ә инде Ирина Павлухина, Лидия Нестерова һәм Зинаида Семенюк — һәммәсе дә яшь хатын-кызлар. Алар, күтәрелеп тә карамыйча, зур илебезнең төрле урыннарыннан килгән хатларны укыйлар, аларга җаваплар язалар. Бу кичкенә эш түгел. Январьдан алып, шушы көнгә кадәр автозавод төзелешенә эш шартларын сорашып яки үзләренең килергә теләүләрен әйтеп, уналты мең кешедән хат килгән.

— Хатларга җавап бирергә житешәсезме?

— Бер хатның да җавапсыз калганы юк,— ди Шәйхетдинев. Аннары ул бер кадәр сүзсез торгач, янә өсти:— һәр хат артында тере кеше тора. Без әнә шул фактны бик нык искә алып эш итәбез.

— Көненә ничәшәр хат аласыз?

— Уртача ике йөз илле.

— Ә килүчеләр саны?

— Хәзер көн саен 70—80 кеше килә. Болар арасында алдан хат язып хәбәрләшкәннәре дә байтак була.

— Эшкә килүчеләрне квартирларга урнаштыру ничегрәк?

Минем бу соравыма Шәйхетдинев шундук җавап бирергә ашыкмый, бер кадәр көттергәч кенә:

— Әле берәүнең дә урамда калганы юк. Әллә ничә мең кешене тулай торакларга, квартирларга үзебезнең шушы Чаллыга урнаштырдык. һич тә яшерен түгел, квартир мәсьәләсе кыен. Тирә-як авылларда да тора безнең төзүчеләр,— ди. Аннары, сүзен дәвам итеп, төзелешкә гаиләләре белән килүчеләрне әлегә кабул итә алмауларын, ялгызакларны эшкә беренче чиратта алуларын әйтә.

Әмма кеше һәммәсен дә үз кулы белән эшли, үзе барлыкка китерә, үзе тудыра. Торак төзелеше мәйданының бик нык арта баруы куанычны арттыра, ышанычны ныгыта.

— Кайлардан килә халык?

— Бөтен җирдән дә,— ди Шәйхетдинев,— Ерак Көнчыгыштан да, Урта Азиядән дә, Себердән дә, үзебезнең республика кешеләре дә күп. Килүчеләр арасында иң зур күпчелек татарлар да руслар. Башка милләт кешеләре дә хәтсез генә. Безнең төзелештә бүгенгесе көндә 23 милләт вәкилләре кулга-кул тотынып эшлиләр.

Биредә өлкән яшьтәге кешеләрне бик сирәк күрәсең. Шуңа күрә бөтенсоюз комсомол-яшьләр удар төзелеше дип атала да инде ул. Әле тормышта бик кыска юллар үткән, тәҗрибәләре дә аз булган яшьләрнең һөнәр яклары да сайрактыр. Шул турыда сорагач, Шәйхетдинев болай ди:

— һөнәрләре булмаганнарга яңа һөнәр өйрәтү өчен безнең уку комбинаты бар. Анда яшь егетләр һәм кызлар эшләп тә, кирәк булганда эштән аерылып та укыйлар.

Кыскасы, теләге булган һәр яшь кеше төзүче профессиясенең һәр төрен рәхәтләнеп үзләштерә, өйрәнә ала монда.

* * *

Язгы иртә.

Бер ягы белән яшь наратларга караган «Спецстрой» идарәсе конторасында утырабыз. Сүз «Спецстрой» коллективының юбилейләр елына алган йөкләмәләрен үтәве турында бара. Бу коллектив автозавод төзелешендә бик авыр йөкләрне тартып баручыларның бер куәтле звеносы икән. Башкарган эшләре дә берәгәйле, саллы.

— Бер миллион ике йөз сиксән дүрт мең кубометр балчык чыгардык,— ди идарә башлыгы В. П. Борисов.

— Димәк, йөкләмәләрегезне үтәдегез?

— Үтәдек. Ләкин без башкарган эшләр аның белән генә чикләнми. Юллар салу, вертикаль планировка...

Әйтергә генә ансат, бер миллион ике йөз мең кубометр. Ә тирәнрәк уйлап карасаң, шушындый олы күләмдәге эшне башкару өчен ни хәтле техника катнашкан, ни хәтле кешеләр маңгай тирләрен түгеп эшләгәннәр. Ни хәтле кичерешләр, тартышлар артта калган! Образлы гына итеп әйткәндә, кешеләр әлеге шул катлаулы, баһадир техниканы иярләп, зур бер тауны тигезләгәннәр яки икенче урынга күчергәннәр...

— Валентин Прокофьевич, әйтсәгез икән, иң якын араларда сезнең алда нинди эшләр тора?

Чандыр гәүдәле, башта телгә алып үткәнебезчә, кысыграк күзле бу кеше, тегеңбу санны телгә алырга кирәк булса, план-мәгълүматлар эзләп азапланмый. Хәтере нык, ул бик күбесен исендә тота.

— Якын арада ремонт-төзелеш заводына мәйдан әзерләргә керешәбез. Моның өчен бер миллион җиде йөз мең кубометр балчык чыгарырга тиеш булабыз.

Бу саннарны ишетүгә, минем күз алдыма тагы зур гына тау калкып чыккандай булды.

— Сездә саннар бик зур! Миллионлап кына...

— Төзелеше дә илдәге иң зур төзелеш бит аның,— ди Борисов.

— Бу сез әйткән завод өчен мәйдан әзерләү ничә айга тартылыр?

— Кимендә биш айга. Әйе, алда очсыз-кырыйсыз эшләр тора безнең: мазут хуҗалыгы һәм электростанциянең төп корпусы өчен урын әзерләү; төзелеш индустриясе базасы өчен мәйдан әзерләү... Беләсезме, күпме балчык чыгарырга кирәк булачак анда? Өч миллион кубометр!

— Бу эшкә кайчан тотынасыз?

— Алдагы кварталда.

Бу саннарны, бу планнарны тыңлаганда, тыныч кына утырып булмый. Югыйсә бит, инде мин дә дөньяны күргән кеше. Өч миллион кубометр!..

Бу хәтле балчыкны кая куеп бетерерләр? Аннары ул балчыкның бик күп өлешендә игеннәр, үләннәр үскән, агачлар тамыр җәйгән бит әле. Әйбәт туфрак әрәм була дигән сүзем монысы. Шул турыдагы кызыксынып соравыма каршы Борисов болай дип җавап бирде:

— Урын табылыр анысы. Ә менә балчыкның өске катламын без аерым урынга ташыйбыз. Соңыннан аны шәһәрдә чәчәк түтәлләре, газоннар, бакчалар утырту өчен файдаланачаклар. Безнең шәһәребез яшеллек эчендә, чәчәкләр эчендә булачак.

Валентин Борисов кырык өч яшьлек кеше. Үз яшендәге бик күпләргә хас булганча, ул йөкнең авырын төпкә җигелеп тарта. Анысы шулай. Безнең Борисовыбыз нинди милләт кешесе икән соң? Сөйләшүенә карганда, ул рус булырга тиеш. Ә үзе тәсе-бите белән, хәер, кысыграк күзләре зәңгәр булсалар да, әллә ничек менә шунда рус кешесе сыман түгел дә. Минем бу турыдагы соравыма каршы ул тыныч кына әйтеп салды:

— Минем әти якут, әнием рус.

— Димәк, сез Якутиядән?

— Әйе, туган җирем! Озак еллар тордым анда.

Борисовның тормыш юлы катлаулы түгел: уку, солдат хезмәте. Ниһаять, үзенең бар язмышын төзелешләр белән бәйләү. Ул Иркутск һәм Братск төзелешләрендә катнашкан. Ул «Камгэсэнергострой»да алтмыш дүртенче елдан — прораб, участок начальнигы, хәзер инде менә хәтсез зур «Спецстрой» идарәсе житәкчесе.

Безгә Борисов белән озаклап сөйләшергә туры килмәде. Аны үзеннән дә өстен-

рәк торган «Камгэсэнергострой» идарәсенә чакыртып алдылар. Юлдашым — «Социалистик Татарстан» газетасының үз хәбәрчесе Хәмит Мөхәмматшиннең бу хәлгә бер кадәр каефе җимерелсә дә, нишлисең? Эш—эш инде ул. Үз хәбәрче дигәннән, Хәмит Мөхәмматшин дә әле яңа кеше бу төзелештә. Моңарчы гел авыл районнарында эшләп, колхозчылар, басулар, борчак һәм кукурузлар турында язып йөргән бу иптәшкә монда һәр күренеш яңа, һәрберсе кызыксындыра аны. Тышкы кыяфәтенә, гадилегенә карап, кайбер участокларда аны «яңа мастер» яки «яңа бригадир» дип тә каршы алалар.

«Спецстрой»ның баш инженеры Линар Фәхриев «газ»игына утырып, шәһәр урамнары буйлап барабыз. Чаллы урамнары бер-бер артлы артта калалар. «Моннан водовод үтәчәк. Бу төшләрдән трамвайлар узачак. Ә тегендә затон булачак»,— дип сөйләп бара Линар Фәхриев. Без аның үзе үткән тормыш юлы белән дә кызыксындык. Линар Фәхриев әле яшь кеше. Нибары утыз дүрттә ул. Казан төзүче инженерлар институтын тәмамлагач, җиң сызганып эшкә тотынган. Унынчы ел эшли. Автомобиль заводы төзелешенә килгәнче, Әлмәттә төзү-монтаж идарәсе башлыгы булып эшләгән. Узган елның декабрь аеннан бирле монда. Әлегә ул да, бик күпләр кебек, вакытлыча тулай торакка урнашкан. Линар Фәхриев — урта гәүдәле, тез борынлы, зәңгәр күзле, саргылт чәчле. Сүзнең тәмен белеп кенә сөйләшә.

Язгы юл өзек чаклар. Үзбушаткычлар, тракторлар, бульдозерлар йөри-йөри казылып беткән сикәлтәле юллардан үрле-кырлы сикерә-талпына барып, «газ»игыбыз безне иң беренче салына башлаган бетон юлга алып чыкты. Әрсез, күндәм «газ»иктан төшкәч, Линар Фәхриев тирә-якка карашын ташлады.

— Күренми ул.

— Кайда булыр икән?

— Борчылмагыз, ары баштарак булыр. Бу төшләрдә аннан аерылып чыккан бригада. Комсомол-яшьләр бригадасы.

Бригадир Виктор Шатунов үзе дә яшь егет. Моңа тикле звено башлыгы булган. Юлның бу өлешендә егетләр һәм кызлар тышламалары алынган араларга бетон коялар иде.

Төзелештә мондый «корт иле аерган» бригадалар байтак икән. Аның сере тик бары шунда гына: яңа кешеләр килә тора, өстәлә тора. Бер кадәр вакытлар үткәч, ике бригада ясарга туры килә.

Юлның Минзәлә ягына таба сузылган икенче башына юнәлдек.

Күктә тургайлар!

Киң кырларның аерылмас дуслары, авыр кышларны уздырып, үзләре йомыркадан борын төртеп чыккан газиз туфракка исән-имин кайту куанычларын кешеләр белән уртаклашырга телиләрдер төсле. Тургайлар шундый ярсып, шашып сайрыйлар, күңел хисләрен шундый оста кузгатып, сине үзләренә ияртәләр, ихтыярсыздан синең йөрәгең дә алар белән бергә сайрый, бергә җырлый!..

Инде Мансур Бәһаветдинов белән дә күрештек. Автомобиль заводына иң беренчеләрдән булып юл салырга керешкән һәм мәңге тын яткан басу күкрәгенә беренче бетон түшәгән, газета һәм радио хәбәрләре аша таныш булган бу яшь ир — төскәбиткә чандыррак кына, куе коңгырт чәчле, ачык чырайлы кеше. Аның белән берничә сүз алышырга өлгерә алмадык, якындагы мотор гөрелтесен дә, тургай тавышларын да күмеп, матур, моңлы җыр ишетелде һәм көчәя барды. Сүзләрен баштарак аеруы кыен булса да, күңелгә якын бу җыр, бу таныш моңнар йөрәккә тирәнрәк үтеп керә барды:

> Хәтердә ул тыныч, айлы кичләр,
> Хәтердә бормалы су юлы.
> Онытылмый беренче саф мәхәббәт,
> Онытылмый Агыйдел сылуы.
> ....Акчарлаклар очып уйный
> Актаныш күлләрендә.
> Ул гына яши елмаеп
> Күңелем түрләрендә.
> Актаныш таңнары...
> Ул минем йөрәк серемне аңлармы!

Әле узган ел гына иген чәчелгән, күптән түгел салам эскертләре алынган, бүген зур төзелеш барган киң басуда ишетелгән бу җырлар, әллә ничек шунда минем дә яшьлек елларымны искә төшерде.

Үзләре күренмиләр, тавыш якында гына сыман, кемнәр җырлый икән?

Минем бу соравыма Мансур Баһаветдинов тыныч кына җавап кайтарды:

— Алар безнекеләр,— диде.

Мансур үзе шушы районның Бигеш авылы кешесе. Утыз җиденче яше белән бара. Солдат хезмәтен тутырып кайткач, туган колхозында һәм районара төзү оешмасында берничә ел балта остасы булып эшләгән. Аннары «Камгэсэнергострой»га күчкән. Хәзер инде бригадирлык йөген тарта. Бригадир булып, тулы бер буын коллективны җитәкләп бару өчен күп төрле эшләрнең рәтен белергә кирәк. Мәктәптә җиде класс белем алганнан соң, Мансур Баһаветдинов балта остасы, ташчы, штукатурчы, бетончы, түбә ябучы кебек дистәгә якын һөнәргә өйрәнгән. Әнә шулай һәммәсенең рәтен белеп эшләгәч, аңа читен түгел. Кешеләр өчен дә әйбәт. Һөнәре булмаган яшьләрне җае-рәте белән генә ул үзе өйрәтә.

Хәзер менә без басып, сөйләшеп торган әллә ничә километрга сузылган юл бу төшләргә үзеннән-үзе генә әкияттәге сыман калкып чыкмаган бит. Аны салуга ни кадәр тынгысыз хезмәт кергән, борчылу-көенүләр кергән! Юлга бетон калын салынган. Нинди генә авыр машиналар булмасын, аларның үз өстеннән үтүләрен сизмәячәк тә бу юл.

* * *

...Ул үзе Нөркәй авылында (Сарман районы) туган булса да, әтисе Чаллы МТСына эшкә күчеп, шунда төпләнеп калганнар. Кара күзле, тере карашлы, җитез хәрәкәтле, тиктормас Марат кышын мәктәптә укып, җәйләрен Кама буйларында кармак салып, балык тотып, табигать куенында үзенең үсмер чакларын уздырган.

Еллар үтә торалар. Ниһаять, Марат Бибишев урта мәктәпне тәмамлый. Аннан Казан төзүче инженерлар институты артта кала. Төньякта, Якутиядә эшләү. Яңадан туган якларга кайту, Әлмәт, Яңа Зәй, Алабуга, ниһаять, бу борылмалы тормыш юллары аны Чаллыда барган зур төзелешләргә китерәләр.

Хәзер инде Марат Бибишев кырыгынчы яше белән бара. Ир уртасы яшендәге бу кешенең чәчләренә иртәрәк ак кунган, әмма күзләре тере, чырае яшь аның. Исәпүйлар ир кешенең чәчләренә иртә «кырау» төшерә, диләр бугай әле. Дистә еллардан артык төрле төзү-монтаж оешмаларында җитәкчелек итү, тынгысыз хезмәт, үзенең дә каударлыгы, төрле кичереш-пошынулар шулай тәэсир иткәннәрдер аңа да. Хәер, мондый үзгәрешләр төрле кешедә төрлечә була.

Марат Бибишев автомобиль заводы эшчеләре өчен торак йортлар, культура-көнкүреш бинаалары төзүче «Жилстрой» тресты идарәсенең башлыгы булып эшли. Аңа мәшәкатьләр, борчылулар җитәрлек. Аның эш көне бик иртә башлана. Эшчеләр иртәнге җидедә эшкә тотынганчы ук, Бибишев теге яки бу участокка килеп җитә. Күбесенчә кичке җиде-сигезләрсез квартирына да кайта алмый. Аның кебек зур җаваплы кешегә шунсыз һич мөмкин түгел.

— Кәефләр ничек, Марат туган,— дип сорыйм мин.

— Безнең кәефләр планны ничек үтәүгә бәйләнгән. Планны үтәсәк — шәп. Үтәмәсәк...

— Сезне болай зур киңәшмәләрдә мактап телгә алалар.

— Уя тиклесе дә планга кайтып кала.

— Ничек соң?

— Сынатмыйбыз шикелле.

— Беренче кварталда хәлләр ничегрәк килеп чыкты?

— Квартал планын үтәдек.

— Җиңел булмагандыр, билгеле.

— Дөрес. Торак төзелеше планы узган елга караганда биш тапкыр артык бит. Йөз мең квадрат метр! Автомобиль заводы төзү барыннан да элек безнең ничек эшләвебезгә бәйле. Материаллар ташырга, йөрергә юллар кирәкме? Кирәк. Эшчеләргә торак кирәкме? Кирәк. Без башкарасы эшләрнең очы-кырые юк...

Ничә җирдә зур-зур йортлар күтәрелде, культура-көнкүреш биналары үсә, ничә йортта эчке эшкәртү, бизәү алып барыла. Һәр көн саен, һәркайсын кимендә бер кат күздән кичереп чыгарга кирәк. Ул барысыннан да күбрәк күрергә тиеш. Марат Бибишевның өстендә җиңелчә җәйге пальто, башында фуражка, аякларында озын кунычлы кирза итекләр. Ул оча гына, артыннан һич житешә торган түгел. Мене әле, кино-театр бинасына килеп кергәч тә, бер-ике сүз алышу белән, мин аны күздән югалттым. Карасам, каяндыр астан тавыш ишетелә:

— Нигә ут юк?

— Белмибез,— диләр кайсылардыр.

— Электрик ни карый, прораб?..

...Мин иркен залда икесе янәшә эшләүче Виктор Нестеров һәм Альберт Хәбибуллиннар белән танышып алдым. Егетләр стенага вак кына дүрткел плитәләр — мозаика түшиләр иде. Бу нечкә һәм игътибар таләп итә торган эшнең рәтен белүләре әллә кайдан сизелеп тора. Эшнең башкарылган тиклесе үзенең төсе, рәвеше белән күрер күзгә ял биреп тора. Шул ук залда Мәскәүдән килгән рәссам Арнольд Макутонен колонна-баганаларның берсен шул мозаикалау ысулы белән бизи. Ул эскизларны да үзе яза, үзе бизи дә. Колонна-баганалар төрле төстәге кирәч белән генә бизәлеп калмыйлар, татар милли орнаменты, түйга чиккән кыз сөлгесе кебек, сине үзенә тартып тора.

Бер урында гаять киң мәйдан biләгән бинаның беренче каты күтәрелеп килүен күреп, сорамый булдыра алмадым:

— Бу нинди йорт тагы?

— Ул безнең культура сарае булачак.

— Кайчан салып бетерәсез?

— Җитмеш беренче елда аның ишекләрен ачып керербез дип торабыз инде.

Бишәр катлы бернечә тулай торак салына. Шуларның берсенә вакытында измә китерелмәү сәбәпле, кешеләр ярты сәгатьтән артык тик торырга мәҗбүр булганнар. Бу хәлгә Марат Бибишев ифрат борчылып, өлкән прораб белән яхшы ук тозлы-борычлы итеп сөйләшкәч тә тиз генә тынычлана алмады. Машинага утырып, без икенче участокларга барганда, ул кабинага куелган рация аша диспетчерлык пунктына хәбәр салды:

— Нишләп измә соңга калып китерелә?

— Кайсы участокта, Марат Шакирович?

— Өченче тулай торакта.

— Анда юллар бик начар. Машина буксовать иткәндер.

— Мин әле генә булдым анда. Юллар йөрешле.

— Тикшерербез,— дигән җавап ирештерде диспетчер Маликов.

— Аннары миңа хәбәр итәрсез. Мондый салкынлык кабатланмасын.

Рация дигәннән, Бибишев аны Удмуртия ягыннан алып кайтып, әле күптән түгел генә куйдырган. Бу бик җайлы. Трест башлыгы рация ярдәмендә үзенә кирәкле объект белән һәр чак элемтәгә керә ала. Контрольлек итү өчен нинди җайлы чара бу.

Зур мәйданда торак төзелеше алып барган бетон заводы поселогына килеп керәбез. Хәзергә ул Чаллыдан өч-дүрт километр читтә. Шәһәр зурая төшкәч, тоташачак. Монда да башка участоклардагы кебек үк бинаһая олы тимер «торналар» — күтәрү краннары муеннарын сузганнар. Аларның күбесе гел йөреп тора. Кайберләрен әле җыярга гына керешкәннәр.

Машинага утырып кайтканда, Бибишев рация трубкасын тагын колагына куйды:

— Диспетчерлык пункты. Маликовмы?

— Тыңлыйм сезне, Марат Шакирович.

— Башлап үзең әйт әле, Маликов.

— Измә ташудагы өзеклек ялганды. Гаеп шоферда. Рапорт язылыр.

— Тагы?

— Икенче участокта газ трубалары җитми...

— Кызыл карандаш белән яз. Иртәгә күрсәтерсең.

— Сантехника материаллары да аз.

— Шулай ук кызыл карандаш белән яз... Иртәгә иртүк шул мәсьәләләрне хәл кылырга тырышырбыз. Булдымы? Булса, хәзер мине тыңла. Специальлашкан идарә начальниклары, участок начальниклары, инженерлар һәм прораблар бүген кичке алтыга минем кабинетка җыелсыннар. Әйе. Сүз җаваплылык хисе һәм сыйфат турында барачак. Сүз куештыкмы?

— Куештык, начальник.

* * *

Төн...

Утлар...

Утлар....

Һәр үсеп килүче, һәр калкынучы йорт үзенә бер йолдыз булып балкый. Төннәр кайдыр, басулар киңлегенә чигенә. Машиналар, моторлар гөрелтесе бер генә минутка да тукталмый.

Бу якларның якын киләчәге гаять зур, гаять өметле. Быел нигездә бишәр катлы йортлар салына. Шулар белән бер рәттән тугызар катлы өч тулай торак бинасы да калка башлар. Ул гынамы соң? Уникешәр катлы дүрт йортка нигез салырга җыеналар. Ул йортларның берсе быел ук өлгерергә тиеш. Бу башлары күккә тиярдәй биек биналарның детальләре Мәскәү һәм Тольятти шәһәрләреннән кила дә башлаган инде. Биек йортлар монтажлаячак яшь эшчеләрнең бер төркеме Мәскәүдә укый, өйрәнә.

Бик киң, бик дәү ул Чаллы офыклары, бик өметле ул бу якларның таңнары!

*Чаллы, апрель, 1970 ел.*

Шәүкәт Галиев

# ГРАЖДАНИН НӘНИ БУЛАМЫ, ЯКИ 437 СОРАУГА ҖАВАП ТУРЫНДА

## «КЫЗЫКЛЫ ИТЕП ЯЗАРГА КИРӘК!»

Соңгы еллар балалар поэзиясе турында сүз барганда, аңа яңарыш китергән сыйфат итеп, мөгаен, юмор жанрының үсеп китүен, формалары баеп, төсмерләре төрләнә баруын әйтергә туры килер. Әйе, соңгы елларда тапкыр һәм кызык язылган әсәрләр өстенлек итә. Бари Рәхмәт, Әхмәт Фәйзиләр традициясенең тагын да үсүе, киңрәк таралуы, балалар поэзиясенең перспективалы дөрес үсеш юлына чыгуы бу. М. Горький куйган төп бурычларның берсе дә шул бит. «Балалар өчен кызыклы итеп язарга кирәк!» дигән иде ул.

Әлбәттә, кызык өчен кызык язу турында сүз бармый. Баланы җәлеп иткән, аның күңелен яулап алган шаян сүз эчендә рухи витамин булсын. Юмор һәм сатира үзенә күрә профилактика ул — хәзер никадәр нәтиҗәлерәк эшләсәк, җәмгыятьнең бер әгъзасы булачак шәхестә төрле «чирләр» шулкадәр азрак булыр. Гражданин рухи нык һәм сәламәт булып үссен өчен, аны төрле «йогышлы микроблардан» сакларга, алардан арынырга булышырга кирәк.

Юмор һәм сатира — бик үтемле жанр. Чуковский, Маршак, Михалковларның киң танылуының, балаларның рухи дөньясына зур тәэсиренең сере шунда. Андый әсәрләрне укып бала тормышка актив мөнәсәбәттә булырга, начарны яхшыдан аерырга өйрәнә, үзендә принципиальлек сыйфатларын үстерә.

Бу жанрда уңышлы әсәрләрнең берсе итеп өлкән шагыйребез Хәсән Туфанның «Юкмыш бабай малае»н күрсәтер идем. Әкият балаларның гадәт-холкын бөтен нечкәлекләре белән белеп, шуны гаҗәеп табигыйлек белән хәрәкәттә күрсәтеп язылган. Монда күңелне кытыклардай серлелек тә, маҗаралар да, адым саен көткән сынаулар да бар. Әкиятнең теле шулкадәр табигый — укучыны, әлеге торна кебек, әкият дөньясыннан очыртып кына бара. Ә «хәйләкәр» Туфан төрле маҗаралар арасында, сиздермичә генә, Бәлкәй атлы малайның нинди намуслы икәнлегенә ишарәләп, нарасый күңеленә намуслылык өчен горурлану салып куя. Бу әсәрдә өйрәнер нәрсәләр күп. Балалар белән нәкъ менә шушы дәрәҗәдә сөйләшергә кирәк.

Әкият, димәктән, «Юк, әкият сөйләмим, алдарга да теләмим», дип башлый И. Юзеев «Пони малае нәни җирәнкәй» турындагы кыйссаны. Беренче юлларында ук мавыктырып, ияртеп алып китә. Җәнлекләр дөньясына сәяхәт ясауның оста алымы табылган. Укучы, экскурсия кылып, дөнья белән танышып йөрим дип башына да китермидер, аның кеше кайгысына үтә сизгер күңеле Пони малаеның язмышын кай-

гырта. Чыннан да, бер карасаң, кызгандыру дигән нәрсә сизелеп китә сымак, тик хикәяләүдә өстенлек иткән хер аһәң, җорлык, куерган болытлар өстендә кояш барлыгын сиздереп, яктырып тора.

Әсәр балаларны табигать белән таныштыруга багышланганмы? Алай гына түгел, Пони язмышы белән кызыксынып, бала дөньяда социаль тигезсезлек, хаксызлык барлыгын төшенә башлый. Әнә бит, шахтада күмер ташыган Пони күпме нужалар күргән! Кыйнаганнар, имгәткәннәр аны, усал булган хуҗалар.

**Бәхетемне эзләп. Гани,**
**Мин килдем сезнең илгә,—**

ди ул. Минемчә, әсәрнең әһәмияте әнә шунда — зур нәрсәләр турында гади итеп, бала күңеленә үтәрлек итеп сөйли белүдә.

Юмор төрле авторда үзен төрлечә сиздерә, төрлесендә төрле микъдарда. Әмма уртаклык шунда — шагыйрьнең аһәңен һәм шигъри телен, хикәяләвен ихлас иткән сыйфат ул. З. Туфайлова шигырьләрен рәхәтләнеп укыйсың, алар шатландыралар, тормышчан табигыйлекләре, гадилекләре белән күңелне җылыталар. Автор балалар психологиясен яхшы белә, алар белән тиңгә-тиң булып сөйләшә. Әсәрләрне үз иттергән, җан керткән сыйфатларның берсе әнә шул — юмор. Үзенең барлыгын да әллә ни белдерми кебек, әмма шигырьгә тәм биреп тора.

Гел җитди генә язган шагыйрьләрнең дә, балаларга багышлагач, күңелләрендә посып яткан шуклыклары ачылып китә. М. Шабаевның «Гомерлек бәйрәм» җыентыгында ул сыйфат, я гыйбрәтле бер мәзәк булып, я тел көрмәкләндергеч булып ялтырап куя («Текә тауда», «Биш мәченең биш башы»). Р. Мингалимов, Р. Вәлиева җыентыкларында да мәктәп балалары тормышыннан алып язылган тапкыр чишелешле шигырьләр бар.

Балалар шигъриятендәге бер вакыйга турында аерым әйтәсе килә. Сүз Нәкый ага Исәнбәтнең «Балалар шатлана» китабы турында бара. Татар баласының йөз еллар буе иҗат иткән алмазы һәм гәүһәрләре — җырлы-сүзле уеннары, такмак-такмазалары, санамышлары тупланган анда. Без бу китапны укып, такмазаларын ятлап үстек, ул бала чагыбызның кызыклы бер бәйрәме булып истә калды. Инде тылсымлы бу китапны кулына алган хәзерге буын күңелендә дә шигъри хис уянмый калмас, сүзне тоярга, бетмәс-төкәнмәс яшерен байлыгын ачарга өйрәтер ул, күңелләрен баерак, тормышларын кызыграк итәр.

Фольклор үрнәкләре шигъри тәрбиянең беренче һәм бик үтемле чарасы. Аерым алганда, юмор хисен тәрбияләү мәктәптә ничек дәвам иттерелә соң? Дәреслекләргә махсус тукталасы булганлыктан, бу урында шул ягына кагылырга уйлыйм.

Балалар табигатьләре белән һәрвакыт шаян, тапкыр һәм җор, әсәрләрдә дә нисбәт юмор ягына шактый тартып тора дидек. Ә хәзерге дәреслекләр шулкадәр коры, шулкадәр җитдиләр — пионерлар өчен түгел, акыл иясе пенсионер абзыйлар өчен язылган диярсең. Бу яктан без бәхетлерәк булганбыз икән. Ул чактагы дәреслекләрдә шаян рәсемнәр дә, мәзәк шигырьләр дә шактый иде. Аларның берсе дә буш көлке булмаган. Көлү белән бала үзендәге шундый яклардан баш тарта, үзен андый җитешсезлекләрдән аерып куя.

Кешедә юмор хисе — акыл билгесе, рухи ныклык билгесе, кыенлыклар алдында сыгылмаска ярдәм итә торган асыл сыйфатларның берсе. Бу сыйфат Муса Җәлилгә палач балтасына башын тоткан көе шаян шигырьләр язарга, фашистларның үз оннарендә алардан үтергеч көләргә, дошманнар алдында елмаеп үләргә көч биргән!

Күптән түгел «Смена» журналында атом су асты көймәсе капитаны белән интервью игълан ителде.

«Кешедә нинди сыйфатны сез барыннан да югарырак бәһалыйсыз»? — дигән сорауга, ул:

«Намус, батырлык, юмор хисе»,— дип җавап бирә. Күпне күргән сугышчан командир бу сыйфатны намус, батырлык белән янәшә куеп сөйли! Тирән мәгънә бар монда, гыйбрәтле сүзләр бу. Юмор безнең арсеналда әнә нинди формада да тора икән!

Нисбәтлек теориясен ничек ача алдыгыз, дигән сорауга Эйнштейн: дөньяга балалар күзе белән карау ярдәм итте, дигән. Әйе, олылар тирә-юньне күнегелгән гадәт буенча, төпченүсез, әзер хакыйкать итеп кабул итсә, балалар тормыш күренешләрен яңа баштан үзләре ачыш ясап, үзләренчә бәяләп үсәләр. Галимнәр санап караганнар: 4 яшьтәге бала көнгә уртача 437 сорау бирә икән! Әлбәттә, җавапның байтагы балалар әдәбияты өстенә төшәдер. Мавыктыргыч һәм кызыклы булуы өстенә, әсәрләр тормыш турында мәгълүмат та бирсен, танып-белүгә ярдәм итсен. Күпне белергә омтылган тиктормас балалар белән уртак тел табу өчен, әдип үзе дә дөньяга соклanып карау куәсен югалтмаска, балалар белән бергәттән өр-яңа итеп күрә белергә тиеш!

Бала барысы белән дә кызыксына, аның башында уйлар туа, ул уйлана, фикер йөртә башлый. «Уйлар кирә күңеленә» дип башланган «Беренче уй» шигырендә Р. Мингалимов шул халәтне сурәтли.

С. Сөләйманова да күңел офыклары ачыла барган малайны күреп алган:

> Урамда юллар такыр да,
> Дөньяда төрле хәлләр.
> Кайдадыр сугышлар бара,
> Шуларны уйлый Әнвәр.
>
> («Йолдызлы каеш билдә»)

Әнә шулай, балалар тормышына җирнең хәвефле язмышы килеп керә, традицион тынычлык күгәрчене аңа Вьетнамның утта янган шәһәр-авыллары, ятим балалары турында сөйли (Н. Арсланов. Бала белән күгәрчен).

Күз алдыбызда, турыдан-туры йогынтыбыз астында, киләчәк кешесе — 2000 елларда яшисе шәхес формалаша. Димәк, шактый елларны алдан күрергә, киләчәк дәрәҗәсендә булырдай зәвыкларга нигез салырга тиеш булабыз. Бала чакта алган тәэсирләрдән, тәрбиядән олы кеше җитешә бит. Зур әдәбиятка килүче барлык укучылар да балалар әдәбиятында әзерләнә. Нинди укучылар килүе балалар әдәбиятының бүгенге торышына да бик бәйле.

Әйе, тормыш кинофильм түгел. Монысын карарга ярый, тегесен ярамый, дип балаларны читтә тотып булмый. Тормыш хакыйкатен төшенеп, үзләренең гражданлык карашларын ачыклап, кетлаулы тормышка, актив көрәшкә әзер булып үссен алар. Әсәрләребез белән мөстәкыйль фикер йөртергә, хаклыкларына инанган, карашларын тартынмый әйтерлек һәм яклырлык кешеләр үстерергә булышыйк. Әлегә моңа ирештек дип үк раслап булмый торгандыр. 4 яшьтә көненә 437 сорау биргән бала, мәктәптә очрашулар вакытында, мәсәлән, бер сорау бирергә дә аптырап кала. Я булмаса, кулына язып тоттырган кәгазьдән тотлыга-тотлыга әзер фикерне укый...

Шундый тәэсир кала: балаларга чын тормыш турында сылап-сыйпабрак төшендерергә, җиңеләштереп күрсәтергә тырышабыз кебек. Бәлкем, баланы кыенлыклардан сакларга инстинктив омтылудыр бу. Мөстәкыйль тормышка аяк басып, катлаулы тормыш белән очрашкач аптырабрак калмасмы, күңел кайту кичермәсме ул?

Балалар күңеленә берни өстәми, аңын кузгатмый торган тезмәләр күренгәли тора. Н. Гайсинның «Яңа өйгә күчкәч» дигән сайланмаларын укып чыккач та канәгатьсезлек хисеннән арынып булмый. Асат кына, бик асат кына, уйсыз-дулкынланусыз гына тезеп бара ул юлларны. Шаблон рифмалы строфалар күңелгә кагылмый гына, гел бер көйгә әйләнеп торалар. Тыштан караганда, шигырь бар, ә эчкәрәк керсәң — шигърият юк... М. Фәйзуллинаның биш-алты шигырьдән торган бизәкле китапларын укыганда матур гына тәэсир кала торган иде. Бергә җыеп укыгач, кайбер шигырьләр беркатлырак балаларны күздә тотып язылгандай тәэсир калдыра, «бер күзәнәкле» шигырьләр дә очрый. Г. Латыйпның «Дусларым минем» җыентыгында утызлап шигырь. Күбесе гаргади информация, эстетик кыйммәте, гыйбрәте, табышы, тапкыр ситуациясе юк. Интонациясе, аһәңе, хикәя ителеше табигый булмаганнары бар, балалар турында олылар өчен язылган шигырьләр дә бернича.

Нәкъ менә шушы урында, минемчә, сүзнең очы балалар әдәбияты тәнкыйтенә барып тоташа. Кызыклы һәм гыйбрәтле яңалыклары булган балалар поэзиясенең нинди характерлы якларын күрсәтүе белән мактана ала ул? Рус балалар поэзиясендә, милли әдәбиятларда эчтәлек ягыннан тирәнәю, форма ягыннан гаять төрләнү процессы бара. Шул поэзия дәрәҗәсеннән һич тә ким булмаган, еш кына өйдәп барырлык хәлдә булган әдәбият белгечләре бар аларның. Ирешелгәннәргә иҗади, фәнни анализ ясала, төп үсеш тенденцияләре ачыклана, дөрес перспектива билгеләнә. Әдәбият — тере организм, яңадан-яңа мәсьәләләре әледән-әле туа тора аның. Без дә аерым әдәбият утравында яшәүче Робинзоннар түгел, безнең дә уртак якларыбыз бардыр. Бәлкем без Бөтенсоюз әдәбиятында үтелгән этапны иҗат ачышлары дип күтәреп йөрибездер. Моңача балалар поэзиясенә ниндидер ташлама ясарга тиешле тармак дип карап киленде, чын мәгънәсендә олы таләпләр куймадык шикелле. Ә бит бары зур максатлар гына, зур таләпләр генә зур нәтиҗә тудыра ала. Бер-беребезнең кәефен кырмыйча гына, ирешелгәннәр белән бик канәгать булып яшәргә дә мөмкин. Тик бу үзеңнең көчсезлегеңне тану, әдәбиятларның алгы сафына чыга алмау белән башта ук ризалашу, потенциаль көчләрне эшкә җикмәү булыр иде. Ягъни, чын иҗат булмас иде. Чын иҗат һәрвакытта иң югары биеклекләргә омтылган, иң яхшы үрнәкләр белән ярышырга җөрьәт иткән һәм җиңеп тә чыккан. Үсеш шулай бара. Язучыларга зур таләпләр куябыз икән, бу, бер үк вакытта, укучыларны үстерү турында да кайгырту дигән сүз. Ә бәлкем кемнәргәдер заман дәрәҗәсендә булган тынгысыз, акыллы укучы дәрәҗәсенә күтәрелү дә кирәктер? Үзеннән түбәнрәк икәнеңне сизсә, укучы бит ул аерылышу турында эш кузгатып тормый, ташлый да китә. Өзеп кенә әйтү дә кыен, бездә тәнкыйтьчеләрнең кайсы балалар поэзиясен даими күзәтеп, гомумиләштерүләр ясап, нәтиҗәләр чыгарып бара икән? Мөгаен, юктыр, сизелми.

Балалар әдәбиятына багышланган 1957 елгы киңәшмәдә, әйтик, Н. Юзиевнең балалар әдәбияты тәнкыйте турындагы доклады куелган иде. Ул әле дә актуаль яңгырый, күп проблемалары хәл ителгәнне көтә. Мондый очракларда кабаттан кайтып, үтелешне тикшерү дә зыян итмәс иде.

## «ҮСӘСЕ БАР ШУШЫ ҖИРДӘ ӘНВӘРНЕҢ, ОЧАСЫ БАР ЙОЛДЫЗЛАРГА КАДӘРЛЕ...»

Баланың үй дөньясын, фикер хәрәкәтен, күңелен күрсәтү юмордан бигрәк, лирика өстенә төшсә кирәк. Уенсыз-шаярусыз сөйләшергә тиешле темаларыбыз шактый. Балалар лирикасына бәя биреп житкермәү дөрес булмас.

Берничә ел элек Ш. Маннурның «Нәниләргә, дәүләргә» дигән китабы чыкты. Автор зур мәсьәләләр турында сөйләү өчен ясалмасыз, ихлас аңгәмә ачкычын тапкан. Шигырьләрдә көрәштә үткән данлы елларыбыз героикасы да, сокландыргыч үзгәрешләре белән бүгенге тормышыбыз да чагыла. Балалар дөньясы бөтен төрлелеге белән, белеп сурәтләнгән. Шигырьләрнең сыгылмалы, биеп торган, фольклорга якын теле сөендерә. Шигъри үлчәүләрнең төрлелеге балалар тормышының байлыгын тоярга ярдәм итә. Балаларның үз күңелләренә аваздаш ул шигырьләр.

Бу уңай белән сөер бер хәлгә тукталасы килә. Ни өчен Ш. Маннурны балалар шагыйре дип атаганнарын ишеткәнебез юк? Олылар өчен дә язганга күрәме?.. Әгәр дә ул балалар шагыйре исемен күтәреп йөргән кайберәүләрдән күбрәк тә, нәтиҗәлерәк тә, яхшырак та эшләгән булса?

Бәлкем балалар әдәбиятында эшләүнең әнә шулай игътибарсыз кала килүе ул әсәрләрне ниндидер икенче дәрәҗәдәгеләр итеп карарга урын калдырадыр? Әйтик, И. Юзеев югарыда телгә алынган әсәреннән тыш, балалар өчен җырлар һәм үзенчәлекле бер төркем шигырьләр язды, аны олылар җыентыгында бастырып чыгарды. Шул китаптагы бүтән шигырьләрне күрәләр, ә менә шагыйрь иҗатының кызыклы яңа ягын ачкан өлеге шигырьләрне күрүче юк. Яки Ә. Баяновның «Васыять» дигән драматик поэмасын һәм «Яшь ленинчы» газетасында басылган шигырьләрен кемнең телгә алганы бар? Производствода «материаль кызыксындыру» булса, сәнгатьтә «мораль кызыксындыру» да кирәктер.

Балалар өчен язган һәр «олылар шагыйрен» кызыксынып укыйсың, яңа әсәрләрен көтәсең. Чөнки иҗатта эшләгән сәен яңа яклар ачыла, байый бара бит. Инде язып күрсәткән Р. Фәйзуллин, Г. Рәхимнәр иҗатында да ул тармакның онытылмавын телар идем.

Балалар лирикасына һәр автор үзенчәлекле өлеш кертә.

Ә. Маликов «Таңбатыр» дип атап, нефтьче турында баллада язды. Ул яшь укучының әкият мажаралары белән ияртеп республикабыз тормышында зур урын тоткан хезмәт кешеләренең әкиятләргә тиң эшләре белән таныштырды.

Балалар өчен күләмле әсәрләр аз. Бу тармакта Р. Вәлиеваның дәвамлы эшләвен әйтергә кирәк. Ул тарихи фактка нигезләп «Ильичка хат» поэмасын язды. «Пионерка Гөлназ»да тыныч көннәрдә эшләнгән батырлык турында сөйләнсә, «Канатлы җайдак» поэмасы Советлар Союзы Герое Марат Казейга багышланган. Әйе, балаларны сугыш-сугыш уйнаудан тыярга да, алай уйнаган өчен битәрләп шигырьләр язарга да иртәрәк шул әле. Көрәш аеруча катлауланган киеренке бу заманда, Ш. Маннур сүзләрен искә төшерсәк: «Бар эшкә дә, көрәшкә дә әзер торырбыз!» диярдәй яшьләр кирәк.

Гадәттә, балалар поэзиясе турында сүз барганда, «олылар шагыйрьләренең» язмаулары турында үпкә сүзләре әйтелә иде. Әлбәттә, шагыйрьләр әле җитәрлек эшләмиләр. Әмма, соңгы елларда балалар өчен чын әсәрләрне алар иҗат иткән, поэзиясен алар алып барган. Үпкә сүзләрен бу юлы балалар шагыйрьләренең үзләренә юнәлтергә туры килә. Мине дөрес аңласыннар, шагыйрьләрне ике төркемгә аерып каршы куярга җыенмыйм. Киресенчә, нәкъ менә бүлмәү ягында торам. Балалар поэзиясе өчен барлык шагыйрьләр дә бер дәрәҗәдә җавап бирәләр, барысыннан да бертигез сорала. Тик балалар әдәбиятында шактый эшләгән авторларның пассивлыгы күзгә ташланып тора икән, моны күрмәмешкә салышу дөрес булмас.

Картина нинди рәк соң?

Җ. Тәрҗеманов балалар поэзиясендә эшләгән еллары турында 1966 елда мемуарлар чыгарды («Ян, йолдызым, ян!»), бер-бер артлы проза китаплары бирде. Яңа шигырьләре күренмәде.

Ә. Бикчәнтәева 1963 елда чыккан сайланмаларын яңадан сайлап 1968 елны тагын бер кат чыгарды. Яңа шигырьләре сирәк күренде.

М. Фәйзуллинаның соңгы елларда яңа китабы күренмәде. Яңа шигырьләре сирәк булды.

Н. Гайсинның сайланмалары турында алдарак сүз булды. Яңа шигырьләре сирәк күренде.

Г. Латыйпның былтыргы «Дусларым минем» дигән җыентыгын әйттек. Яңа шигырьләре сирәк күренде.

С. Шакирның китабы да, шигырьләре дә күренмәде.

Балалар поэзиясенә яңадан-яңа көчләр өстәлә торырга тиеш. Күнегелгән профессиональ гадәт буенча, тәҗрибә җимеше генә булган салкын шигырьләр санын үрчетүче авторлар урынына яңа каләмнәр килергә тиеш. Яңа исемнәр, яңа күңелләр, еш кына, ярыш алып килүчән булалар. Ә балалар поэзиясе яңа төсмерләр исәбенә байый торырга тиеш. Бала үсә, аның ихтыяҗлары да, таләпләре дә үсә. Лирикабызда шул туктаусыз үсүче баланың күңеле булсын. С. Сөләймановага кушылып әйтсәк:

Үсәсе бар шушы җирдә Әнвәрнең,
Очасы бар йолдызларга кадәрле...

(«Тәпи баскан җир»)

## ҖЫРНЫҢ ЕРТЫГЫ БАР...

Музыка сәнгатебездә шатланырлык үзгәрешләр бар. Музыка мәктәпләренә йөреп белем алу көнкүрешкә кереп, табигый бер хәл булып китте. Нәни куллар хәзер дөнья музыка культурасы үрнәкләренә үрелә. Мәшһүр әсәрләр белән таныш балаларыбыз өчен без нинди җырлар иҗат итәбез?

Соңгы елларда нәшрият ноталар белән бастырып чыгарган кайбер җыр җыентыкларын күздән кичердем. Алар шактый. Композиторларыбыз балаларны онытмыйлар

икән. Җырларның музыкаль ягына кагылмастан (анысы белгечләр эше), текстлары турында берничә сүз әйтмәкче булам. Композиторларның, беренче чиратта, заман сынавын үткән, шигъриятнең алтын фондына кергән шигырьләргә җыр канатлары куючылары сөендерә: Тукай, Дәрдмәнд, Такташ, М. Җәлил, Н. Исәнбәт, С. Хәким, Б. Рәхмәт исемнәре очрый. Әмма олылар өчен язылган җыр текстларына булган талымсызлык балалар җырларында да күренә. Берничә мисал китерик.

1957 елда үткәрелгән киңәшмәдә М. Мазуновның «Кунак китәләр» исемле шигыре тәнкыйтьләнгән иде. Докладчы Ә. Исхак аны рифмага салынган хәбәрләр рәтенә кертте. Әле хәбәр буларак та редакцияләмичә генә урнаштырып булмый дип, кимчелекләрен санап күрсәтте. М. Мазунов моннан нинди нәтиҗә ясый? Сигез ел үткәннән соң, шул хәлендә, әмма көй яздыртып — «Җыр безнең дустыбыз» дигән җыентыкта нота белән бастырып чыгара!

М. Хәсәендә икенчерәк мисал бар. Аның «Пионерлар җыры»на башта Ә. Бакиров музыка яза, дүрт ел узгачтын Б. Мулюков шул ук текстны «Пионерлар маршы» итә. Ике композитор ярышып эшләрлек нинди сүзләр соң ул? Менә бер өзек:

Пионер, тырыш!
Алда — зур тормыш.
Якты иртәбез.
Без — кыю халык,
Галстуклар тагып,
Җырлап үтәбез.

Җыр әнә шундый аңга-күңелгә кагылмый торган, кабатлый-кабатлый шомарып беткән сүзләрдән тора.

Икенче елны Б. Мулюков М. Хәсәен сүзләренә балалар хоры өчен биш җырдан торган җыентык чыгара. («Бөтен ел матур».) «Чаңгы шуганда» дигән беренче җырда шундый юллар бар:

Ял итәргә чыгабыз без
Ап-ак кырларга;
Нинди рәхәт саф һавада
Чаңгы шуарга,
Чаңгы шуарга,
Чаңгы шуарга!

Тагын бер елдан «Пионерлар маршы» дигән коллектив җыентыкта М. Хәсәеннең мондый җыры күренә:

Җиңел кием өстә,
Чаңгы кулларда;
Әйдә киттек, дуслар,
Чаңгы шуарга!
Чаңгы шуарга!
Эх, дуслар!

Тегесе белән бутамагыз, бусы инде яңа җыр — «Чаңгы шуабыз» дип атала. Музыкасын да бүтән композитор — Җ. Фәйзи язган. Соңгы юлларына кушылып: «Эх, дуслар...» дип күрсенергә генә кала. Шулай да, көрсенгәч, җиңел суларга ашыкмыйк. Бер үк вакытта М. Хәсәеннең яңа җыры пәйда була. Монысы «Кышкы җыр» дип аталса да, И. Шәмсетдиновның «Җәйге урман» җыентыгына эләккән:

Җилләр белән шаярышып,
Чаңгыларда шуам мин.
Ару белмим, талу белмим,
Шат һәм таза шуңа мин.

Бу җырлардагы аерма шунда: «чаңгы шуу» сүзе җырдан җырга кими генә бара. Беренчесендә өч тапкыр кабатланса, икенчесендә икегә кала, өченчесендә бер тапкыр гына телгә алына. Текстлар арасында бүтән аерма күренми. Хөрмәтле композиторлар

ничек таптылар икән ул аерманы? Әллә, гафу итегез, яхшыны яманнан аера белмибезме?..

Г. Зәйнашеваның «Яңа мәктәп», «Яшь бакчачылар», «Ялкау малай», «Исәнме, мәктәп» җырлары да коры информациядән узмый, бер калыптан төшкән кебек тонык һәм төссезләр, балалар аларны үз җырларыдай кабул итәренә ышанып булмый. Х. Вахитның «Җәйге урман» җыры да урман күренешләрен тезеп чыгудан ары китә алмаган.

Менә бу балалар җыры, диярлекләре дә юк түгел. З. Нуриның «Чаңгыларым кыска», «Курчактан сорыйм», Р. Әхмәтҗановның «Космонавтлар җыры» һәм А. Сәләхетдиновның «Җәлил йолдызлары», «Мәңгелек чишмә» шундыйлардан. Мисалларны, ихтимал, арттырып та булыр иде. Бүген борчыганы турында фикер алышасы килде.

Соңгы елларда балалар поэзиясендә яңа җилләр исте, яңа тавышлар өстәлде, дидек. Кызганычка каршы, поэзиянең үтемле тармагы булган җырга карата әлегә моны әйтеп булмый. Балалар җырларының рухи дөньясы фәкыйрь әле, уйсыз-хиссез, ясалма, шаблон һәм шалтыравык җырлар бар.

Җырларның әле күбесе радиодан кат-кат өйрәтеп тә балалар күңеленә ирешми. Иләртеп, канатландырып китәрлек җырлар кирәк! Музыкасы да, сүзләре дә безнең хәвефле һәм катлаулы заманыбызга, бәхетле һәм ышанычлы тормышыбызга, эшчән һәм акыллы кешеләребезнең рухи дөньясына тиң булсын. Онытмыйк: яхшы җыр безнең идеяләребезнең иң үтемле пропагандисты. Бүгенге балалар күңелен — сәнгатебезнең киләчәген — без бары талантлы каләм ияләренә генә тапшыра алабыз. Иҗат принципларын кәсепкә алмаштырган әрсез кешеләргә юл куярга, читтән битараф кына тамаша кылып торырга хакыбыз юк. Югары таләпчәнлек беркайчан да көн тәртибеннән төшәргә тиеш түгел.

## ДӘРЕСЛЕК һӘМ ШИГЪРИ ДӘРЕСЛЕК

Балалар өчен язылган китапларыбыз башлангыч мәктәптә укучы һәр бала кулына керәдер дип үзебезне алдый алмыйбыз. Ә менә дәреслекләр һәр укучы кулына керә, алар аркылы бала күңеленә шигърияткә юл ачыла. Узган ел башлангыч класслар өчен дәреслекләр менә нинди тираж белән чыкты:

Әлифба — 75 мең
1 класс өчен «Туган тел» — 67 мең
2 класс өчен «Туган тел» — 53 мең
3 класс өчен «Туган тел» — 53 мең
4 класс өчен «Туган тел» — 48 мең

Күрәсез, бер елгы гомуми тираж 300 меңгә якынлаша. Соңгы өч класс өчен «Туган тел»нең алтынчы-җиденче басмалар булуын да хәтерләп үтик. Димәк, бер алынган шигырь алты-җиде тапкыр басыла! «Яшьлектә белгән — ташка язылган», ди халык. Гомергә күңелдә калуга лаеклы булырга тиештер инде ул шигырьләр?

Сүзне башлап китү өчен, искиткеч зәвык белән эшләнгән, балалар өчен чын-чыннан төсләр бәйләме булган «Әлифба»дагы бер шигырьне мисал итеп алмакчы булам.

Безнең илдә һәркем эшли
Үзе яраткан эштә:
колхозларда, заводларда
яки зур төзелештә...

Шунсы характерлы — «Әлифба»дагы кебек, «Туган тел»дә М. Садриның шундый өч шигыреннән соң «Сезнең семьяда кемнәр бар? Алар кайларда эшлиләр?» дигән игезәк сораулар куела. Ни өчен ел эчендә бала бер төрле сорауга бер төрле җавапны дүрт тапкыр кабатларга тиеш? Күрәсең, шаблон шигырьләр шаблон сорау тудырадыр... Укучылардан мондый анкета мәгълүматларын кабатлатуга караганда, хезмәтнең матурлыгы турында мавыктыргыч сүз кузгату мәгънәлерәк булыр иде.

Нә өчен дәреслектә хезмәткә багышланган коры һәм тәссез шигырьләр урын алган? Хезмәт белән кызыктыру, балага хезмәт дәртен тойдыру, эш тәмен татыту урынына, ул әсәрләр белән аның күңелен генә кайтармыйбызмы? Мондый шигырьләрнең балага тәэсире булмый калмый, билгеле. Шигырь шундый була икән дип инанган беркатлы сабый шуңа ошатыбрак үзе дә яза, редакцияләргә җибәрә һәм басылып чыкканын көтә башлый. Шигырь мондый булмый, энем, бу бит мәгълүм нәрсәләрне өстән-өстән санап чыгу гына, дигән җавап алгач аптырап кала: ник алай? Нәкъ шундыйлар безнең дәреслектә бар ич?! Бала бәлкем мавыгуын онытыр да иде, икенче класска күчкәч тагын М. Садриның «Яңа Баулы» дигән, тышкы күренешләрне санап чыгуга гына җайланган җырына юлыга:

Безнең Баулы җирләрендә
Кара алтын табыла,
Нефть тәяп кене-төне
Эшелоннар агыла...

Шунда ук, ике тамчы нефть кебек охшаш тагын бер шигырь бар:

Нефтькә дә бай
Җиребез,
Нефть өчен көрәшә
Илебез.
(Г. Латыйп)

Бала үсә, үзгәрә — дүртенче класска җитә. Шигырьләр генә үзгәрмиләр, класслары артмый — шундый ук шигырь аны бу дәреслектә дә көтеп тора. Бусын инде укучы ятларга тиеш...

Дәреслектәге шигырьләр балалар поэзиясенең бүгенге дәрәҗәсенә тигезләнергә тиешләр, үтелгән этап булган кичәге көн әсәрләре белән саташтырырга ярамый балаларны. Югыйсә, әлегә берниндн чама юк. Беренче класс өчен «Туган тел» китабына хәтта укучыларның үзләре язган ике шигырь дә килеп кергән... Бу яңа дәреслекне Татарстан Мәгариф министрлыгы сынау өчен раслаган икән. Башка якларын әйтмим, әмма шигырьләрен 67 мең укучыда сынаганчы, шагыйрьләрнең үзләре белән сынап карарга кирәк булгандыр?...

* * *

Балалар турында еш кына: алар безнең нәни гражданнар, дигәнне ишетергә туры килә. Бик үк төгәл микән бу сүзләр? Гражданин нәни буламы? Балалар киләчәкнең безнең арада яшәүче тулы хокуклы гражданнары. «Һәр бала — шәхес, һәм моны истә тотарга кирәк»,— ди Бенджамин Спок. Бөтен гомерен балаларның физик, психик һәм акыл сәламәтлеге өчен көрәшкә багышлаган гуманистның һәм Вьетнамдагы сугышка каршы үзенең мөнәсәбәтен кыю белдергән куркусыз кешенең сүзләрендә тирән мәгънә бар: «Һәр бала — шәхес...» Һәр шәхес тормышта, җирдә хаклык өчен көрәшче— гражданин булсын.

Балалар тормышыбызның чәчәкләре дип сокланабыз. Чәчәкләр нинди җимеш бирер? Безгә — кеше күңеленең бакчачыларына — моны онытырга ярамый. Бары чын җимешләр — яхшы кешеләр үстерү өчен тырышыйк.

Җирдә кеше күңеле өчен көрәш бара. Моңача күрелмәгән масштабларда зур көрәш бара. Бер шагыйрь, хәрби терминга күчереп, кеше күңелен биеклек белән чагыштырган иде. Ул буш тормый, бездә булмаса, аны дошманнар яулап ала дигән иде. Бер генә күңелне дә ятларга бирмик!

Буыннар арты буыннар алмашына. Буыннар... Ракета буыннары кебек киләчәк өчен янып калган буыннар яңа буыннарны яңа орбитага чыгаралар. Без дә, бер-беребезгә югары талапчанлек белән, барлык иҗат көчебезне куеп, алмашка килер буынны — бүгенге укучыларыбызны югары рухи орбитага чыгару өчен эшлик!

# УЛ МИНЕМ ОСТАЗЫМ ИДЕ

1924 елда без, Башкортстанның төрле почмакларыннан җыелган бик күп авыл яшьләре, Уфада укып ята идек. Бүгенге кебек хәтеремдә, Пушкин урамындагы 92 нче номерлы ике катлы йортның бер бүлмәсендә без берничә малай торабыз.

Билгеле, якынрак танышып алгач, үзара дуслаштык. Минем белән янәшә койкадагы иптәшем, озын буйлы ябык малай Әбделманов бер көнне үзенең Мәҗит Гафури туып-үскән Җилемкаран авылыннан булуын, ул гына да түгел, горурланыбрак, Мәҗит аганың якын туганы да икәнен сөйләде. Моны ишетүгә, билгеле инде, колакларым үрә торды, бик кызыксындым һәм тагын да җентекләбрәк Гафурига ничек туган булуын сораша башладым.

Минем кебек кече яшьтән үк мәктәпләрдә Каюм Насыйри, Г. Тукай, М. Гафури, Ш. Мәрҗани, Г. Ибраһимов, Фатих Әмирхан, Дәрдмәнд, Сәгыйт Рәмиев, Г. Камал кебек атаклы шагыйрь һәм язучыларның әсәрләрен укып үскән, шулар белән тәрбияләнгән кешегә Гафурины якыннан белгән, хәтта үзен аның туганы, дип атаган кешенең очравы, аның үз янымда ук булуы, ничектер, гаҗәбрәк булып китте.

Мәҗит абый эшләгән «Яңа авыл» газетасы идарәсенә без бергәләп барырга булдык.

Барганда Гафурины күз алдына китерергә тырышам. Ни өчендер, мин аны авылыбызның җәдит мулласы шикелле таза гәүдәле, зур мыеклы, мәһабәт бер кеше итеп күрергә тырышам. Ә үзем эчемнән генә: «Ул минем белән сөйләшерме икән, сөйләшсә, ничек сүз башларга, укытучылар кебек сораулар бирә башласа, ничек җавап кайтарырга», дип уйлап барам һәм үзем дулкынланам. Чөнки минем кебек меңләгән яшьләр аның революциягә кадәрге һәм аннан соң да өлкәннәр һәм балалар өчен бербер артлы татарча чыгып торган шигырьләре, хикәяләре, мәсәлләре белән таныш, аларның күбесен мәктәпләрдә укып, җырлап йөрсәк тә, үзен күргәнебез юк иде. Ә менә бүген, гомеремдә беренче мәртәбә, тере шагыйрьне, безгә китаплар язып чыгаручы кешене күрергә барам!

Бүрәнә өстеннән сипләнгән такталарның кайчандыр буялган, инде нинди төскә буялганлыгын да әйтүе кыен булган бер бинаның парадный ишегеннән кереп, тар гына текә һәм караңгы баскычтан өскә күтәрелдек.

Анда уртача буйлы, кара чәч-мыеклы, башында түбәтәй, өстенә кара костюм кигән, галстук таккан өлкәнрәк яшьтәге, матур кеше аяк өсте баскан килеш бик җитди рәвештә нәрсәдер эшли иде. Эчке бүлмәләрдә дә кешеләр күренә.

Монда мине гаҗәпләндергәне шул булды: Әбделманов кергәч тә:

— Исәнмесез, Мәҗит абый! — дип исәнләште. Миңа, зур гәүдәле кеше күрергә ниятләп баручыга, бу бик сәер тоелды. Минем башка келт итеп:

— Бәй, бу Гафури үзе микәнни! — дигән сорау килде. Чөнки алда һич көтмәгән кеше басып тора иде.

Биш минут та үтмәгәндер, ул эшен бетереп, кәгазьләрен җыйгалады да:

— Әйдә, утырыгыз,— дип, безгә урын күрсәтте.

Мин сүз башлый алмый торганда, кыен хәлдән иптәш коткарды.

— Мәҗит абый, без синең янга хәл белергә генә кердек. Монда укырга килдек. Менә бу егет тә безнең якныкы,— диде. Мин баш кагып кына аның сүзен расладым.

Гафури аңа сораулар биреп, нинди укуга килүебез белән кызыксынды, аның ата-аналарын, тагын кемнәрендер сорашты. Аннан соң әкрен генә, йомшак тавыш белән минем кайдан килүем, исемем, атам-анам турында сорап китте. Аның сорауларына оялып кына җавап кайтарып, үземнең Стәрлетамак кантоны Сәмән авылыннан булуымны әйттем. Безнең авыл исемен ишеткәч, ул җанланып киткәндәй булды:

— Ә... ә... Якташ икәнсең.

Мәҗит абый тагын ниндидер сораулар биргәләде. Мин исә, шундый зур кешенең безнең кебек авыл малайлары белән үз тиңе кебек итеп сөйләшүен күргәч, батыраеп киттем шикелле.

Бер дә көтмәгәндә, ул:

— Сәмәндәге теге ирләр кимене киенеп малайлыкта йөргән Миңнеяр-Хәтимә исәнме әле! — дип сорады. Мин бераз аптырап калдым. Гомумән, ул вакыйганы ишеткәнем булса да, Хәтимәнең соңгы язмышы турында белми идем.

— Әйтә алмыйм, Мәҗит абый.— Ә үзем аның безнең авылда күптән булган вакыйганы белүенә хәйран калдым. Шуннан ул:

— Ул чакта син яшьрәк булгансыңдыр шул,— дип куйды.

Шушы гасырның башларында безнең авылда бер кызыклы вакыйга була: күрше Балыклыкүл авылының Хәтимә исемле яшь хатын ата-анасы көчләп биргән ирдән котылу өчен киемнәрен авыл уртасындагы зур тирән күлнең яры башында салып калдыра да (суга батып үлгән, дип белсеннәр өчен), ирләр кимене киенеп, авылыннан чыгып китә һәм бер сәүдәгәргә малайлыкка керә. Берничә ел буе авылда батрак булып йөри, ләкин аның хатын икәнен берәү дә белми. Тик авыл яшьләре белән солдатка каралу, метрика алу мәсьәләсе килеп тугач кына, чын хәл ачыла.

Заманында тирә-якны шаулаткан шушы вакыйга соңыннан бөек әдип Галимҗан ага Ибраһимовка «Татар хатыны ниләр күрми» повестен язу өчен сюжет һәм Хәтимә образы әсәрнең төп каһарманы булган Гөлбануның прототибы хезмәтен үти. Мин Галимҗан аганың Солтанмораттан Сәмәнгә һәм Балыклыкүлгә килеп, шул турыда материаллар җыйнап йөрүен хәтерлим.

Мәҗит абыйның ул вакытта сорашканы менә шушы әсәрнең тере героинясы Хәтимә турында иде.

Без шатланышып китәргә җыендык. Ул безгә:

— Тагын килегез,— дип калды.

Мәҗит абый белән минем беренче танышуым һәм сөйләшүем көтелмәгәнчә уңышлы чыккач, үзе дә: «Тагын килегез», дип калгач, миндә хәзер яңа теләкләр, яңа өметләр туды.

Аның янына юлны белеп алгач, берәр атнадан соң йомышсыз-нисез үзем генә киттем. Хәзер инде ул миңа укытучым кебек якын күренә иде.

Бу юлы инде мин һичбер тартынмый, үземне иркен тотарга тырышып, аның һәр соравына җавап бирдем.

Ул үзе эшли, үзе миңа әкренләп сораулар бирә торды. Нинди китаплар укуым белән дә кызыксынды.

Гафуриның мөлаем йөзен, аталарча йомшак сүзен тиз генә онытa алмадым, берничә атна үткәч, тагын бардым. Ул мине, ничектер, үзенә тарта иде.

— Синең газетка язганың бармы! — дип сорады ул.

Мин «Яшь юксыл»да авыл яшьләре турында бер-ике хәбәрем чыгуын әйттем.

— Алай булгач, сиңа һәрвакыт язышып торырга кирәк, килешмәгән урыннары булса, идарәдә төзәтерләр,— диде.

Укуда булу сәбәпле, хәбәрләр яза алмавымны әйткәч, ул өстәл тартмасыннан кечкенә генә форматтагы ике яңа китап чыгарды да миңа сузды:

— Мә, шушыларны бик җентекләп укып чык та, алар турында нәрсә аңласаң, шул турыда фикерләреңне язып миңа китер,— диде.

Кадерле китапларны бик игътибар белән укып чыктым да, аларның эчтәлеге, теле, яшьләр өчен аларның файдалы булуын әйтеп, кайсы нәшрият чыгаруын, хәтта оформлениесен, хакларын күрсәтеп, яшь укучыларга тәкъдим рәвешендә яздым һәм Мәҗит абыйга алып киттем. Бу ике китапка рецензия сыман нәрсә иде.

Гафури язманы укып карады да:

— Син моны «Яшь юксыл»га кертеп бир,— диде.

Рецензия «Яшь юксыл»да басылып та чыкты.

Моны күргәч иптәшләремнең күзләре шардай булды. Кайсы мактый, кайсы мыскыллап көлә.

— Син Мәҗит Гафури янына күп йөри башладың. Моны син язмагансың, ул язып биргән,— диючеләр дә булды. Материал иптәшләрем арасында минем «хәбәрче» дигән исемемне таратты.

Икенче көнне, газетаны кесәгә тыктым да, тагын Мәҗит абый янына киттем. Барып керүем белән ул көлемсерәгән кыяфәт белән:

— Әһә... килдеңмени, автор Маннани! — дип ярым шаярып каршы алды. Ул бу материалны күптән укыган икән. Миңа кесәдәге газетаны чыгаруның кирәге дә калмады.

Аның бу сүзләренә югалыбрак калдым булса кирәк, рәтләп бер сүз дә әйтә алмадым. Ул «Яшь юксыл»ның минем материал басылган санын өстәл өстенә салып куйган икән. Аны алып миңа сузды да:

— Менә синди шәп чыккан, молодец, болай яза алгач, һәрвакыт язып тор,— диде.

«Автор Маннани» дию миңа һич тә сәер тоелмады. Чөнки мин бу беренче мәкаләмне Гафуриның үзенә һәм фамилияләренең ахыры «и»гә беткән башка күренекле кешеләргә охшарга тырышып: «Хәлил Маннани»,— дип куйган идем.

Мәҗит абыйдан чыкканда мин газеталарга туктаусыз язып торырга карар биргән идем инде. Бу карарым гомерем буе, 45 ел бозылмыйча килде, бүгенге көнгәчә дәвам итә.

1925 елда Уфадан авылга кайтып киттем һәм, Мәҗит абыйның киңәше буенча, авылдан туктаусыз хәбәрләр язып тора башладым. Аларның кайберләре газетада басуны сорап Мәҗит абыйның үзенә дә адреслангән була иде.

Шундый бер момент хәтердә калган: «Совет лавкасы түгел, Сабит лавкасы» исемле бер хәбәрне «Яңавыл» газетасына, Мәҗит абыйга адреслап җибәрдем. Күп тә үтми, хәбәр бик кызыклы, көлкеле карикатуралар белән басылып та килде. Шуннан соң лавка эчендә барган эчү, карта уйнаулар бетте. Тик үзем генә Сабит агайның гомерлек дошманы булып калдым.

Укудан «Яңавыл» газетасы редакциясенә эшкә күчтем. Күп тә үтми, газетаның исеме «Коммуна» дип алмаштырылды (хәзерге «Кызыл таң»).

Бервакыт редакциягә Мәҗит абый килеп керде. Танышлары белән исәнләшеп бетүгә мине күрде дә:

— Оһо! Син, Маннани, әллә журналист булып киттеңме! — диде көлемсерәп. — Шәп, бик шәп, нәкъ урынын тапкансың инде.

Редакциягә килгәндә Гафуриның кулында бер папка бар иде. Шагыйрь Гариф Гомәр белән сөйләшеп киттеләр. Ул шушы елларда гына язган «Тормыш баскычлары» повестен газетада бастыру турында сөйләшү өчен килгән икән.

Гафуриның беренче бөтендөнья сугышы вакыйгаларын чагылдырган бу зур повесте газетада бүлеп-бүлеп басылды һәм хәтсез саннарга сузылды.

Ул үзе көн дә диярлек редакциягә һәм типографиягә килеп йөрде. Материалның әдәби бүлектән ничек чыгуын, корректурасының ничек укылуын, типография хаталарын булдырмауны кайгыртты.

Тугандаш татар һәм башкорт халыкларының сөекле шагыйре Мәҗит ага Гафури минем күңелгә шулай бик тирән кереп калды.

ХӘЛИЛ МАННАН,
журналист, пенсионер.

# ЛЕНИН НУРЛАРЫ ЯКТЫЛЫГЫНДА

**1969** елда Мәскәүдәге «Фән» нәшрияты СССР Фәннәр Академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Казан тел, әдәбият һәм тарих институты фәнни хезмәткәре Мөнирә Сәйдәшеваның «Ленин һәм Татарстанда социалистик төзелеш» дигән монографиясен бастырып чыгарды [1]. Бу мөһим хезмәт Совет властеның беренче елларында милли мәсьәләне хәл итүдә В. И. Ленинның һәм Коммунистлар партиясенең җитәкчелек ролен күрсәтүгә багышланган. Китапта Совет Россиясенең милли өлкәләрендә, бигрәк тә Татарстанда, милли дәүләт, экономика һәм культура төзелеше процессына В. И. Ленинның конкрет җитәкчелек итүе һәм бу мәсьәләләр турында даими кайгыртучанлык күрсәтүе ышандырырлык итеп күрсәтелә.

Автор үзенең бу хезмәтендә татар халкының милли үсешендә Владимир Ильич Ленинның турыдан-туры катнашын раслаган төп өч мәсьәләне тикшерә. Беренчедән, Татарстан АССРның барлыкка килү процессы; икенчедән, экономик төзелеш һәм 1921—1922 елларда Татарстанда булган ачлык белән көрәш; өченчедән, культура төзелеше, республикада культура революциясен тормышка ашыруның башлануы.

Безнең тарих фәне өчен бу мәсьәләләр күтәрелмәгән чирәм түгел, билгеле. Болар буенча Татарстан тарихчыларыннан И. М. Климов, Р. И. Нафиков, М. К. Мөхәррәмов, Я. Ш. Шәрәпов, Н. А. Андриянов, К. А. Толстяков, Т. М. Насыйров, К. А. Нәҗипова, А. Л. Литвин, М. А. Кибардин, В. Г. Саркин, А. А. Шишкин һ. б. күп эшләделәр һәм байтак фәнни хезмәтләр яздылар. Алардан аермалы буларак, иптәш Сәйдәшева төп игътибарны бу мәсьәләләрнең В. И. Ленин исеме белән, Совет властеның беренче елларында Татарстан хезмәт ияләре турында аның кайгыртучанлыгы белән бәйле якларына юнәлтә. Автор турыдан-туры Татарстан республикасына бәйле булган бик күп Ленин документларын җыйган һәм аларга анализ ясаган. Партиянең Үзәк архивында Ленин документлары шактый күп, аларның гомуми саны 30 меңләп исәпләнә. Шулар арасыннан иптәш Сәйдәшева Татарстан автономияле республикасының төзелүенә һәм үсешенә бәйле 280 документ тапкан. Аларның 46 сы беренче тапкыр файдаланыла. Автор, В. И. Ленин хезмәтләрен, аның матбугатта басылмаган документларын, партиябезнең һәм хөкүмәтебезнең карарларын, күп кенә архив документларын, революциядә катнашкан кешеләрнең истәлекләрен анализлап, бик күп кызыклы тарихи фактларны һәм вакыйгаларны үзенчә яктырта. Мәсәлән, иптәш Сәйдәшева татарларның милли автономиясен булдыру юнәлешендә үтелгән ике этап турында мөһим нәтиҗә ясый, «Татар-Башкорт Совет Республикасы турында Положение»гә (ТБСР) тирәнрәк һәм тулырак бәя бирә, аның тормышка ашырылмый калу сәбәпләрен төплерәк дәлилли. Татарларның милли дәүләтен төзүдә беренче этап итеп, автор 1918 елның башыннан алып 1919 елның ахырына кадәр булган вакытны ала. Бу чорда «Татар-Башкорт Совет Республикасы турында Положение» эшләнә һәм кабул ителә, аны тормышка ашыру буенча кайбер чаралар күрелә. Иптәш Сәйдәшева «Татар-Башкорт Совет Республикасы» игълан ителүнең зур әһәмияте булуын күрсәтә. «Ул,— ди автор,— татар һәм башкорт буржуазиясенең идеологик җирлеген җимерде һәм, шуның нәтиҗәсендә, татар-башкорт хезмәт ияләре Совет власте ягына борылдылар» (79 бит). Татар һәм башкорт хезмәт ияләре ленинчыл большевиклар партиясенең милли Совет республикасы төзүгә юнәлтелгән

[1] М. А. Сәйдәшева. Ленин һәм Татарстанда социалистик төзелеш. Рус телендә. Мәскәү, «Фән» нәшрияты, 1969 ел, 326 бит.

политикасын бердәм якладылар һәм «Идел-Урал штаты» дигән исем астында контрреволюцион буржуаз республика оештырырга маташучыларга кискен каршы чыктылар. Ул вакытта татар һәм башкорт хезмәт ияләреннән В. И. Ленин һәм Халык Комиссарлары Советы исеменә килгән күп санлы хатлар, телеграммалар һәм резолюцияләр нәкъ менә шул турыда сөйлиләр. Аларда Татар-Башкорт Совет Республикасы төзүгә теләктәшлек һәм Совет властена тулы ышаныч белдерелә.

Ләкин, чит ил буржуазиясе оештырган хәрби интервенция һәм гражданнар сугышы башлану сәбәпле, Татар-Башкорт Совет Республикасын төзү тоткарланды. Бу мәсьәләне яңадан көн тәртибенә кую гражданнар сугышы барышында контрреволюцион буржуазияне тар-мар иткәч кенә мөмкин булды. Хәзер инде, автор бик дөрес күрсәтеп үткәнчә, партия-совет работникларының игътибары конкрет сорауга юнәлде: татар һәм башкорт халыкларының дуслыгын ныгытуга, аларның экономикасын һәм культурасын үстерүгә нинди автономия әйбәтрәк җавап бирәчәк? Бердәм автономияме, әллә мөстәкыйль автономия булдыру дөресрәкме?

1919 елның язында башкорт хезмәт ияләре мөстәкыйль автономияле республика төзергә теләк белдерәләр. Шуны искә алып, Совет хөкүмәте Башкортстан Автономияле Совет Социалистик Республикасын төзү турында декрет игълан итә. Казан губернасы мөселман коммунистларының 1919 елның ноябренда булып узган 1 нче конференциясе дә мөстәкыйль Татарстан Автономияле Республикасы төзүне яклап чыга (72 бит). Конкрет шартларны күздә тотып, бер үк вакытта башкорт һәм татар халыкларының теләкләрен, интересларын искә алып, партия Үзәк Комитеты һәм В. И. Ленин мөстәкыйль Башкортстан һәм Татарстан Автономияле Республикалары төзү максатка яраклырак булачак, дигән нәтиҗәгә киләләр.

Татарларның милли автономиясен төзүдә икенче этап итеп, автор 1919 елның ахырыннан алып 1920 ел урталарына кадәр, ягъни Татарстан Автономияле Республикасы төзелүгә кадәр булган вакытны ала. Үзәк Комитет документларын өйрәнү нәтиҗәсендә, иптәш Сәйдәшева татар халкының үзбилгеләнү мәсьәләләре В. И. Ленин председательлегендә РКП(б) Үзәк Комитеты Политбюросының 11 утырышында тикшерелгәнлеген раслый. Татарстан АССРны төзүгә хәзерлек барышында, ягъни 1919—1920 елларда, В. И. Ленин күп тапкырлар Казан губкомы делегациясе белән сөйләшә, милли мәсьәләне дөрес хәл итүнең социалистик революция һәм социализм төзү өчен гаять әһәмиятле булуын аңлата. Иптәш Сәйдәшева күрсәткәнчә, Татарстан республикасын төзүнең барлык мөһим мәсьәләләре буенча партия Үзәк Комитеты һәм В. И. Ленин бик күп принципиаль фикерләр әйтәләр. Монографиядә В. И. Ленинның шовинизмга һәм җирле милләтчелеккә каршы принципиаль көрәшенә аеруча игътибар бирелә, Татарстан АССРны төзүдә аның һәм үзәк партия-совет оешмаларының ярдәме киң яктыртыла.

Тарихи әдәбиятта беренче буларак, монографиядә 1921—1922 елларда Идел буендагы, шул исәптән Татарстандагы, ачлык белән көрәшне оештыруда В. И. Ленинның эшчәнлеге һәрьяклап һәм киң яктыртыла. В. И. Ленинның бу эшчәнлеген автор өч юнәлештә тикшерә: 1) ачлык һәм аның нәтиҗәләре белән көрәштә гомумдәүләт күләмендә чаралар оештыру; 2) илебезнең корылыктан зарар күрмәгән өлкәләрендәге һәм республикаларындагы хезмәт ияләрен ачлыктан интегүче районнарга ярдәм итүгә мобилизацияләү; 3) ачтан интегүчеләргә бөтендөнья пролетариатының ярдәмен оештыру.

В. И. Ленинның Татарстан республикасы хезмәт ияләренә ярдәм оештырудагы эшчәнлеген күрсәтүгә авторның күбрәк тукталуы табигый, әлбәттә. 1921 елның апрелендә үк инде РСФСР Халык Комиссарлары Советы, В. И. Ленин инициативасы белән, Татарстан АССРга 300 мең пот орлык бирү һәм башка чаралар белән ярдәм итү турында карар кабул итә (118 бит). Нәтиҗәдә, республикада сабан ашлыгы өчен билгеләнгән барлык мәйданнар да чәчелә. Ләкин Татарстанда корылык гаять көчле булу сәбәпле, хәтта чәчелгән орлык кадәр дә уңыш җыелмый. 1921 елда терлекләр саны да 1920 елдагыга караганда 40 процентка кими. РСФСР Халык Комиссарлары Советы һәм Бөтенсоюз Үзәк Башкарма комитеты комиссиясе 1921 елның җәендә Татарстан республикасындагы хәлне тикшерә һәм, азык-төлек җитешмәү сәбәпле, Татарстан халкының яртысын һәм беренче чиратта 15 мең баланы башка өлкәләргә күчерергә кирәк, уҗым чәчү өчен 6 миллион поттан артык орлык таләп ителә дигән нәтиҗәгә килә (122 бит). Комиссиянең бу фикере 1921 елның 8 августында В. И. Ленинга җиткерелә.

В. И. Ленин житәкчелегендәге Совет хөкүмәте күргән чаралар нәтиҗәсендә 1921 елның көзендә Татарстан дәүләттән 2.700 мең поттан артык чәчүлек орлык ала. 1921—1922 елларның 15 ае эчендә Совет хөкүмәте Татарстан республикасына 3,5 миллион пот азык-төлек һәм башка тер товарлар җибәрә («1921—1922 елларда ачлыкка каршы көрәш йомгаклары» дигән китапны кара. Мәскәү, 1922. 469 бит). Автор, хәзергә кадәр басылмаган документларга таянып, Татарстанга дәүләт тарафыннан азык-төлек, орлык һәм башка средстволар белән ярдәм оештыруда В. И. Ленинның даими житәкчелек итүен дәлилли.

Мәскәү һәм Ленинград, Тула һәм Ташкент, Әзербайҗан һәм Украина, Владимир һәм Иваново, Төньяк Двина губернасы һәм башка өлкә хезмәт ияләренең ачлык елларда Татарстанга ярдәм кулын сузуы — илебез халыклары арасындагы дуслыкның һәм пролетар ярдәмләшүнең дулкынландыргыч мисалы. Автор бу турыда ышандыргыч фактлар китерә.

Ул елларда Россиянең ачлыктан интеккән хезмәт ияләренә ярдәм итү буенча Халыкара Комитет оештырыла. Аның башында күренекле галим Ф. Нансен тора. Бу комитет ачлык елларда Советлар Россиясенә 5 миллион пот чамасы азык-төлек кертә. Профсоюзларның Халыкара федерациясе дә Россиянең ачлыктан интегүче өлкәләренә ярдәм итүне оештыра һәм 243 мең пот азык-төлек җыеп җибәрә («СССР тарихы» журналы. 1963 ел. № 1. 155 бит).

Ләкин империалистик илләрнең буржуаз хөкүмәтләре Россиядәге бу авыр хәлне үзләренең мәкерле максатларында файдаланырга тырыштылар. Ниләр генә кыланмады алар. Большевикларга һәм революциягә каршы кампанияләр үткәрделәр, патша хөкүмәтенең бурычларын түләүне талап иттеләр. Ярдәм оештыручылар делегациясе яки төрле комиссияләр исеме белән Россиягә шпионнар һәм разведка кешеләрен җибәрделәр. Болар барысы да бер нәрсәгә — эшчеләр һәм крестьяннар властен бәреп төшерүгә юнәлдерелгән иде. Империалистик дәүләтләр шундый кампанияләр үткәрү өчен гаять зур акчалар түздырдылар. Бөтенсоюз Үзәк Башкарма Комитетының ачыгучыларга ярдәм оештыру буенча Үзәк Комиссиясе бу турыда болай дип белдерде: «Мәгълүм даирәләр тарафыннан узган елда рус революциясенә яла ягар өчен тотылган чыгымнарның меңнән бер өлеше генә дә ачлыкның барлык нәтиҗәләрен бетерергә җиткән булыр иде» («1921—1922 елларда ачлыкка каршы көрәш йомгаклары», 23 бит).

Совет дәүләтенең В. И. Ленин тарафыннан оештырылган искиткеч зур ярдәме, Советлар Россиясендәге барлык халыкларның туганнарча булышлыгы һәм татар халкының героик тырышлыгы нәтиҗәсендә ачлык китергән кыенлыклар җиңелде. 1923 елда инде ачлыкка дучар ителгән төбәкләрдә хәл яхшыра төште, республика халык хуҗалыгының барлык тармакларында торгызу эшләре башланды. Китапның бер бүлеге В. И. Ленинның Татарстанда промышленностьны һәм транспортны үстерүдәге ролен, бу өлкәдә аның конкрет житәкчелек итүен күрсәтүгә багышланган. Монда автор бик кызыклы тарихи фактлар китерә. Паратский затонындагы суднолар ремонтлау һәм механика заводлары В. И. Ленинның турыдан-туры күрсәтмәсе нигезендә оештырыла. Тире иләү-экстрат производствосын булдыруда һәм республиканы электрлаштыруда да Ильичның турыдан-туры ярдәме бик зур була. Советлар Республикасы өчен иң авыр чакта — 1918 елда — В. И. Ленин инициативасы белән Халык Комиссарлары Советы Татарстан территориясендәге капиталист Ушковтан тартып алынган Бондюг, Кокшан, Казан һәм Самарадагы заводларга финанс ярдәме күрсәтү турында берничә карар кабул итә. 1918 елның май—июль айларында гына да бу предприятиеләр өчен чимал һәм материал әзерләүгә 10 миллион сум акча җибәрелә. Паратскидагы суднолар ремонтлау заводын төзү һәм анда эшчеләр поселогы салу өчен, В. И. Ленин тәкъдиме буенча, Халык Комиссарлары Советы тарафыннан 25 миллион сум акча бирелә. 1919—1920 елларда В. И. Ленин Совет Россиясен чит илләрдән экстрат сатып алудан коткарачак һәм күн ясау промышленностен Татарстанда гына түгел, илебезнең башка районнарында да киң җәелдереп җибәрү мөмкинлеге тудырачак тире иләү-экстрат заводын төзүнең барышы белән даими кызыксынып тора.

Монографиянең шул ук бүлегендәге материаллар В. И. Ленинның Татарстан территориясендә тимер юлларны һәм су транспортын торгызуда житәкчелек ролен дә ачалар. Идел — Бөгелмә, Мәскәү — Казан һәм хәзерге Казан — Свердловск линияләрендә торгызу эшләрен оештыру, Бакалтайга тимер юл үткәрү, Иделдә елга транспортының эшен җайлаштыру, Кама белән Ка-

зәнка аша күпер салу нәкъ менә шуны раслыйлар. Хезмәт һәм Оборона Советының Транспорт Комиссиясе председателе буларак, В. И. Ленин җимерек транспортны аякка бастыру программасын эшли һәм аны тормышка ашыруда конкрет җитәкчелек итә. Шунысы характерлы, Владимир Ильич тимер юл һәм су транспорты хуҗалыгының вак детальләренә хәтле белә, аерым участокларда эшнең торышы белән якыннан танышып тора. В. И. Ленинның ул елларда транспортка шундый игътибарлы булуы аңлашыла. Илдә промышленностьны үстерү, шәһәрләрне ягулык һәм азык-төлек белән тәэмин итү, җыеп кына әйткәндә, Советлар республикасының язмышы күп яктан транспортның ничек эшләвенә бәйле иде.

Китапның соңгы бүлегендә Татарстанда милли культура үсешенә кагылышлы мәсьәләләр яктыртыла. Автор бу мәсьәләләрнең республика өчен ул елларда иң актуаль булганнарын тикшерә. Татарстанның оештырылуы һәм культура өлкәсендәге беренче уңышлар, бу өлкәдә куелган зур проблемаларны хәл итү — болар барысы да В. И. Ленин исеме белән бәйле. Китапта халык мәгарифе системасын үзгәртеп кору һәм наданлыкны бетерү өчен көрәш, партия мәктәпләре һәм рабфаклар булдыру, югары уку йортлары челтәрен киңәйтү һәм республикада милли кадрлар хәзерләү темпларын көчәйтү чаралары киң яктыртыла.

Владимир Ильичның партия һәм совет аппараты өчен милли кадрлар тәрбияләүгә даими игътибар биреп торуын аның М. Вахитов, Г. Ибраһимов, Б. Мансуров, С. Сәетгалиев һәм Татарстан республикасының башка вәкилләренә мөнәсәбәтендә ачык күренә.

Партия һәм дәүләт төзелешендә В. И. Ленин пролетар интернационализм принцибын эзлекле рәвештә тормышка ашыру турында зур кайгыртучанлык күрсәтте. Көнчыгыш халыклары коммунистик оешмаларның Үзәк Бюросында, Үзәк Мөселман Комиссариатында, шулай ук Татарстандагы партия һәм совет оешмалары эшендә тәгәл учет булдыруны таләп итте. Китапта солтангалиевчеләргә, милли тайпылышларга һәм группачылыкка каршы ул елларда Татарстан партия оешмасының ленинчыл Үзәк Комитет җитәкчелегендә алып барган көрәше тирән яктыртыла.

Совет дәүләтенең В. И. Ленин җитәкчелегендәге Россия пролетариатының татар халкына һәрьяклы ярдәме, революция юлбашчысы белән Татарстан хезмәт ияләре арасында урнашкан элемтәләр һәм мөнәсәбәтләр, рус һәм татар халыкларының туганнарча дуслыгы — республикабыз социалистик төзелештә ирешкән барлык уңышларның политик һәм рухи нигезен тәшкил иткән нәрсәләр шулар. Бу тәп сөземтә иптәш М. Сәйдәшева китабында китерелгән күп санлы тарихи фактлардан һәм автор тарафыннан өйрәнелгән һәм яктыртылган чорның вакыйгаларыннан килеп чыга.

Китапның тагын бер әһәмиятле ягы шунда: автор күп төрле буржуаз «галимнәр»нең бик күп хезмәтләрен өйрәнгән һәм аларны тәнкыйть күзлегеннән анализлаган. А. Лоу, Р. Пайпс, С. Зеньковский, В. Коларз, О. Кэроу, В. Хостер, В. Монтей, А. Беннингсен, Ш. Келькеджей, Г. Менде, Г. Кох, Т. Дәүләтшин, Д. Уязбәк, Б. Мусабай, В. Гришко һәм монополистик капиталның шуларише бүтән ялчылары Татарстан турында, татар халкының язмышы турында лаф орып күп язалар. Алар татар халкының милли дәүләтен булдыру, Татарстан АССРны төзү процессын, Советлар Союзы халыклары арасындагы туганнарча дуслыкны, В. И. Ленинның вак халыклар өчен милли дәүләтчелек булдыру турында кайгыртуларын һәм аларда социализм төзү барышын бозып күрсәтәләр. М. Сәйдәшева китабында бу тенденцияләр фаш ителә.

Монографиянең фәнни аппараты гаять бай. Бу инде китапка кертелгән һәр фактның, һәр вакыйганың тарихи тәгәл булуын раслый торган күренеш.

Автор В. И. Ленин тормышының һәм эшчәнлегенең Татарстан тарихына бәйле булган әһәмиятле даталар (1917—1923 еллар буенча) хроникасын да биргән. Аларның кайберләре автор тарафыннан, яңа документлар нигезендә, әле беренче тапкыр билгеләнә, ә кайберләренең тәгәллеге аныклана.

В. И. Ленинның Коммунистлар партиясе һәм Совет дәүләте белән идарә итүгә кагылышлы теоретик мирасын һәм практик эшчәнлеген өйрәнү — иҗтимагый фәннәрнең иң актуаль, иң мөһим һәм мактаулы бурычы. Иптәш М. Сәйдәшеваның хезмәте— бу зур бурычны үтәү эшенә лаеклы өлеш. Аның китабы — автор тарафыннан В. И. Ленинның 100 еллык юбилеена һәм Татарстанның 50 еллык бәйрәменә әйбәт бүләк булды.

**Г. БИЛАЛОВ,**
**тарих фәннәре кандидаты.**

# ГЕЛ КОЯШКА КАРАП

Соңгы елларда поэзиябезгә бер-бер-сен кабатламаган, үз тавышы, көрәшер өчен үз шигъри мәйданы, үз сукмагы булган талантлы яшьләр килә. Кайберәүләр үзләренең укучыларын тапканчы, әсәрләре белән киң катлаулы укучылар йөрәгенә күпер салганчы, тәмам өлгереп, камилләшеп җиткәнче һәм нечкә зәвыклы таләпчән укучыларның күңелен җәлеп итеп өлгергәнче шактый вакыт узып китә. Бу күренеш үтә талантлы яшьләргә дә хас. Ә кайберәүләр исә газета-журнал битләрендә күренгән беренче шигырьләре белән үк үзләренә кызыксыну уяталар һәм беренче җыентыклары белән шигырь сөючеләрнең җанын җәлеп итеп, үзләренә буйсындырып өлгерәләр. Һич икеләнмичә әйтергә мөмкин, шигърият мәйданына нык, ышанычлы адымнар белән соңгы елларда гына килеп кергән һәм «Язлар алда», «Һәрвакыт янымда» исемле җыентыклар чыгарып, болардан тыш, вакытлы матбугат битләрендә күп санлы матур-матур шигырьләр бастырып өлгергән Клара Булатова шул соңгылар рәтенә керә.

Клара Булатова үзен иң беренче чиратта дөньяның, галәмнең матурлыгын һәм иркенлеген, «тауларның биеклеген», «юлларның яктылыгын» күреп шатланучы, туган илебезне, «бәхет тулы» туган җиребезне бөтен рәхәте-газаплары, шатлык-кайгылары белән тормышны яратучы, җир, кеше, ил язмышы, кешенең тормыштагы урыны, яшәү мәгънәсе турында уйлanучы һәм борчылучы лирик шагыйрә итеп танытты.

Ул укытучылар, игенчеләр, төзүчеләр турында яза, авыл һәм шәһәр хезмәт кешеләренең күңелендә туган уй-фикерләрен, аларның кичерешләрен һәм омтылышларын самими һәм гади поэтик детальләр аша чагылдыра. «Төзелештә», «Рауза апа», «Монтер җыры», «Токарь кыз», «Укытучы апаң йокламаган», «Үшнә буе әле тын ята», «Үзлегеннән үсми шау бакчалар» исемле шигырьләрендә кешенең бәхете һәм гүзәллеге хезмәттә дигән матур фәлсәфи идея үткәрә, хезмәт кешесенең матурлыгына соклана, аңа дан җырлый һәм аның белән горурлана, «ялгыз төннәр үткәреп», «күпме йөрәк кичә түгеп» хезмәт иткән һәр кешенең зур бәхеткә һәм олы хөрмәткә лаеклы булуын раслый.

Дәһшәтле һәм шомлы, рәхимсез һәм газаплы еллар — авыр сугыш еллары турында кемнәр генә дистәләгән шигырь-поэмалар язмады икән? Әмма һәр шагыйрьнең, кошныкы кебек, үз җыры дигәндәй, Клара Булатова, башкаларны кабатлап, тапталган юлдан бармый. «Күрдеңме син?», «Бала чакта», «Әти кайтты», «Юк, кайтмасын ул чор!», «Без кичердек моны», «Егерме ел сугыш беткәнгә» шигырьләрендә «өтисен сугышка озатып калган бала сагышын», шул бала кичерешләре аша тасвирланган тетрәндергеч, кыен һәм гаять катлаулы сугыш еллары картиналары бүгенгедәй булып күз алдына килеп баса, канлы сугыш тудырган вакыйгаларның драматизмы, трагик газаплары укучылар йөрәгендә сугыш уты кабызучыларга тирән һәм сүнмәс нәфрәт уята, уяу булырга, зур корбаннар, авыр югалтулар биреп яулап алынган бүгенге тормышыбызның кадерен белергә, аны күз алмасыдай сакларга чакыра.

Шагыйрәнең:

> ...Кара алабута күмәчемне
> Күз яшенә манып ашадым...

Яисә:

> ...Бала чакны безнең танклардай
> Авыр еллар изеп киттеләр...—

дигән юллары тирән мәгънәле булып, шул елларның кискенлеген гәүдәләндерәләр һәм фаҗигасен бөтен авырлыгы белән ачып салалар. Шигырьләрне укыгач «нәфрәтләрдән металл коелуын»а «күз яшенең дары бирүен»ә, кешеләрнең гомерендә «җуелмаслык эзләр салынып калган»ына ышанасың. Гомумән, аның әсәрләрендә шундый матур урыннар, образлы итеп әйтелгән фикерләр һәм тирән хисле строфалар аз очрамый.

Клара үзенә тормыш бүләк иткән, балалары хакына тормышның ачысын һәм төчесен татыган, авырлыклар алдында тез чүкмичә, каушамыйча, шулар бәхетле булсын дип уфылдап һәм алҗып, авыр сулап булса да эшләп, тырышып-тырмашып тормыш алып барган, тамагы тук булсын, күңеле китек булмасын дип, үз өлешен бүлеп ашатып үстергән, тәрбияләгән, укыткан һәм кеше иткән, күңелендә һәм йөрәк түрендә чорыбызга авазлаш җыр чаткылары уяткан газиз анасына яратып һәм үз итеп «ак канатым, әнием, җан кисәгем» дип олылап эндәшә, аның изге анага ихтирамы һәм хөрмәте зур. Бу темага язылган кыска гына шигырьләрдә ананың балага һәм баланың «әйләнмәле тормыш чылбырында алмашын-

мас божра» булган ата-анага булган тирән мәхәббәте сурәтләнә.

Аз булмады жаның кыйган чагым.
Йөрәгеңне беләм — кичергән.
Үзем салган борчу сызыкларын
Ничек сөртим маңгай өстеңнән? —

ди автор. Бу юлларда бары тик аналарга гына хас гүзәл сыйфатлар да, баланың анага булган керсез мәхәббәте, мәңге суынмас күңел жылылыгы, бәһаләп булмаган зур хөрмәте һәм рәхмәте дә чагыла.

Кем белә, Клара Булатованың тар интим темалар белән артык мавыгуын, кирәгеннән артык өзгәләнүен билгеләп үтүчеләр арасында (Р. Башкуров, Ә. Давыдов, мәсәлән), бәлкем, дөреслек тә бардыр?.. Бәлкем, кайбер иптәшләргә шундый фикергә килергә авторның әсәрләрендә кыю һәм йөрәкле, артык тәвәккәл булуы төп сәбәп булгандыр. Әмма шагыйрә үзенең әчке драматизмга бай шигырьләрендә әчкерсез, ул алдаша белми, чын ихлас күңелдән яза һәм дөреслеккә омтыла. Аның лирик героена тормышта җан өшеткеч катлаулы кичерешләр дә, йөрәк әрнеткеч шәхси газаплар да күрергә туры килә, чын бәхет аңа җиңел бирелми. Ләкин үз башыннан трагик язмыш һәм фаҗигале мәхәббәт кичергән әлеге лирик героебыз беркайчан да, канатлары салындырылган кошка охшап, төшенкелеккә һәм пессимизмга бирелми, ул көрәшә, ул яктылыкка омтыла, кешеләргә таянып, «еллар күмеп киткән йөрәк яраларын» төзәтергә тырыша, ул сөю һәм сөелү хокукын даулый һәм авыр, ләкин таза, нык бәхеткә ирешә.

Шигырьләрдә саф мәхәббәт белән яраткан, сөйгәне өчен бөтенесен дә эшләгән һәм эшләргә әзер булган бердәнбер сөекле кешеңне бөтенләйгә югалту ярасыннан йөрәкнең бер сыкрап куюы — өметсезлеккә төшүдән ачыгланып, җәнҗалланып кычкыруы түгел, ә бәлки йөрәкнең олы кичереше, күңел түреннән бәреп чыккан моң булып гәүдәләнә. Тора-бара ялгызлык һәм кайгыру мотивлары, кичерешләрнең драматик киеренкелеген саклаган хәлдә, тормыш тантанасы темасына әверелә. Шуңа күрә, үтә интим күренгән әсәрләре дә укучылар күңелендә канәгатьләнү һәм теләктәшлек табалар.

«Яшьлек эзем калган...», «Ерак димәс идем...», «Көймәләре калган Енисейда» һәм башка шигырьләрен укыгач, лирик геройның тирән һәм сәламәт, кешелекле һәм саф, газаплы һәм шатлыклы «беренче һәм соңгы мәхәббәтенә» ышанасың.

Клара Булатованың туган якларның искиткеч ямьле, гүзәл табигатенә багышланган шигырьләре аеруча отышлы, бу темада ул үзен бигрәк тә көчле һәм иркен сизә, бу тема, әйтергә кирәк, аның стихиясе... Кыска һәм жыйнак кына шигырь тезмәләрендә, күңелгә сеңеп калырлык итеп, табигать күренешләренең бөтен нечкәлеген һәм нәфислеген сурәтли. Әсәрләрдә табигать күренешләре бары тик фон өчен генә бирелми, алар геройның олы кичерешләре, тирән тойгылары белән тыгыз элемтәдә һәм кеше тормышы белән бергә үрелеп, кеше күңеленең кешелеклелеген, күркәм якларын, бөеклеген һәм гүзәл сыйфатларын ачарга һәм аңларга ярдәм итә.

Шагыйрә табигатьне җаны-тәне белән, чын күңелдән ярата, беркайчан да сөеп туя алмаслык туган-үскән җиргә аның мәхәббәте зур, кайнар һәм көчле.

...Зәй буйларын кем куллары чиккән,
Исле гөлләр белән бизәлгән?
Юк, син кара,
Мин болардан китсәм,
Сыңар көн дә читтә түзәлмәм.
. . . . . . . . . . .
...Көн бик матур бүген.
Матурлыгын
Йөз шигырьгә булсаң житәрлек.
Зәй буеның шушы матур көнен
Казаннарга алып китәрлек.—

диган юлларда һәм табигать күренешләрен тасвирлауга багышланган башка шигырьләрендә ул аларның матурлыгына соклана, ерак җирләргә киткәч аларны сагынып яши һәм ямансулап юксына, кайда гына булса да табигатьнең гүзәллеген йөрәгендә үзе белән йөртә, күңелендә туган җир жылылыгын тоеп илһамлана.

Алай гына да түгел. Шагыйрәнең бөтен рухи тормышы табигать тормышыннан аерылгысыз. Ул «яшь топольләрнең нидер сөйләшүен,тургайлар жырын кыр тыңлавын» ишетеп, «куакларның черем итүен, былбылларның таңны көтүен, ай нурының дулкыннарда тирбәлүен, ромашкаларның кырда күз ачуын, алкаланып су өстендә таралган дулкыннарның май кичендә шаярышып куышуын, уҗымнарның елмаеп кояшка күтәрелүен, кояшның күзен кысып, яңалыгы белән яз аңкыткан шәһәргә сокланып тау өстендә тукталып торуын һәм аңардан аерылмаска теләп шәһәр өстен озак иркәләвен» күреп һәм сизеп шатлана, табигать тормышында күзгә күренмәгән, бары олы җанлы йөрәк белән генә тоеп булган серле үзгәрешләрне, мавыктыргыч нечкәлекләрне зур сизгерлек белән күзәтеп, сиземләп оста тотып ала һәм беренче җылы тәэсирләр суынганчы, аларны йөрәгә аша уздырып, шигъри аһәң белән укучыларга җиткерергә ашыга.

Клара Булатованың тынгысыз җаны җир-анага һәм җирдәге барлык җанлы нәрсәләргә эчкерсез һәм олы мәхәббәт белән сугарылган. Ул табигать картиналарына гашыйк, аларга үз итеп, дус итеп карый һәм табигать күренешләрен, андагы аерым детальләрне үзе белән тиң итеп күреп, алар белән сөйләшә, киңәшә, алар турында зур кайгыртучанлык күрсәтә һәм аларга ышана.

Менә «Ялгыз каен» шигыре. Яр буенда үскән ялгыз каенга автор:

...Кеннәр туган саен, каенкаем,
Үзәккәең нигә өзелә?..
...Бичкемең юк нигә янәшәңдә?
Гомерләрең ялгыз ник үтә?
. . . . . . . . . . . .
Ак кәүсәңдә синең кара эзләр...
Кемнәр икән шулай салганнар?
Минем дә бит, җаным, йөрәгемдә
Уелып калган кара ярам бар.
Сизәсеңме, каен? —

дип мөрәҗәгать итә һәм ялгыз каенның фаҗигасен аңлап, аңа үзенең моң-зарларын сөйләп бирә, еллар буе күңелендә авыр төер булып җыелып килгән уйларын бушатып сала. Шулай итеп, ялгыз каен белән лирик герой арасында ачыктан-ачык сөйләшү һәм аңлашу барлыкка килә. Лирик герой серле табигать күренешләрендә, табигать тормышы белән үзенең тормышында алар икесе генә аңлый ала торган зур охшашлык таба, бу аны ялгызлык тойгыларыннан арындыра, шушы охшашлык аңа тормышта зур өметләр белән, оптимист булып юанып яшәргә көч бирә һәм кыенлыкларны җиңәргә ярдәм итә.

К. Булатованың гади бер тәрәзә белән кеше уйларын һәм кичерешләрен сурәтләгән «Ә мин кичә әллә ничә тапкыр» дип башланган шигырен, башка әсәрләрендәге:

...Кайчак шулай ерак йолдызларның
Сулышларын тоя аласың...
...Бу җир якын миңа бүгенгесе,
Киләчәге белән тулаем...
...Шул серләрнең серенә төшенү белән
Кызык безнең җирдә бу тормыш.—

дигән юлларын укыгач, образлы итеп әйтелгән сүзләренә, шигырьләренең фәлсәфи тирәнлеген, андагы фикер тыгызлыгын арттыру турында нык уйлануын күреп шатланасың.

Туган җирнең гүзәллеген тасвирлауга багышланган барлык шигырьләрендә туган-үскән җир, туган ил һәм Кеше образлары, аларның үзара бәйләнеше, берберсеннән аерылмыйча, бергә үрелеп бирелә һәм болар барысы бергә сокландыргыч, гүзәл Ватаныбызның тулы канлы образын тудыралар.

...Клара Булатованың кайбер әсәрләрендә үз-үзен кабатлавы, матур фикер әйткәч тә вакытында нокта куя белмәве, кайбер фикерләрнең бер дә үстерелмичә әсәрдән-әсәргә күчүе турында үз вакытында бик дөрес тәнкыйть сүзе әйтелгән иде инде. Өстәп шуны гына әйтәсе килә:

Кларага иҗади хезмәт, аерым алганда, шигырьләр җиңел бирелә. Әсәрләрен укыгач, аның бер дә азапланмыйча, бертуктаусыз матур рифмалы строфалар яза алу сәләтен һәм мөмкинлеген тоясың. Әмма механик рәвештә, ничектер, автор теләгенә буйсынып үзеннән-үзе язылган һәм тезелгән строфалар иҗатта җавапсызлыкка китерә. Сирәк булса да, Клара әсәрләре арасында җиңел кулдан эшләнгән, таркау язылган шигырьләр дә очраштыргалый.

«Постта торам», «Шатлыгым», «Яз җыры», «Eминә», «Комсызлык» һ. б. шигырьләрдә Клара әсәрләренә хас булган тынгысызлык юк, тойгы тирәнлеге һәм йөрәк ялкыны да сизелми. Аларда авторның үз йөзен төсмерләве кыен. Дөресен генә әйткәндә, ул шигырьләр Клара өчен характерлы да түгел. Аларның тормыш җылылыгы бөркелеп торган әсәрләр белән бергә ряттән җыентыкларда урын алуы кызганыч.

Халык иҗаты әсәрләренә тартым җиңел тел белән язылган музыкаль яңгырашлы юллар үзләре үк моңлы җыр булып укучылар күңелен яктыртып җибәрәләр. Шуңардыр инде, шагыйрә сүзләренә композиторларыбыз дисталәгән популяр җырлар яздылар, ә аның сүзләренә язылган «Кыңгыраулар» җыры тиз арада еракларга таралып, халкыбыз тарафыннан иң яратып җырлана торган җырлар рәтенә керде.

Әсәрләрен укыгач, Клара Булатованың укучыларга күпне вәгъдә иткән табигый таланты булуына ышанасың һәм шатланасың. Аның таланты, шигърияте — иң беренче чиратта без көн саен уйлап йөргән, безгә якын булган гади уй-фикерләрне, тойгыларны поэтик детальләр аша шигъри формага әверелдереп шигъри аһәң белән үзебезгә җиткерә белүендә.

Иң әһәмиятлесе, иң куанычлысы шунда ки, ул һәрвакыт эзләнә, һәрвакыт юлда.

Шулай булачагына шикләнергә урын юк. Үзенең һәм каләмдәшләренең иҗатына зур таләпчәнлек белән караган сөекле шагыйребез мәрхүм Әнвәр Давыдов сүзләре белән әйткәндә, Клара Булатованың «шигъри таланты тормышның җитди, иҗтимагый әһәмиятле темаларына, гражданлык мотивларына якын килергә мөмкинлеге булуын күрсәтә».

**РАВИЛ ЛОТФУЛЛИН**

**1969** елда Татарстан китап нәшрияты Габдулла Шамуковның мәсәлләрен аерым җыентык итеп бастырып чыгарды[1]. Бу җыентыкка, үз әсәрләреннән башка, авторның тәрҗемәләре дә урнаштырылган. Тәрҗемәләр турында сүз кузгатмыйча, турыдан-туры оригинал әсәрләргә тукталасы килә.

Гел мәсәлләрдән генә торган шактый зур күләмле китапны кулга алгач, бу кадерле нәрсәне укып чыгарга көч җитәрме дип, куркыбрак калдым. Ни дисәң дә, гел аллегорик алым белән язылган, бер төсле формадагы әсәрләр зиһенне ялыктыра. Әмма куркуым юкка булган икән: китапны башыннан ахырына кадәр бер дә ялыкмыйча укыдым, чөнки бирегә тупланган әсәрләр оста һәм үткен каләмле әдип тарафыннан иҗат ителгән. Тематикасы ягыннан төрле булган кебек, язылу формасы белән дә күп төрле алар. Кайберләре традицион «Эзоп теле» белән, мәсәл жанрының үзенчәлекләрен нык саклаган хәлдә иҗат ителсә, икенчеләре мәсәлдән бигрәк шигырьгә тартым. Аларда хәрәкәт итүче геройлар без укып күнеккән хайваннар яки җансыз предметлар түгел, ә безнең арабызда ук яши торган гадәти кешеләр. Г. Шамуков мәсәлләренең үзенчәлеге һәм заманчалыгы да нәкъ менә шунда күренә. Җыентыкка сүз башы язган тәнкыйтьче Нил Юзиев та Г. Шамуков мәсәлләрендәге бу үзенчәлеккә игътибар иткән: «Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр турында сөйләүче шундый аллегорик образлардан һәм шартлы вакыйгалардан тыш, Г. Шамуков хәзерге заман мәсәлендә активлаша башлаган яңа алымнарны, әйтик, шигъри фикерне төрле предметлар аша яки турыдан-туры кешеләрнең үз образлары аша ачу алымын да куллана».

«Чүлмәкче белән Исерек» мәсәлендә антик әдәбияттан ук килгән традицион Бүре яки Аю образлары юк. Сүз бер исерек кешенең сокландыргыч матур чүлмәкләрне типкәләп, ватып бетерүе турында бара. Чөнки исерек күзенә чүлмәкләр ямьсез, гарип булып күренә. Автор, мораль өлешен кертмичә, әсәрне шуның белән тәмамласа да фикер тәгәлләнер, тик бу вакытта ул үзенең мәсәллеген югалтыр иде. Автор әсәрдәге фикерне тагын да үстереп җибәргән. Гадәттәге мәсәлләрдәгечә мораль өлеше әсәрнең идеясен ачып бирү өчен генә кулланылмаган, ә фикерне үстерү, бер гыйбарәтле хәлдән икенче төрле яңа нәтиҗә ясау өчен дә кулланылган:

> Айныгач та аның күзе төзәләчәк,
> Бу эш өчен үкенәчәк
> һәм сугәчәк
> Үзен үзе;
> Әмма, дустым, һич тә кәтмә,
> Төзәлер дип өмет итмә
> Аек килеш кыйшык күрүченең күзе.

Әйе, исерек кеше бер айныр, бәлки аның болай исерүе дә беренче тапкырдыр. Гадәттә эчми эчкән кешеләр шулай «мәзәк» күрсәтүчән була бит. Әмма айнык килеш исереп йөрүчеләрне төзәтүе, чынлап та, кыен.

«Ефрейтор» әсәренең идеясе дә тормыштагы кешеләр хәрәкәте аша ачыла. Ефрейторга көннәрдән бер көнне взвод тапшырганнар һәм бер взвод солдат аның командалыгында атлап килә. Тик, гөнаһ шомлыгына каршы, ефрейторның адымы ялгыша. Ләкин башка солдатларга карап үз адымын дөреслисе урында, ул, үзенә бирелгән властьтан файдаланып, башкаларны ялгыш адымга этәрә... Автор, тышкы портретындагы кайбер штрихлар аша, Ефрейторның нинди кеше икәнлеген, холкынфигылен ача. Менә ул «купшы басып, күкрәк киереп, борын яфракларын өрелдереп» атлап килә. Үзенә шундый зур взвод тапшыруларына ул бик канәгать: «Авызы җиткән колагына». Мактанчык, һаваланырга яратучы, үзенең «бөеклегенә» чиктән тыш ышанучы кешенең эчке портреты гаять оста һәм саран детальләр аша ачылган.

Менә шундый эчке портрет осталыгы «Аптыраш» әсәрендә тагын да ныграк чагыла:

> Верәү тәмам аптыраган
> Бер дустына очраган;
> «Ни булды? Ник төсең китте?» — дип сорагаң.
> Әйткән теге: — Яңа гына
> Хуҗам чакырып шундый сорау бирде миңа:
> Зинһар, тизрәк әйтсәнә, ди,
> Кайсы тирәсендә кайсы әйләнә, ди,
> Кояшмы Җир тирәсендә,
> Җирме Кояш тирәсендә?

Билгеле, бу мәхлук Җирнең кояш тирәсендә әйләнгәнлеген яхшы белә. Тик ул хуҗасына туры җавап бирүдән генә курка, чөнки аның начальнигы киресенчә уйларга мөмкин. Үз начальнигына ярарга тырышучы ялагай кешенең «драма»сы чагыла бирәдә. Шул ук вакытта әсәрнең логикасы «начальник»ның да тугрылыклы кеше түгеллеген

[1] Г. Шамуков. Мәсәлләр. Казан. 1969 ел.

күрсәтә. Дөреслекне яратучы кеше булса, үз тирәсенә куштаннарны, үз кубызына гына биючеләрне җыймас иде. Автор монда бер ук белән ике куянга аткан һәм икесенең дә нәкъ йөрәгенә тидергән.

Формасы белән бу әсәрнең традицион мәсәлләрдән шактый үзгә икәнен әйтми булмый. Гадәттәге мораль өлеше дә юк. Сатирик шигырь дип әйтергә булыр иде моны. «Саф мәсәлләр» белән сатирик шигырь арасында торган әсәрләр рәтенә тагын Г. Шамуковның «Саф егет»ен кертергә мөмкин. «Өч балалы һәм хатынлы, шактый олы» яшьтәге кешенең яшь кенә кыз белән йөри башлавын күреп, әсәрнең лирик «мин»е аптырап кала. Күп тә үтми, теге «егетебез» тагын «мин»гә очрый, бу юлы инде янында чибәр кыз булмый. «Егет» ялгыз.

— Чибәркәең кайда, дускай,— дим мин моңа.
— Ташладым бит мин ул кызны...
— Китче! Нинди шайтан бозды
Арагызны?

Шушы сорауга җавап биргәндә теге «егет»нең чын йөзе ачыла. «Бик бозык кыз булып чыкты, хатыным барын белә торып, мине ул аздырып йөрткән»,— дип, үзен саф итеп күрсәтергә теләве һәм гаебен кешегә аударырга тырышуы бу кешенең никадәр түбән һәм мескен икәнен күрсәтә. Хатыны, балалары бар аркылы кызлар белән йөрүе бер әшәкелек булса, үз гөнаһын башкаларга ыргытуы икенче начарлык. Автор шактый әчкә яшерелгән ирония аша кеше характерындагы иң үзенчәлекле моментны тотып алган һәм кыска гына шигъри юллар белән шуны ача алган. Әсәрнең диалогка корылуы, әсәрдәге сурәтләнгән хәлләргә йомгак ясаганда авторның катнашмавы һәм геройның үзенә-үзе үтергеч характеристика бирүе аны тагын да отышлы иткән. Әгәр дә автор «хатыным барын белә торып, кыз мине аздырып йөрткән» дигән сүзләрне геройның үз авызыннан әйттермәсә, ирония бетәр һәм әсәр сатирик үткенлеген югалтыр иде.

Г. Шамуков үз геройларының психологиясен яхшы аңлап эш итә. Һәр әсәрендә вакыйгаларның яки кичерешләрнең иң кабарынкы моментын гына тасвирлана. Теле үткен. Тешләгәндә шактый авырттырып тешли. Сатирик әсәрләр өчен нәкъ менә шулар кирәк тә инде.

Шагыйрь сатира белән эш итәме яки лирика беләнме, ул тормыш матурлыгын раслый. Тормыштагы кире күренешләрне сурәтләп нәфрәтләндерә, уңайларын бөтен матурлыгы белән күрсәтеп тормышка мәхәббәтебезне арттыра. Г. Шамуков, мәсәлләр остасы буларак, сатира белән эш итә. Әмма аның мәсәлләре арасында да тормыш матурлыгына мәдхия бар. Фикеребезне раслар өчен Крыловтан алынган «Карт һәм үлем» мәсәләнә тукталу отышлы булыр. Бу әсәрдә сатира бөтенләй юк. Автор берәүне дә камчыламый. Биредә нечкә юмор һәм тапкырлык кына күрергә мөмкин. Авыр эштән һәм фәкыйрьлектән интеккән Карт кочагына утын күтәреп кайта. Байга эшләп, ясак түләп яшәүдән тәмам туйган һәм йөдәгән ул. Шушы хәлдән башка котылу чарасы күрмичә, ул Газраилне чакыра. Әмма Газраил аның җанын алырга килгәч:

Чакырдым мин...
Күтәрешмәссең микән дип шул утынны.—

ди. Бик оста әйтелгән. Кешенең оптимистлыгына дан бу! Нинди генә хәлдә булмасын, вакыты-вакыты белән бераз йомшап, төшенкелеккә бирелсә дә, барыбер яшәүдән туймый.

Соңгы сүз итеп шуны әйтәсе килә: авторның һәр әсәре чарланган, һәр сүзе дә урынында. Ләкин мәсәлләрдәге ритм бертөрлелеге турында да әйтми булмый. Әсәрләр, яңгырашы ягыннан бер генә кылга корылган музыка коралын хәтерләтәләр. Шигырь язган һәркем белә: һәр әсәрнең үз «көе» була. Дөрес, кайбер әсәрләрдә оста үреләп бирелгән диалоглар интонацияне үзгәртеп җибәрергә ярдәм иткәннәр. Тик алар гына зур бер җыентыкны бертавышлылыктан коткара алмаган.

ФӘНИС ЯРУЛЛИН

Гомәр Саттаров

# ТАТАРСТАН РАЙОННАРЫ ҺӘМ РАЙОН ҮЗӘКЛӘРЕНЕҢ ИСЕМНӘРЕ

Гамәлдәге административ-территориаль бүленеш буенча республикабызда 36 район бар. Билгеле бер эзлеклелек булсын өчен, алфавит тәртибен саклап, аларның исеме кайдан алынуын ачыкларга тырышыйк.

**АЗНАКАЙ РАЙОНЫНЫҢ ИСЕМЕ** үзәге Азнакай исеменнән алынган. Азнакай 1956 елдан башлап эшчеләр поселогы категориясенә керә. Бу атаманың нигезендә Атнакай дигән кеше исеме ята дип карыйбыз. Бу исем, татар теленең Минзәлә сөйләшенә хас т-д-з тартыклары тәңгәллеге җирлегендә үзенчәлекле фонетик үзгәреш кичереп, Азнакайга әйләнгән. Минзәлә сөйләшенә шактый якын булган башкорт телендә Азнабай, Азнагол, Азнакилде кебек кеше исемнәре бар.

Атнакай (Азнакай) исеме **атна** һәм **кай** компонентларыннан тора. Борынгы вакытта татарларда **атна** сүзе **җиде тәүлек** (неделя) мәгънәсендә дә һәм **җомга көн** мәгънәсендә дә кулланылган. Әле хәзер дә татар теленең көнбатыш диалектында, урта диалектның Тау ягы сөйләшләрендә пәнҗешәмбе көнне «кич атна» яки «атна кич», җомга көнне «атна көн» дип атыйлар. Борынгы заманнарда татарлар яхшы, изге көн дип саналган **атна көнне** (җомга) туган ир балаларга шул көн исемен кушу йоласы булган. Әтнә, Әтнәгол, Әтнәбай, Атнахуҗа, Атнакилде, Атнакай, Азнакай һ. б. кебек исемнәр әнә шул йолага нисбәтле рәвештә барлыкка килгәннәр. Атна (азна) сүзенә иркәләпяратып әйтүне белдерә торган кеше исемнәре ясаучы — **кай** кушымчасы ялгану юлы белән (чагыштыр: Күзкәй, Канкай, Тиңкәй, Сатукай, Сылукай, Ишкәй, Котлыкай, Чупакай, Миңлекәй, Йөзлекәй, Тимеркәй һ. б.) Атнакай (Азнакай) дигән антропоним (кеше исеме) ясалган һәм авыл исеменә әверелеп безнең көннәргәчә сакланган.

Борынгы йола тәэсирендә, **атна көн** термины урынына гарәп теленнән алынган **җомга** (җыелу көне) термины кулланыла башлагач та, татарларда шул көнне туган балаларга **җомга** (диалекталь әйтелештә **җома** яки **йома**) сүзен кертеп исем бирү дәвам иттерелгән: Җомагол, Җомахуҗа, Җомабикә, Җомагали, Җомабай, Җомакай яки Йомакай (соңгысыннан баштагы **җо-йо** иҗеге төшү нәтиҗәсендә Макай исеме һәм Макаев фамилиясе ясалган) һ. б.

**АКСУБАЙ РАЙОНЫНЫҢ ИСЕМЕ** шушы районның үзәге Аксубай авылы исеменнән алынган. Бу атама Аксубай дигән борынгы кеше исеменә мөнәсәбәтле.

Башка төрки телләрдәге кебек, татар телендә дә **ак** һәм **кара** сүзләре ялгызлык исемнәренең барлык төрләрен (антропонимнар — кеше исемнәре; топонимнар — географик атамалар; зоонимнар — хайван исемнәре; этнонимнар — халык исемнәре һ. б.) ясауда актив катнашкан. Мәҗүсилек чорында төрки халыклар **ак** һәм **кара** сүзләренең магик көче бар дип санаганнар. **Ак** төсне **пакьлык, тазалык, яктылык, бәхет, көн, кояш** символы, ә **кара** төсне **төн, туфрак, җир** символы итеп караганнар, утка һәм кояшка багышлап ак төстәге, ә җиргә багышлап кара төстәге кош-корт яки хайван чалганнар. Бу йолаларның калдыклары озак сакланган. Академик Л. Я. Штернберг кояш хөрмәтенә

ак хайван корбан итүнең гомумилеге һәм барлык халыкларга хас булган кояш культында ак төснең «алтын кояш белән ассоциацияләнүе» турында яза [1].

Татар антропонимиясендә **ак** сүзе кушылып ясалган кушма тамырлы борынгы кеше исемнәре бик күп. Мәсәлән, Актуган, Акбаш, Акбатыр, Акъегет, Акбит, Акчура, Акбулат, Аппак, Акбарс, Акбуга, Актимер, Акбүләк, Аксубай һ. б.

Соңгы исем **ак+субай** сүзләреннән тора. Борынгы татар теленә фарсы теленнән кергән **сыбай** сүзе **атлы сугышчы** (кавалерист) дигән төшенчәне белдергән. Татар теле сөйләшләрендә шул мәгънәсендә әле дә сакланган. Мәсәлән, пәйнә, эчкен һәм красноуфим татарлары телендә **сыбай — җайдагат** (всадник): «**Бригадир сыбай йөри**» [2]. Аксубай исемендә, икенче компонент буларак, шушы сүз чыгыш тапса кирәк. Хәзергечә Аксубай исемле район үзәге Аксубай (чуваш авылы) атамасында һәм татарларда Субаев фамилиясендә сакланган. Әлмәт районында Ерсубайкино (исеме Ирсубайкай дигән антропонимнан ясалган чуваш авылы) һәм Балык бистәсе районында Юлсубино (атамасы Юлсубай дигән кеше исеменнән ясалган татар авылы) авыллары бар.

**АКТАНЫШ РАЙОНЫНА** үзәге Актаныш авылы исеме бирелгән. Бу топонимның нигезендә Актаныш дигән елгачык исеме ята. Шушы елгачык башланып киткән урынга урнашкан авыл Актанышбаш исемен йөртә. Актаныш гидронимы **агыт** [3], **акты+аныш** сүзләреннән тора.

Борынгы төрки телгә хас **акты, акту, агыш** фигыленең соңгы иҗеге төшеп калу нәтиҗәсендә бәрлыкка килгән «ак» сүзе төсне белдерә торган «ак» сүзе белән бердәй әйтелеш алган, ягъни омонимлашкан.

**Аныш** сүзе борынгы телебездә **елга** һәм **инеш** мәгънәсендә кулланылган. Чувашиядә Иделгә коя торган шактый зур Аниш елгасы бар. Аңа Югары Аниш, Урта Аниш һәм Түбән Аниш дигән елгалар коялар. Татарлар хәзер дә зур булмаган елгачыкны **инеш** дип йөртәләр.

Димәк, Актаныш гидронимы борынгы телебездә (Идел — Кама болгарлары телендә) **акты+аныш** компонентларыннан гыйбарәт булып, **ага торган аныш (инеш)** дигән төшенчәне белдергән. Мәгънәне үзгәртеп кабул итү нәтиҗәсендә, Актаныш авылы һәм районы исемен хәзерге татар телендә «ак таныш» (ак булган билгеле кеше яки әйбер) мәгънәсен белдерә, дип аңлыйбыз.

Җирле халык Актаныш авылы уртасыннан агып уза торган кечкенә генә, сай һәм болганчык сулы елгачыкны (Иске Иделгә коя): «Элек Акинеш дип аталган, тора-бара Актанышка әйләнгән»,— дип сөйли.

**АЛАБУГА РАЙОНЫНЫҢ ИСЕМЕ** үзәге Алабуга шәһәре исеменнән алынган. Алабуга шәһәре XVI гасырның икенче яртысында нигезләнгән.

Төрки халыкларда **алабуга** дип **окунь** балыгын атыйлар. **Бога-буга-бука** сүзе борынгы төрки телдә **үгез** дигән мәгънәдә йөргән. Тара татарлары хәзер дә үгезне бога диләр. Шушы мәгънәсендә **бога** сүзе борынгы венгр теленә кабул ителгән. Рус телендәге «бык» та «бога-бука»дан килеп чыккан дигән караш бар. Алабуга балыгының башы **ала үгез** башына охшаганга, аңа шул исем бирелгән дип саныйлар.

Алабуга сүзе төрки халыкларда кеше исеме буларак та кулланылган. Баланың үгез кебек көчле булуын теләү ырымына бәйләнешле рәвештә, составына **бога-бука** сүзе кергән: Букатимер, Тимербука, Бишбука, Акбуга, Айбуга, Илбука, Котлыбуга, Тайбуга, Тәгәлбуга, Сарыбуга, Ташбука, Төгәлбуга, Бугаарслан (шуннан: Бугруслан шәһәре исеме һәм Бугрусланов фамилиясе) һ. б. кебек кушма төзелешле борынгы кеше исемнәре кулланылышта йөргән. Алабуга шәһәренең исеме Алабуга дигән кеше исеменнән алынган булырга тиеш. Тамбов һәм Тобол губерналарында Алабуга исемле авыллар булган [4].

---

[1] Л. Я. Штернберг. Орнамент из оленьего волоса и игл дикообраза. «Советская этнография» журналы. 1931 ел. 3—4 саннар. 120 бит.

[2] Татар теленең диалектологик сүзлеге. Татарстан китап нәшрияты. Казан. 1969. 377 бит.

[3] **Агыт** термины Төмән өлкәсе Төмән районындагы Интряй авылы халкы телендә **елга, ермак** мәгънәсендә кулланыла.

[4] П. Семенов. Географическо-статистический словарь Российской империи. Рус телендә. 1 том. СПб. 1863 ел. 39 бит.

**АЛЕКСЕЕВСК РАЙОНЫНЫҢ ИСЕМЕ** үзәге Алексеевское **авылы** исеменә мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килгән.

И. А. Износков бу авыл исеменең 1846 елда Мәскәү митрополиты изге Алексей хөрмәтенә салынган чиркәү исеменнән алынуына, элекке исеменең янында зур күл булудан чыгып, Киркуль (татарча **кыр+күл**—Кыркүл) дип аталуы турында яза[1].

**АПАС РАЙОНЫНЫҢ ИСЕМЕ** үзәге Апас авылы исеменнән алынган. Авыл картларының сөйләвенә караганда, бу атама гарәп теленнән кергән **Габбас** дигән кеше исеменең фонетик үзгәреш кичерүе нәтиҗәсендә барлыкка килгән.

Безнең карашыбызча, **Апас** — шушы авылга нигез салган кешенең мәҗүси исеме. Элек болгар-татарлар һәм чувашлар арасында **Абачъ, Апасъ** кебек кеше исемнәре кулланылышта йөргән[2]. Болар—**ач** кушымчасына беткән борынгы төрки кеше исемнәре (мәсәлән, Тукач, Тутач, Пимач, Имач, Богач, Карач, Ювач, Котрач, Тапач, Балтач һ. б.) группасына карыйлар. **Апач** исеме **аба** — өлкән ир туган, абый сүзенә **ач** кушымчасы ялганып ясалган булырга тиеш. Сүз азагындагы **ч** тартыгының **с** тартыгына күчүе — татар теленең Тау ягы сөйләшләре өчен характерлы күренеш. Шушы җирлектә Абач—Апач исеме Апаска әверелгән. Татарстанның Арча районында **Апаз**, ә Актаныш районында **Апач** исемле татар авыллары булуы да игътибарга лаеклы. Боларда бер үк топоним мисалында татар теле сөйләшләрендә **ч-с-з** тартыкларының тарихи чиратлашуы чагылыш таба.

**АРЧА РАЙОНЫНЫҢ ИСЕМЕ** үзәге Арча эшчеләр поселогы исеменнән алынган. Арча атамасының беренчел нигезендә удмурт халкының борынгы исеме **ар** ята. XIV—XVI гасырларда **Арча җире** (Арская земля) термины арлар (удмуртлар) яши торган территория дигән төшенчәне белдергән, Чуваш тарихчысы П. В. Денисов **ар** сүзе «урман кешесе» мәгънәсен белдерә дигән карашта тора[3].

Арча топонимы **ар** этнонимына (халык исеме) — **ча** кушымчасы ялганып ясалган. **-ча, -чә** кушымчалары төрле сүз төркемнәренә караган сүзләргә ялганып, әйбернең һәм билгенең кечкенәлеген, тулы түгеллеген белдерә торган сүзләр ясыйлар: **кисәкчә, сыекча, алача, кодача, калдырча, борча, көлчә, телчә, бетчә, сүзлекчә, төрчә, сапкынча, җиңелчә, кызмача** һ. б. Хәзерге Арча поселогы урынында борынгы заманнарда арлар (удмуртлар) яшәгән кечкенә генә бер авыл булган булса кирәк. А. Артемьев «Арск» дигән мәкаләсендә: «Арчада борынгы заманнан калган җир ныгытма, валның саклануы...»[4] турында яза.

Арча топонимының әйтелеш бердәйлеге, охшашлыгы нигезендә артыш агачының бер төрен белдерә торган **арча** сүзе белән бәйләнеше юкмы, ул шушы сүздән алынмаганмы? Арча агачы безнең якларда үсмәгәнгә, болай дип карый алмыйбыз. Арча куаклары һәм урманнары Урта Азия тауларының субальп поясында үсәләр[5].

Әйтелеш ягыннан **Арча атамасы** белән **арча** сүзе үзара омоним (аваздаш сүз) тәшкил итәләр. Семантик яктан төрле мәгънә белдерәләр. Менә шуңа, Йосыф Гәрәй иптәш кебек[6], Арча топонимының килеп чыгышын агач исеме арча белән бәйләп булмый.

**БАЛТАЧ РАЙОНЫНЫҢ ИСЕМЕ** үзәге Балтач авылы исеменә нисбәтле. Бу атаманың нигезендә **балта** сүзенә — **ач** иркәләү-кечерәйтү кушымчасы ялганып ясалган кеше исеме ята. **Балта** сүзен исем итеп бирү исә борынгы вакытта татарларда бала авыруларга, усал көчләргә бирешмәсен, таза-нык булып үссен дигән теләктән чыгып, аңа каты, нык әйберләрнең исемен бирү йоласы булу белән бәйләнешле. Борынгы заманнарда металл әйберләре (мәсәлән, балта, ат дагасы, кылыч, хәнҗәр һ. б.) усал көчләрне куркыта, аларны китерми дип ышанганнар. Балта — хуҗалыкта еш кулланыла торган корал, каты һәм үткен металл әйберләрнең берсе. Ир балаларга составларында

---

[1] И. А. Износков. Список населенных мест Казанской губернии с кратким описанием их. Лаишевский уезд. Рус телендә. 1893 ел. 4 бит.

[2] В. К. Магницкий. Чувашские языческие имена. Казан. 1905 ел. 24 һәм 28 битләр.

[3] П. В. Денисов. Религиозные верования чуваш. Рус телендә. Чувашгосиздат. 1959 ел. 42 бит.

[4] А. Артемьев. Арск. «Казанские Губернские ведомости». 1847 ел. 10 сан.

[5] Краткая географическая энциклопедия. Т. 1, М. 1960. 142 бит.

[6] Йосыф Гәрәй. Сүз җыярга килегез! «Казан утлары» журн. № 10. 1969. 155 бит.

балта сүзе булган: Балтач, Болтай, Балтан, Балтук, Балтавар, Балтабай, Балтакол, Бишбалта һ. б. кебек исемнәр кушылган. Балтач исеме Болгар чоры кабер ташы язмаларында байтак очрый [1], республикабызның Кама тамагы, Әгерже, Азнакай, Актаныш районнарында һәм Башкортстан АССРда шушы исемне йөртүче авыллар бар. Бу авылларның кайберләре Болгар чорында ук барлыкка килгән булса кирәк. Татарларда Балтачев фамилиясе дә очрый.

И. А. Износков Балтач (русча Балтаси) атамасын татарча «бал тач» сүзләреннән тора, дип карый. Кайчандыр бу авыл кешеләре күп итеп бал корты асраганнар һәм, шуннан чыгып, бу авылда бар да бал, балтесь, дип әйтерлек булган [2], ди. Болай аңлату дөреслеккә туры килми, әлбәттә. Балтач авылының Аманова, Ахматово дигән икенче бер исемнәре дә булган. Болар барысы да шушы авылга беренче башлап нигез салган кешеләрнең исемнәре булырга тиеш: **Балтач**, **Аман** һәм **Әхмәт**.

**БАЛЫК БИСТӘСЕ РАЙОНЫНА ИСЕМ** итеп үзәге Балык бистәсе авылы исеме бирелгән. Балык бистәсе авылы турында «Памятная книга Казанской губернии на 1863 год» (Казань. 1862. 122 бит) дигән китапта түбәндәге мәгълүматлар урнаштырылган: «авылның исеме күрсәткәнчә, монда беренче килеп утыручылар балыкчылар булганнар. Балыкны, мөгаен, Казан патшалары сараена җибәргәннәрдер. XVI гасырның азагында Борис Годунов җир үлчәүчеләргә барлык буш җирләрне патшага язарга куша һәм бу урын да шунда теркәлә. Башта монда дворцовыйлар һәм һөнәрчеләр, ә аннан соң патшага балык тотарга һәм оброк түләргә тиеш булган балыкчылар килеп утырганнар». П. Семенов [3] һәм И. А. Износков та, Балык бистәсе авылы турында сүз алып барганда, шушы фактларны китерәләр. И. А. Износков тагын: «Бик күптәнге заманнардан бирле бу авыл кешеләренең кайберләре көмешчелек һәм бакырчылык эше белән шөгыльләнүләре, сату өчен төрле савыт-саба, бизәнү әйберләре, ат сбруе ясаулары, ә хатын-кызларның пароход пристанենда сәүдә итү өчен челтәр әйберләр бәйләүләре» [4] турында яза.

Балык бистәсе атамасында игътибар итәргә кирәкле тагын бер момент бар. Бу исемдә шәһәр читләрен атау өчен кулланыла торган **бистә** термины урын ала һәм аның **балыкка** нисбәтлелеген белдерүче изафәтле сүз тезмәсе (**балык бистәсе**, ягъни **бистә балыкныкы**) төзи.

Борынгы төрки телдә **балык** сүзе ике мәгънә аңлаткан: 1) су җәнлеге балыкны һәм 2) шәһәрне.

Топонимик **Балык бистәсе** сүз тезмәсенең беренче өлеше борынгы төрки телдә шәһәр мәгънәсендә йөргән **балык** (balyk) сүзе [5] дип карaганда (мәсәлән, Бишбалык һәм Арыкбалык — Төркстандагы борынгы шәһәрләр), бу атаманың компонентлары арасында тыгыз логик бәйләнеш барлыкка килә. Ул вакытта Балык бистәсе дигән сүз тезмәсе «шәһәр бистәсе» дигән мәгънәне белдерә. Бу атама әлек бу авыл урынында борынгы шәһәр бистәсе булуга ишарә итә. Моның чыннан да шулай булуы бик ихтимал. Киләчәктә анда археологик казынулар алып бару бу тирәләрдә борынгы шәһәр калдыклары табылуга китерергә мөмкин. Безнең крайда шәһәр яки крепость мәгънәсендә белдерелгән башка архаик сүзләрнең топонимнар составында саклануы да игътибарга лаеклы: Ташкирмән, Таукирмән (**кирмән** — крепость, шәһәр) — Лаеш районындагы авыллар; Иске Кирмәле, Яңа Кирмәле — Зеленодольск районындагы авыллар; Урта Кирмән, Кече Кирмән — Мамадыш районындагы авыллар; Аккирмән — Оренбург өлкәсендәге поселок; Калатау, Кызкала — болгар чоры топонимнары һ. б.

**БАУЛЫ РАЙОНЫНЫҢ ИСЕМЕ** үзәге Баулы исеменнән алынган.

Баулы авылының төзелүе һәм исеменең барлыкка килүе турында авыл картлары мондый риваять сөйлиләр:

---

[1] Г. В. Юсупов. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. Рус телендә. М.—Л. 1960 ел. 108 бит.

[2] И. А. Износков. Список населенных мест Казанского уезда с кратким их описанием. Казан. 1885 ел. 4 бит.

[3] П. Семенов. Күрсәтелгән хезмәт. IV том. 1873 ел. 358 бит.

[4] И. А. Износков. Список населенных мест Казанской губернии с кратким описанием их. Лаишевский уезд. Казан. 1893 ел. 22 бит.

[5] С. Е. Малов. Памятники древнетюркской письменности. Рус телендә. М.—Л. 1951 ел. 368 бит.

«Баулы утырган урын борынгы вакытларда калын урман белән капланган булган. Бу урманда төрле җәнлекләр яшәгән, агач куышларында бал кортлары күп булган. Бер җәйне монда өч башкорт килеп чыккан. Алар Бакыр тавы итәгенә авыл корганнар. Елга буенда бик күп бал кортлары күргәннәр. Бер куыш агачны кисеп аударганнар. Ул елгага аркылы авып ярылган. Елга өсте бал һәм кәрәз белән тулган. Корман исемлесе: «Авылыбызга нинди исем кушабыз?» дигән. Болар авылга, әлеге бакыйгадан чыгып, Баллы елга дип исем кушарга булганнар. Баллы елга халык теленә Баулы елга булып кереп киткән.

Баулы авылының бер өлешенә мишәрләр килеп утырганнар. Алардан: «Сез кайсы авылдан?» дип сорасалар, «Без Мансур авылыннан, Баллы төштән (биредә **төш** сүзе **урын** төшенчәсен белдерә — Г. С.), дигәннәр».

Бу риваятьтән чыгып, авыл исеменең «Баллы төш»тән Баулы булып үзгәрүен аңлатуы кыен. Чөнки татар теле тарихында **л-у** (w) тартыкларының тәңгәллеге очрамый.

Әйбернең яки күренешнең булуын белдерүче **-лы, -ле** кушымчалары татар топонимиясендә продуктив кулланылалар. Алар үсемлек, агач, кош-корт, хайван, балык, минерал, корылма, йорт инвентаре, хуҗалык әсбапларын һ. б. белдерә торган исемнәргә ялганып килү юлы белән күп кенә топонимнар ясаганнар. Мәсәлән, Кыяклы, Камышлы, Зирекле, Каенлы, Балчыклы, Чуртанлы, Буралы, Баулы һ. б.

Баулы поселогының исеме хуҗалык әйбере — **бауга** (аның булуына: **баулы**) нисбәтле рәвештә барлыкка килгән булырга тиеш. Бу атама авыл халкының электә бауаркан ишү һөнәре белән шөгыльләнүе нәтиҗәсендә ясалган булса кирәк.

**БИЕКТАУ РАЙОНЫНА** үзәге Биектау поселогының исеме кушылган. Бу атама **биек+тау** компонентларыннан тора. Бу авылга калкурак урынга утырганга күрә, Биектау дигән исем бирелгән [1]. Чагыштырмача зур, биек булмаган калкулыкка урнашкан торак пунктларның кайберләренә әлеге исем тагылган. Биектау исемле авыллар Әгерҗе һәм Балык бистәсе районнарында да бар. Казан артындагы Биектау (Высокая Гора) авылы кебек, алар да биек булмаган, хәтта тигез дип әйтерлек урынга утырганнар. Безнең якларда Тау иле дип аталган авыллар да артык зур булмаган **тау итәгенә** яки **тау өстенә** урнашканнар.

**БУА РАЙОНЫНЫҢ ИСЕМЕ** үзәге Буа шәһәре исеменнән алынган. Бу атама исә ясалма су саклагыч **буага** мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килгән [2]. Буа, бөя дигән гидронимик терминның топонимлашуы Тау ягының башка төбәкләрендә дә урын ала. Мәсәлән, Апас районында Иске Буа, Яңа Буа (Кыр Буасы) исемле авыллар бар.

Проф. Н. И. Золотницкий Буа шәһәренең исеме, оборона максатыннан чыгып, җир казып-өеп ясалган плотина, ягъни җир ныгытма (буа) белән мөнәсәбәтле, анда башта саклау линиясенең каравыл пункты булган булырга тиеш дип карый. Буа шәһәре тирәсендә бик борынгы заманнарда, Болгар һәм Казан ханлыклары чорында корылган һәм XVII—XVIII гасырларда төзелгән җир корылмалар булуы турында яза [3].

Хәзерге Буа шәһәре урынында шул исемдәге авыл 1703 елда барлыкка килгән. Буа 1780 елда Сембер наместничествосының өяз шәһәре итеп билгеләнә.

**БӨГЕЛМӘ РАЙОНЫНА** үзәге Бөгелмә шәһәре исеме бирелгән. Шәһәр атамасы аның аша ага торган Бөгелмә елгачыгы исеменнән алынган. Бу елгачыкка, **бөгелә-бөгелә** бормаланып агуыннан чыгып, әлеге исем бирелгән булырга тиеш. Чагыштыр: **Уратма** — уратып ага торган елга (Зәйгә коя), **Шушма** — шуыша, су юлын үзгәртә торган елга (Вяткага коя) һ. б.

Бөгелмә шәһәре урынында башта шушы исемне йөрткән татар авылы була. Бөгелмәнең шәһәр буларак салына башлавы 1741—1745 елларга карый. Шәһәрнең әүвәлге халкын җир эше белән шөгыльләнүче солдатлар, ясаклы крестьяннар һәм сөргенгә җибәрелгән кешеләр тәшкил иткән. 1781 елда Бөгелмә рәсми рәвештә шәһәрләр категориясенә кертелә.

---

[1] И. А. Износков. Список населенных мест Казанского уезда с кратким их описанием. Казань. 1885 ел. 2 бит.

[2] В. А. Никонов. Краткий топонимический словарь. «Мысль» нәшрияты. М. 1966. 69 бит.

[3] Н. И. Золотницкий. Название гг. Буинска и Цивильска, некот. селений и р. Цивиля.— Корневой чувашско-русский словарь. Казань. 1875. 265—266 битләр.

**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК РАЙОНЫ** үзәге Зеленодольск шәһәре исеме белән аталган. Шәһәр исеме Зеленый дол — ложбина[1] (Яшел уйсулык) авылы исеменнән алынган. Бу авыл 1932 елдан шәһәргә әйләнгән.

Зеленый дол авылы 1820 еллар тирәсендә Зөя өязенең Вязовых һәм башка авылларыннан күчеп килеп утыручылар тарафыннан нигезләнгән. Авылга исем утырган урынының тышкы формасыннан чыгып кушылган[2].

**КАМА ТАМАГЫ РАЙОНЫНА** үзәге Кама тамагы эшчеләр поселогы исеме кушылган. Бу торак пунктка исә Кама елгасының Иделгә коя торган төшенә — **тамагына** каршы ярда утыруыннан чыгып, Кама тамагы дигән исем бирелгән.

Авылларга, күбесенчә, елганың яки башка физик-географик һәм сирәк очракларда ясалма географик объектның башланып киткән урынына утырса, **баш** яки **башы**, ә елганың койган җиренә — тамагына урнашса, **тамак** яки **тамагы** компонентлары кергән исем бирү төрки топонимиягә, шул исәптән татар топонимиясенә дә, хас күренеш. Мәсәлән, Татарстанда: Шурабаш, Ашытбаш, Шушмабаш, Иябаш, Ашабаш, Күпербаш (Арча районы), Чатбаш, Төябаш (Апас районы), Елгабаш (Мөслим районы), Көекбаш (Балтач районы), Чишмәбаш (Актаныш һәм Кукмара районнары) һ. б. исемле авыллар бар.

Составында **тамак** яки **тамагы** сүзе булган кушма төзелешле авыл исемнәре дә байтак кына: Муртыштамак, Ләшәүтамак (Сарман районы), Мәллətамак (Мөслим районы), Димтамак (Баулы районы), Ык тамагы (Алабуга районы), Үртамак (Минзәлә районы), Сазтамак (Кукмара районы), Стәрлетамак (Башкортстан АССР), Ишимтамак (Түмән өлкәсе) һ. б.

Инде бу атаманың беренче компоненты **Кама** сүзенең мәгънәсен ачыклыйк. В. А. Никонов күрсәтүенчә, аның этимологиясен **камы** — камень (таш) яки **кам** — лодка (көймә) һ. б. сүзләре белән бәйләргә тырышу нигезсез. Ул удмурт һәм башка угро-фин телләрендәге кам — елга сүзенә якын тора[3].

Элек Кама елгасын удмуртлар Буджим Камъ (ак елга), чувашлар — Шайга идилъ (шул ук мәгънәдә), марилар — Чолман вись, татарлар Чулман идел һәм тагын Ак идел (ак елга) дип атап йөрткәннәр[4].

**КУЙБЫШЕВ РАЙОНЫНЫҢ ИСЕМЕ** үзәге Куйбышев шәһәре исеменнән алынган.

1935 елда Коммунистлар партиясе һәм Совет дәүләтенең күренекле эшлеклесе В. В. Куйбышев хөрмәтенә элекке Спасск шәһәренең исеме Куйбышев шәһәре дип үзгәртелә.

Спасск күршесендәге Никольский (Чертык) авылыннан күчеп килүчеләр исәбенә үсә. Никольский авылы XVI гасырда ук салынган була һәм Воскресенский монастырена карый. 1781 елда Спасск авылы Казан наместничествосының өяз шәһәренә әверелә.

**КУКМАРА РАЙОНЫНА** үзәге Кукмара эшчеләр поселогы исеме бирелгән. Бу атаманың килеп чыгышы мари теле белән бәйләнешле. Аны марича **кок**[5] (ике) һәм мара (мари халкының үз-үзен атау исеме) яки **кук — кугу**[6] (зур) + **мара** сүзләреннән гыйбарәт дип карыйлар. Җирле халык аңа кайчандыр **ике мари** нигез салган һәм шуңа авыл исеме Кукмара (ике мари) булган дип саный.

Кукмара атамасын борынгы иран (скиф-сармат) телләре белән бәйләп аңлатырга да мөмкин. Аларда кук сүзе «тау» төшенчәсен белдергән (чагыштыр: фарсы телендә **кҹh**, осетин телендә **hoh** — тау). Мари АССРның Яңа Торъял районында Кукмар, Югары һәм Түбән Кукмар исемле авыллар бар[7].

---

[1] Энциклопедический словарь географических терминов. М. 1968. 110 бит.

[2] И. А. Износков. Список населенных мест Казанского уезда с кратким их описанием. Казан. 1885. 5 бит.

[3] В. А. Никонов. Краткий топонимический словарь. 170 бит.

[4] П. Семенов. Күрсәтелгән хезмәт. 2 том. 914 бит.

[5] Русско-марийский словарь. Изд-во «Советская энциклопедия». 1966 ел. 140 бит.

[6] И. А. Износков. Список населенных мест Мамадышского уезда. Труды IV археологического съезда в России... I том. Казан. 1884 ел. 127 бит.

[7] Ф. И. Гордеев. Балтийские и иранские заимствования в марийском языке.— Происхождение марийского народа. Йошкар-Ола. 1967. 188 бит.

**ЛАЕШ РАЙОНЫНА** үзәге Лаеш эшчеләр поселогы исеме бирелгән.

Лаеш шәһәре 1557 елда корыла башлаган. С. М. Шпилевский аңа кадәр бу урында борынгы авыл булган дип саный һәм, шушы фикерен дәлилләү өчен, татар тарихчысы Хисаметдин Шәрәфетдин бине Мөслиминең «Тәварихы Болгария»сеннән: «Болгар шәһәре Аксак Тимер тарафыннан җимерелгәннән соң, Лаеш карт үзенең нәсел-токымы белән Кама елгасы буена килеп чыга һәм шунда Лаеш авылын нигезли», дигән өзек китерә [1].

Болгарлардагы Лаеш исеме исә гарәп теленнән кергән Латыйфулла (гарәпчә **латыйф** сүзе **йомшак, мөлаем, нәфис** мәгънәләрен белдерә) исеменең беренче иҗеге «**ла**»га борынгы төрки кеше исемнәрен ясауда актив катнашкан -еш (иш) иркәләү-кечерәйтү кушымчасы ялгану юлы белән ясалган булырга тиеш. Болгар-татар телендә Агиш, Баеш, Дәүеш, Туриш, Күгеш, Тиңиш һ. б. кебек ике иҗекле төзелеш тәшкил иткән, җыйнак-җиңел әйтелешле кеше исемнәре күп булган. Шушы традицион исемнәр калыбының йогынтысы нәтиҗәсендә телебезгә гарәп, фарсы, рус һ. б. телләрдән алынган өч-дүрт иҗекле кеше исемнәре кыскартылып әйтүгә яраклаштырылган, җыйнаклаштырылган. Аларның күбесе ике иҗеккә калдырылганнар, икенче иҗек, күпчелек очракта, иркәләү-кечерәйтү кушымчасыннан торган: Латыйфулла — Лаеш, Вәлиулла — Вәлүш яки Вәлкәй, Тимерша — Тимуш, Бикмулла — Бикмуш яки Бикми, Янбулат — Янбуш һ. б.

**ЛЕНИНОГОРСК РАЙОНЫНЫҢ ИСЕМЕ** үзәге Лениногорск шәһәре исеменнән алынган.

Яңа Писмән авылы 1955 елда шәһәргә әверелде һәм даһи юлбашчыбыз В. И. Ленин истәлегенә Лениногорск дип аталды.

**МАМАДЫШ РАЙОНЫНЫҢ АТАМАСЫ** үзәге Мамадыш шәһәре исеменнән алынган. Мамадыш 1781 елга кадәр авыл булган, шул елны шәһәр категориясенә кергән һәм Октябрь революциясенә кадәр өяз шәһәре саналган.

Географ П. Семенов борынгы татар кульязмасында Мамадыш авылын, Болгар шәһәре Аксак Тимер тарафыннан җимерелгәннән соң, монда качып килгән Мамадыш исемле кеше нигезләве хәбәр ителә дип яза [2].

Вятка буендагы бу шәһәр XVII йөздә аеруча үсә. Шушы елларда болгар шәһәренә көчеп килгән руслар үзләре белән Троицкое дигән яңа исем алып киләләр. Спасск монастырена ясак түләүче шәһәрне ногайлардан саклау өчен, ул ныгытыла. 1781 елда, Екатерина II җирләргә генераль үлчәү үткәргәндә, шәһәрнең иске исеме яңадан кайтарыла [3].

Каюм Насыйри «Зәя өязе» дигән хезмәтендә барысы да бер кеше балалары тарафыннан нигезләнгән биш авыл: Мамадыш-Әкил, Тәүгелде-Мамадыш, Мамадыш-Сатылган, Бигай-Мамадыш һәм Мамадыш-Гордеевоны күрсәтә. «Ахры, бу авылларның Мамадыш дип аталуына сәбәп шулдыр. Ул Җәмитнең балалары берсе агасы янына барганда, юлда берәү очрап: «Кая барасың?» — дигән. Ул әйткән: «Мәмәдәшләргә барам», ягъни туганнарым-имчәктәшләрем катына барам, дигән икән. Шул сүздән чыккан Мәмәдәшләр авылы, ахыры, Мамадыш авылы дигән исем калган. Бәгъзылар риваять кылалар: «Бу Җәмит дигән адәм Мамадыш каласында кадим булган Бабадыш бабаның нәселеннәндер. Иске заманда Болгарда Мәмәдәш дигән берәүнең ләкабе (кушаматы — Г. С.) булгандыр. Монда янә башка төрле риваятьләр бардыр» [4], — дип яза һәм Мамадыш исеменең килеп чыгышын, нигездә, ачык, хәл ителмәгән килеш калдыра.

Профессор Л. Җәләй Мамадыш топонимы **мәмәдә иш** (**мәмә** балалар телендә имчәк) **имчәктәш** дигән сүздән алынган дип саный иде.

Мамадыш атамасы Мөхәммәтиш (чагыштыр: Ишмөхәммәт, Нурмөхәммәт һәм Мөхәммәтнур, Ярмөхәммәт һәм Мөхәммәтъяр һ. б.) дигән кеше исеменең фонетик яктан җирле әйтелешкә яраклаштырылган варианты (Мөхәммәтиш > Маматиш > Мамадыш) булса кирәк.

[1] С. М. Шпилевский. Древние города и другие болгаро-татарские памятники в Казанской губернии. Казань. 1877 ел. 383 бит.

[2] П. Семенов. Күрсәтелгән хезмәт. III том. 160 бит.

[3] З. Хәсәенов. Минем Мамадышым. «Социалистик Татарстан» газетасы. 1969 ел. 28 декабрь саны.

[4] К. Насыйри. Сайланма әсәрләр. Татгосиздат. Казан. 1956. 150 бит.

**МИНЗӘЛӘ РАЙОНЫ** үзәге Минзәлә шәһәре исемен йөртә. 1645 елны Минзәлә острогына нигез салынган һәм ул Кама арты иске линиясенең көнчыгыш пунктын тәшкил иткән. Минзәлә 1781 елны шәһәргә әверелгән.

Минзәлә шәһәре исеменең килеп чыгышы турындагы бер риваятьтә бу урында Болгарга сәүдә белән килүче гарәпләрнең тукталыш пункты — **мәнзәлә** булуы хәбәр ителә. Риваятьтәге мәгълүматларның чынбарлыкка туры килүе дә бик ихтимал. Идел буе болгарлары ераклыкны **көнлек юл** һәм **айлык юл** берәмлекләре белән үлчәгәннәр. Гарәпләр ара ераклыгын махсус үлчәү берәмлеге — **мәнзель белән** исәпләгәннәр[1]. Җәйхани әйтүенчә, Болгардан Куйабка (Киевкә) егерме тукталыш»[2]. Озынлык үлчәве буларак бер мәнзель 87 километрга тигезләшә»[3]. «Тукталыш» яки «мәнзель», Маркварт тарихи-географик хезмәтләреннән күренгәнчә,— дип яза Я. А. Манандян,— гарәп географлары өчен көн буена үтелгән юл түгел, бәлки станцияара ераклык»[4].

X йөзнең беренче чирегендә гарәп илчесе һәм сәяхәтчесе Әхмәт Ибне Фадланның Болгар иленә башкорт җирләре аша көньяк-көнчыгыш юлдан, ягъни Җаек, Агыйдел, Ык, Минзәлә, Чирмешән һ. б. суларны (елгаларны) кичеп килүен исәпкә алганда, Болгар белән гарәп илләре арасында сәүдә һәм илчелек бәйләнышлары шул юл аша барган, Минзәлә елгасы буенда борынгы сәүдә юлының бер мәнзеле — туктап ял итә торган урыны булган һәм шуңа мөнәсәбәтле рәвештә бу елгага Минзәлә исеме кушылган дип уйларга мөмкин. Ул чагында Минзәлә топонимы Минзәлә елгасы исеменнән алынган булып чыга.

**МӨСЛИМ РАЙОНЫНЫҢ ИСЕМЕ** үзәге Мөслим авылы исеменнән алынган.

Авыл халкының сөйләвенә караганда, Мөслим XVI гасыр башларында нигезләнгән. Шул заманнарда Ык буйларына Казан якларыннан Мөслим, Әхмәт, Мөэмин, Афзал, Якуп, Булат һәм Сәет исемле җиде кеше килеп чыккан. Алар монда төпләнеп яши башлаганнар, авыллар корганнар. Мөслим авылына беренче башлап Мөслим баба казык каккан, шуңа авыл аның исеме белән аталган.

Гарәп теленнән алынган Мөслим исеме «ислам динендәге ир кеше, мөселман»[5] дигән мәгънәне белдерә.

**ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНА** Россия халыкларына азатлык кояшы алып килгән Бөек Социалистик революция булган октябрь ае исеме бирелгән. Октябрь — социалистик революция, азатлык символы.

Октябрь районының үзәге — 1961 елдан башлап Норлат шәһәре. Норлат топонимы Нурдәүләт дигән кеше исеменең фонетик үзгәреш кичерүе — икенче иҗеге «дәү»нең төшүе нәтиҗәсендә барлыкка килгән булырга тиеш. Бу районда тагын Югары Норлат, Түбән Норлат, Буа һәм Зеленодольск районнарында Норлат исемле татар авыллары бар.

**ПИТРӘЧ РАЙОНЫНЫҢ ИСЕМЕ** үзәге Питрәч авылы исеменнән алынган. Бу авылга Питрәч атамасы (русча Пестрецы) авыл халкының милли составы ягыннан чуар (пестрый) булуыннан чыгып бирелгән, имеш, дигән сөйләк бар. Ләкин Питрәч топонимы борынгы болгар-татар кеше исеме Питрәчтән ясалса кирәк. Болгарларда һәм чувашларда Питрәч һәм Әтрәч дигән кеше исемнәре булган[6]. Тәтеш районында Зур Әтрәч һәм Кече Әтрәч исемле татар авыллары бар. Шушы авыллар янында XIII—XIV йөзләргә караган кабер ташы язмалары табылу аларның Болгар дәүләте чорында ук төзелгән борынгы авыллар булуын күрсәтә. Питрәч районында да Әтрәч (Атряси) дигән рус авылы бар. Бу авыл урынында Болгар чорында ук нигезләнгән борынгы авыл булуы бик ихтимал. Шушы исем монда археологик казынулар үткәрергә кирәк-

[1] В. М. Беркутов. Болгар-татар озынлык һәм аралык үлчәү берәмлекләре. Казан. 1964. 10 бит.

[2] Ф. Ф. Вестберг. К анализу восточных источников о Восточой Европе. Журнал «Мин. Народ. Просв.». XIII. СПб. 1908. 139 бит.

[3] Б. А. Рыбаков. Русские земли по карте Идриси 1154 г.— Краткие сообщения института истории материальной культуры АН СССР. Вып. XLIII. М. 1952. 28 бит.

[4] Я. А. Манандян. О торговле и городах Армении в связи с мировой торговлей древних времен (V в. до н. э.— XV в. н. э.). Ереван. 1954. 236 бит.

[5] Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге. Татарстан китап нәшрияты. Казан. 1965. 284 бит.

[6] В. К. Магницкий. Күрсәтелгән хезмәт. 30 һәм 67 битләр.

легенә ишарә итә. Казан артында Питрәч һәм Әтрәч авыллары (бу атамаларның икесенең дә — әч кушымчалы булулары игътибарга лаеклы) бер чорда, Болгар дәүләте җимерелгәнче яки җимерелгәч, озак вакыт үтмәстән, барлыкка килсәләр кирәк.

Татар теле диалектларында **питрас** һәм **питрәч** сүзе куас кисмәге төбендә калган камырдан ясалган **төпчек ипи** — кечкенә икмәк һәм вак күмәч[1] мәгънәсендә йөри. Питрәч исеменең (аның Битрәч, Пәкрәч вариантлары да булган) соңгы, төпчек ир бала-га бирелүе бик ихтимал.

**САБА РАЙОНЫНА** үзәге Саба авылының исеме бирелгән. Бу авыл исеменең килеп чыгышы турында төрле карашлар бар. Болар исә **саба** сүзенең күп мәгънәлелеге нәтиҗәсендә барлыкка килгәннәр. Мәсәлән, академик В. В. Радлов төрки телләрдә **саба** сүзенең 6 төрле кулланылуын күрсәтә[2].

Саба топонимының килеп чыгышы турындагы карашларга кыскача тукталыйк.

Сөйләүләргә караганда, имеш, Саба авылының исеме кымыз саклау өчен хезмәт итә торган **тире капчык — саба** сүзеннән алынган. Икенче бер версиядә Саба авылы халкы агачтан һәм балчыктан төрле **савыт-саба** ясау белән шөгыльләнгән. Имеш, шуннан чыгып, авылга Саба исеме бирелгән.

Саба районында тагын исемнәре составында **саба** сүзе булган: Сабабаш, Саба-Туктар, Чәбки-Саба, Урта-Саба авыллары бар. Бу авыллар Саба (Сабинка) дип атала торган ике инеш (елгачык) буена утырганнар. Инешләр Мишә елгасына коялар. Бирелгә өлеге инешләргә исем Саба авыллары исеменнән чыгып бирелгәнме яки, киресенчә, авылларга инешләр исеменнән чыгып исем кушылганмы? дигән сорау туа. Ленинград өлкәсендә Луга елгасының сул як кушылдыгы булган Саба елгачыгы бар. Бу елгачыкларга исем элек шушы территорияләрдә яшәгән бер үк халык — борынгы угро-финнар тарафыннан бирелгәнме? Шулай булганда, Саба елгачыкларының исеме — беренчел, ә Саба авылларының исеме — икенчел.

Борынгы болгар-татар, чуваш һәм башка төрки халыкларда Сабакай, Сабай, Сабакан, Сабачи кебек кеше исемнәре кулланылышта йөргән[3]. Болардан чыгып, Саба авылына өлеге исемнәрнең берсен йөрткән кеше нигез салмаганмы, авыл шуңа Саба дип аталмаганмы? дигән сорау туа. Шунсы кызыклы: Саба районында Тимершык (бу исем Тимершәехтән) авыл Советына караган Сабай исемле татар авылы, Ульяновск өлкәсендә шулай ук Сабай, ә көнчыгыш Себердә Сабинская авыллары бар. Монда үзара билгеле бер бәйләнеш, система булуы бик мөмкин.

Проф. С. М. Шпилевский рус елъязмаларында 1184 елда князь Всеволодның Биләргә һөҗүме турында сөйләгәндә, Сабакуль һәм Челматның шәһәр дип язгыш күрсәтелүе, Идел болгарларының андый шәһәрләре булмавы, саба, кул һәм челмат исемнәрен болгар халкының тармаклары мәгънәсендә кабул итәргә кирәклеге турында яза. Лаеш, Мамадыш өязләрендәге Тәмте, Саба һәм Куль дигән авыл һәм елгалар атамасында өлеге кабиләләр исеме сакланган дип карый[4].

Димәк, С. М. Шпилевский, топонимия мәгълүматларына таянып, **саба**, **кули** һәм **тәмтез** исемле болгар кабиләләре Казан артының Мишә елгасы буйларында яшәгәннәр дип саный.

Академик Б. Д. Греков һәм доцент Н. Ф. Калинин, 1182—1184 еллар датасы белән билгеләнеп, рус елъязмаларында болгар шәһәрләре: Собакуль, Челмат, Темтюз һәм Торьцький телгә алынуы турында язалар һәм, борынгы заманда шәһәрләрне, географик урыннарны халык исеме белән атау гадәти күренеш булуга таянып, бу исемнәрне болгар кабиләләренең синонимнары итеп санарга мөмкин, дигән нәтиҗә ясыйлар[5].

Без Саба атамаларының иң элек Саба, Сабакай, Сабай... яки Сабакол дигән борынгы кеше исеменең сабакол дигән кабилә исеменә (этнонимга) әверелүе һәм

---

[1] Диалектологик сүзлек. II чыгарылыш. Татгосиздат. Казан. 1963. 154 бит.
[2] В. В. Радлов. Опыт словаря тюркских наречий. IV том. I кисәк. СПб. 1911 ел. 411 бит.
[3] В. К. Магницкий. Чувашские языческие имена. Казан. 1905 ел. 70 бит.
[4] С. М. Шпилевский. Күрсәтелгән хезмәт. 140 бит.
[5] Б. Д. Греков, Н. Ф. Калинин. Булгарское государство до монгольского завоевания.— «Материалы по истории Татарии» исемле җыентык. I чыгарылыш. Казан. 1948 ел. 108 бит.

шушы кабилә исеменең башта елгачыклар һәм аннан соң авыл исемнәренә әйләнүе нәтиҗәсендә барлыкка килгән булырга мөмкин, дигән караштa торабыз.

**САРМАН РАЙОНЫ** үзәге Сарман авылының исемен йөртә. Сарман топонимының асылында Сарман дигән кеше исеме ята. Борынгы болгар-татар һәм чуваш кеше исемнәре арасында Сарман, Сарманай, Сармандай, Сармандей кебек исемнәр урын ала. Пермь татарларында Сарманай исеменә нигезләнгән Сарманаев фамилиясе бар.

Сарман исеме **сары+ман** компонентларыннан гыйбарәт. **Сары** өлеше—**төс**, ә **ман** өлеше **кеше** (мин) яки **елга** (гомумән предмет) төшенчәсен белдерсә кирәк. **Сары** сыйфаты борынгы төрки кеше исемнәре составында шактый еш кулланыла. **Ман** сүзе дә борынгы төрки антропонимнары составында еш кына очрый: Сарман, Сарманай, Акман, Акманай, Сайман, Шайман, Тайман, Айман, Битаман, Атаман, Салман, Карман, Әлмән һ. б. Күргәнебезчә, Сарман бу исемнәр белән бер система тәшкил итә.

Казакъ теле белгече Т. Жанузаков[1] Сарман исемен монгол теле белән бәйли, беренче компоненты монголча **сар — ай** дигән мәгънәне белдерә дип карый.

Шәҗәрәләр һәм халык арасында сакланган риваятьләргә караганда, Сарман авылына исеме бирелгән Сарман картның нәселе бик ерак тарихка китә, борынгы башкорт ыругы аксакалы Карагай Атайга һәм аның Болгар илен җимерергә килүче Батый хан гаскәрләренә каршы бик зур каршылык күрсәткән каһарман улы Бикчурага барып тоташа[2].

**ТӘТЕШ РАЙОНЫНЫҢ ИСЕМЕ** үзәге Тәтеш шәһәре исеменнән алынган.

Бу топонимның нигезендә Тәтеш (татлы иштән фонетик үзгәрешләр нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Чагыштыр: Татлы, Татык, Татлыби — кеше исемнәре) дигән кеше исеме ята, дигән караштa торабыз. Ул, алда әйткәнебезчә, Дәүеш, Күгеш, Баеш, Бураш һ. б. кебек борынгы болгар-татар кеше исемнәренә нигезләнгән топонимнар (авыл исемнәре) белән бер система, топонимик рәт төзи. XVII йөзгә караган бер тарихи документта Татыков дигән татар фамилиясе белән очрашабыз.

Тәтеш шәһәренә, башта хәрби-сторожевой пункт буларак, Идел буендагы биек тау башына 1578 елда (кайбер чыганакларда 1565—1567 еллар арасында) нигез салына. 1708 елда инде ул шәһәрләр исемлегенә кертелә. Рәсми рәвештә 1781 елдан шәһәр дип исәпләнә.

1847 елда «Казанские губернские ведомости» газетасының 21 санында билгесез авторның «Тәтеш» исемле мәкаләсе басыла. Ул Тәтеш шәһәре урынында борынгы заманнарда шул исемне йөрткән авыл булган, авыл исеме исә XII гасыр азагында рус елъязмаларында телгә алынган болгар кабиләләре **тәмтезләрне** хәтерләтә, дигән фикер үткәрә.

С. М. Шпилевский **тәмтез** кабиләләре Казан артында Мишә елгасы буйларында яшәгәннәр, Төрек — Тәмте, Тәмте — Мәтәскә авылларының исеме шушы этнонимга нисбәтле дип саный һәм XII гасырда тәмтезләрне Тәтеш белән тәңгәлләштерү болгар тарихчысы Хисаметдин Мөслиминең: «Тәтешкә Болгарны Аксак Тимер җимергәннән соң нигез салынган»,— дип каравына каршы килүен күрсәтә[3]. Тәтеш авылы хәзерге Тәтеш шәһәренә туры килә, ди[4].

Кафтанников, җирле халык сөйләвенә нигезләнеп, Тәтеш шәһәренең исеме Тәтеш дигән татар кнәзе исеменнән алынуы турында яза[5]. И. А. Износковның да шундый фикердә булуын алда күреп үткән идек.

**ТҮБӘН КАМА РАЙОНЫНА** үзәге Түбән Кама шәһәре исеме кушылган. Шәһәргә, Кама елгасының **түбән агымына** урнашуыннан чыгып, Түбән Кама дигән исем бирелгән, ул — русча Нижнекамск исеменнән татарчага калькалаштырылган атама. Кама

---

[1] Т. Жанузаков. Казакъ телендәге жалкы есемдер. Алма-Ата. 1966 ел. 134 бит.

[2] Фәйзелхак бабай Һадиуллинның сөйләүләренә таянып, Сарман район газетасы редакторы урынбасары Х. Хәйруллин «Еллар тузанын каккач» исемле документаль хикәя язып, аны «Ленинчы» газетасының 1967 елгы 31 май һәм 2, 4, 7 июнь саннарында бастырган. Без югарыда шушы хикәядәге тарихи фактларга нигезләнеп фикер йөртәбез.

[3] С. М. Шпилевский. Күрсәтелгән хезмәт. 321 бит.

[4] Шунда ук. 97 бит.

[5] Кафтанников. Древние Булгары.— «Библиотека для чтения». 82 том. 1847 ел. Июнь. 45 бит.

елгасы буена урнашкан берничә шәһәр исеме составында шушы елга атамасы урын ала: Пермь өлкәсендә — Соликамск, Краснокамск, Башкортстанда — Нефтекамск.

**ЧАЛЛЫ РАЙОНЫНА** үзәге Чаллы шәһәре исеме кушылган. Бу торак пункт 1930 елдан алып шәһәр санала.

Чаллы топонимының килеп чыгышы Чаллы гидронимы (елга исеме) белән мөнәсәбәтле. Татарстанда исемнәре составында **чаллы** (русча **челны**) сүзе булган авыллар бик күп һәм алар республикабызның төрле районнарында сибелгәннәр.

Чаллы гидронимының этимологиясен ачыклау өчен, шушы исемне йөрткән елгаларга географ П. Семенов биргән физик-географик характеристика зур игътибарга лаеклы. Ул: «Чаллы (Челны) исемле ике елга бар: 1) Кама елгасының сул як кушылдыгы, 20 чакрым озынлыкта, Камага Ярчаллы (Бережные Челны) авылы янында коя. Аның ярлары биек кыялы кыргый **ак таштан** гыйбарәт. Бу елга Уфа губернасы Минзәлә өязендә, монда халык бик тыгыз урнашкан; 2) Шишмә елгасының сул як кушылдыгы, Казан губернасының Чистай өязендә, озынлыгы 30 чакрым, бу елганың ярлары һәм төбе йомшак ак балчыктан гыйбарәт»[1],— дип яза. Моннан яхшы аңлашылганча, Чаллы исемен **ак таш** яки **ак балчык** сүзе белән бәйләп аңлатырга нигез бар.

**Чул — чал** (бередә **у** һәм **а** сузыкларының тарихи тәңгәллеге чагыла) сүзе борынгы болгар-татар телендә «таш» төшенчәсен белдергән. Чуваш телендә **чул** хәзер дә **таш** дигән сүз. Алар Горький шәһәрен Чулкала, ягъни Ташкала дип йөртәләр.

Ярлары яки төбе ташлы булган елгаларга бабаларыбыз Чуллы Чаллы дигән исем бирсәләр кирәк.

Чуллы Чаллы гидронимнары безнең крайда Ташлы яки Ташлык, Кенәр, Каменка кебек елга исемнәре белән, семантик тәңгәллек нигезендә тарихи аспектта бер синонимик рәт ясыйлар һәм гидронимик стратиграфик катлаулар барлыкка китерәләр.

Югарыда сөйләгәннәргә нигезләнеп, Чаллы шәһәренең исеме **Чаллы — ташлы** (ташлы елга) исеменнән алынган дип карыйбыз.

**ЧИРМЕШӘН РАЙОНЫНЫҢ ИСЕМЕ** үзәге Чирмешән авылы исеменнән алынган. Бу топоним исә Зур Чирмешән елгасы исеме белән мөнәсәбәтле. Хәзер район үзәге булган Чирмешән авылы шул елга буена урнашканга, Чирмешән дип аталган.

Чирмешән гидронимының этимологиясе, үз чиратында, мари халкының борынгы исеме **чирмеш** сүзе (этнонимы) белән бәйләнешле.

Структурасы ягыннан Чирмешән гидронимы ике компонентта тора: **чирмеш+ән.**

Чирмеш компонентының килеп чыгышын түбәндәгечә аңлатырга мөмкин. Ул борынгы болгар һәм чуваш телендәге **сирем** (егерме)гә **еш (иш)** сүзе кушылып ясалган. **Л-ш** тартыкларының тәңгәллегенә нигезләнгән ламбдаизм күренеше нәтиҗәсендә (мәсәлән, чувашча **кемел** — татарча **көмеш**, чув. **чул** — тат. **таш**, якутча **тул** — тат. **төш**, тат. әдәби телендә **кашык** — тат. теле диалектларында **калак** һ. б.), **еш (иш)** сүзе кабилә, халык төшенчәсен белдергән **ил** сүзенә барып тоташа. Менә шуннан чыгып чирмеш этнонимы «егерме кабилә» төшенчәсен белдерә дигән нәтиҗәгә киләбез. Билгеле булганча, борынгы төрки этнонимнар составында сан еш кына урын алган: тукуз татар, утуз угур, вунгур һ. б.

Урта Идел буеның болгар чоры гидронимиясендә -**ан**, -**ән** форманты еш очрый. Ан, ән сүзләре борынгы төрки телдә елга мәгънәсендә кулланылган дигән фикер бар.

Татарстан территориясе аша Зур Чирмешән, Кече Чирмешән (Кама ар ягында) һәм Чирмешән (Апас районында) елгалары агып узалар. Бу елгалар исеменең беренче өлешенең мари халкының борынгы этнонимы — **чирмеш** термины белән белдерелүе аларның буйларында безнең эра башларында мариларның борынгы бабалары яшәгәннәр дип уйларга җирлек тудыра. Әхмәт Ибне Фадланның Чирмешән елгасының башкортлардан болгарларга бара торган юл арасында ятуын әйтеп үтүенә таянып, академик Б. Д. Греков һәм доцент Н. Ф. Калинин: «922 елда телгә алынган бу атама борынгы Болгар дәүләте төзелү вакытыннан элгәреге санала, мәгаен, кабиләнекедер»[2],—

---

[1] П. Семенов. Күрсәтелгән хезмәт. V том. 1885 ел. 606 бит.
[2] Б. Д. Греков, Н. Ф. Калинин. Булгарское государство до монгольского завоевания.— Материалы по истории Татарии. Вып. I. Татгосиздат. 1948. 112 бит.

дип язалар. Безнең крайда Чирмешән һәм Казан елгаларының исемнәре беренче өлешләре энтоним, ә икенче өлешләре **-ан, -ән** (елга) формалары аша белдерелүләре нигезендә охшашлар. Димәк, Чирмешән — **чирмеш кабиләләре елгасы**, ә Казан — **каз кабиләләре елгасы** дигән төшенчәне белдерә булып чыга.

**ЧИСТАЙ РАЙОНЫНА** үзәге Чистай шәһәре исеме бирелгән.

Кайчандыр Чистай шәһәре урынында исемсез бер поселок булган. Аны алпавыттан качкан крестьяннар корганнар. Алпавыт аларны эзләтеп таптырган һәм кире үзенә кайтарткан. Поселокны бөтенләй җимергәннәр һәм бу урында ачык, **чиста кыр (поле)** барлыкка килгән. Соңрак монда Чистополь дигән шәһәрчек төзелә башлаган. Чистай 1781 елдан шәһәр санала.

**ЧҮПРӘЛЕ РАЙОНЫ** үзәге Иске Чүпрәле авылы исемен йөртә.

Иске Чүпрәле авылы исеменең килеп чыгышы ул утырган урынның физик-географик үзенчәлеге белән бәйләнешле.

Риваятьләргә караганда, бу авыл урыны элекке заманнарда урман белән капланган булган. Кече Чынлы елгасына коя торган бер елгачык буена ике карт килеп чыккан. Алар елгачыкта суның күбекләнеп, күпереп агуын күргәннәр һәм: «Карале, **чүпрә** кебек күбекләнә, күперә бу елга, чүпрәледер ул»,— дигән берсе. Шуннан елгачыкка һәм авылга Чүпрәле дигән исем бирелгән, имеш.

Иске Чүпрәле авылының түбәндәге өлеше әле хәзер дә сазлыклы баткаклыктан гыйбарәт. Аннан инешкә чүпрәләнеп, чымырдап кызыл су чыгып тора. Черү процессы барганга, чымырдау, әчү күренеше хас булган баткак-сазлыклы урыннарны, чүпрәгә аналогия ясап, бабаларыбыз Чүпрәле дип атаганнар. Монда утырган авылга Чүпрәле дигән исем бирелгән.

**ЮГАРЫ ОСЛАН РАЙОНЫНА** үзәге Югары Ослан авылы исеме бирелгән.

Югарыда Ослан авылы турында «Известие Казанской епархии» журналының 1781 елгы 7 санында түбәндәге мәгълүматлар урнаштырылган:

«1594 елга караган бик күптәнге документта Услон (Ослан) авылы Идел елгасы култыгына, Гостиный утравыннан өстәрәк, ә Таш таудан (Каменных гор) астарак, Ирех утравына каршы яр буена утырган. Документтан Югары Ослан авылының XVI гасыр азагында, атап әйткәндә, 1594 елда нигезләнүе аңлашыла. Шушы елга кадәр бу авыл булмаган, чөнки «Зөя өязенең писцовая кенәгәсе»ндә (1568 ел) аның күршесендәге Моркваши, Сәет, Борындык, Кильдеево авыллары телгә алынса да, Югары Ослан авылы турында бер сүз дә әйтелми.

Югары Ослан авылы башта ук Зөя каласындагы Троице-Сергеев монастыреның вотчинасы булган». Иң әүвәл Яңа Займища (Новая Займища) исемен йөрткән [1].

Бу өзектә Югары Ослан атамасының этимологиясен ачыклау өчен мөһим фактлар китерелгән. Анда Югары Ослан авылының Таш таудан түбәндәрәк урынга нигезләнүе хәбәр ителә. Бу авыл утырган урынның русча Каменных гор дип бирелүе игътибарга лаеклы.

Ослан тавы — безнең республикада билгеле булган зур тауларның берсе. **Ослан** исеме борынгы иран телендәге **асман** — таш сүзенә фонетик яңгырашы ягыннан бик якын тора. Аның безнең крайда борынгы заманнарда ук яшәгән иран телле сармат яки башка кабиләләр тарафыннан Осман<Ослан (Таш тау) дип аталган булуы һәм рус теленә Каменных гор дип калькалаштырылуы бик мөмкин. Шулай булганда, **Ослан** атамасы **таш** дигән мәгънәне белдерә. Югары Ослан авылы исеме шул сүз белән мөнәсәбәтле булып чыга һәм «Югары таш» дигән төшенчәне аңлата. Югарыдагы өзектә бу авылның башта Услан (Ослан) дип аталуы белән очраштык. Югары Ослан һәм Түбән Ослан атамалары бер үк исемне йөртә торган ике авыл барлыкка килгәч, аларны бер-берсеннән аеру өчен ясалган. Югарырак, таулырак урынга, утырганы Югары Ослан, ә түбәнгәрәк утырганы Түбән Ослан дип атала башлаган.

---

[1] Н. А. Спасский. Очерки по родиноведению. Казанская губерния. Казань. 1913, 169 бит.

Ослан исеме фонетик составы ягыннан **арслан**[1] сүзенә дә бик якын.

В. В. Цыбульский иңли алмастай масса топонимнар арасында теге яки бу хайван исеме белән аталган группаны аерырга мөмкин дип күрсәтә. Аларның күпчелеге монда элек яки хәзер шул төр хайванның яшәве (Юлбарыс чокыры) яки физик-географик объектның тышкы формасын — йөзен бирәр хайванга охшатудан чыгып (Дөятау, Аютау) исемләнгән[2].

Борынгы татар халык җырында:

**Ослан таулары биек,**
**Йөри арслан-киек...—**

дигән юллар бар. Безнең крайда арсланнар яшәмәгәннәр. Бу җырдагы **арслан** — фантазия җимеше булган поэтик деталь. Чынбарлыкта Ослан тавында арсланнар яшәмәсә дә, халык хыялы поэтик сурәт һәм рифмалаштыру (биек-киек) максатын күздә тотып, «биек Ослан тауларында арслан-киек йөри» дип күрсәтә һәм зур тәэсири көчкә ия булган образлы поэтик сурәт барлыкка китерә.

В. В. Цыбульский фикеренә таянып, Ослан тавының кыяфәте арсланга охшаганга Арслан тау > Аслан тау > Ослан тау дип аталган булуы ихтимал дияргә дә урын бар. Әмма аның тышкы йөзе арсланга охшамаган булу һәм борынгы документларда аның русча Каменные горы дип теркәлүе бу топонимның **асман** — ташка мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килгән дип санау өчен фәнни җирлек тудыра.

**ӘГЕРҖЕ РАЙОНЫНА** үзәге Әгерҗе шәһәренең исеме кушылган.

Әгерҗе 1938 елдан алып шәһәр исәпләнә.

Әгерҗе сүзе татар теле диалектларында әче камырдан пешерелгән коймак, әчеткеч, куас камыры, чүпрә мәгънәсендә кулланыла. Әгерҗе шәһәре урнашкан урында кайчандыр чүпрә кебек кабарып, әчеп утыра торган сазлык булган. Шул сазлыктан башланып аккан елга да Әгерҗе исемен йөртә. Соңрак шушы елга исеме Әгерҗе авылы һәм шәһәре исеменә күчкән.

Азнакай районында да Әгерҗе исемле татар авылы бар.

**ӘЛКИ РАЙОНЫНЫҢ ИСЕМЕ** шушы район территориясендәге Әлки авыллары (Югары Әлки, Түбән Әлки, Урта Әлки) исеме белән аталган. Бу районның үзәге Базарлы Матак авылы.

Әлки авылларының атамасы Әлкәй дигән борынгы кеше исеме белән мөнәсәбәтле. Бу исем **әл+кәй** компонентларыннан тора. Борынгы төрки телдә **әл** сүзе «кул» дигән төшенчәне белдергән һәм шушы мәгънәдә әзербәйҗан, төрек h. б. телләрдә хәзер дә кулланыла. **Кәй** кушымчасының борынгы кеше исемнәрен ясауда актив катнашуын алда әйткән идек. Гәүдә-баш әгъзасы исеменә нигезләнгән антропонимнар

---

[1]Мәшһүр тюрколог Н. И. Ашмарин Югары Ослан һәм Түбән Ослан авылларының исеме, чувашларның бары тик бер табышмагында **арслан** сүзенең **услан** рәвешендә кулланылуыннан чыгып, Услан дигән борынгы кеше исеменнән алынган булуы мөмкин дип карый. Шунда ук бу сүзнең рус телендә булуын һәм Даль сүзлегендә «Услонъ тмб спуск или подъем, изволок, покость под гору или в гору || Услонъ иск. затулье, затишь, защита» мәгънәсендә кулланылуын искәртсә дә, җирле этник үзенчәлекләрне исәпкә алып, бу авылларның исеме борынгы болгар чорына караса кирәк, дигән фикер үткәрә. (Кара: Н. И. Ашмарин. Болгарлар һәм чувашлар. Казан. 1902 ел. 127—128 битләр).

Н. И. Ашмарин Ослан атамасын борынгы дип санавы белән хаклы булса да, Арслан дигән кеше исеменең болгарларда, чувашларда һәм татарларда Услан формасында кулланылмыйча (табышмакта сүз услан — кайык, ягъни арслан — киек «лев» турында бара), Арслан рәвешендә йөрүе бу атаманың әлеге кеше исеменнән алынуын инкарь итә. Усланъ сүзенең рус теле сөйләшләрендә «спуск или подъем...» мәгънәсендә кулланылуы игътибарга лаеклы. Шушы географик номенклатур терминның авыл исеменә әверелүе дә ихтимал. Әмма 1954 елгы борынгы документта Ослан авылының Каменных гор янында төзелүе хәбәр ителүгә таянып, бу атама башта сармат кабиләләре тарафыннан шушы тауга бирелгән (Асман < Осман < Ослан < Услан (Таш) сүзеннән алынган, болгарлар һәм татарлар аны Ослан дип атап йөрткәннәр һәм ул соңрак рус теленә Каменные горы итеп калькалаштырылган, ә тауның беренче исеме — Ослан, авыл исеменә әверелеп, хәзергәчә сакланган, дип уйларга нигез бар.

[2] В. В. Цыбульский. Топонимы Маймун, Койун-адасы һәм Домуз-адасы. Топонимика Востока. Новые исследования. Мәскәү. 1964 ел. 37 бит.

борыңгы төрки телдә байтак очрый: Акбаш, Карабаш, Каракаш, Акбит, Акчач, Карачач, Каракүз, Аккүз, Күзкәй, Йөзлекәй, Йөзкәй һ. б. Әлкәй исеме дә шулар белән бер үк антропонимик рәт-система төзи. Составында әл (кул) сүзе булган Туграл яки Турал (туглы+әл — туры кул), Әлмән һ. б. кебек исемнәр кулланылышта йөргән. Апас районында Әлмәндәр, Чувашстанның Козловка районында Әлмән дигән татар авыллары һәм Курган өлкәсендә Әлмән исемле район һәм татар авылы бар.

Татар теленең көнбатыш диалекты вәкилләре (мишәрләр) сөйләменә хас закончалык нигезендә Әлкәй антропонимының беркадәр фонетик үзгәреш аша («әй» дифтонгы «и» гә күчеп монофтонглашкан), Әлки топонимына әверелеп сакланган. Буа районында Әлки, ә Азнакай районында Әлкәй исемле татар авыллары бар.

Район үзәге Базарлы Матак авылы исеменең икенче өлеше — Матак — борыңгы чуваш антропонимы, ә беренче өлеше — базарлы эпитеты бу авылны башка Матак авылларыннан аеру, конкретлаштыру хезмәтен үти. Бу районда тагын Иске Матак, Югары Матак дигән чуваш авыллары бар.

**ӘЛМӘТ РАЙОНЫ** үзәге Әлмәт шәһәре исемен йөртә. Әлмәт 1953 елдан алып шәһәр исәпләнә һәм республикабызның нефть промышленносте үзәге санала.

Әлмәт топонимы (башта авыл исеме буларак) Әлмөхәммәт дигән кеше исемен (татарларда Әлмөхәммәтов фамилиясе бар) кыскарту, аның икенче һәм өченче иҗеген (мөхәм) ташлап, беренче һәм дүртенче иҗекләрне янәшә әйтү (Әлмәт, шуннан Альметьев фамилиясе) нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Әлмәт тирәсендә Габдрахман, Сәләй (Сөләйманнан кыскарган), Колшәрип һ. б. кебек кеше исеме белән аталган татар авылларының булуы да шушы фикерне куәтли. Сарман районында Әлмәт (Әлмөхәммәтулладан кыскарган) исемле татар авылы бар.

* * *

Күреп үткәнебезчә, республикабыз районнары һәм аларның үзәкләре бай тарихлы, исемнәренең килеп чыгышы ягыннан үзенчәлекле һәм кызыклы.

Без карап узган җирле географик атамаларның күбесе борыңгы заманнарда ук барлыкка килгәннәр. Ул исемнәр, буыннан-буынга күчә барып, артык зур үзгәрешләр кичермичә, безгә килеп җиткәннәр һәм яшәешләрен дәвам иттерәләр. Алар әйләнәтирәнең табигате, халыкның теле, тарихы, тормыш-көнкүреше, гореф-гадәтләре, материаль һәм рухи культурасы турында ерак гасырлар аша безгә күп нәрсә сөйлиләр. Халкыбызның тарихи үткәннәрен һәм хәзергесен тулы итеп күз алдына китереп бастырырга һәм туган ягыбызны яхшырак танып белергә булышалар.

## Рәдиф Тимершин



*Миңа 23 яшь.*

*Туган җирем — Башкортстанның Яңавыл районы, Мәсәгут авылы. Ямады урта мәктәбен тәмамлагач, Башкорт дәүләт университетына укырга кердем.*

*Беренче шигырем, урта мәктәптә укыган чакта, «Ялкын» журналында басылды. Шуннан бирле балалар өчен язган шигырьләрем белән матбугатта катнашып киләм. Яратып язам, язганнарымны балалар да яратса иде.*

### Беренче кар

Бүген зур сөенеч бар,
Бөтен җирдә ап-ак кар.
Йөрибез йөгерешеп,
Шаярышып, көлешеп.

Әвәлибез кар-йомгак,
Ясыйбыз без шугалак:
Арыттырмый да үзе,
Ялыктырмый да үзе.

Тик менә кичкә табан
Кар эреп бетте тәмам.
Нигә булды соң болай?
...Иртәрәк чыктык бугай,
Кышны куркыттык бугай.



### Тере алма

Уйнаганда бакчада,
Энем әйтә: — Баксана,
Алмагачта — бер алма.
Мин күрдем, мин иң алда!..

— Инде, димен, кыш булган,
Мөгаен, бер кош кунган.
Кызылтүш ул, күрәмсең,
Очып китә күрмәсең!..

Энем һаман ышанмый:
— Алма ич ул, очалмый.
Алыйк инде, ди, өзеп,—
Энем торалмый түзеп:

Үрелгән иде алга —
Очты да китте «алма».



## Флюгер

Тын чакларда кымшанмый да,
Гүя тора ул сакта.
Җил истеме — шундук үзе
Угын бора шул якка.

Уйнаганда күз сала да
Уйлап куя Флюр гел:
«Кайсы яктан җил искәнен
Каян белә флюгер?..»

## Сикәлтә



Шоп-шома эздән
Шуып туйдык без.
Тауда сикәлтә
Өеп куйдык без.

Хисмәт килде дә,
Кычкырып көлә:
— Сикәлтәмени,
Бу бит чүп көнә!..

Бергәләп тагын
Өйдек кар өстәп:
— Әйдә, башта син
Шу әле, Хисмәт!

Инде бу шуып
Төшәдер, дисәк,
Өенә табан
Сыпыртты Хисмәт.

## Белеп торам

И боргалана песи,
И сыргалана песи,
И сыйпалана песи,
И юхалана песи.

Белеп торам: сөт бир, ди,
Җәлләмичә, күп бир, ди.
Аннан тотам тычкан, ди,
Алар минем дошман, ди.

Сөт эчә дә туя ул,
Мыек сыйпап куя ул,
Аннан тычкан тотмый ул,
Рәхәтләнеп йоклый ул.



## Үкенеч

...Талип кинәт туктап калды —
Җиргә беректе табан:
Коточкыч бер ерткыч хайван
Килә Талипка табан.

— Аһ, юлбарыс!
Инде өскә
Ыргылды бу дигәндә,
Сискәнеп уянса Талип —
Аунап ята идәндә.



Үкенеп әйтеп куйды ул,
Кия-кия күлмәген:
— Ну, кирәген бирә идем —
Төш икәнен белмәдем!..

## Кызыгалардыр әле



Кояшка куеп арканы
Комда ятабыз озак.
Эсселәгәч, салкын суга
Чумып алабыз азак.

Болытлар да шулай күктә
Кызыналардыр әле.
«Их, бер чумып чыгарга»,—
дип,
Кызыгалардыр әле.

## Көз

Урман читенә ут капкан,
Ялкын өскә үреләl
Юк ла, чаган яфраклары
Ялкын булып күренә.

Болыт — янгын сүндерүче —
Түгә генә яңгырны,
Ахры, ул да чын дип белгән
Урмандагы «янгынны».

# ТӘРҖЕМӘЛӘР ӘЙБӘТРӘК БУЛСЫН!

Моннан берничә ай элек, гаять үзенчәлекле, аз сүзле, тирән фикерле шагыйрь Дәрдмәнд шигырьләрен радио аша рус телендә дә тапшырдылар. Мин Дәрдмәнд шигырьләренең русча тәрҗемәсен укыштыргалаган идем. Ләкин ул тәрҗемәләр күңелдә ризасызлык хисе калдырганнар иде. Ә менә радио аша тапшырылган шигырьләрнең тәрҗемәләре, минемчә, уңышлы эшләнгән. Аларда Дәрдмәнд шигырьләренең рухы, тел үзенчәлекләре әйбәт сакланган. Ә аның шигырьләренең элекке тәрҗемәләре бик йомшак. Дәрдмәнд әсәрләре белән таныш булган кешенең күңеле һич тә кабул итәрлек түгел иде. Мисал өчен әллә ни ерак бармыйча, Дәрдмәнднең «Татар поэзиясе антологиясе»ндә татарча һәм русча басылган бер шигырен чагыштырып карау да бик җитәр төсле. Менә аның «Бәлләү» исемле шигыре. Җиңел укылуы, сүзләренең тирән мәгънәле һәм төгәл әйтелеше белән бер укуда күңелгә сеңеп кала торган бу шигырьдә, мәсәлән:

Колынкаем,
Кил, җанкаем,
Йоклаек икәү,—

дигән юллар бар. Менә шул искиткеч матур әйтелгән юлларны русчага:

Лошонок мой,
Мышонок мой,
Спи, милый, засыпай...—

дип тәрҗемә иткәннәр. «Лошонок» сүзе русларда да еш кулланылмый, минемчә. Ә бу очракта ул бөтенләй ятышмый. «Мышонок» сүзе русча кулланылса да һәм бераз иркәләп әйтелсә дә, бездә ул «җанкаем» дигән мәгънәне һич тә бирә алмый. Шул ук шигырьдәге «алмакаем», «аппаккаем» дигән сүзләрне «спи мой, дичок, мой белячек» дип тәрҗемә итүне уңышлы дип әйтеп булмый. «Дичок» сүзе русларда вак һәм ачы кыргый алманы аңлата, ә «белячек» дип алар сары чәчле малайга әйтәләр. Кыйгач кашым, асыл ташым» дигән юллар русчага «ты кровь моя, любовь моя» дип тәрҗемә ителгән.

Матур сүзләр бу, әлбәттә. Ләкин Дәрдмәнд шигыренең бу юлларын сүзгә-сүз тәрҗемә иткәндә генә көчлерәк, төгәлрәк килеп чыгар иде.

Бровки дугой,
Рубин ты мой.

Ә бит әдәби тәрҗемә оригиналдан ким булырга тиеш түгел, минемчә! Мин әйтеп киткән радиотапшыруда Дәрдмәнд әсәрләре рус телендә басылып чыгачак диделәр. Чыкса бик әйбәт булыр иде. Тик ул басмасында элекке кимчелекләр кабатланмасын, Дәрдмәнднең шигырьләре рус укучыларына әйбәтрәк, төгәлрәк тәрҗемәдә ирешерелсен иде.

ХӘДИЧӘ АЛМАЕВА

Миңа Аяз абый Гыйләҗевның «Урамнар артында яшел болын» әсәре бик ошады. Без Аяз абыйны повестьлар һәм хикәяләр остасы буларак күптән үз итеп өлгергән идек инде. Язучының бу романы безнең өчен ифрат та әйбәт сюрприз булды.

Бүгенге көн геройлары, әйтерсең лә, безнең арадан роман эченә кереп киткән.

Әдипнең бу әсәре, һичшиксез, татар прозасының яңа казанышы, горурлыгы.

Романның теле сокландыргыч. Әсәрнең масштабы, фикер колачы гаять киң.

Без әдиптән яңа романнар көтәбез һәм аның иҗат юлында тагын да зуррак уңышларга ирешеп, безне, үзенең укучыларын, куандырсын иде, дигән теләктә калабыз.

ҺӘНҮЗӘ АФЗАЛОВА, КДУ студенткасы

Туфан Миннуллин

# ГОМЕРДӘ БУЛМАГАННЫ...

КОМЕДИЯ БЕР ПӘРДӘДӘ, ИКЕ КҮРЕНЕШТӘ

КАТНАШАЛАР:

Суербаев Шаһибәк Шаһиевич — бер учреждениенең дәрәҗәле җитәкчесе.

Айнеев Яббар Атаяллович — заманында урта кул җитәкче булган. Түбән үк тәгәрәүдән пенсиягә чыгып котылган.

Мөкәррәмә ханым — Суербаевның хатыны. Кайбер комедиялардагы җитәкче хатыннарыннан үзгә буларак, акыллы һәм сабыр.

Шырмали Мортазин — Суербаев учреждениесенең утыз яшьлек дуамал хезмәткәре. Җитмәсә, яшь-яшь башыннан сакал үстергән.

Төхби Шәмиев — Шырмалиның хезмәттәше.

Дәрига — Шырмалиның хатыны һәм юл күрсәтүчесе.

## БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Күп бүлмәле квартираның бер бүлмәсе. Иркен, җыйнак. Пәрдә ачылганда сәхнәдә берәү дә юк. Менә ишектә звонок. Мөкәррәмә ашыгып кухня яктан чыга, алгы бүлмәгә чыгала. Ишекне ача һәм тиз генә кухняга кереп китә. Суербаев керә. Кәефе юклыгы йөзенә, хәрәкәтенә чыккан. Диванга ава, тирә-ягына карана.

Суербаев. Малайлар кайда? *(Җавап юк.)* Мәкәррәмә, малайлар кайда?

Мөкәррәмә *(чыгып)*. Ни диден, Шаһибәк?

Суербаев. Малайлар кайда?

Мөкәррәмә. Нигә кирәкләре чыкты?

Суербаев. Үз малайларымны көнгә бер тапкыр гына булса да күрергә хакым бардыр ич. Эшкә китсәң — йоклап калалар, кайтасың — каядыр чыгып киткән булалар. Алар хәзер миңа әти дип әйтергә дә оныткannардыр.

Мәкәррәмә. Кәефең юкмы дип әйтим, Шаһибәк? Кыланышың үзеңә охшамаган. Төсең дә качкан.

Суербаев *(кинәт икенче тонга күчеп)*. Нәрсә? Әллә сизеләме?.. Нишләгән?

Мөкәррәмә. Агарып киткәнсең. Авырмыйсыңдыр ич?

Суербаев. Юк ла.

Мөкәррәмә. Арыдыңмы?

Суербаев. Юк.

Мөкәррәмә. Ашыйсың килдеме? Хәзер өлгерә.

Суербаев. Кунаклардан калган берәр нәрсә юкмы?

Мөкәррәмә. Ни сөйләвең, Шаһибәк? Гомердә булмаганны.

Суербаев. Гомердә булмаганны шул. Минә бүген...

Мөкәррәмә *(шиккә төшеп)*. Әллә инде югарыда?..

Суербаев. Юк ла.

Мөкәррәмә. Миңа әйтергә ярыймы? *(Суербаев эндәшмәгәч.)* Нишләдең соң син? Ни булды?

Суербаев. Бүген Шаһибәгеңнең йөзенә лач итеп төкерделәр. Хур иттеләр.

Мөкәррәмә. Абау ямьсез итеп сөйлисең. Кем?

Суербаев. Теге пумала баш.

Мөкәррәмә. Кайсысы? Секретареңмы?

Суербаев. Секретарьдан башка пумала баш беткәнмени дөньяда. Секретарь аның янында чепуха. Моның башы, яңагы, чәге йон. Орангутан? Син аны барыбер белмисең. Я, берәр мендәр ыргыт әле, ятып торыйм.

Мөкәррәмә *(мендәр биреп)*. Малайлар нигә кирәк иде соң? Алар кинога дип киткәннәр иде.

Суербаев. Кирәкләре юк ла. Эч пошканнан. *(Ята.)*

Мөкәррәмә нишләргә белми басып тора.

Суербаев *(яткан җиреннән башын күтәреп)*. Нигә ни өчен төкерделәр дип сорамыйсың?

Мөкәррәмә. Ни уйларга да белмим.

Суербаев. Минә мин дә белмим шул. *(Кинәт сикереп торып бүлмә буйлатып йөреп китә.)* Әйт әле дөресен генә, Мөкәррәмә, ахмакмы мин? Ныклабрак кара, бәлки, егерме ел бергә яшәп белмәгәнсең. Кара әйбәтләбрәк. Ничек?

Мөкәррәмә. Хәзерге кыяфәтеңә караганда акыллы ук түгел...

Суербаев. Рәхмәт, Мәкәррәмә. Рәхмәт, җаным. Дөрес! Ахмак! Буш баш, тишек барабан! Минә кем ул Суербаев Шаһибәк Шаһиевич. Шул ахмакны нинди зур учреждениедә җитәкче итеп тоталар. Куарга, иртәгә үк куарга һәм эшен прокурорга бирергә? Ул карак, рецидивист!

Мөкәррәмә. Шаһибәк, акылыңа кил.

Суербаев. Ахмак кеше акылына ничек килсен. Акылы юк аның. Бер бөртек тә юк. Бу башта нинди акыл булсын. *(Диванга барып ята. Паузадан соң.)* Ни булды дип нигә сорамыйсың?

Мөкәррәмә. Минә әкәмәт. Гомердә булмаганны... Ни кылануыңдыр. Аңлатып бир, Шаһибәк, зинһар.

Суербаев. Әле мин аңлатмадыммыни? Башны тотып карале, эсисе, кайнармы?

Мөкәррәмә *(Суербаевның башын тотып)*. Температураң бар.

Суербаев *(хәлсезләнеп)*. Температурага ук тәэсир итте микәнни? Кара син аны, кирәк бит. Үлемеңне әллә кайда эзләп йөрерсең, ә ул синең кул астында йон үстереп эшләп йөрер. Фамилиясе ничек әле үзенең?

Мөкәррәмә. Кемнең?

Суербаев. Соң әлеге... Ә-ә, син анда булмадың бит. Мортазинмы шунда.

Мөкәррәмә. Мортазин? Сездә аны мактыйлар түгелме соң? Өметле диләр.

Суербаев. Өметсез булса, Суербаев булып Суербаевны аяктан екмас иде. Күрәсең, чиргә сабыштым.

Мөкәррәмә. Шул Мортазин сиңа?..

Суербаев. Шул! Үзе! Кайда диген, зур җыелышта. Президиумда Әхәт Исламович үзе утыра. Докладымны сөйләп бетергәч, тора да бу

йон тəргəге, шул Мортазинны əйтəм, сүз сорый. Трибунага мен, дилəр. Минем сүзем кыска, урынымнан гына əйтəм, ди. Ни əйткəндер дисеңме?

М ө к ə р р ə м ə. Тəнкыйтьлəгəндер. Җыелышта була торган хəл. Нигə шуның өчен күтəрелеп бəрелергə.

С у е р б а е в. Тəнкыйтьлəсен ул, уттан алып утка салсын. Кычкырсын, сүксен... Юк-юк!.. Ул нəрсə ди. Шаһибəк Шаһиевичның сəгать ярымлык докладын тыңлап, сəгать ярымлык гомеремне бушка уздырдым, ди. Ни əйтергə телəгəнен аңламадым, ди. Күптəн билгеле хакыйкатьне кабатлау өчен нигə сəгать ярым вакыт əрəм итəргə, диде дə утырды. Я?

М ө к ə р р ə м ə. Нəрсə, я?

С у е р б а е в. Синеңчə ничек, дим.

М ə к ə р р ə м ə. Белмим бит. Докладыңны мин тыңламадым. Бəлки, ул хаклыдыр.

С у е р б а е в *(өзгəлəнеп)*. Аңламадың, Мөкəррəмə.

М ө к ə р р ə м ə. Нəрсəсен аңламаска. Докладың начар эшлəнгəн булгандыр.

С у е р б а е в. Мəсьəлə докладның начар булуында түгел, җанкисəгем. Мин дə аны шəп иде дип мактамыйм. Сөйлəгəндə үк нинди, ничек булгандыр. Мəсьəлə фактта. Җыелыш бит. Əхəт Исламович президиумда утыра. Шул йонлы бүкəннең сүзеннəн соң җыелыштагылар тынып калдылар. Ике урынбасарым икесе дə ап-ак булып агарды. Əхəт Исламович тамагын кырып куйды. Əхəт Исламовичның тамак кыруы нинди мəгънə аңлатканын шəһəрдəге бөтен җитəкчелəр белə. Ничек шуны аңламыйсың, Мөкəррəмə?

М ө к ə р р ə м ə. Ят, ял ит. Син арыгансың. Шуңа һəрнəрсəгə артык зур əһəмият бирəсең. Кысыр хəсрəт.

С у е р б а е в. Һəрнəрсəгə?! Кысыр хəсрəт?! Сине буш баш дип атасыннар да шул һəрнəрсə, шул кысыр хəсрəт буламы? Гомердə булмаган хəл бу, җаным. Мондый хəлне үз күзлəрем белəн күрү түгел, ишеткəнем дə юк иде.

М ө к ə р р ə м ə. Җыелыш əйбəт кенə беткəндер ич.

С у е р б а е в. Ничек беткəнен кем белə. Берни ишетмəдем, берни күрмəдем. Йомгаклау сүзеннəн дə баш тарттым.

М ө к ə р р ə м ə. Серкəң су күтəрми, ə? Һəр сүзеңне кул чабып каршылауларына өйрəнгəнсең.

С у е р б а е в. Җаның юк икəн синең, Мөкəррəмə җанкисəгем. Сəгать ярым бит. Сəгать ярым буш сүз сөйлəдем микəнни соң? Əллə бу йон йомгагын берəрсе котыртып куйды микəн? Үз башы белəн əйтмəс адəм баласы андый сүзне... Мөкəррəмə, китер əле портфельне, карап чыгыйм əле докладымны, шулай ук...

М ө к ə р р ə м ə. Шаһибəк...

С у е р б а е в. Китер. Кычкырып укыйм. Тыңла — əйтерсең. Əгəр чыннан буш сүз булса...

М ө к ə р р ə м ə. Сəгать ярым буе тыңлап утырыйммы?

С у е р б а е в. Гомер иткəн хəлəл ирең өчен сəгать ярымлык вакытын кызганычмыни?

М ө к ə р р ə м ə. Буш вакытта үзем генə укып чыгармын.

С у е р б а е в. Юк. Бəлки, доклады əйбəттер, мин сөйли белмəгəнмен.

М ө к ə р р ə м ə. Егерме ел буе доклад сөйлəп, сөйли белмəскə. Я, тынычлап ят. Иртəн торгач, бер кычкырып кəлəрсең дə...

Ишектə звонок.

С у е р б а е в. Кертмə. Мине сорасалар, юк диген.

М ө к ə р р ə м ə. Тилермə инде, Шаһибəк.

Ишеккə бара. Култык астына шахмат тактасы кыстырган Айнеев керə.

Айнеев. Хәерле кич, Шагибек Шагиевич.
Суербаев. Хәерле кич.
Айнеев. Сез кайтканны көтеп алҗыдым. Өч партия.
Мөкәррәмә. Кәефе юк әле аның, Җаббар Гатауллович.
Айнеев. Яббар Атауллович, Мокаряма ханым. Ә Шагибек Шагиевичка ни булган?
Суербаев. Юк ла. Чепуха.
Айнеев. Руководительнең андый чаклары була. Беләм. Утыз ел руководство эшендә эшләдем. Аның өчен, Шагибек Шагиевич, үзенне ял иттерергә кирәк. Өйгә кайткач, все к черту, оныт. Только тынычлык. *(Шахматны өстәлгә таратып.)* Вот иң яхшы ял. Ике-өч мат и тынычлап йоклыйсың.
Суербаев. Гафу итегез, бүген уйнамыйм, Яббар агай.
Айнеев. Серьезныймы берәр нәрсә? *(Бармагы белән түшәмгә күрсәтеп).* Анда?
Мөкәррәмә *(идәнгә күрсәтеп).* Монда.
Суербаев. Мөкәррәмә!..
Айнеев. Алайса, действительно чепуха. Ә между прочим, хәзер... Килешәсезме, Мокаряма ханым, хәзер руководство һәм сотрудниклар арасындагы интервал югалды. Мин пенсиягә киткәнче үк югала башлаган иде, хәзер бөтенләй бетеп бара. Любой обыкновенный сотрудник руководитель белән шундый итеп сөйләшә, гаҗәп и только. Хөрмәт бетә.
Мөкәррәмә. Хөрмәтне, Яббар Гатауллович, интервал саклап кына яулап булмый.
Айнеев. Ә авторитет кайда? Руководительнең авторитеты? Әгәр аны руководитель итеп куйганнар икән, значит, ни дә булса бар. Необязательно һәрбер сотрудникка аны белергә. Минем бәхет — пенсиягә чыгып котылдым. Ато эшләргә дә була иде. Опыт бар. Һәрберсе акыл өйрәтә башлагач, үзегез эшләгез дидем дә киттем.
Мөкәррәмә. Хәзер чакырмыйлармы?
Айнеев. Кая?
Мөкәррәмә. Элекке эшегезгә. Сез киткәч, сездән башка нишлиләр икән мескеннәр?
Суербаев. Мөкәррәмә!..

Мөкәррәмә көлеп кухняга кереп китә.

Айнеев. Әйе... Да... Уйнамыйм дисезме?
Суербаев. Яббар абзый, сезгә буш сүз сөйлисең, иптәш Айнеев, дип әйткәннәре булдымы?
Айнеев. Буш сүз? Ничек?
Суербаев. Бүген минем докладым беткәч, бер сотрудигым торды да мәгънәсез буш сүз сөйләдең, диде.
Айнеев. Сиңамы? Лично үзеңә?
Суербаев. Җыелыш алдында. Әхәт Исламович та шунда.
Айнеев. Вот оно что-о!.. Кем инде ул?
Суербаев. Бүлектә эшләүче гади сотрудник.
Айнеев. Прямо шулай дип әттеме?
Суербаев. Әйтте.
Айнеев. Әхәт Исламович ничек реагировать итте?
Суербаев. Күрмәдем.
Айнеев. Вот монысы начар. Иң беренче аның йөзенә карарга иде. Шуннан вывод ясыйсың.
Суербаев. Кем уйлаган. Гомердә булмаган хәл бит. Ни уйларга да белмим. Мөкәррәмә кысыр хәсрәт ди...
Айнеев. Мокаряма ханым белми, ул руководитель булып карамаган. Куарга, Шагибек Шагиевич, немедленно куарга! Да, куарга! Если син үзеңнең руководителеңнең берәр недостаткасын күрәсең икән,

рөхсәт сорап кабинетыңа кер. Җайлап кына әйт. *(Айнеев пенсионер икәнлеген онытып, үзе җитәкче булган чагындагы кебек өстәлгә ике кулы белән таянып сөйли. Әйтерсең лә, Суербаев аның гаепләнгән хезмәткәре).* Син монда, иптәш, демагогию не разводи. Эшлисең килә икән, эшлә, условиеләре тудырылган. Ато нәрсә бу, безобразие, җыелышта торасың да теләсә нәстә кычкырасың. Бу сиңа не базар! И мин сиңа какой-нибудь ит сатучы түгел! Что, җыелышның порядогын белмисезме, институтта сиңа нәрсә өйрәттеләр? Молчать! Бу нинди анархия? Вот сиңа шул. Я эшлисең, я башка руководитель эзлисең. Миңа андый бутозерлар кирәкми. Мин государственный учреждениене җитәклим, минем көпчәккә таяк кыстырырга ничево. Җаловаться итәм дисәң, пожалуйста. Подумаешь, герой.

Суербаев. Реплика өчен куу...

Айнеев *(туктый алмыйча)*. Авторитетыңны трын-трарам китерү өчен бер реплика җитеп арткан. Ежовый перчаткада тотарга кирәк. Если син яхшы, пожалуйста, условие, если так-сяк, да еще телең авызыңа сыймый, үзеңә үпкәлә, иптәш. Мин әйттерми идем, Шагибек Шагиевич, минем заместителем дә кабинетыма в порядке очереди керә иде. Что ж, мине пенсиягә җибәрделәр, хәзер юбилейларга да чакырмыйлар, зато үземнән көлдермәдем. Вот күрерсең, иртәгә Әхәт Исламович чакырып алыр да әйтер, но и дисциплина синдә, Суербаев, дияр. Ни әйтерсең? Ул тегенең буш сүз дию чепуха, вот Әхәт Исламовичның ишетүе... Вот кайда собака зарыта. Допустил шуна хәтле, үзеңә үпкәлә. Күпме предупредил мин сине.

Суербаев. Хәзер ул заман түгел, Яббар абзый. Сезнең стиль белән эшләп булмый. Һәм рөхсәт тә итмәячәкләр.

Айнеев. А нигә, алай булгач, кайгырасың? Үз стилең. Иртәгә кыйнап та китәчәкләр сотрудникларың. Вот тебе и стиль.

Суербаев. Әллә чыннанда буш сүз сөйләдем микән?

Айнеев. Но и что. Мин утыз ел эшләдем. Утыз ел постоянно акыллы сүз генә сөйләп булмый. Сотрудник икән, будь добр, тыңла. Руководитель булгач, үзең сөйләрсең. Докладны үзең язган идеңме?

Суербаев. Шәмиев әзерләште. Бүлек мөдире. Ашыгыч булгач, чынлап укып чыгарга да өлгермәдем.

Айнеев. И аңарга да строгачны чәпә. Кемгә нәрсә язганын белсен.

Телефон шалтырый. Суербаев трубканы ала.

Суербаев. Суербаев тыңлый. Әхәт Исламович?!

Шомлы пауза.

Пәрдә

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шырмали Мортазинның бер бүлмәле квартирасы. Пәрдә ачылганда Дәрига китап укып ята. Ишек ачылган тавыш.

Дәрига *(тавышны ишетеп)*. Син кайттыңмы?

Шырмали тавышы. Мин.

Дәрига. Ботинкаңны салып чистартып куй, тәтием. Кулларыңны юып бәрәңге әрче. Ит кайнаган.

Шырмали *(бүлмәгә узып)*. Гүзәлләрнең гүзәле, сылуларның сылуы патша кызы Дәрига диванда ырын ятып китап укысынмы?

Дәрига. Синең кайчан кайтасыңны кем белә... Театрга барабыз диган идең.

Шырмали. Һәм барабыз. Билет кесәдә. Бүген театрга барам трата-та, трата-та, хатыным белән бергә, трата-та, трата-та. *(Дәриганы кочаклый.)*

Д ә р и г а. Җибәр. Сакалың кытыклый.

Ш ы р м а л и. Кытыкласын. Үзең шулай телисең.

Д ә р и г а. Сиңа килешә. *(Шырмалиның сакалын сыпыра.)*

Ш ы р м а л и. Бәйләнделәр шуңарга. Ни өчен үстерәсең, имеш. Безнең бүлектәге бер пеләш егет, сакал үстерү кыланчыклык бәласе, ди.

Д ә р и г а. Ә син аңа әйт, үсеп җиткәч сиңа бүләк итәм, парик итеп киярсең, диген. Күтәреп илт, тәтием, кухняга. Пешереп бетерик ашны.

Ш ы р м а л и. Иртәгә ял, рәхәтләнеп пешерербез. Бүген берәр җиргә генә кереп ашарбыз.

Д ә р и г а *(Шырмалины кочаклап)*. Тәтием лә соң минем. Арыдыңмы?..

Ш ы р м а л и.

Арыдыңмы дип сорыйлар,
Арымаган кайда ул.

Д ә р и г а. Шырмали, җырны бозма.

Ш ы р м а л и.

Бозма җырны дип әйтәләр.
Бозучылар без түгел.

Д ә р и г а. Ни булды сиңа бүген, тәтием? Җырлап кына торасың.

Ш ы р м а л и. Гүзәлләрнең гүзәле, сылуларның сылуы патша кызы Дәрига, синең Шырмалиең бүген зур батырлык эшләде.

Д ә р и г а. Тагын берәрсе белән бәхәсләшеп кайттыңмы?

Ш ы р м а л и. Бәхәсләшеп тормадым, әйттем генә. Тордым да әйттем, табигать биргән кыска гына гомернең сәгать ярымы тагын әрәмгә китте, дидем. Бер сәгать ярым буш сүз тыңлап утырдым, дидем.

Д ә р и г а. Кемгә?

Ш ы р м а л и. Башлыкның үзенә.

Д ә р и г а. Шаһибәк Шаһиевичкамы?

Ш ы р м а л и. Нәкъ үзенә. Ул бүген сәгать ярымлык эчпошыргыч буш доклад сөйләде.

Д ә р и г а. Җыелыштамы?

Ш ы р м а л и. Шунда. Зал шым булды. Шаһибәк Шаһиевич бер агарды, бер кызарды. Сүз әйтә алмады. *(Дәриганы кочып.)* Нигә шулай карыйсың, гүзәлләрнең гүзәле, сылуларның сылуы?..

Д ә р и г а. Я, җибәр әле. Акылың да сакалың кебек булса... Күпме өйрәтәм, күпме тырышам. Көн саен нинди дә булса тилелек эшләп кайтасың. Я инде, нәрсә инде, тагын нәрсә җитмәде?

Ш ы р м а л и. Туктале син...

Д ә р и г а. Туктамыйм да, нитмим дә. Ана сөте белән кермәгән тана сөте белән керми, ахры. Соңыннан гафу үтендеңме, ичмасам.

Ш ы р м а л и. Ни өчен?

Д ә р и г а. Үзеңнең юньсезлегең өчен.

Ш ы р м а л и. Минемчә, ул үзе гафу үтенергә тиеш иде. Ул бит минем вакытымны урлады.

Д ә р и г а. Ташла, зинһар. Кәефем әйбәт иде, боздың. Театрына да бармыйм. *(Диванга барып ята.)*

Ш ы р м а л и. Мин тилелек эшләдем инде, алайса?

Д ә р и г а. Синнән башкалар дәшми утырганнардыр әле. Бу каян килгән Камыр батыр. Сикереп чыгарга оста. Урыныңа утыртырлар әле бер. Исеңә төшәр. Имеш, ул курыкмый. Юньсезлек эшләр өчен батырлык кирәкми.

Ш ы р м а л и. Я инде, әйткән беткән.

Д ә р и г а. Беткәнен көтеп тор. Синең аркада миннән дә көләләр. Әйбәт белгеч дип мактаганга үсеп киттең. Ни әйткәнеңне белмисең. Шырмали дисәң Шырмали, исемеңне белеп кушканнар. Ни күзең белән күренерсең Шаһибәк Шаһиевичка?

Ш ы р м а л и. Соң, Дәрига, дөресен әйткән өчен... безнең Шаһибәк Шаһиевич юләр түгел, аңлар.

Д ә р и г а. Аңлады ди, аңламый ни. Болай булсаң, гомереңдә рәтле кеше була алмыйсың син. Кая эшкә керсәң, шуннан куып чыгарачаклар. Дөрес сүзләреңне, аннары, урамда кычкырып йөрерсең.

Ш ы р м а л и. Булды, куркытма. Әйдә, җыен.

Д ә р и г а. Мине саңга сукмагач, минем киңәшләремә колак салмагач, үзең генә йөр.

Ш ы р м а л и. Ярый соң, алайса. *(Чыгарга җыена.)*

Д ә р и г а. Кая?

Ш ы р м а л и. Билетларны сатып кайтам.

Д ә р и г а *(елап)*. Кай җиреңне яратамдыр. Берәү булса, синең бу тинтәк холкың белән бер көн дә тормас иде.

Ш ы р м а л и. Мин дә торам ич, син генә түгел. Гел мине гаеплисең.

Д ә р и г а. Кешеләрдә ачуың булса, миңа кайтып кычкыр, мине ачулан, дөрес сүзләреңне миңа әйт, түзәрмен. Синең үзеңне кызганып әйтәм, харап буласың.

Ш ы р м а л и. Я инде, ишеттем ич инде...

Д ә р и г а. Ишетәсең син, тик аңламыйсың.

Ш ы р м а л и. Ярый инде, тупасрак чыккандыр, әдәпсезрәк булган. Аңладым. Нишләтим, характерым шундый булгач, түзә алмадым. Үтер инде шуның өчен.

Д ә р и г а. Юк, син мине үтерәсең.

Ш ы р м а л и *(утырып)*. Уф, кем уйлап тапкан бу өйләнешеп яшәүне. Рәхәт иде егет чагымда — акыл өйрәтүче дә, юл күрсәтүче дә юк иде.

Ишектә звонок. Шырмали барып ача. Шәмиев белән керәләр.

Ш ә м и е в. Исәнмесез, Дәрига ханым.

Д ә р и г а *(төзәтенеп)*. Исәнмесез.

Шәмиев урындыкка утыра. Шактый озын пауза.

Ш ә м и е в. Кәефләрегез ничек, Дәрига ханым?

Д ә р и г а. Әйбәт.

Тагын пауза.

Ш ә м и е в *(Шырмалига)*. Дәрига ханыма сөйләденме?

Ш ы р м а л и. Дәрига дип кенә сөйлә әле. Төхби, ханым дигәч хатыным карт булып күренә башлый. Тагын вәгазь укырга килдеңме?

Ш ә м и е в. Юк. Эчем пошканнан. Өйгә кайткан идем, тынычлана алмадым, килдем.

Ш ы р м а л и. Без хәзер театрга китәбез.

Д ә р и г а. Алдаша. Мин бармыйм дидем.

Ш ә м и е в. Димәк, сез беләсез, Дәрига?

Д ә р и г а. Кайтып мактанды.

Ш ы р м а л и. Сез икәүләшеп мине төзәтә торыгыз, мин кәмит карап кайтыйм.

Ш ә м и е в. Утыр әле, Шырмали дус, мәсьәлә син уйлаганнан катлаулырак бит. Бу синең үзеңә генә түгел, миңа миңа да кагыла.

Ш ы р м а л и. Синең ни катнашың бар. Әгәр чыннан да мин начар эшләгәнмен икән, үзем генә җавап бирермен.

Ш ә м и е в. Җавап бирерсең. Анысы икенче мәсьәлә. Монда мәсьәлә болай тора, син коллектив члены. Синең һәрбер әйткән сүзең коллектив исеменнән, дусларың исеменнән. Син дусларың, коллектив турында да уйларга тиеш идең. Бүгенге синең ахмаклыгың очраклы хәл түгел. Синең андый анархистлыгың гадәтенә кереп бара. Бу безне борчый. Мин бүлек мөдире һәм синең дусың буларак...

Шырмали. Без синен белән дус булганыбыз юк, Төхби.

Дәрига. Шырмали!..

Шәмиев. Дус булмасак, дошман да түгел. Менә мин синең өчен борчылып килдем бит әле.

Шырмали. Куркып диген. Син килеп ялгышкансың. Әгәр Шаһибәк Шаһиевич безгә килгәнеңне сизсә, эшләрең харап. Син аңа каршы әзерләнгән заговорда катнашучы буласың.

Шәмиев. Шаярма.

Шырмали. Чынлап, шаярырлык түгел шул. Я, хода, минем бер репликам кешеләрне нишләткән. Шырмалиның яшь әтәч кебек бер талпынып куюы... Көлке бит бу, Төхбетдин. Шаһибәк Шаһиевич аны әллә кайчан онытткандыр, син чебеннән фил ясап...

Шәмиев. Хәтерең ялгышмаса, президиумда бүтәннәр дә бар иде.

Шырмали. Әхәт Исламович дип өзеп әйт. Беләсең килсә, Әхәт Исламович иртәгә Шаһибәк Шаһиевичны чакырып алып минем репликамны хуплаячак. Мин әйткән кебек кенә әйтмәячәк. Ул акыллы мужик. синең белән без түгел. Бар, тынычлап кайтып йокла, Төхби, ул-бу булса, син мине белмисең, мин сине белмим. Күргәнем дә юк.

Шәмиев. Шулай да син, Шырмали, гафу үтен. Кызып китеп ялгышканмын, уйлап ук бетермәгәнмен, диген.

Шырмали. Мин уйлап бетермәгән сүземне әйтмим.

Дәрига. Сөйләп утыра, ичмасам, эч пошырып. Синең телең акылыңнан алда селкенә башлый.

Шырмали. Рәхмәт, гүзәлләрнең гүзәле, минем хатыным. Ничек бер-берегезне элегрәк табышмагансыз, гаҗәп. Бер-берегезгә акыл өйрәтеп, вәгазь укып рәхәтләнеп гомер кичерер идегез. Картлыгыгыз бәхетле һәм мул булыр иде. Беләсең килсә, Дәрига ханым, Төхби безгә синең юләр иреңнең язмышы өчен борчылып килмәгән. Аның үз хәле хәл. *(Кычкырып көлә.)* Син барып гафу үтен, Төхби, Шаһибәк Шаһиевичтан. Ул бит син язып биргән мәгънәсез, ялыктыргыч буш докладны укыды. Син бит аңа, урысча итеп әйткәндә, свинью подложил. *(Көлүен дәвам итеп.)* Үзеңә эш эзлә, Төхби. Суербаев сине алып ыргыта да зирәклегем өчен бүлек мөдире итеп мине куя. Менә эшләр кая тәгәри... Җитди сөйләшсәк, мин гафу үтенәчәкмен. Ләкин синең өчен түгел, Төхби. Үземнең тотнаксызлыгым өчен. Үзенә генә әйтергә кирәк иде Шаһибәк абыйның.

Шәмиев. Әйе, синең белән уртак тел таба алмабыз, күрәсең. Үзеңне коллективтан өстен дип санныйсың икән...

Ишектә звонок.

Шырмали. Тагын бер хәзрәт үгетләргә килә. Кемгә кирәк, ишекне шул ачсын.

Звонок кабатлана. Дәрига барып ишекне ача, Суербаев белән Мөкәррәмә керәләр.

Мөкәррәмә. Хәерле кич!

Суербаев. Таныш булыгыз, Мөкәррәмә апагыз. *(Дәригага.)* Сез шушы сакалбайның хатыны буласызмы?

Дәрига. Әйе... Утырыгыз.

Суербаев. Менә килдек әле. Көчкә эзләп таптык адресыңны. Телефон кертергә кирәк, сакалбай. Без килгәнгә аптырадыгызмы? Гомердә булмаганны, әйе бит?

Шәмиев. Мортазин үзе, Шаһибәк Шаһиевич...

Суербаев. Менә Мөкәррәмә апагыз алып килде. Аңлат, Мөкәррәмә, безнең визитның сәбәбен.

Мәкәррәмә. Алар аңладылар инде.

Суербаев. Әйе, син гафу үтенергә тиеш, сакалбай. Иртәгә кабинетыма чакыртып гафу үтендерергә теләгән идем дә, иртәгәгә хәтле ничек түзәсең. Миңа йокларга да кирәк. Ә минем яшьтә тиз генә йоклап китү — чиген нәрсә. Бигрәк тә бүгенге хәлдән соң.

Шырмали. Әллә чынлап?..

Суербаев. Үзең ничек уйлыйсың. Мин бит син уйлаганча ук аңсыз түгел. Менә син житәкче булырсың, трибунадан доклад сөйләрсең. Дистәләгән кешеләр сине өмет белән тыңларлар. Шунда берәү сикереп торыр да сиңа буш баш дип кычкырыр.

Шырмали. Мин алай дип әйтмәдем. Мин конкрет бүгенге докладыгыз турында...

Суербаев. Бүтәннәре әйбәт идеме?

Шырмали. Файдалы...

Суербаев. Я, гафу үтен дә без китик.

Мөкәррәмә. Шаһибәк, син ничек сөйләшәсең? Ничек сиңа оят түгел. Ул сиңа сабый мәллә. Без бит...

Суербаев. Тукта, Мөкәррәмә, башта мин кушканны эшләсен. Житәкче буларак әйтмим, өлкән кеше буларак боерам. Минем шуңа хакым бармы, Мортазин?

Шырмали. Мин оныткансыздыр инде дип уйлаган идем.

Суербаев. Юк. Син гафу үтен. Кичерегез, Шаһибәк абзый диген.

Шырмали. Кичерегез, Шаһибәк Шаһиевич.

Суербаев. Шаһибәк Шаһиевич түгел, Шаһибәк абзый.

Шырмали. Шаһибәк абый.

Суербаев. Кичерәм. *(Дәригага.)* Берәр чынаяк чәең булмасмы, сеңел?

Дәрига. Гафу итегез, Шаһибәк абзый. *(Кухняга кереп китә.)*

Суербаев. Инде әйт, Мортазин, син ни өчен гафу үтендең?

Мөкәррәмә. Шаһибәк, интектермә.

Суербаев. Әйтсен!

Шырмали. Шаһибәк Шаһиевич!..

Суербаев. Кызма, кызма, кызма! Мин синең куңагың.

Шырмали. Соң бит ни... Үземне ялгыш тоттым, начар, әдәпсез һәм башкалар. Уйламыйчарак.

Суербаев. Димәк, минем докладым син җыелышта әйткәнчә түгел иде? Әйбәт иде, әйеме?

Шырмали. Әйбәт дип...

Суербаев. Кистереп әйт!

Шырмали. Сез нәрсә?

Шәмиев. Ул аңлады, Шаһибәк Шагиевич...

Суербаев. Мин сезнең белән сөйләшмим, Шәмиев. Мортазин үз теле белән җавап бирсен. Ничаклы халык алдында әйткәнне миннән оялмас.

Шырмали. Докладыгыз начар иде, бик начар иде, Шаһибәк абый. Мин сезнең өчен оялып утырдым.

Суербаев. Ала-ай! Аңлашылды. Киттек, Мөкәррәмә.

Мөкәррәмә. Житәр, шаярма, Шаһибәк. *(Шырмалига.)* Сез борчылмагыз... Сакалбаймы әле?.. Гафу итегез. Мортазин, Шаһибәк абзагыз барысын да аңлады. Ул...

Суербаев. Әйе. Сиңа борчылмаска мөмкин. Акыллы доклад сөйләүче житәкчеләрне эзлә. Үз теләгем белән китәм, дип үтенеч язарсың иртәгә. Мин үтенечеңә каршы килмәскә тырышырмын. Үз кулым белән үңган, принципиаль, туры сүзле егет дип характеристика язып бирермен. Килештекме!

Дәрига *(чәй алып чыгып)*. Рәхим итегез, Шаһибәк Ша...

С у е р б а е в. Утырмыйм да, чәегезне дә эчмим. Котлыйм сине, сеңел, ирең шәп егет. Ләкин, аерылышырга туры килә миңа аның белән... Озын теллеләрне мин яратмыйм.

Д ә р и г а. Шаһибәк Шаһиевич, зинһар өчен... Аның характеры...

С у е р б а е в. Характерын бүтәннәргә күрсәтсен. Шулай, түбәннән тәнкыйть әйбәт нәрсә, сакалбай. Иртәгә документларыңны әзерләп бирерләр. *(Ишеккә бара.)*

М ө к ә р р ә м ә. Шаһибәк, әллә син чынлап?.. Килгәндә...

С у е р б а е в. Килгәндә шулай иде, киткәндә болай. Күрәсең ничек. Сер бирергә теләми.

Д ә р и г а. Шырмали!.. Бераз гына вөжданың бармы синең?

Ш ә м и е в. Иптәш Мортазин, бүлек мөдире буларак мин сиңа әйтәм, коллектив сине...

Ш ы р м а л и. Нәрсә барыгыз да. Ни кирәк сезгә миннән, ни телисез?

Д ә р и г а. Әйбәт диген, Шырмали.

Ш ә м и е в. Файдалы иде, диген.

Ш ы р м а л и. Күңелегез булсын...

С у е р б а е в. Я, я... *(Шырмали янына килеп)*. Әйтеп бетер. Я инде! Нигә туктап калдың?

Ш ы р м а л и. Бик начар иде, Шаһибәк абый.

Д ә р и г а. Кире беткән Шырмали!..

Ш ә м и е в. Кире беткән Мортазин!

С у е р б а е в. Шырмали Мортазин! Бир әле кулыңны.

Ш ы р м а л и. Нигә?

С у е р б а е в. Бир! Молодец, дип әйтеп бер кысыйм. Кире беткән, үз сүзле һәм хаклы булганың өчен.

Ш ы р м а л и. Менә инде... *(Кулын суза.)*

С у е р б а е в. Гафу ит, сакалбай.

Ш ы р м а л и. Гомердә булмаганны...

**Пәрдә.**

# ТАТАРСТАН–РЕСПУБЛИКАМ МИНЕМ

## БӘЙРӘМ ТАНТАНАЛАРЫ

Татарстанның 50 еллык бәйрәмен республикабыз хезмәт ияләре гаять тантаналы шартларда, зурлап билгеләп үттеләр. Театрларда, концерт залларында, клубларда, культура сарайларында, паркларда атна буе бәйрәм тантаналары дәвам итте.

Республикабызның ярты гасырлык бәйрәменә багышланган тантаналар Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында башланып китте. 25 июнь көнне бергә СССР, РСФСР һәм ТАССР Верховный Советлары депутатлары, Советлар Союзы Геройлары һәм Социалистик Хезмәт Геройлары, партия ветераннары, хезмәт алдынгылары, фән һәм культура эшлеклеләре, күп санлы кунаклар җыелды. Алар КПССның Татарстан өлкә комитетының һәм Татарстан АССР Верховный Советының республикабызның 50 еллыгына багышланган берләштерелгән тантаналы утырышына килгәннәр иде.

Тантаналы утырышны, кыскача кереш сүз сөйләп, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе **С. Г. Батыев** ачты. Шуннан сүз КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы члены, партия Үзәк Комитеты секретаре **А. П. Кириленкога** бирелде. Ул 50 ел вакыт эчендә Совет Татарстаны ирешкән казанышлар турында сөйләде, аннары СССР Верховный Советы Президиумының Татарстан АССРны **Октябрь Революциясе** ордены белән бүләкләү турындагы указын игълан итте һәм утырыш президиумына КПСС Үзәк Комитетының, СССР Верховный Советы Президиумының һәм СССР Министрлар Советының котлау хатын тапшырды.

КПССның Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре **Ф. А. Табеев** «Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасына 50 ел» дигән темага доклад ясады.

Тантаналы утырышта шулай ук РСФСР Министрлар Советы Председателе урынбасары **В. И. Кочемасов**, күрше өлкәләрдән һәм Автономияле Республикалардан килгән делегация җитәкчеләре, республикабыз җәмәгатьчелеге вәкилләре чыгыш ясады. Татарстан АССРның 50 еллыгы уңае белән килгән котлау телеграммалары игълан ителде.

Тантаналы утырышта катнашучылар КПСС Үзәк Комитеты, СССР Верховный Советы Президиумы, СССР Министрлар Советы адресына һәм РСФСР Верховный Советы Президиумына, Россия Федерациясе Министрлар Советына тәбрик хатлары белән мөрәҗәгать иттеләр.

Татарстанның 50 еллыгына багышланган тантаналы утырыш совет халыкларының интернациональ дуслыгын раслаучы матур демонстрациягә әйләнде.

* * *

Шул ук көнне КПСС өлкә комитетының һәм Татарстан АССР Верховный Советының берләштерелгән тантаналы утырышында катнашучылар һәм юбилейга килгән кунаклар Ирек мәйданындагы В. И. Ленин һәйкәленә чәчәк бәйләмнәре куйдылар.

* * *

Кичен Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында, тантаналы җыелышта катнашучылар өчен, республикабызның сәнгать осталары көче белән зур концерт бирелде.

* * *

Республикабызның 50 еллык юбилеена багышланган зур бәйрәм тантанасы 27 июньдә В. И. Ульянов-Ленин исемендәге үзәк стадионда дәвам итте. Бергә җыелган 30 меңнән артык тамашачы алдында революция һәм хезмәт ветераннары, төрле спорт җәмгыятьләре коллективлары, цирк артистлары, җырчылар чыгыш ясады.

Казанка елгасында һәм шәһәр паркларында да олы бәйрәмгә багышланган шундый ук тантаналар булып үтте.

## ХЕЗМӘТЕ ЗУРНЫҢ — ХӨРМӘТЕ ЗУР

Татарстан АССРның 50 еллыгы уңае белән һәм хезмәттә ирешкән уңышлары өчен, республика халык хуҗалыгы һәм культурасының бик күп хезмәткәрләренә РСФСРның һәм Татарстан АССРның мактаулы исемнәре бирелде, меңнән артык кеше почет грамоталары белән бүләкләнде. Алар арасында әдәбият һәм сәнгать кешеләре дә байтак.

Совет сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен, Татар дәүләт академия театры артисты Ш. Биктимировка, Качалов

исемендәге Зур драма театры артисткасы **В. Павловага**, Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры җырчысы **В. Шәриповага РСФСРның халык артисты** дигән, Г. Камал исемендәге Татар академия театрының директоры **Р. Җиһаншинага** һәм Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры бинюесе **Р. Садыйковка РСФСРның атказанган артисты** дигән мактаулы исемнәр бирелде.

Совет сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен, композитор **Р. Яхинга РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе** дигән исем бирелде.

Өлкән буын язучыларыбыздан **Гариф Галиев** һәм **Нури Арсланов** РСФСР Верховный Советы Президиумының **Мактау грамоталары** белән бүләкләнделәр.

Сәнгатебезне үстерүдәге хезмәтләре өчен, Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе җырчысы **Ә. Афзаловага**, Качалов исемендәге Зур драма театры артисткасы **В. Уликка**, Минзәлә татар драма театры артисты **Ә. Фәсхетдиновка**, Г. Камал исемендәге Татар академия театры артисткасы **М. Халитова-Миңлебаевага Татарстан АССРның халык артисты** дигән, ә Татарстан республика күчмә театры артисткасы **С. Исмәгыйловага**, Качалов исемендәге Зур драма театры артисты **В. Кушнерга**, Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры җырчысы **Ф. Тимеровага** һәм Әлмәт драма театры артисты **Т. Кичүбаевка Татарстан АССРның атказанган артисты** дигән мактаулы исемнәр бирелде.

Театр сәнгатен пропагандалауда күренекле хезмәтләре өчен, Татар академия театрының баш художнигы **М. Сутюшевка Татарстан АССРның халык художнигы** дигән исем бирелде.

Художниклардан **В. Карамышевка** һәм **В. Маликовка**, яшь композитор **М. Ярулլинга Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе** дигән мактаулы исемнәр бирелде.

Культура өлкәсендәге хезмәтләре өчен, Татар академия театрының баш администраторы **С. Шәкүровка Татарстан АССРның атказанган культура работнигы** дигән исем бирелде.

Татарстан язучыларыннан унлап кеше ТАССР Верховный Советы Президиумының **Мактау грамоталары** белән бүләкләнде.

## БҮЛӘК АЛГАН КИТАПЛАР

Республикабызның 50 еллык юбилее көннәрендә Мәскәүдән шатлыклы хәбәр килде. РСФСР Матбугат Комитеты үткәргән конкурста Татарстан китап нәшрияты чыгарган китаплар да югары бәя алган.

Журналыбызның алдагы санында әйтелгәнчә, Сибгат Хәкимнең рус һәм татар телләрендә чыккан «Күңелем Ленин белән сөйләшә» исемле сувенир китабы икенче дәрәҗә диплом алды, ә шул ук китапның полиграфия ягыннан эшләнеше өчен, Камил Якуб исемендәге Матбугат комбинатына беренче дәрәҗә диплом бирелде.

Беренче класс өчен төсле рәсемнәр белән чыгарылган «Татар теле» дәреслеге (авторлары М. Ш. Галлямова, С. Г. Вагыйзов, Р. Г. Вәлитова) шулай ук икенче дәрәҗә диплом белән бүләкләнде. Редакторы М. Әхмәтгалиева, художниклары П. Григорьев, А. Садыйков, Э. Зарипов, макет А. Садыйковныкы, техник редакторы В. Галкина.

Р. Нәфиковның «Первый шаг в революцию» дигән китабы (редакторы В. Белокопытов, художнигы М. Семенов, техник редакторы Ә. Трофимова), Ф. Вәлиевның «Орнамент казанских татар» исемле хезмәте (редакторы В. Юневич, художнигы И. Субаев, художество редакторы Э. Сподикова, техник редакторы Э. Зарипов) һәм «Татарстан» исемле фотоальбом (редакторлары М. Зарецкий белән Р. Шахмуратова, художнигы И. Әхмәдиев, художество редакторы Б. Әлменов, техник редакторы З. Ибраһимова) кызыксындыру дипломнары алды.

Полиграфия ягыннан яхшы эшләнеше өчен, Г. Тукайның «Эш беткәч, уйнарга ярый», Г. Мөхәммәтшинның «Ак песи» дигән китаплары икенче дәрәҗә дипломнары белән бүләкләнде. Бу китапларның икесенең дә редакторы Р. Вәлиева, художнигы Т. Хаҗиәхмәтов, техник редакторы Ә. Трофимова.

## ЮБИЛЕЙ СПЕКТАКЛЬЛӘРЕ

Татарстан бәйрәмен республикабыз театрлары яңа спектакльләр белән каршыладылар.

23 июньдә Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында «Беренче факел» исемле музыкаль комедиянең премьерасы булды. Татарстан нефтьчеләренә багышланган бу әсәрне композитор Әнвәр Бакиров иҗат иткән. Либретто авторы — Алла Рустайкис.

Комедияне сәхнәгә режиссерлар В. Жданов һәм В. Загурский, хормейстрлар В. Макаров һәм Т. Гудкова, балетмейстр В. Шумейкин куйган. Төп рольләрне РСФСРның халык артисты А. Аббасов, Татарстанның халык артисткасы Г. Сәйфуллина, Татарстанның атказанган артисткасы Н. Зайцева һәм башкалар башкарды. Дирижеры — В. Васильев, художнигы — Э. Нагаев.

Яңа музыкаль комедияне Казан тамашачылары җылы каршылады.

* * *

Шул ук көнне Казан тамашачылары тагын бер премьера белән таныштылар. Ленин орденлы Татар академия театры сәхнәсендә Кәрим Тинчуринның «Зәңгәр шәл» исемле мәшһүр драмасы күрсәтелде. Әсәрне сәхнәгә театрның баш режиссеры, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе М. Сәлимҗанов куйган. Художнигы — М. Сутюшев, балетмейстры — Ф. Гаскәров. «Зәңгәр шәл»нең яңа постановкасын халык гаять җылы кабул итте.

## ТАТАРЧА ЦИРК

Республикабызда тагын бер сәнгать коллективы артты. Татарстанның 50 еллыгын бәйрәм иткән тантаналы көннәрдә Казанда татар циркы эшли башлады. Яшь коллектив тамашачылар каршындагы беренче имтиханны уңышлы тотты. Алар хәзерләгән барлык номерларны диярлек халык алкышлап каршылады.

## ЮБИЛЕЙ КҮРГӘЗМӘСЕ

Татарстан сынлы сәнгать музеенда республика художникларының юбилей күргәзмәсе ачылды. Анда художникларыбызның ярты гасыр вакыт эчендә иҗат ителгән иң яхшы әсәрләре куелган.

## ОЧРАШУЛАР, ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

Июнь урталарында Татарстанның X еллыгы исемендәге Культура сараенда республикабызның 50 еллыгына багышланган әдәби-музыкаль кичә булып узды. Киров районының хезмәт алдынгылары каршында үзешчән артистлар, язучылар чыгыш ясады.

Татарстан язучылар союзы идарәсенең җаваплы секретаре Г. Ахунов илле ел эчендә татар совет әдәбияты узган зур юл турында сөйләде. Шагыйрьләрдән З. Нури, Ш. Галиев, И. Юзеев үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар. Кичә бик җылы узды.

* * *

РСФСРның төрле өлкәләрендәге мәктәпләрдә татар теле һәм әдәбияты укытучылар, һәр елны Казанга килеп, үзләренең белемнәрен күтәреп китәләр. Быелгы курсларга 300 дән артык кеше килгән иде.

30 июньдә алар Г. Тукай исемендәге клубта язучылар белән очраштылар. Очрашуда татар язучыларыннан Г. Бәширов, Х. Туфан, С. Хәким, Г. Кашшаф, Г. Гобәй, Г. Минский, Н. Дәүли, З. Нури, Л. Ихсанова, Г. Латыйп, Г. Бакиров, Р. Батуллин, Р. Гатауллин һәм башкалар катнашты. Алар үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар, иҗат планнары белән уртаклаштылар, истәлекләр сөйләделәр. Очрашуда катнашучы укытучылар исеменнән дә берничә кеше чыгыш ясады.

## КАЗАНДА МОНГОЛИЯ ЯЗУЧЫЛАРЫ

1—3 июльләрдә республикабыз башкаласы Казанда бер төркем Монголия язучылары булып китте. Делегация составында Монголия язучылар союзы идарәсе секретаре, «Цог» журналының баш редакторы, шагыйрь Д. Тарва, прозаик С. Дашдор, тәнкыйтьче О. Бямбажав һәм Мәскәү язучысы, тәрҗемәче А. Гатов иптәшләр бар иде.



Кунаклар Казан шәһәренең истәлекле урыннарын карадылар, республикабызның Ленин исеме белән бәйле урыннарында, Сынлы сәнгать музеенда, М. Горький музеенда, халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсендә булдылар. Алар шулай ук республика партия җитәкчеләре янында булдылар, Татарстан язучылар союзында татар язучылары белән очраштылар.

## ЖУРНАЛ СОРАП...

Шушенскоеда яшәүче Иван Варламович Рехлов дигән кеше бөек юлбашчыбыз В. И. Ленинга багышланган картиналар җыю белән шөгыльләнә икән. Утыз ел буена ул искиткеч бай коллекция туплаган. Ул туплаган картиналардан оештырылган күргәзмәләр хәзер киң илебезнең бөтен почмакларында, хәтта чит илләрдә дә күрсәтелә.

1971 елның маенда И. В. Рехлов Шушенскоеда «Совет матбугатының бер көне» дигән темага зур күргәзмә оештырырга уйлый. Анда 1970 елның апрелендә чыккан, ягъни В. И. Ленинның 100 еллыгына багышланып чыккан газета-журналлар куелачак. И. В. Рехлов, шул күргәзмәгә кую өчен, «Казан утлары» журналының Ленинга багышланган санын соратып алды.

* * *

Пенза шәһәрендә Халык музей-китапханәсе оештырылды. Ул юлбашчыбыз В. И. Ленин һәм Ульяновлар гаиләсе хакында материаллар җыя. Музей-китапханәнең Ленин фонды көннән-көн тулылана бара. Редакциягә «Казан утлары» журналының бөек юлбашчыга багышланган бәйрәм санын сорап, музей эшчеләреннән хат килде.

## ФИНЛЯНДИЯ КУНАКЛАРЫ ТАТАРСТАН БӘЙРӘМЕНДӘ

Республикабызның 50 еллыгына багышланган бәйрәм тантаналарында катнашыр өчен, Казанга Финляндиядә яшәүче татарлардан бер төркем кунаклар килде. Кунакларның берсе — Хельсинки университетында төрки телләр укытучы, әле күптән түгел

гена фәннәр докторы дәрәҗәсенә уңышлы рәвештә диссертация яклаган Гомәр әфәнде Таһир Казанда әүвәл дә ике тапкыр булып киткән иде. Бу юлы ул үзенең гаиләсе — хатыны Халидә ханым, улы Окан һәм кызы Рәхилә белән бергә килде. Соңгылар икесе дә — студентлар. Кунаклар арасында Тампере шәһәреннән килгән һәвәскәр шагыйрь Айса әфәнде Хәкимҗан да бар иде.

Бер атна дәвамында кунаклар Казан белән танышып күп урыннарда булдылар, күп кешеләр белән очраштылар, Үзәк стадиондагы спорт бәйрәменә бардылар, Идел буйлап сәяхәт ясадылар һәм Совет районындагы сабан туен күрделәр. Кояшлы иртәләрнең берендә кунаклар Тукай һәйкәле алдына чәчәкләр куйдылар, аннан соң, Г. Таһир Ирек мәйданындагы Ленин һәйкәленә чәчәкләр салды.

Г. Таһир әфәндене Татарстанның культура министры Булат Гыйззәтуллин кабул итте. Әңгәмә вакытында Хельсинкидагы Г. Тукай җәмгыятенең эшчәнлеге, планнары турында сүз барды. Шул җәмгыятьнең идарәсе исеменнән Г. Таһир киләчәктә дә татар галимнәре һәм артистларының Финляндиягә килеп, андагы татарларга гыйлем һәм мәгариф, сәнгать һәм әдәбият өлкәсендә ярдәм хезмәте күрсәтүләренә ихтыяҗ зурлыгын сөйләде.

## БӘЙРӘМ КИТАПЛАРЫ

Владимир Ильич Ленинның тууына 100 ел тулуга һәм Совет Татарстанының 50 еллыгына багышлап, республикабыз нәшриятлары күп кенә кызыклы китаплар чыгардылар. Журналыбызның алдагы саннарында аларның байтагы белән укучыларыбызны таныштырган идек. Бүген сезнең игътибарыгызга данлы юбилейлар хөрмәтенә чыгарылган тагын берничә китап тәкъдим итәбез.

**50 лет Татарской АССР. Рус телендә. «Статистика» нәшрияты. Казан. 1970 ел**

Узган ярты гасыр вакыт эчендә Татарстанның йөзе танымаслык булып үзгәрде. Иске Россиянең изелгән һәм кимсетелгән, караңгы һәм артта калган бер губернасыннан ул нык алга киткән эре промышленность үзәгенә, иң алдынгы техника белән коралланган авыл хуҗалыгы республикасына әверелде. Татарстан статистика идарәсе хезмәткәрләре тарафыннан әзерләнгән «50 лет Татарской АССР» исемле җыентыкка экономика һәм культура төзелеше өлкәсендә ирешкән уңышларыбыз хакында сөйли торган цифр һәм фактлар тупланган. Җыентыктагы саннар халык хуҗалыгының бөтен тармакларын иңли. Һәм алар Казан губернасының элекке кыен хәлен күзалларга, ярты гасыр вакыт эчендә ирешкән казанышларыбыз белән горурланырга мөмкинлек бирәләр.

Менә кайбер мәгълүматлар: 1913 ел белән чагыштырганда, республикада промышленность товарлары эшләп чыгаруның




гомуми күләме 337 мәртәбә арткан. Төзү материаллары промышленносте — 430, химия промышленносте — 253, электр энергиясе җитештерү 663 мәртәбә үскән. Билгеле булганча, республика халык хуҗалыгы үсешендәге төп урынны нефть промышленносте алып тора, Татарстан бөтен ил күләмендә җитештерелә торган нефтьнең өчтән берен биреп бара. Җыентыкта нефть һәм газ чыгаруның гомуми күләме, шулай ук нефть промышленностеның техник-экономик күрсәткечләре хакында сөйли торган бик күп мәгълүматлар китерелгән. Авыл хуҗалыгы өлкәсендәге уңышларыбыз, республикадагы игенчелек, терлекчелекнең бүгенге хәле белән кызыксынучылар да китаптан канәгать калачак. Анда авыл хуҗалыгының бөтен тармаклары, авылда төзелеш һәм культура үсеше мәсьәләләре һәрьяклап тулы яктыртыла.

Совет власте елларында Татарстан җирендә йөзләрчә яңа корылмалар: машина төзелеше һәм химия, нефть һәм энергетика, азык һәм җиңел промышленность предприятиеләре үсеп чыкты. Капиталь төзелеш мәсьәләләренә багышланган бүлек бу эшкә тотыла торган чыгымнарның елдан-ел арта, үсә баруы турында сөйли.

Җыентыкның зур бер өлеше сәүдә, халык мәгарифе, фән, культура, сәламәтлек саклау, торак төзелеше, халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү мәсьәләләренә багышланган.

Китапта китерелгән саннар узган ярты гасыр вакыт эчендә Социалистик Татарстан хезмәт ияләре башкарган гигант эшләрне бөтен зурлыгы һәм тулылыгы белән гәүдәләндерә.

**Здравствуй, земля родная. Рус телендә. Казан. 1970 ел.**

Республикабызның ярты гасырлык бәйрәменә багышлап чыгарылган җыентыкларның тагын берсе «Здравствуй, земля родная» дип атала. Аңа күләмнәре белән артык зур булмаган 12 мәкалә урнаштырылган. Һәр мәкалә республика тормышының нинди дә булса бер өлкәсенә багышланган. Автор-




лары — гади слесарьдан алып министрга кадәр.

Китап Татарстан АССР Министрлар Советы председателе Гомәр Усмановның «Тиңнәр арасында тиңе» («Равная среди равных») исемле мәкаләсе белән ачыла. Үз мәкаләсендә ул 50 ел вакыт эчендә Татарстан хезмәт ияләре ирешкән казанышлар, алар узган зур юл турында сөйли. «Татнефть» берләшмәсе начальнигы А. Вәлихановның «Туган җир хәзинәсе» исемле мәкаләсе нефть кешеләренә, аларны тынгысыз һәм авыр, данлы һәм мактаулы хезмәтенә багышланган. Татарстан мәгариф министры М. Мәхмүтовның «Октябрь һәм татар мәктәбе», Сәламәтлек саклау министры И. Мөхетдиновның «Безнең бурыч — кешеләрне дәвалау» исемле мәкаләләрен дә укучылар яратып каршы алыр дип ышанырга кирәк. РСФСР Верховный Советы депутаты, Социалистик Хезмәт Герое слесарь М. Карповның «Галиҗәнап эшче сыйныфы», КПССның Минзәлә райкомы секретаре, Социалистик Хезмәт Герое М. Хөсәеновның «Игенче хезмәте мәңгелек» һәм Буа районының Ленин орденлы «Татарстан» колхозы председателе Н. Сабирҗановның «Яңа, ирекле гаиләдә» дигән мәкаләләре безнең тынгысыз, бүгенге эшчеләрнең һәм колхоз кешеләренең борчу-мәшәкатьләр, шатлык-сөенечләр белән тулы чын тормышы күз алдына баса. Запастагы генерал-лейтенант, Советлар Союзы Герое Г. Сафиуллин мәкаләсе татар солдатларының сугыш кырларында күрсәткән батырлыкларын тасвирлауга багышланган, бүгенге яшьләрне ул зур корбаннар бәрабәренә яулап алынган бәхетле тормышның кадерен белергә, ил азатлыгы өчен һәлак булган каһарманнарның якты истәлеген кадерләп сакларга чакыра.

Экономикага һәм культура үсешенең төрле тармакларына караган гомуми мәкаләләрдән тыш, китапта тагын турыдан-туры әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләренә багышланган мәкаләләр дә урнаштырылган. Татарстан язучылар союзы идарәсе председателе Ибраһим Гази мәкаләсендә татар әдәбияты узган юл хакында сөйләнә. Татарстан композиторлар союзы идарәсе председателе Нәҗип Җиһанов укучыларны татар совет музыка сәнгате ирешкән казанышлар белән таныштыра. РСФСРның халык художнигы Харис Якуповның «Кеше хезмәтен җырлыйк» дигән мәкаләсе рәссамнарыбыз иҗатына багышланган.

Китап матур тышлыкта, яхшы кәгазьдә чыгарылган, күп төрле фоторәсемнәр белән бизәлгән. Нәшрият һәм Камил Якуб исемендәге матбугат комбинаты бәйрәмгә матур бүләк әзерләгәннәр. Шушындый затлы китаплар киләчәктә дә күбрәк чыгарылсын иде.

**Р. НАФИГОВ. Первый шаг в революцию. Рус телендә. Казан. 1970 ел.**

Ленин һәм Татарстан, Ленин һәм татар халкы бер-берләреннән аерылгысыз.

В. И. Ленин үзенең сабыйлык һәм балалык елларын Казан тирәсендәге матур табигать кочагында уздыра. Ул — безнең бөек якташыбыз.

В. И. Ленин безнең Казан университетында укый, шунда революция юлындагы беренче адымнарын ясый. Аның яшьлеге, революцион эшчәнлеге, төпле марксист булып житлегүе Татарстан белән бәйләнгән.

Татарстан республикасы Ленинның турыдан-туры катнашы белән, аның житәкчелегендә төзелә. Республиканың экономикасын торгызуда булсын, татар халкының милли культурасын үстерүдә булсын, ул якыннан булышып, ярдәмләшеп тора.

Шуңа күрә татар халкының юлбашчыга булган ихтирам хисе дә аеруча зур һәм үтә самими иде. Татарстандагы әдәбият-сәнгать әсәрләрендә аның образы ин хөрмәтле урынны алып тора. Тарихчы галимнәребез даһи юлбашчының иҗат мирасын, аның эшчәнлегенең Татарстан белән бәйле якларын өйрәнүне үзләренең җаваплы һәм мактаулы бурычлары дип исәпләләр. Әле ел башында гына Мәскәүнең «Наука» нәшрияты тарих фәннәре кандидаты М. Сәйдәшеваның «В. И. Ленин һәм Татарстанда социалистик төзелеш» дигән монографиясен чыгарган иде. Татарстан республикасының 50 еллыгын бәйрәм иткән көннәрдә китап кибетләрендә юлбашчыга багышланган тагын бер капиталь хезмәт



сатыла башлады. Ул — тарих фәннәре докторы, профессор Р. Нәфыйковның «Революциягә беренче адым» исемле китабы.

Яңа документларга һәм моңарчы билгесез булган архив материалларына таянып язылган бу кызыклы хезмәт Владимир Ильич Ленин тормышының һәм эшчәнлегенең Казан чорын өйрәнүгә багышланган. Хезмәттә яшь Ульянов тормышының бу чоры киң иҗтимагый фонда, Казан губернасындагы гомуми революцион хәрәкәт белән тыгыз бәйләнештә карала. Тикшеренүче үзенең тәп игътибарын В. И. Ленинның яшьлек елларында, һәм төпле марксист иткән шартларны, губернадагы алдынгы революцион традицияләрне ачыклауга юнәлткән.

Китап зур-зур өч бүлектән тора. Ул бүлекләрнең һәрберсе үз чиратында тагын да кечерәк бүлекләргә бүленәләр. Һәр бүлекчә В. И. Ленин тормышы һәм эшчәнлеге белән бәйләнгән берәр этапны тикшерүгә багышланган. Ахырдан йомгак ясала һәм библиография китерелә.

**Идел. Яшьләрнең әдәби альманахы. Казан. 1 сан. 1970 ел.**

Татарстан республикасы үзенең ярты гасырлык бәйрәмен уздырган тантаналы көннәрдә тагын бер сөенечебез артты. Күптән көтелгән «Идел» альманахының беренче саны басылып чыкты. Совет хөкүмәтенең, Коммунистлар партиясенең иҗат кешеләре турында даими кайгыртып торуы, аларга һәрвакыт эшлекле һәм җитди ярдәм күрсәтеп килүе турында сөйли торган матур бер факт бу. Яшь иҗат көчләренең, әдипләрнең, композиторларның, артистларның уртак шатлыгына без барыбыз да чын күңелдән рәхәтләнеп кушылабыз. «Идел» альманахының беренче санын, алар белән бергә, «Хәерле сәгатьтә!» дип каршылыйбыз.

**Безнең буын җиргә киләсене**
**Ничә еллар алдан күргәнсең!**
**Безгә, көрәшчеләр токымына,**
**Комсомол дип исем биргәнсең. —**

Бу юллар яшь шагыйрь Г. Рәхимнең «Ильичка» исемле шигыреннән алынды.



Ф. Шәфигуллинның «Уэллска хат», Ә. Рәшитовның «Болгар хәрабәләре янында уйланулар», Р. Мингалимовның «Татарстан» исемле шигырьләрендә һәм З. Шакировның герой шагыйрь Муса Җәлил истәлегенә багышланган «Юллар, юллар» дигән нәсерендә дә асылда шул ук фикерләр уздырыла. Альманах сөекле юлбашчыбыз В. И. Ленинның тууына 100 ел тулуга һәм Татарстан республикасының 50 еллыгына карата язылган шушы әсәрләр белән ачыла.

Альманах битләрен актарганда, без күп кенә яңа исемнәр белән очрашабыз, алар язган шигырьләр, хикәяләр һәм сәхнә әсәрләре белән танышабыз. Шунысы куанычлы, җыентыкта әдәбиятның барлык жанрларында эшләүче яшьләр катнашкан. Шулай да иң күбе, әлбәттә, шагыйрьләр. Хикәячеләр байтак кына. Кызганычка каршы, чын мәгънәсендә әдәби әсәр дәрәҗәсенә күтәрелеп, тәмам «пешеп җиткән» хикәяләр юк диярлек. Арадан М. Маликованың «Янар таулар аша» һәм Х. Хәлиловның «Тарлавык кичүе» исемле хикәяләре генә уңайрак тәэсир калдыра. Тагын Ф. Садриевның Оҗмах ишеге төбендә» дигән әсәре мавыгып укыла. Ләкин бусы инде — сәхнә әсәре, бер пәрдәлек комедия...

Билгеле булганча, республиканың төрле почмакларында яшь язучыларның күп санлы әдәби берләшмәләре һәм иҗат түгәрәкләре яшәп килә. Үзенең беренче санында альманах шундый ике берләшмәнең: Түбән Камадагы «Кама таңнары» исемле берләшмәнең һәм В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты студентлары әдәби берләшмәсенең эше белән таныштыра. Авыррак тел белән язылуларына һәм аерым кытыршы урыннары булуга карамастан, М. Госмановның «Шагыйрь Мифтахетдин фаҗигасе һәм ике Акмулла турында», М. Зариповның «Фәнис елмаюы», Б. Галиевнең «Тавышларның төсе бармы?» исемле мәкаләләре дә нигездә уңай тәэсир калдыра һәм кызыксыну белән укыла. Ахырдан К. Шәйхетдиновның эпиграммалары һәм көлке шигырьләре бирелгән.

«Идел» альманахының беренче санында урын алган төп материаллар әнә шулар. Дөрес, укучыларның һушын алырлык, вакыйга ясарлык шәп әсәрләр юк диярлек. Шул ук вакытта бөтенләй телгә алмастай начарлары да күренми. Альманах безне моңарчы матбугатта исемнәре күренмәгән байтак яңа авторлар белән очраштырды. Димәк, дары базларыбыз буш түгел икән...

Сүз ахырында альманахны дөньяга чыгарышкан кешеләр белән дә танышып узыйк. «Идел» альманахының җаваплы редакторы — шагыйрь Марс Шабаев. Аның редколлегия составында Г. Ахунов, А. Гыйлаҗев, И. Илялова, Т. Миннуллин, Р. Мостафин, Р. Фәйзуллин, Р. Хәкимов, И. Юзеев, М. Яруллин, И. Әхмәдиев кебек урта һәм яшь буын иҗат кешеләре бар. Художнигы — С. Кульбака, техник редакторы — Ә. Трофимова. Соңгы икесенең хезмәтен аерым билгеләп үтәсе килә. Альманахны кулга тотарлык спай, матур итү өчен, алар күп көч куйганнар.

**М. НИГЪМӘТҖАНОВ. Татарстан музыкасы. Казан. 1970 ел**

Революция сәнгатькә яңа сулыш өрде, аны моңарчы күрелмәгән биеклекләргә күтәрде. Моны татар халкының музыка сәнгате мисалында да бик ачык күрергә мөмкин. Кайчандыр бездә профессиональ музыка сәнгате бөтенләй диярлек булмаган. Хәзер исә Татарстанда күп санлы музыка мәктәпләре, музыка училищелары һәм консерватория эшли. Безнең үз филармониябез, опера һәм балет театрыбыз бар. Татар халкы арасыннан дистәләрчә талантлы композиторлар үсеп чыкты. Алар иҗат иткән җырлар һәм романслар, опера һәм балет әсәрләре, музыкаль симфонияләр киң илебезнең бөтен почмакларында яңгырый.

Музыка белгече Мәхмүт Нигъмәтҗановның «Татарстан музыкасы» исемле яңа монографиясе ярты гасыр вакыт эчендә татар совет музыка сәнгате узган данлы юлны тикшерүгә багышланган. Автор музыка сәнгатенең төп үсеш этапларына туктала, һәр чор өчен аеруча характерлы булган үзенчәлекле сыйфатларны һәм тенденцияләрне тикшерә.




М. Нигъмәтҗанов бик дөрес язганча, татар совет музыка тарихы 20 еллардан башлана. Шул давыллы елларда яңа чынбарлыкка, яңа заманга багышланган җырлар һәм маршлар языла, күп санлы музыкаль драмалар, «Сания», «Эшче» кебек беренче опералар иҗат ителә. Күренекле композиторыбыз Салих Сәйдәшев иҗаты да нәкъ шул еллардан активлашып китә, аның спектакльләргә язган музыкаль әсәрләрен, оркестр өчен фрагментларын, увертюраларын һәм бию көйләрен монография авторы киләчәктә туачак опера-балетлар һәм симфонияләр өчен ныклы нигез булды, дип бәяли. Утызынчы елларда профессиональ музыка сәнгатебез тагын да кызурак темплар белән үсә. Җыр жанры нык активлашу белән бергә, утызынчы елларның икенче яртысыннан романслар, инструменталь музыка, хор өчен җырлар, балет, симфония һәм опера музыкасы күпләп иҗат ителә. Халык иҗатының уңай традицияләренә таянып үскән профессиональ музыка сәнгатебез нәкъ шул елларда үз стилен, үз «телен» таба... Татарстандагы барлык иҗат оешмалары Мәскәүдә булачак татар декадасына әзерләнеп яткан көннәрдә Бөек Ватан сугышы башланып китә. Сугыш елларында музыка сәнгатенең бөтен тармаклары һәм жанрлары фронт өчен эшли. Шагыйрьләр белән берләшеп, композиторлар героик көрәш рухы белән сугарылган патриотик җырлар, маршлар язалар, алар, шулай ук, сугыш темасына караган эре күләмле музыкаль әсәрләр иҗат итәләр. Сугыш тәмамлануга Совет хөкүмәтенең карары белән Казанда консерватория ачыла. Бу — музыка сәнгатенең алга таба үсешенә зур этәргеч ясый. Гомумән, сугыштан соңгы еллар яңа күтәренкелек, барлык музыкаль жанрларның бик нык үсүе белән характерлы. Бүгенге татар музыкасы иҗади өлгергәнлек һәм янарыш дәвере кичерә. Ул үзенең тематикасын, жанрларын һәм сәнгатьчә эшләнеш дәрәҗәсен көннән-көн киңәйтә, тирәнәйтә бара.


Музыка сәнгате үсешенең төп этапларын билгеләү һәм гомуми мәсьәләләрне яктырту белән бергә, хезмәттә аерым композиторлар һәм башкаручылар иҗатына да күп урын бирелгән. Монография авторы С. Сәйдәшев, Ф. Яруллин, Н. Җиһанов, М. Мозаффаров, Ж. Фәйзи, З. Хәбибуллин, А. Ключарев кебек күренекле композиторларыбыз иҗатына аеруча киң туктала. Ул аларның иҗатына гомуми бәя бирә, һәр авторның иң күренекле әсәрләренә тәфсыйллы анализ ясый, теге яки бу композитор татар музыка сәнгатенә керткән яналыкны, үзенчәлекне ачыкларга омтылыш ясый. Урта буын вәкилләре, шулай ук 60 елларда гына музыка мәйданына килгән яшь композиторлар иҗаты да тикшеренүче игътибарыннан читтә калмаган.

Бу монография белән һәм руслар, һәм татар укучылары таныша ала. Ул берьюлы ике телдә: татар һәм рус телләрендә басылган. Хезмәт композиторларыбызның һәм җырчыларыбызның портретлары, музыкаль әсәрләрдән алынган фоторәсемнәр белән бизәлгән. Ул полиграфик яктан да әйбәт һәм пөхтә эшләнгән.

**Татарстан. Фотоальбом. Казан. 1969 ел**

Татарстан китап нәшрияты фотоальбомнар чыгару эшен җайга салып килә. Әле кайчан гына Габдулла Тукайга һәм Муса Җәлилгә багышланган альбомнар белән танышкан идек. Шуннан күп тә үтмәде, Татар академия театры һәм башкалабыз Казан турындагылары дөнья күрде. Һәм алдыбызда менә «Татарстан» исемле тагын бер яңа альбом.

Бусы, исеменнән үк күренгәнчә, укучыларны республика тормышы белән таныштыру максатын күздә тотып чыгарылган. Максатның зурлыгы анда урнаштырылган фотолар санын һәм ул фотоларның тематик колачын, характерын да билгеләгән. Альбомда барлыгы 250 ләп фоторәсем урын алган. Алар республикабыз тормышының бөтен якларын иңлиләр.




Альбом Татарстанның табигате, хайваннар дөньясы һәм табигый байлыклары турында сөйли торган фотолар белән ачыла. Туган җиребезнең мул сулы елгаларын, тын күлләрен, калын урманнарын тагын бер кат күргәндәй буласың. Ул да түгел, фотолар безне бүгенге колхоз авылына алып китә, колхоз авылының алдынгы кешеләре, аларның фидакарь хезмәте, дингездәй шаулап утырган иген кырлары, меңәрләгән башлы терлек көтүләре белән таныштыра.

Билгеле булганча, Казан — тарихи истәлекләргә бай шәһәр. Бөек юлбашчыбыз Владимир Ильич Ленин революцион эшчәнлеген безнең шәһәрдә башлап җибәрә. Юлбашчыбызның изге хатирәләрен борынгы кала кадерләп саклый. Альбомда В. И. Ленин исеме белән бәйле истәлекләргә зур урын бирелгән. Укучылар, башкалабыз Казаннан тыш, Түбән Кама, Әлмәт, Бөгелмә, Лениногорск, Чистай, Зеленодольск кебек промышленность шәһәрләре тормышы турында да күп нәрсә белә алалар. Альбомдагы фоторәсемнәр шулай ук республикабыздагы төп промышленность тармаклары белән таныштырыла, безгә Татарстандагы фән һәм культура казанышлары, әдәбият һәм сәнгать үсеше турында сөйли.

«Татарстан» альбомын журналист Б. Марихин төзегән. Аңа М. Блатт, А. Шакирҗанов, А. Бураков, Ю. Ананьев, А. Геринас, И. Әхмәдиев, Б. Мясников, Н. Степанцев, Э. Хәкимов, Г. Столяров, С. Хәмәдиев, И. Кокшарев, Ш. Җамалиев, Җ. Акчурин, С. Токарев, Ю. Столяров, М. Кашапов, М. Шакирҗанов, Б. Денисов кебек танылган фотографларның һәм фотожурналистларның рәсемнәре урнаштырылган.

## *Хөрмәтле укучыларыбыз!*

— Журналыгызда 1971 елда нинди повестьлар һәм романнар басылачак?

— Киләсе елда «КАЗАН УТЛАРЫ»ында шагыйрьләребезнең нинди яңа поэмаларын һәм шигырьләрен бастырырга җыенасыз?

Соңгы айларда редакциягә килгән хат авторларының күбесен менә шушы сораулар кызыксындыра. Бу хәл бик табигый, чөнки **шушы елның сентябрь аеннан 1971 ел өчен газета-журналларга язылу башланды.**

Иң элек шуны искәртеп үтәргә кирәк: «КАЗАН УТЛАРЫ» журналында, узган еллардагы кебек үк, алдагы елда да татар язучыларының иң яхшы романнары, повестьлары, поэмалары, шигырьләре, хикәяләре, драма әсәрләре, очерклары һәм публицистик мәкаләләре урнаштырылып барылачак. Укучыларыбыз таләпләрен искә алып, замандашларыбызның бүгенге тормышын, эшләрен һәм уй-фикерләрен чагылдырган әсәрләргә аеруча зур урын биреләчәк. Әдәби тәнкыйтькә, яңа чыккан китапларга рецензияләргә һәм әдәбият тарихына, культура тормышына, театрга, музыкабызга бәйләнешле материалларга шулай ук киң мәйдан булачак. Язучыларыбызның иҗат портретларын һәм танылган артистларыбыз, композиторларыбыз, художникларыбыз иҗатын яктырткан мәкаләләрне тагын да ешрак бастырып барачакбыз.

Прозаикларыбыздан **Сөббух Рафиков** үзенең **«Тын елга буенда»** исемле яңа романын, **Аяз Гыйлаҗев, Фатих Хөсни, Әмирхан Еники, Әхсән Баянов** яңа повестьларын редакциягә тапшырдылар инде. Танылган язучыларыбыздан **Афзал Шамов, Мирсәй Әмир, Габдрахман Әпсәләмов, Гомәр Бәширов, Гариф Гобәй, Ибраһим Салахов** иптәшләр дә яңа повестьлар, хикәяләр өстендә эшлиләр һәм шушы ел ахырында әсәрләрен редакциягә китерергә вәгъдә итәләр.

Киләсе елда сез журнал битләрендә шагыйрьләребезнең дә күп кенә яңа шигырьләрен һәм поэмаларын укый алачаксыз. **Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Әхмәт Исхак, Нури Арсланов, Шәйхи Маннур, Мөхәммәт Садри, Зәки Нури, Илдар Юзеев, Хисам Камалов, Әдип Маликов, Шәүкәт Галиев, Рәшит Гәрәй, Равил Фәйзуллин, Гәрәй Рәхим, Зөлфәт, Рөстәм Мингалимов, Рәдиф Гатауллин, Фәнис Яруллиннар** журналның алдагы елдагы саннарында бастыру өчен яңа әсәрләрен шулай ук редакциягә тапшырдылар. Кыскасы, «Казан утлары» киләсе елда яңа әсәрләргә тагын да баерак булып чыгачак.

Редакциягә килгән укучы хатларыннан күренгәнчә, кайбер иптәшләр безнең журналга вакытында язылырга онытып җибәрәләр дә аны ел башыннан ала алмыйлар. Нәтиҗәдә беренче саннан басыла башлаган роман һәм повестьларны тулысынча укудан мәхрүм калалар, ярдәм сорап редакциягә мөрәҗәгать итәләр. Ә бу очракта без аларга ярдәм итә алмыйбыз, чөнки **подписка кабул итү белән редакция түгел,** бәлки **«Союзпечать» һәм элемтә бүлекләре шөгыльләнә.**

Менә шундый уңайсыз хәлдә калмас өчен, без сездән, кадерле укучылар, «Казан утлары»на газета-журналларга подписка кабул итү башланган көннәрдән үк язылып куюыгызны үтенәбез.

«КАЗАН УТЛАРЫ»на Советлар Союзының теләсә кайсы элемтә бүлегендә һич тоткарлыксыз язылырга мөмкин, ул Бөтенсоюз газета-журналлар каталогына 73210 индексы белән теркәлгән.

**ЯЗЫЛУ БӘЯСЕ: Бер елга — 6 сум. Бер саны — 50 тиен.**

## *Газета укучыларыбыз игътибарына!*

Укучыларыбыз алдыра һәм яратып укый торган газеталарның берсе — «Социалистик Татарстан»га 1971 елга подписка дәвам итә.

Газетада төп урынны Совет Татарстанының күпьяклы хуҗалык һәм культура тормышы, республикада коммунистик төзелеш, КПССның XXIV съездына бөтенхалык хәзерлегенә бәйле мәсьәләләр алып тора. Шулай ук илебездәге һәм дөнья күләмендәге вакыйгалар, Татарстандагы көндәлек яңалыклар, кызыклы вакыйгалар, фән һәм техника казанышлары, алдынгы тәҗрибә, бишьеллык геройлары турында материаллар газета битләрендә даими урнаштырылачак. Укучы шулай ук әдәбият-сәнгать эшлекләләренең яңа әсәрләре, аларның иҗади портретлары белән киң танышачак. Газетада совет кешесенең иҗади һәм рухи үсешен сурәтләгән очерклар һәм хикәяләр басыла, тәнкыйть хәбәрләре, фельетоннар, мораль темаларны яктырткан гыйбрәтле мәкаләләр урнаштырыла, юридик, педагогик темаларга, медицина мәсьәләләренә карата консультацияләр, белгеч киңәшләре бирелә.

«Социалистик Татарстан» газетасына барлык почта бүлекчәләрендә һәм «Союзпечать» органнарында чикләнмәгән санда язылырга мөмкин.

Газетага язылу бәясе: бер елга —6 сум, ярты елга —3 сум.

Татарстанга күрше һәм тугандаш өлкәләрдәге иптәшләргә, үзләре яшәгән урыннарда подписка кабул ителмәсә, акчаны түбәндәге адрес белән җибәрергә мөмкин:

*Казань, ул. Куйбышева, 17/25, Областной отдел «Союзпечати», для газеты «Социалистик Татарстан».*

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ